# казан утлары

9

СЕНТЯБРЬ-1971

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

9

СЕНТЯБРЬ
1971

## Бу санда:

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Ә. БАЯНОВ. Ут һәм Су. Роман . . . . . . . 3
Н. АРСЛАНОВ. Партияле кеше диләр мине. Карпат итәгендә. Гади бер фәлсәфә. Байрон рухы. Язгы тамчылар. Кобзарь янында. Табигать белән тартышканда. Мин бик риза. Илһамга. Мэрцишор. Минем балдыз. Хафиз газәлләре. Гомәр Хәйям робагыйлары. Шигырьләр, тәрҗемәләр . . . . . . . . . . . . . . 41
Б. КАМАЛОВ. Ялыкмаслар. Повесть . . . . . . . 50
Г. ЛАТЫЙП. Мәскәү яны. Иртәдән үк... Аның гомере... Яратылган иде җиргә... Картаясың,— диләр... Гөлгенә. Җырчы чыршы. Туры килдек... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 96
Ә. РӘШИТОВ. Дусларга. Яшьлек белән саубуллашканда . . . . . . . . . . . . . . 100
Ф. ГАЛИЕВА. Җиргә ак юрган түшәп... Юртак атың булса... Күзләреңнән алып... Шигырьләр . . . 102
Т. МИҢНУЛЛИН. Кульяулык. Хикәя . . . . . . . 103
Г. МӨХӘММӘТШИН. Табылдык хатлар. Хикәя . . 106
М. ЛЬВОВ. Безнең Атлантида. Госпитальдә. Минем татар телем. Өстәлемдә — Җәлил... Билгесез солдат. Казан вокзалында... Хәким дустым... Ир кешеләр. Шигырьләр . . . . . . . . 109
М. ХӨСӘЕН. Мәхәббәттә янса йөрәкләр... Сонетлар . . . . . . . . . . . . . . . 114

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Г. ПАУШКИН. Чаллы җирендә. Очерк . . . . . 120
Р. ХИСМӘТУЛЛИН. Тирәннән чыккан шытымнар. Очерк . . . . . . . . . . . . . . 130

СӘНГАТЬ

Л. ЕЛЬКОВИЧ. График публицистиканың сугышчан жанры . . . . . . . . . . . . . . 136

АЛАР БЕЗДӘ БУЛГАННАР

В. КЛИМЕНТОВСКИЙ. Даими һәм эшлекле элемтә. 141

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Г. ХАЛИТ. Тизләтелгән әдәби үсеш һәм иҗат методлары . . . . . . . . . . . . . . 144

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Читлектәге кош бәхетләме!.. . 167
Ф. МИННУЛЛИН. Кичке уйлар . . . . . . . . 170
И. АБДУЛЛИН. Кеше һәм яз . . . . . . . . 171

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . 173

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Ф. КАМАЛОВА. Салих Сәйдәшев һәм театр . . . 176
Безнең сафка . . . . . . . . . . . : 179

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

З. ТУФАЙЛОВА. Яфрак ява. Трай. Яңа мәктәп. Кыш килде. Шигырьләр . . . . . . 182
З. ГОМӘРОВА. Кайсы берлек. Илгизнең диңгезе. Җәй. Яратам сары балны. Шигырьләр . . . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Җан Али. Хикәя . . . . . 185
В. МОНАСЫЙПОВ. Казан кешесе. Юмореска . . 188
А. БУЛАНОВ. Багана. Күнекте. Зарлана. Мактанды. Яраталар. Качты. Ал да гел. «Соавтор» Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 189
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 190


Редакциягә килгән
кульъязмалар
кире кайтарылмый


Редакция адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*



Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.



Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сулейманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 1/VI-1971 ел. Басарга кул куелды 19/VII-1971 ел. ПФ 09062. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 79346 экз. Заказ И-403. Бәясе 50 тиен.
ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бәуман урамы, йорт 19. 1971 ел.

Әхсән Баянов

# УТ ҺӘМ СУ

РОМАН

Әнисенең исеме — Идел.

Үзенеке — Кама.

Әнкәсе — Идел күкрәгенә башын куеп, рәхәтләнеп йоклый Кама.

Матурлыкны күрә белгән күзләр буыннан-буынга — гасырлар буена — көн саен, сәгать саен, минут саен соклана алсын өчен Табигать дөньяга мәңгелек гүзәллек — хатын-кыз сынын бүләк иткән. Бу могҗизалы бүләк Камага уннарча, йөзләрчә, меңнәрчә кабат бирелгәндер, мөгаен. Югыйсә, барлык чибәрләр мөлаемлыгын бергә җыйган якты чырай каян килсен? Җәйге кояшлы көннәрдә аның йөзендә күкнең бөтен киңлеге, саф зәңгәрлеге, ап-ак болыт кәрваннары сыеп тирбәлә, ә төннәрен — йолдызлар сибелә, ай чайкала. Бу яктылык, бу зәңгәрлек, бу аклык һәм пакьлек — бер-берсенә һич тә сыеша алмаслык бүтән төсләр — ничек бергә, бер сулыш белән сулый һәм яши алсын, югыйсә?!

Яр читенә, болын буена кил дә тыңла: ерак гасырлардан ишетелгән барлык чулпылар чыңы түгелме бу?

— Чың... чың... чылтыр... чылтыр...

Үләннәрнең әллә яңа буынга сикергәндә чыңлап китүеме? Кошлар, чикерткәләр сайравы, дулкыннарның ярларга, ташларга бәрелүеннән яралган көйләрме? Әллә гүзәллекнең, мәхәббәтнең нәкъ шулай аһәң булып ишетелүеме? Нәрсә бу?

Бөтенесен бергә җыеп әйткәндә, Кама бу.

Изге һәм тирән, уйчан һәм... вакыты белән, тыелгысыз дәрткә бирелүчән ул Кама.

Язгы ташулар, җәйге күкрәүләр, кышкы ачы бураннар вакытында килегез сез бу чибәр янына. Сәбәбен сизә, аңлый алмассыз да, бәлки, әмма ярсыну, ашкынулары, әрнү, сөенүләре ишетелми калмас. Могҗиза гади күзләргә күренми — моның өчен сихерче яки художник булу фарыздыр. Ә бәлки, аны бүтән берниндн гүзәлне дә ярата алмаслык көчле мәхәббәт белән яратырга кирәктер...

Ә хәзер, тып-тынып хәлдә, әнкәсенең күкрәгенә башын куеп, рәхәтләнеп йоклый Кама.

Тирән-тирән сулап чайкала, кузгалып куя. Үзенең тынычсыз һәм изге ялангачлыгын калын урманнар белән, камышлыкларның карасу-яшел чәчләре белән каплап куя, ят күзләрдән саклый, яшерә...

Аны бу тәмле йокысыннан беркем дә беркайчан да аермаган — вакыты житмичә, ул уянмаган. Дөнья яратылганнан бирле аның изге тынычлыгын бүлдерергә җөрьәт итүче дә булмаган. Андые табылса да — кодрәтеннән килүчесе булмаган. Әмма егерменче гасыр урталарында, төгәлрәк әйтсәк, мең дә тугыз йөз алтмыш алтынчы елда, аның янына бер Егет килә дә болай дип сүз куша:

— Әй, чибәр Кыз, вакыт житте, уян!

Кама бу сүзләрне төштә генә ишетәм дип уйлаган шикелле, сизелер-сизелмәс кузгалып, болыттай, урмандай кабарып торган чәчләре белән үзен тагын да яхшырак капларга тырышып, чайкалып куя да янадан тына.

— Чибәр кыз, Кама, вакыт җитте, уян!

«Бу ниткән тәкәллефсезлек, каян килгән кыюлык һәм, әйтергә яраса, акылсызлык?..»

Ихтимал, шушы сорау, шундый гаҗәпләнү, беләсе килү уяткандыр Каманы. Әллә шушында әкият башланамы?

Ни булса шул — теп-тере кызга әверелеп, «Кайда, кем икән бу?» дигәндәйрәк итеп карады да уянды Кама атлы кыз бала:

— Кем син, ни кирәк сиңа?

— Мин — синең мәхәббәтең... Бүләк китердем.

Кама аптыраудан сикереп үк куйды:

— Нинди?

Егет, тагын да кыюрак кыланып, Каманың каршысына ук килеп басты:

— Утлар тезмәсеннән муенса...

Кама каядыр йөгереп китәргә чамалап хәрәкәт тә ясаган иде бугай, шулай да, белергә тырышу, кызыксыну, гаҗәпсенү хисләре җиңде, ахрысы, тагын тын калды һәм бер дә яшермичә әйтте:

— Уттан ясалган муенса? Нигә ул?

— Сине тагын да матуррак итү өчен...

Егет нидер әйтмәкче, аңлатмакчы иде, ләкин Кыз аны тыңлау үзе үк әдәпсезлек дигән төслерәк кыяфәт белән алиһәләргә хас көязлек һәм бөеклек саклаган хәлдә, комда кызынып яткан йөзләрчә кыз һәм егетләр яныннан уза-уза, яр читенә яп-якты пыяладан гына диярлек ясалган кибеткә таба атлады.

Егет аның буй-сынына карап, соклануыннан телсез калып, хәрәкәтсез торганын аңлагач, Кыз киткән якка ашыкты. Ләкин яр читенә житкәндә күздән ычкындырды — Кыз кибеткә кереп китте.

Кибеткә керсә, анда йөзләгән хатын-кыз чиратка баскан — житмәсә, барысы да су коену костюмнарыннан гына... Кызлар, үз туалетларына кирәкле әйберләр, киемнәр алырга торалар бугай. Егетне күрүгә, барысы да елмаешып куйдылар һәм аптырап, телсез калган егеттән, каз көтүе кебек каңгылдаша-каңгылдаша, көлә-шаярта башладылар:

— Сиңа ни кирәк, егет? Комбинацияме?

— Әллә бюстгалтермы?

— Әллә...

Озак түзә алмады егет — ишектән тышка атылды. Мыскыл итүчеләрнең берсе — Кама иде бугай, тавышын шуныкына охшатты егет. Ишек төбендә кызның чыкканын көтәргә булды һәм көтте. «Ялангач иде бугай Кама, мөгаен, монда кием алырга кергәндер,— дип уйлады ул.— Кибеттә куна алмас, барыбер чыгар... Ах, менә ул бугай».

— Кама!

Кыз «егет акылдан язган!» дигән кыяфәт белән карап куйды һәм, волейбол уйнаган иптәшләре арасына йөгереп, уйнарга да керешге. Ул арада егет тагын бер кызны туктатты:

— Гафу итегез, сез Кама бит?

— Юк, Кама түгел, Вятка! — диде кыз һәм хихилап анысы да каядыр китеп югалды.

Шул рәвешле ул тагын, тагын ниндидер кызларны көлдерде һәм барысы да, кулдан ычкынган кош шикелле, пырхылдап оча тордылар.

Ниһаять, кояш баер чиккә житкәндә, кибетне шылтырдатып бикләделәр. Димәк, кызны ычкындырды егет, аны танымады. Пляждагы барлык кызларга яңадан карап чыкса, яңадан озак-озак көтсә дә, инде комлыкта бер җан иясе дә калмагач, башын түбән иеп, ямансулап, өенә таба атлады.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Дөресен әйткәндә, егет пролог төслерәк бу вакыйганы уйлап кына чыгарды диярлек. Әмма шунысы хак — ул Камага шулай эндәште, табигатьнең барлык матурлыгын үзенә җыйган чибәр кызны да күрде. Һәм, ничектер, ике гүзәллек шул рәвешле бергә кушылып, болай да гашыйк булырга гына торган йөрәкне тылсымлы шатлык белән тутырды. Кызык: хыял искиткеч якын — кул белән сыйпап сөяргә мөмкин кебек аны, ләкин кагылыйм дисәң, юкка чыга да куя.

Бераүләр әйтә: дөньяда юк ул могҗиза, ди, икенчеләре — бар, ди. Юк диясегез килсә, кырысрак кешеләрдән сорагыз, бар дисәгез — гашыйклардан. Әкиятне гүзәллек һәм мәхәббәт бар иткән.

Кама елгасы шушы хәтле матур булмаса, егет бер күрүдән яраткан кыз әкиятләрдә генә язылганча чибәр булмаса, өстәвенә, исеме дә Кама булмаса, бу әкият тә тумаган булыр иде. Хәер, егетебез, бераз гына үз файдасына ялгышып, Камилә дигән исемне үзенә кирәкчәрәк үзгәртте үзгәртүен... Ләкин моннан кемгә ни зыян?

Шулай, әкият бар һәм егет, аның белән очрашачагына, кавышачагына иртәгә кояш чыгарына ышанган кебек ышанып, көннәр буе, айлар буе аны эзләде.

Эзләде, тапты, югалтты,
Инде табылачак түгел.

Әмма җырдагычарак килеп чыкты шул. Вакыйгаларны узып — ах, бу ашыгычлык! — карасак, кыз белән егет бөек яшьлек уртасында бер кич, бер төн һәм бер көн бергә булдылар. Ләкин...

Моннан соң ничек ышанмыйсың инде могҗизага?! Ничек ышанмыйсың әкияткә? — Яшьлек кочагында көн буе уйнап-шаярып йөргән кыз бала кинәт һуштан язды да куйды. Дөнья яратылганнан бирле кешеләр йөрәгенә мәхәббәт дигән ук атып җәрәхәтли торган Амур эше булдымы бу, әллә бүтәнме, әйтү, аңлап бетерү кыен әле. Егетнең бергә килгән дусты Борис кыз тәнендәге җәрәхәтне алданрак күреп, аңа ярдәм итмәкче иде — үзе дә аңын югалтты. Хәзер көймәгә утырып, кайтыр юлга чыгасы гына калды...

Кечкә елга тып-тыныч ялтырап ята. Җылы июль үзенең рәхәт җиле белән аркалардан, чәчләрдән сыйпый — дөнья рәхәтен кичереп йөр генә дә бит. Юк, булмады — гомерендә беренче тапкыр фарт килмәде егеткә. Һәрхалдә, мондый да көтелмәгән уңышсызлыкка очраганы ул хәтерләми — гомумән үзен бәхетле йолдыз астында туган балалардан исәпли иде. Югыйсә, Кама белән — үзе уйлап чыгарган фантастик кыз белән кемнең очрашканы, табышканы бар? Ә менә ул тапты. Кул белән кагылгач кына... нәкъ әкияттәге кебек... һушын югалтты кыз...

Көймәдә алар дүртәү.

Егет үзе койрыкта, алда — Борисның таныш кызы Гета. Борис Кама белән бергә көймәдә ята. Ни булганын берсе дә белми — бары тик чамалый гына, тизрәк калага барып җитәргә, врачлар кулына тапшырырга — бердәнбер хис, теләк һәм бурыч — шул.

Күңел дигәнең, инде мең кабат кайтып, мең дә бер тапкыр урап килде, ә мотор, сигез ат көчле «Ветерок», уйга иярә алмый шул.

Көймә башында утырган Гета әледән-әле Каманың пульсын санап карый, аннары Борисныкын. Егет «Ничек?» дигән кебек сораулы караш белән кызга текәлә, ә җавапны Гета баш кагып кына кайтара — пульсы бар, ди.

Көймәдә алар дүртәү.

Көймәдә егетнең хыялы ята — исән калырмы, юкмы, әйтүе кыен. «Кама ята — чит егет янында. Ичмасам, шул егет урынында ник мин түгел?!»

Гета, аның уен сизгәндәй, сагышлы гына елмаеп сорый:

— Нәрсә, Фәез, көнлисеңме әллә?

— Әйе.

Ирексездән икесе дә елмаялар.

Кояш инде баеп та өлгерде, ә кайтып җитәргә ким дигәндә (шушы тизлек белән) өч сәгать вакыт кирәк әле. Ерак кителгән шул. Кем белгән аны, мондый хәл килеп чыгарын...

Сизелмичә генә караңгылык инде һәм көймә төнге табигать эчендә кечкенә бер йомычка кебек чайкала башлады. Су да, яр буйлары да, күкләр дә бер төскә, күксел төскә кереп, бергә кушылды һәм, бу киңлекнең күпме, нинди иканлеген күрсәтеп, еракта-еракта йолдызлар җем-җем итә башлады.

Чиксезлек һәм кечкенәлек.

Галәм һәм көймә...

Көймә югалмаска тиеш...

Мондый хәлдә нәрсә эшләргә инде?

Уйланырга, уйланырга, уйланырга.

Мөгаен, Гета да таралган чәчләрен сыпыргалау-рәтләүдән калган барлык вакытын шул «шөгыльгә» багышлаган, мөгаен, ул да үзенең бик үк рәтле килеп чыкмаган язмышы белән бәхәсләшәдер. Ә Фәез үзенеке белән...

Фәезнең уйлары бер тирәгә әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта — сигез ат көчле шушы «Ветерок»сыман.

* * *

Әкиятләр, гадәттә, матур чишелеш белән төгәлләнә. Гыйбрәтле беткәннәре дә бар. Бу юлы әнә шул сирәк очрый торганы, гыйбрәтлесе килеп чыкты.

Әле кайчан гына Фәез үзенең дусы Борисның көнләшүен гаеп итә, аламалык дип тирги иде. Ә хәзер, бер сәбәпсез диярлек, үзе көнләшә... Борисның, югыйсә, көнләшер сәбәпләре күбрәк иде бит...

Дөрес, сәбәп дигәне Фәез аркасында килеп чыккан нәрсә түгел, аларны тудыручы — бүтәннәр. Борис белән Фәезне чагыштырма берәмлекләр хәлендә ике олы агай, ике җитди кеше куйды. Ник? Фәез менә шуны аңларга тырыша...

Кама елгасының сул ягында, иске шәһәрнең дәвамы буларак, шәһәрнең, мөгаен, иң биек төшендә, бишәр катлы өр-яңа йортлар тезелгән. Үзәнлеккә табарак, ераклардан узып баручы кораб төслерәк, бер йорт аерылып тора... Ныклабрак карасаң, ул каядыр бара, шәһәрне каядыр өстерәп барадыр төсле.

Теплоходка куелган траплар — баскычлар... Шуларга мең өметләр белән баса-баса, кемнәрдер керә, ә кемнәрдер якындагы пристаньда төшеп кала...

Бу йорт — Баш идарә, барлык бүтән идарә һәм трестларны берләштерә торган акыл һәм кодрәт тупланышы. Барлык төзелешләрдәгечә, монда да төп җитәкчеләр — управляющий белән баш инженер. Руль, кем әйткәндәй, алар кулында. Алар бердәм булса, кораб дигәнебез дөрес юнәлештә һәм шәп бара, ә икесе ике якка боргалый башласа, чайкала, калтырый.

Гадәттә, управляющий белән баш инженер ишекләре капма-каршы тора, кабул итү бүлмәләре уртак була. Ә бу юлы алар бинаның ни өчендер икесе ике ягына урнаштылар.

Баш идарәнең баш инженеры Казимир Романович Лебедев — аз сүзле, тыныч холыклы кеше. Йомыш белән керсәң, тыңлап бетергәч тә я тегe, я бу якка бәхәссез-нисез генә хәл итеп куя. Уңайлы кеше. Шулай да Фәез, сәбәбен үзе дә аңлап җитмәгән хәлдә, төзү-монтаж идарәсенең баш инженеры буларак, йомышларын Лебедев белән түгел, управляющийның үзе, Анатолий Самойлович Лазарев белән хәл итәргә ярата. Ярата һәм якын күрә. Икенче катта сөйләшкәне беренче бүлмәдә яңгырап торган акырбайны ярата. Ә Борис өчен Лебедев мәхәббәтле.

Фәез эшли торган дүртенче идарә — үзәнлектә. Җәяүләпме, машина беләнме, көн саен ул шунда, мең машина актарып ташлаган балчык һәм туфрак дөньясына юл тота. Иләмсез зур чокырлар һәм таулар арасыннан юл табыла тагы.

Чама белән бер квадрат километр зурлыктагы чокыр өстендә тукталсаң, аста гаҗәеп бер күренешкә тап буласың — беренче карашка тәмуг анда. Мең яктан мең төрле ут агыла. Ут, ут, ут — чиге-чамасы юк. Мондый күренеш телескоп аша караган астрономга гына очраса очрыйдыр. Галәм чиксезлегенә караган галим генә шундый утларга бернинди куркусыз карый ала торгандыр. Ут диңгезе шулай шаулыймы, әллә моторларның туктаусыз гүләвеме бу? Хәер, Фәез аны ишетми, күрми дә диярлек, аның өчен бу — гап-гади төзелеш мәйданы, шлюз, ә чак кына уңдарак — гидростанция бинасы. Төзелешнең бүгенгесе көндә иң нык бәйләнгән төене. Болай да түбән җир тигезлегеннән уналты метр аста... төзелеш үкереп ята.

Уйласаң, гаҗәбрәк, Каманың төбе — синең өстә, күп өстә. Күз иләшә төшкәч, әйберләр үзләренә хас рәвешләр алып, бөтен нәрсә уч төбендәге шикелле аермачык күренә: кешеләр дә, аларның эшләре, хәрәкәтләре дә. Мәйдан — цирк аренасы шикелле, стадион шикелле, борынгы грекларның ачык театрлары шикелле. Турысын әйтсәк, бу — тышкы охшашлык. Монда тамаша юк, монда бер генә очкын да кешенең күңелен күтәрү өчен, кызык өчен ялтырамый, монда илаһи трагиклар да, берсен-берсе бары тик һәлак итәргә хокуклы гладиаторлар да, үгезне кызыл төс белән үртәп кадап үтерергә тиешле тореадорлар да, биюче атлар һәм арысланнар да юк. Монда — мөмкин булган барлык маҗаралар мәгънәсен туплаган тормыш.

Илнең барлык почмакларын диярлек күргән, Мәскәү институтыннан соң Якутия бозлыкларын, тайга чиксезлеген тойган Фәез хәзер менә туган җирендәге шушы тормышка моңарчы күрмәгән ят дөньяга карагандай карап тора һәм киләчәген күз алдына китерә: хәзергә корыч каркаслардан, челтәрләрдән торган бу рәвешләр, ут, тимер, бетон кушылмасы буларак, шлюзга әйләнәчәк. Күпмедер вакыттан соң шушы җирдән, могҗизалы мәрҗән-лампалар иленнән, чиксезлеккә таба пароходлар узып йөриячәк.

Фәез чокыр башыннан чак кына сулгарак күз төшергән иде, җиңел машиналар күзгә чалынды. Кемнәрнеке икәне әллә каян билгеле. Фәез тиз-тиз атлап килеп җитүгә, компрессорлар тавышын җиңеп дөбердәгән тавыш аның өстенә ябырылды:

— Кайда болай адаштың, иптәш Нәсибуллин?

Акырса да, каушатмый бу кеше — коңгырт чиста йөзендә, зур гына чем-кара күзләрендә ниндидер үз итү, яктылык уйный кебек. Аның янында — Лебедев, озын һәм төз гәүдәле, көл төсле плащ һәм эшләпә кигән. Җитдилеген күзгә бәрелерлек итә торган деталь — карчыга борын. Бөтен гәүдә һәм чырайда классик интеллигентлык һәм иң югары баскыч дипломат пөхтәлеге. Ул сүзгә катнашмый диярлек, ләкин ниндидер мәгънә ишетергә тырышкандай сак тора. Фәез аңа никтер курыкбрак карый. «Капма-каршы ике кыяфәт һәм әле кыяфәттә генә микән аерма?!»

Фәез Лазарев янына килеп елмайды:

— Мин сезгә кергән идем.

Управляющийны бүтәннәр дә, курыкмыйча, ләкин күзгә күренеп торган ихтирам белән тыңлыйлар. Бәхәс Зәй ГРЭСындагы ходка җибәреләсе объект хакында бара икән: идарә начальнигы Харламов үзе шушында торса да, авыру булганлыктан һәм җаваплылыкны баш инженерга тапшырганлыктан, эшне хәл итәр өчен Фәезне көткәннәр. Бу идарәдән утызлап кеше алмакчылар.

Озын сары егет Харламов Фәезгә күз кыса:

— Мин власть түгел, үзең кара, янәсе.

Күк күкрәгән тавыш үз дәлилләрен китерә:

— Берничә көннән ут бирәчәк объектны тоткарлауның күпме зыян китерәчәген исәпләп күрсәтергәме сезгә? Үзегез хисап белмисезме?

Фәезнең үз кайгысы:

— Сез бит мондагы планны киметмәячәксез, ә үти алмый калсак?..

— Үтәми карагыз! — ди Лазарев, Фәез әйтеп бетергәнне дә көтмичә.

— Шул хәтле эшче киткәч, без ничек үтик ди аны?

— Белмим.

— Димәк, бирмим.

— Димәк, бирәсең.

Бәхәс шаярган төслерәк — һәр як елмая: Лазарев иреннәрендә — хәйләлерәк елмаю. Тыныч, ләкин аптыраулырак елмаю — Фәез йөзендә.

Управляющий машинага таба атлагач, бүтәннәр аңа иярде. Килеп җитәрәк, Харламов кесәсеннән өр-яңа сигарет пачкасы чыгарып, аны ачарга азаплана иде, көтмәгәндә Лазарев шул пачканы эләктерде:

— Сиңа тартырга ярамый, синдә язва.

— Больницада тартмам әле.

— Ә соңыннан?

— Соңыннан да.

— Алайса, мә.— Управляющий пачканы кире сузды.— Сүзеңдә торалмасаң, төзелешкә кайтма.

— Изеп бетергән,— ди тегесе үпкәләгәнрәк кыяфәт белән.

Управляющий исә аның үзен Лебедевка әләкли:

— Юньсез егет бу Харламов. Ике көн элек, ашказанынннан кан китеп, «ашыгыч ярдәм» белән алып киткәннәр иде. Тагын шушында килгән. Тозлы су сипкәннәрмени! Җилбәзәк егет. Үзе идарә начальнигы тагы, яшьләр идарәсе начальнигы! Нинди үрнәк инде бу, ә?..

— Егетләр шәп,— ди үзенә хас сабырлык белән сузып Лебедев.

— Бөтенесе дә түгел. Җай чыкса качарга гына торучылар да бар. Карагыз сез менә бу егеткә.— Управляющий киңчә йөзле, базык гәүдәле берәүнең аркасына кулын куйды: — Эх, Борис, Борис...

Борис Филинов ни әйтергә белми кызарып торганда, чокыр башыннан дөбердәп машиналар килеп төште. Филинов Харламов артыннан бетон саласы блокка ашыкты. Фәез дә китмәкче иде, аны Лебедев туктатты: йомышы бар икән.

Машина ишегең ача-ача, управляющий сүзен төгәлләде:

— Менә шулай, утыз кеше.

Беркем бернәрсә вәгъдә итмәсә дә, эшнең нәкъ үзе әйткәнчә булачагына Лазаревның шик-шөбһәсе юк иде шикелле.

Казимир Романович белән Фәез идарә будкасына таба атладылар. Будка дигәч тә, алай ук кечкенә түгел — озынлыгы ким дигәндә йөз метрлы такта йорт ул.

Ишектән узгач та Фәез Лебедевка үз урынын тәкъдим итсә дә, тегесе никтер әкренрәк кузгалып, утырмыйрак торганга, Фәез каушабрак куйды. Аның кулларын кая куярга белмичә, әле алгарак сузып, әле аксыл плащының кесәләренә тыгып интегүен күреп бугай, Лебедев көлемсерәде. «Оялчан егет». Ләкин бу егетнең кирәк чакта шактый кырыс була белүен шулай ук чамалый иде ул.

— Мин сездәге рационализация тәкъдимнәре белән кызыксынмакчы идем,— диде Казимир Романович, ниһаять, өстәлнең бирге ягына утырып.— Ел буе ниләр керде икән?

Фәез кушуы буенча, секретарь кыз производство бүлегеннән зур гына папка күтәреп чыкты. Ун-унбиш минут чамасы тикшереп утыргач, Лебедев папканы Фәез алдына куйды:

— Аз түгел, ләкин яңа сүз юк. Филинов тәкъдимнәреннән башка.

— Филинов бүтәнчәрәк шул.

— Талантлы артистлар, спортсменнар хакында шаулыйбыз, ә талантлы инженерларны санга да сукмыйбыз. Я, гаделлекме бу?

— Филинов болай да аерым урында. Арттырып та җибәрә, минемчә.

— Шуңа күрә дә талант бит инде ул. Андыйлар сирәк, ә безнең кебекләр белән дөнья тулы.

— Без дә тик ятмыйбыз бугай.

— Техниканы үстерә алырлык кешеләр хакында әйтәм мин. Аларның кадерен белергә кирәк, якларга. Ә бездә киресенчәрәк килеп чыга.— Бераз уйлангач өстәде: — Аның яңа тәкъдиме каралдымы әле? Монда юк,— диде папканы күрсәтеп.

— Кайсы тәкъдим?

— Соңгысы. Ул булачак водопровод системасын үзгәртмәкче иде.

— Мин нишләптер белмим.— Фәез шактый кырыч кыяфәткә кереп, стенадагы сәдәпкә төртте дә, секретарь кыз башын күрсәтүгә:

— Филиновка әйтегез, пожалуйста, хәзер үк монда керсен,— дип боерды. Кыз ишекне ябыйм дигәндә, өстәп өлгерде: — Яңа тәкъдименең схемасын да алып керсен.— Аннары Казимир Романовичка таба борылды.— Шулай, сез беләсез, ә мин белмим. Сизгерлек җитмәгән.

— Мин сезне тиргәмим. Шулай да уйлана төшү кирәк. Әгәр сиңа турыдан-туры буйсынучы кеше киңәш сорап сиңа килми башласа, югарырак начальство белән генә эш итәргә керешсә, бик үк шәп нәрсә түгел бит бу.

— Миннән узып сезгә бара диген, ә? Кызганыч...

Лебедев бу сүзләрне «ишетмәде».

— Аны Лазарев бик каты рәнҗетте. Без дә якламасак...— дип битараф кына әйтеп куйды.

Фәез исә блокнотына: «Аккош белән ябалакны нәрсә берләштерә?» дигән сорау төшереп куйды.

Баягыдан чагыштыргысыз күңелле кыяфәт белән кергән Филинов, чакыру көтмичә түргә узып, Фәез алдына схемаларын җәеп салды да исәпләрен сүзгә күчерә башлады:

— Ким дигәндә ике километр ара кыскара.

— Әһә, син торбаларны бу тирәгә китереп тормыйча...— Лебедев, сызымнарга линейка белән сузылып, уйлана калды.

— Әйе, туп-туры узам.

— Күпме торба, күпме металл.. Шулай бит, Фәез Сәлимович, шактый бит, ә?

Фәез исә мөнәсәбәт белдермичә генә:

— Проектчылар хатасы,— дип куйды.

Лебедев та үзенә хас битарафлык белән әйтте:

— Аларны төзәтү — безнең бурыч.

Баш идарәнең баш инженеры шулай дип торганда, СМУ идарәсе баш инженерының каршы килмәячәген сизгәнгә, Борис Фәезгә карап көлемсерәде:

— Син нәрсәдәндер риза түгел кебек.

— Болай гына... Без бит бу эшне синең участокка бирәбез дип конкрет хәл итмәдек әле. Синең белән кинәшкән генә идек. Ә син, хәл ителгән әйбер итеп, уйлана ук башлагансың, хәтта тәкъдим дә әзер.

— Начармы бу өлгерлек? — дип елмайды Филинов.

— Киресенчә.

Аларга колак салмыйча, исәпләр белән мавыгып утырган Лебедев башын күтәргәч, тынып калдылар.

— Эффект шактый кызык. Минемчә, үзендәге грунтны тагын бер тапкыр тикшертеп, тәкъдимне ПТОга бирергә мөмкин.

— Әлбәттә, син риза булсаң. Каршы килсәң, бирмәскә дә мөмкин. Пожалуйста,— диде Филинов, Фәезгә карап.

— Иҗади эшне кысарга сәләтле дип күз алдына китерәсеңме син Нәсибуллинны? — Лебедев Фәез өчен шулай җавап бирде.

— Юк, гафу итегез, һич тә.

Лебедев, китәр алдыннан плащ төймәләрен каптырган арада:

— Тагын бер кабат әйтәм, мондый егетләргә игътибарлырак булырга тырышыгыз,— дип куйды.— Гомумән, докладларда гына түгел, ә конкрет...

— Мин һәрвакыт әзер, тик ул үзе сер яшерә башлады — туп-туры сезгә, баш идарәгә чаба.

— Минем масштаблар зуррак бит,— диде Филинов, шаяртып.

— Ләкин син хәзергесе көндә СМУда баш инженер түгел. Иске гадәтләрне чак кына үзгәртеп торсаң да яхшы булыр.

— Ярый, ачуланма, иртәгә үк киләм үзеңә.

— Тагын тәкъдимең бармы?

— Бергә генә түгел, икәү.

— Син — сәләтле кеше, канешно...

Филинов тагы елмайды:

— Ләкин...

— Ләкин нәрсәдер комачаулый сиңа.

— Ярый, начальство алдында хурлама, житәр.

Шул сүзләр белән кабинеттан чыктылар һәм, Лебедевны озаткач, бетон сала торган төшкә атладылар.

Машиналар көн буе диярлек тукталмады. Мондый бәхетле көннәр сирәк була — кадерен белергә кирәк. Шуңа күрә, Харламов белән Фәез кичкә кадәр беркая да китмәделәр.

Сәгать кичке дүрт тулды, бу исә — эш вакыты бетте дигән сүз. Бишенче ярты җиткәч, Филинов, бераз читкәрәк китеп уйланып торгандай итте дә үз будкасына керде һәм, озак та үтмәстән, машинасына утырып шәһәргә элдерде.

— Тәки качты Борис,— диде Фәез үзе өчен генә.

Ләкин Харламов аны ишетте:

— Мең кабат сөйләштек инде. Управляющийга кадәр барып җиткәк — барыбер үзенекен итә.

— Куя белә кеше үзен.

— Формаль яктан ул хаклы — эш сәгате беткәч, ничек тота аласың син аны?

— Уникаль күренеш бездә.

— Бәлки, илдә дә юктыр.
— Аның каравы — чын иҗат кешесе, чын инженер. Безнең кебек бетон юллап йөрми, запчасть артыннан да чапмый.

* * *

Харламов больницага кергәч, Фәезгә, кем әйткәндәй, ике арбага берьюлы җигелергә туры килде. Идарә начальниклары киңәшмәсенә дип килсә, бер көнне управляющий бүлмәсендә ниндидер хатын елап утыра иде.
— Елама, иплəп кенә сөйлә. Ни булды? — диде аңа Лазарев юатырга тырышкан тавыш белән.
— Шул инде, ирем, өйгә кайтмый. Җиде тәүлек инде, эшләгән җирендә юклый. Үзем бер хәл, балалар курка.
— Янына барып сөйләшеп карадыңмы соң? — диде Лазарев.— Утыр, Сәлимыч.
— Барган идем, дөм-исерек. Култыклап алып кайттым, шәһәр буйлата кеше көлдереп. Өстен-башын юдым. Икенче көнне тагы кайтмады. Аңа кем кирәктер тагы...
Сөйләшә торгач, иренең Керосинников Иван булуы һәм аның Фәезләр идарәсендә, Филинов участогында эшләве билгеле булды.
— Ничек эшли? — дип сорады управляющий.
— Балта остасы. Кирпеч тә, бетон да сала белә. Начар түгел. Тик эчкегә салынды.
— Тиз арада Казанга дәваланырга озатыгыз.
— Ай, ходаем...— Хатын тагы елый башлады.— Озата күрмәгез, куркытыгыз гына, бүтән эчмәслек булсын, өйгә кайтсын.
Шунда Фәез дә, Анатолий Самойлович та рәхәтләнеп бер көлделәр дә сүз икенчегә борылды:
— Күпме кеше китте Зәйгә?
— Утыз.
— Шәп.— Лазарев хатынга карады.— Ярый, апа, иреңне үзеңә тапшырырбыз. Бүтән качып йөрмәс.
Хатын мең рәхмәтләр укып чыгып киткәч, кабинетка бүтәннәр дә керде һәм чираттагы планёрка башланды. Ләкин, агымдагы эшләр хакында сүз барса да, чынлыкта бәхәс төзелешнең төп юнәлешен ачыклауга бәйле иде.
Башта җәйге сезонга күчкәч эшне ничек тизләтү мөмкинлекләрен эзләргә тырыштылар.
Управляющий телефон трубкасына акыра:
— Җәй — безнең өчен дә урак өсте, ул бездә дүрт айга сузыла. Приказга ничек кул куйыйк?
Кыяфәте күрсәткәнчә, Казан эшне хәл итми. Мәскәү дә.
— Ике төрле график булырга мөмкин: күчмә ял көне белән атна буе эшләү, яки шимбәне сверхурочный эш көненә әверелдереп, якшәмбедә ял итү — атнасына бер генә көн ял.
Шуннан соң ким дигәндә ярты сәгать сөйләшсәләр дә, уртак фикер килеп чыкмый. Ләкин җавап барыбер табылачак дип исәпләргә кирәк. Анатолий Самойлович секретарь кызга барлык проект заданиеләрен алып керергә кушты. Яшел ефәк кофта якалары өстеннән ап-ак челтәр яка күренеп торган кыз, шактый хәйләкәр зәңгәрсу күзләре белән бөтен бүлмәгә карап елмайгач, управляющий өстәленә дермантин тышлы калын папка китереп куйды. Чыкканда да елмаюын яшерә алмыйча, аска караган булды. Кемнәндер ояла, янәсе, бүтәннәр белмәгәнне белә, имеш.
Папка ачылып, бәхәс тагын да куера төшкәч, Фәез кызның чыннан да нәрсәнедер белүен һәм аның секретарь кыз булудан бигрәк, сихер-

ләрәк зат икәнен уйлап утырды. Анатолий Самойлович үзенә хас бул-маганча тантана беләнрәк игълан иткән сүзләрне тыңлаганда, Фәезнең шикләнүе тагы да арта төште.

— Без сезнең белән миллионерларга әвереләдек,— диде управляю-щий,— дәүләт безнең карамакка алты йөз миллион сум акча бирде. Шул акчага Камада өч Днепрогэс чаклы станция төзергә тиешбез. Кулыбызда акча һәм Кама. Бүтән берни юк. Фактта — нульдән баш-лыйбыз. Сүз шул миллионнарны ничек ваклый башлау хакында бара.

Лебедев, управляющийдан көлгәнрәк төстә (бәлки Фәезгә генә шулай тоелгандыр) шундый ук тантаналы ясалмалылык белән әйтте:

— Башта ук шунысын да әйтеп куйыйк, иптәшләр. Безнең кулга, алты йөз миллион сум акча белән бергә, бүгенге көндә тугыз мең кеше үз язмышларын тапшырган. Алар һаман арта торачак. Тугыз мең кеше, тугыз мең өмет. Берсен дә алдамаска, берсен дә җимермәскә, ватмаска кирәк.

— Син матур әйттең, әлбәттә,— Анатолий Самойловичның тавы-шында аның сүзен җөпләп бетермәве сизелә иде.— Анысын без бары-быз да беләбез, иң кадерле төзү материалы — әлбәттә, кешеләр йөрәге. Ләкин бүген сүз ул хакта түгел.

Лебедев тагын урыныннан кузгалып куйды:

— Нишләп ул хакта түгел? Безнең беренче максатыбыз — кеше-ләргә эш, тормыш бирү. Дөньяга яктылык өстәү. Кая таба барасыбыз-ны билгеләгәндә...

— Боже мой! — диде Анатолий Самойлович авыр сулап (ниндидер әчерәк сүз эзләп торды булса кирәк), шулай да тыелып калды һәм ясалма бер тынычлык белән сүзен дәвам иттерде: — Зинһар, жит-дирәк...

Тик Лебедев та азау тешле. Бөтенләй уңайсызланмас булды.

— Син бездән нәрсә ишетергә телисез соң? — диде ул, управляю-щийга туп-туры карап.

— Кабатлыйк, алайса, ничек, нәрсәдән башлыйбыз, нинди юнәлеш сайлыйбыз?

— Аңлашыла.

Тынлык. Никтер бөтенесе тагын Лебедевка карый. Фикер барын сизәләр бугай.

Лебедев башта аягүрә басарга чамалап кузгалган итте дә, янадан тынычланып, костюм сәдәпләрен каптырды һәм, кесәсеннән авторучка чыгарып, шуның белән исәпләрен һавага сызгалый-сызгалый сөйләргә кереште.

— Әгәр дөрес аңласам, Анатолий Самойлович, әгәр нульләрне, гомуми фәлсәфәләрне конкретлаштырсак, беренче чиратта сүз торак йортлар төзү күләме хакында бара. Шулай бит?

— Билгеле инде.

— Алайса, мин сүзне дөрес башлаган булганмын. Нәкъ эш хакын-да... Әлбәттә, минем ялгышуым бик ихтимал, тик хаклы булып чыгуым да мөмкин. Шуңа күрә бәхәс килеп чыгар төсле тоела миңа.

Сүзнең кискен төс аласын Анатолий Самойлович та сизә иде бу-гай — дәшмичә генә баш какты.

Лебедев юри үртәргә тырышкандай, һаман ашыкмыйча:

— Кызганыч, без протокол алып бармыйбыз,— дип куйды.

Бу кадәресе бүтәннәргә дә килешмәде, күрәсең, тынычсызлана башладылар:

— Анысы нигә тагы?

— Ягез инде, сөйләгез, нәрсә ул хәтле... тарихи моментмы әллә?

— Минемчә, тарихи...— Лебедев чигәсен сыпыргалады.— Ярый, бу фикерләрне газетага язып чыгарга да мөмкин булыр.

— Мин сезне аңламыйм, Казимир Романович, сез нәрсә, үзегезне дипломат итеп күрсәтеп утырасыз. Без сезне көчләп сөйләтмибез — курыксагыз, пожалуйста...

— Юк, мин курыкмыйм — киресенчә. Хәзер... Менә шул, иптәшләр — безнең карамактагы тугыз мең кешенең яшәү шартлары борчый мине.

— Сез баш инженермы, әллә көнкүреш бүлеге буенча минем урынбасармы?

— Мин бу сорауны көттем, әлбәттә. Мин хәзер механизмнар хакында сөйләргә тиеш кеше. Ләкин кешеләр өчен кайгырам. Мәзәк.

— Тыңлыйбыз. Я...

— Механизмнардан бигрәк, шул аппаратларны эшләтә торган кешеләргә җитәкчелек итүне артыграк күргәнгә күрә, шуларның язмышы борчый мине. Чөнки аларның хәле хәзергә һич тә рәтле түгел. Дөрес, яңарак мәлдә энтузиазм үз эшен әйбәт башкара. Энтузиазм, романтика, героизм... Барысы да бар һәм барысы да бик кирәк. Ләкин кешеләрнең шул матур хисләрен дөрес файдаланмау безне бик үк матур итеп бизәмәс.

— Тәкъдим?

— Тәкъдим шул: безнең эш девизы «бөтенесе кешеләр өчен, бөтенесе кешеләр хакына!» булсын. Төзелеш — үзмаксат түгел.

— Акыллы кеше син, әлбәттә.

Управляющийның ачыктан-ачык чәнчүе иде бу. Ләкин баш инженер да бирешмәде:

— Конкрет дисәк, шул: безгә килгән барлык кешеләрне квартирларга урнаштыра барырга кирәк.

Бу юлы Анатолий Самойлович тынып калды. Мәсьәләнең җитди икәнлеге бүтәннәргә дә шунда гына аңлашылып җитте, ахрысы.

— Кабатлап әйтәм, иптәшләр, эшкә килгән һәр кеше үзенең баш өстендә су үтми торган түбә булуын тоярга тиеш. Шул чакта гына безнең эш чынлап барыр.

— Мин сезне дөрес аңласам, сез — агач шәһәр салу ягында.

— Вакытлыча — шулай.

— Аннан аларны җимереп...

— Таш кала салырга. Җимерү — кыен эш түгел.

— Ансат эш. Төзергә, җимерергә, төзергә. Аңлашылды. Беттеме сезнең?

— Кирәк булса, яңадан сөйләрмен.

— Тагын кем ничек уйлый? Дәвам итик.

Шлюз янында, үз идарәсендә сөйләшкәндә, Фәезгә Лебедев бик үк охшап бетмәгән иде. Ә хәзер икенчерәк кыяфәттә күренеп, ул бүтәннәргә караганда хаклырак сыман тоелды. Мәҗлеснең бер мәлгә уйланып калуы да юкка гына түгелдер. Башлык карашы белән исәпләшмичә, фикерләрен шулай кыю әйтә алуы белән Казимир Романович, мөгаен, башкаларга да әйбәт фикер калдыргандыр.

— Я, кем сөйли? — Лазаревның кыяфәте шактый кырыс иде. — Тик шунысын истә тотыйк, без төзелешкә демагогия белән шөгыльләнер өчен килмәдек, үзебез төзегәнне җимерә барыр өчен дә түгел... Күпмедер вакыттан соң безгә үзебез салган корылмаларга карап бәя бирәчәкләр. Нинди инженерлар икәнлегебез агач шәһәргә, времянкаларга карап түгел, ә таш һәм корыч стеналарга карап, бетон һәм корыч корылмаларга карап билгеләнәчәк. Каршылар юкмы шуңа?

— Анатолий Самойлович...— Лебедев, әлбәттә, каршы килмәкче иде, шуңа күрә управляющий кырт кисте:

— Сез инженер кеше, исәпләп карагыз...

— Кеше гомере акча белән исәпләнми. Эшләргә генә түгел, ул яшәргә тиеш, үзе өчен дә...

— Шуның өчен дә сез аларны ферма төсле такта баракларга кертеп тутырмакчы буласызмы?
— Вакытлыча.
— Вакытлыча алар частный квартирларда да түзәчәкләр.
— Кешеләр һаман килә тора, ә Чаллы зур түгел...
— Бераз гына түзгәннән соң аларга менә дигән газлы, ванналы, өр-яңа кирпеч өйләр булачак.
— Яңа мебельләр белән бергә, ул өйләргә яңа чирләр, авырулар да күченмәс дисезме? Алары да бүләкме? Яхшы!
Анатолий Самойлович бер мизгелгә аптырабрак калды, үзенә хас булмаганча, кызарынды, каушады. Утырдашлар исә, баш инженерга да, аңа да кушылмыйча, тын утыра бирде — бигрәк тә шул нәрсә борчый булса кирәк Лазаревны — ул бөтен кабинетны карашы белән айкап чыкты. Житәкче буларак, кычкырышка әйләнеп барган киңәшмәгә карау аны, әлбәттә, рәнжетә, ләкин шул ук вакытта бар көченә кызган фикер бәрелешен инде туктата да алмый иде.
— Димәк, сез тизрәк файда китерәчәк төп объектлар төзелешен әкрен барышка көйләп, планны өзәргә, миңа каты җәза бирдерергә, ә үзегез, шуңа кул чабып, рәхәтләнеп елмаеп утырырга җыенасыз?..
— Анатолий Самойлович...
— Ләкин мин сезгә ирек куймаячакмын.
— Проект заданиеләре барыбер әзер түгел, төзелеш барыбер озакка сузылачак...
— Ә сезгә сөенечме?
— Мин алай димәдем.
Лазарев урыныннан торды:
— План үтәлешенә торак йортлар төзелеше дә керә, ә времянкалар — юк. ГЭСның эш сызымнары килеп житкәнче без менә дигән чын өйләр төзи торачакбыз. Мин шулай уйлыйм. Ә сез, минем белән килешмәсәгез, үзегезгә бүтән төзелеш алыгыз һәм кешеләрегезне, тантаналы рәвештә фанфаралар уйната-уйната, баракларга тутырыгыз — анда сез әйткән авырулар булмас. Пычкы чүбе тутырылган, юеш тактадан оешкан стеналардан ул чирләр куркыр...
Бу сүзләрне үзенә кабул итәргә теләмәгәндәй, Лебедев кырыс бер елмаю белән сүзне чикләде:
— Менә монысы, ичмасам, демагогия!
Бәхәсне дәвам иткән хәлдә кычкырышка әйләнәчәге сизелгәнгә, бүтән сүз кушучы булмады. Фәез ике олы кешене ачуланыштырган сәбәпнең нәрсә икәнен ачык белсә дә, үзенчә уйларга тырышты: «Сәбәп — Кама, секретарь кызга әверелеп, бая ул керде бит!»
Бераздан, тынычлана төшеп, управляющий шулай ук кырыс итеп әйтте:
— Бәхәс принципиаль, әлбәттә, сүз төзелешнең генеральный юнәлеше хакында бара.
— Хәл итүне эшчеләрнең үзләренә калдырырга мөмкин,— диде баш инженер да, аның белән килешеп.
Анатолий Самойлович, таралышырга мөмкин дигәнрәк ым белән, телефоннан номерлар җыя һәм сөйләшә башлады:
— Павел Александрович? Лазарев, исәнмесез. Силикатный завод хакында борчуым. Әйе, ничек анда геодезистлар, привязканы ясап бетерделәрме? Алары булыр. Иртәгә үк наряд бирелер. Котлован казырга. Ничек күчте? Елына йөз миллион кирпеч. Шунсыз рәтләнә алмаячакбыз.
Бу сөйләшүнең телефон чыбыгының теге очындагы кешедән бигрәк Лебедевка җавап икәнен, ихтимал, сизмәүче дә булгандыр.

Югары ике житәкче арасындагы бәрелеш баштарак кешеләрне шомландырса да, соңыннан, киңәшмәләр яңадан тыныч уза башлагач, онытыла төште. Беренче чиратта капиталь йортлар салу белән Казимир Романович үзе дә килеште бугай. Ләкин Фәез каршылыкның эчкәрәк кенә яшеренгәнен, дөресрәге, Борис белән үз арасына көчкәнен тоймыйча булдыра алмады. Югыйсә, участок башлыгының СМУ баш инженерын санга сукмавы каян килә?

Элек, Фәез производство бүлегендә гади инженер чакта, сулыш алулары да бергә булган кешеләрнең, хәзер әйтерсең араларыннан кара мәче узды. Гадәткә әйләнгән аралашу калды калуын, ә дуслык... Әйтү кыен. Һәрхәлдә, дусты шактый борчый Фәезне.

Инде кич.

Шлюз төбеннән югарыга карасаң, кып-кызыл яктылык аша узган машиналар мәзәк шәүлә төсле тоелалар. Шәүләләр әкияттәге кебек жиңел, күңелле. Ләкин бу карап торганда гына шулай. Ә ул машиналар китергән бетонга кагылу белән аның никадәр авыр икәнен бетон салган кешеләр яхшы белә... Бигрәк тә эштән соң килгән бетон авырлыгын. Ә Борис аны бик үк теләп күтәрми шул.

Барлык төзелешләрдәге кебек үк монда да материал житмәүдән зарлануны көн саен ишетергә туры килә. Соңгы көннәрдә кая, нинди материал жибәрелергә тиешлеге турында гомумграфик төзелеп, «Промстройматериалы» тресты кешеләренә чак кына жан керсә дә, хикмәт, алар, үч иткәндәй, кичкә таба, эш беткәчрәк кузгалалар. Шоферларга нәрсә — китерә дә аудара. Эшчеләр китеп өлгергән булса, иртәгә эшкә килүгә блок урынында кыялы тау барлыкка килер иде. Шуңа күрә мондый чакта Фәез үзе калырга тырыша.

Озын такта күперләрне шыгырдатып, самосвал уза. Иләмсез зур кузов шыгырдап күтәрелүгә аста жир тетри башлый. Бүтән күперләрдән дә шундый тавышлар ишетелә. Ул арада вибраторлар да эшкә тотынып, жир чын-чынлап калтырый башлый. Ничаклы катырак калтыраса, шул чаклы шәп — вибратор дигәне шул калтырдаткыч машина бит инде.

Шулай, дөнья көйле генә калтырап торган мәлдә, ерак та түгел, мәче мияулаган тавыш ишетелде. Тыңлый төшкәч, тавыш жырга да охшагандай тоелды. Сагаеп калдылар.

> Расцветали веники в сарае,
> Поплыли калоши по реке.
> Выезжала на берег старуха,
> На своем горбатом старике.

Кем булыр мондый вакытта? Бу тирәдә кеше яши торган йортлар юк лабаса! Каян килеп чыккан бу адәм? Адәм дигәннәре, очкылык тотудан бүленә-бүленә, акыра бирә:

— Выезжала на берег старуха... Һык...

Кинәт Кәрам шаркылдап көлеп жибәрде:

— Карагыз, бәй, үзебезнең Иван бит бу!

— Чынлап, шул әкәмәт.

— Ләгънәт, тапкан эчеп йөрер урын.

Иван, үз адресына яуган сүзләрне ишетергә теләмәктән, чайкалачайкала, кешеләрнең иң күп жыелган төшенә килеп керде:

> Выезжала на берег Катюша,
> На своем горбатом старике.

Читтәрәк калган Кәрам бияләен салды, беретын баскаладыда абзый янына узды:

— Хәзер җырлатам мин сине, хайван,— дип, күз ачып йомганчы Иванның якасыннан эләктереп тә алды.— Кемнән рөхсәт алдың эчеп йөрергә, ә?

Иван аптырашлы кыяфәт белән егеткә карап торды-торды да аннары, нидер исенә төшкәндәй, дусын кочакларга кулларын җәйде:

— Коля җаным, син ич бу, җанекием!

Кәрам дустын турайтып бастырды:

— Кемнән рөхсәт алдың эчеп йөрергә дим, ә?

Иван исә шаркылдап көлде генә:

— Менә инде, кемнән булсын, иптәш Лазаревның үзеннән, җанекием.

— Бөтен кеше эшләгәндә ник болай йөрисең?

— Ничек алай? Мин дә эшләп йөрим ләбаса. Беләсең килсә, мин бүгенгесе көндә иң җаваплы зат монда. Иптәш Филинов үзе билгеләп китте мине.

— Кем итеп?

— Бетон салганда җаваплы кеше итеп. Син барыбер өеңә кайтмыйсың, шунда җитәкчелек ит, диде.

Исерек баштан адәм рәтле сүз ишетмәсен төшенгәч, Фәез кискен тавыш белән боерды:

— Бар, өеңдә бул.

— Әйтәм бит, кайта белмим, и кайтмыйм. Бүгенгесе көндә мин җаваплы кеше, Филинов үзе калдырды.

— Молодец, тапкан кешесен,— диде Кәрам, аның аркасыннан каккалап.

Эш беткәч, офыкларда таң яктырганда, кычкырта-кычкырта булса да, Иванны да алып кайттылар. Участокта өстәлгә бөгәрләнеп яткан җиреннән өстерәп төшерде аны Кәрам...

Шушыннан соң ничек сөйләшәсең инде Борис белән. Ярый әле, икенче участокта начальник ышанычлы кеше, Бориска бик ачуы килсә, тынычланыр өчен, Фәез шунда, Пичугин янына килергә тырыша.

Менә алар чиге тауларга, офыкларга тоташкан үзәнлек буйлап атлыйлар. Промбаза дип аталган йөзләрчә корылмалар сибелгән монда — үзе бер шәһәр.

Пичугин белән Фәез үзләре төзегән шул шәһәрне, шул корылмаларны карап йөриләр.

Бетон заводы — элеватор төсле.

Гравийны сортларга аеру заводы. Ике йөз илле мең куб...

Аннан ары — механизация базасы.

Сулда — баш энергетик базасы.

Сантехника детальләре заводы.

Водопровод, җылылык трассасы.

Болардан тыш тагын унлап база.

Бер гидростанция төзү өчен күпме корылыш!

Кирпечтән салынган шактый биек корылмаларның берсе алдында туктадылар.

Автобаза цехы. Аның тимерчелек бүлегенә керделәр.

Цех — чиркәү эче шикеллерәк. Югарыда чәүкәләр, күгәрченнәр оялыйсы урын дияргә мөмкин булган аралык күренә. Конструкция буенча, иң өстәге түбә белән стена тоташкан җирне уттан курыкмый торган түшәм аерып торырга тиеш. Ут белән бәйле һәр цехта шулай эшләнә.

— Проектта табаклы калай беркетмичә генә куела,— диде Фәез, түшәмнән күзләрен алмыйча.

— Алай гына аны һава агымы ачмасмы икән соң, кузгатмасмы?

— Дөрес, бик ихтимал. Ябыйм дип, яки бүтән калай куйыйм дип, берәр белмәгән кеше түшәмгә менсә, түбәнгә мәтәлүе мөмкин, калай

аны кутәрә алмый. Андый хәл килеп чыкмасын өчен, ул калайны фиксаторлар белән ныгытып куярга кирәк.

Пичугин, Фәезнең бу хакта карары әзер икәнне сизенеп, озак уйлап тормыйча сорады:

— Фиксатор... Анысы ничек була инде?

— Менә болай,— дип, Фәез блокнот алып сызгаларга керешге.— Калайның ике ягында — ике сәдәп. Икесе дә калайларны тишеп узган бармакчалар башына беркетелә.

— Сварка аппараты беләнме?

— Әйе, барлык табакларны да шулар тотып торачак.

— Шактый четерекле нәрсә икән.

— Шуңа күрә дә сиңа тапшырам бит инде, Бориска түгел.

Кичә бетон салганда Керосинниковның ничек «житәкчелек итүен» хәтерләп, икесе дә көлештеләр. Шуннан соң Пичугин Фәез блокнотындагы сурәтләргә карап уйлана калды. Шушы кечкенә сәдәпкә никадәр зур кичерешләр һәм хәтта язмышлар бәйләнгәнен ул әйтерсең сизенә иде.

Заман шундыйрак шул: кайбер урыннарда кечкенә бер сәдәпкә бассаң, бер секундта бөтен дөньяң ут булып очарга мөмкин. Гаҗәп нәрсә ул ут, гаҗәп... Ә без дөньяда бүтән төрле ут күбәйсен дип тырышабыз!..

Ярый, анысы хакында — соңыннан. Безгә хәзер шунысын әйтү кирәк: шулай итеп, Фәезнең чираттагы рационализаторлык тәкъдиме барлыкка килде. Махсус эзләнеп түгел, мәҗбүрият кушуы буенча. Һәм Лебедев «кечкенә яңалык» дип кенә әйтер әле... Ә менә Борис бу җәһәттән күбрәк ачышлар ясый һәм туктаусыз эшли шул. Көнләшмичә генә әйткәндә, чынлап та гади инженер гына түгел бугай ул. Соңгы көннәрдә тагын бер тәкъдим кертте Борис: бөтен промбазаны су белән тәэмин итү системасын үзгәрткән. Проектта су елгадан алынырга тиеш. Ә Филинов аны Камадан түгел, бәлки җир астындагы басымлы горизонттан алу юлын тапкан. Скважиналар гына кирәк. Анысы инде кыен эш түгел. Тагын күпме торбага, күпме металлга экономия дияр иде Лебедев. Ә вакытка күпме! Каян башына килә?! Кама дип өзелгән Фәез ут тирәсендә, ә аны бар дип тә белмәгән Борис су тирәсендә ачышлар ясый. Кызык...

Бер көнне үзен көлке хәлгә куйган Филинов икенче көнне бөтенләй башка яктан ялтырап китә. Әйтерсең аның гәүдәсе булып ике кеше яшәп ята.

Кешене тиргәве җиңел, аңлавы кыенрак. Бигрәк тә иҗат кешесен. Бәлки моның өчен башта Лебедевны аңлау кирәктер?

Шундый уйлар һәм ниятләр белән Фәез эштән соң Кәрамнар торган җиргә китте.

* * *

Ни өчен «бронвахта» дип атаганнардыр бу төшне,— белүче юк. Исем кушучылар аның мәгънәсен үзләре дә әйтә алмыйлардыр, бәлки. Хәер, хикмәт исемдә түгел. Аның ни икәнен белик без.

Елгаларда йөзеп яки өстерәлеп йөргән баржаларны күргәнегез бармы? Менә шулардан тора инде ул бронвахта. Аларны коры җиргә өстерәп чыгарганнар. Ямь-яшел болын уртасында егерме-утыз баржа каядыр юнәлгән кәрван шикелле тезелеп тора. Тик беркая да бара алмый. Ничектер, кызганыч — суда йөзәргә ясалган нәрсәне һич тә коры җирдә күрәсе килми — ком өстендә калган балыклар шикелле сикерешә, сулыш ала алмыйча интегәләрдер кебек тоелалар.

Ләкин алай ук түгел бугай, андый ук кыенлык сизелми бугай монда. Киресенчә, иркенлек, яшеллек — сирәк бәхеттәр... Яшел тәсне чуарлап, малайлар йөгерешә, малайлар кычкырыша. Качышлы уйныйлар алар.

Бер куак артына ике малай яткан. Фәез шулар янына килде:
— Мине дә уйнатыгыз әле.
Малайлар елмаештылар:
— Абый, монда тормагыз, сезнең белән сөйләшкәнне күреп, көтүче безнең монда икәнне белә.
— Ярый, алайса, мин дә качам.
— Ул сезне күргәндер инде.
— Юк, күрмәде.
Фәез куак артына малайлар белән бергә ятты да, икесен дә баштанаяк күздән кичергәч:
— Битләрегез нишләп бу хәтле шешенгән сезнең? — дип сорады.
— Черки... у-у! Кичкә таба болыт пряме!
Малайларның күз тирәләре бигрәк тә нык бүрткәләнгән. Куллары да шундыйрак хәлдә.
— Ә кулларыгыз нигә бетчәләгән? Кулны черки тешләми торгандыр бит?
— Тешләмәс! Күрерсез әле, көтегез.
Хәер, көтәсе дә юк — хәзер үк сырып алганнар. Һавада тузан шикелле сорыланып бөтереләләр. Игътибар гына ителмәгән икән.
— Алайса, монда кыендыр яшәү.
— Булды ди. Нишләп кыен булсын. Бик шәп...
Малайларның Фәезгә бигрәк тә сипкеллесе ошады. Сап-сары сипкел малайның бөтен битен диярлек каплаган. Сирәк урында гына бизәлмичә калган ак чырай, теп-тере күзләр шаянлык сирпеп, күңелне кытыклый.
Шул вакыт бронвахта ягыннан музыка яңгырады — малайлар күңеле төсле җиңел һәм шаян тавышлар.
— Репетиция башланды,— диде сипкелле сары малай.
— Концертка әзерләнәләр,— диде икенчесе.
Бүтән сүз әйтергә өлгергәнче янда гына ялт итеп әлеге «көтүче» — яшеренгәннәрне эзләүче күренде.
— Серьга, Фәрит, чыгыгыз, күрдем,— диде дә кире йөгерде.
— Минем аркада булды инде, ярый, ачуланмагыз,— диде Фәез.
Ә малайлар, аны тыңлап та тормыйча, иптәшләре янына чаптылар. Фәез барып җиткәндә, такта башына өелгән вак чыбык кисәкләре яңадан һавага чөелеп, аларны баягы сары малай яңадан җыярга керешкән иде инде. Үз гаебен сизеп, аңа бүтән сүз катарга кыенсынганга күрә, Фәез баржалар янына атлады.
Ярдан егерме метрлап әчкәре, бер-берсенә иллешәр метр чамасы ара калдырып тезелгән баржалар. Берсе суда. Якорьдадыр инде. Кәрам шунда булырга тиеш, дип, Фәез су буендагысына китте.
Баржага шактый озын трап буйлап күтәреләсең. Аннан палуба. Палубаның уртасындарак каюта — Фәез шунда килде. Кәрамнар аста икән. Текә тимер баскычтан төшелә. Ә түбәндә коридор — бөтен бер урам шикелле сузылган — ишекләр, ишекләр. Берсенә керде, икенчесенә кагылды. Көчкә эзләп тапты Кәрам каютасын.
— Әйе, керегез! — диде хатын-кыз тавышы.
Фәез керде дә ишек төбендә үк туктап та калды.
— Кәрам шушында торамы?
— Шушында.
— Ул кайтып җитмәдемени әле?
— Кайткан иде дә... репетициягә китте.
— Ә! Анда тавышлар ишетелгән иде шул.
— Әйдәгез, узыгыз, озакламас инде.
Узарга дисәң, узарлык урын юк — алты-җиде квадрат метрлы кечкенә генә бүлмә. Кергәч тә уң якта — тимер карават. Каршыда —

өстәл, ике урындык. Гомумән, бөтен җиназ һәм мәйдан ике кешегә исәпләнгән. Өченче кеше — артык. Озак торылмас монда.

— Мин теге репетиция дигәннәрен карап кайтыйм инде,— дип, ишекне ачсам, коридордан баягы сары малай ишеккә атылды:

— Әни, ипи бир әле.— Тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, Фәезне күрүгә шым булды һәм шундук елмаеп җибәрде.— Ә-ә, сез икән! Әти дә кайта, әни...

— Бик әйбәт, әнә кунак килде безгә.

Авызы колагына җиткән хәлдә, Кәрам да килеп керде:

— Килдеңме? Шәп булган. Күреп китәсең инде, алайса, безнең тормышны.

— Китәсең дип... Бәлки минем китәсем килмәс,— дип, Фәез үзенчә шаярткач, хатын чын күңелдән көлде:

— Бу оҗмахны ташлап ничек китәсең. Менә без дә китә алмыйбыз.

Ул, ишектән чыга-керә, табын әзерләргә кереште.

Кәрам исә чынлап сөйләшә иде.

— Ошаса, калырга да мөмкин. Буш бүлмә бар.

— Карават бармы соң?

— Табарбыз.

— Алайса, мин бүген шушында гына йоклыйм.

— Ярый, урынны рәтләп бирербез дә... Рәисәгә әйтербез.— Фәез бу исемнең кем икәнен абайламый торгач, Кәрам аңлата төшебрәк әйтте: — Минем хатын Рәисә исемле. Ятарга урын рәтләп бирер.— Рәисә үзе күренгәч, аңа: — Кунак бүген монда гына йоклый. Теге буш бүлмәдә,— диде.

— Кунакны чит өйдә йоклату килешмәс, үзебез анда кунарбыз.

Фәез:

— Юк, сез борчылмагыз...— дип әйтә башлаган иде дә Кәрам сүзне төгәлләде:

— Ярый, анысын карарбыз...

Якын-тирәдә кибет юк икән, хуҗага — сылтау, кунакка — куаныч,— аракысыз гына ашап-эчтеләр һәм, малайны житәкләп, дүртәүләп кичке прогулкага чыктылар. Монда башлыча яшьләр торганга, аларның күбесе шәһәргә киткән. Шулай да иртәгә иртүк эшкә барасын ныклабрак уйлаганнары (эшкә илтә торган автобуска ара ким дигәндә жиде чакрым) инде өйләрендә тынычланып ял итә. Ә кайберләре? Дистәләрчә чакрымнарга җәелгән тип-тигез болын — алар өчен танцы мәйданы, теләсәң ничек иркенләп бие һәм җырла, син монда чын мәгънәсендә ирекле. Бер генә инструмент түгел, бөтен бер квартет уйный. Ял итәргә дип, шәһәрдән килүчеләр дә байтак.

Фәез бик үк яшь егет булмаса да, өметсез үк карт та түгел. Әмма ни өчендер, бөгелә-сыгыла, гәүдәләрен, башларын җиргә тидерә-тидерә биегән кешеләрне күрсә, ул үзенең кеше булуыннан ояла башлый. «Үзеңне шушындый да тиле хәлгә куяр өчен никадәр буш һәм мәгънәсез булырга кирәк бит!» дип уйлый ул. Мондый чакта гомумән танцы житди кешенең дәрәҗәсен мыскыл итә төсле тоела.

Ләкин бүген андый яман уй тумады. Яшьләр, беренчедән, күп түгел, аннары, ул хәтле маймылланмыйча, үзләренең кеше икәнлекләрен онытмыйча гына бииләр. Тукталган арада — кызык-кызык сүзләр.

Кешеләрнең күбесе таныш түгел икән. Арада күзгә ташланган бер чибәр кызны «Кем ул?» дип кызыксынган иде, Кәрам әйтә алмады.

— Монда бетмәс инде алар,— дип кенә куйды һәм хатынына карап елмайды.— Бүген мин аны беренче тапкыр күрәм әле.

— Кама түгелме соң бу?

— Түгел! Что син!

Ул арада кыз, квартетка кушылып, моңарчы ишетелмәгән бер җыр җырлый башлады. Аңа бүтән кызлар да иярде:

Бүтәнчә киенгәнгәме, Фәез кызны танып ук бетерә алмады. Сүз арасында кызның исемен дә атап әйтмәделәр, ичмасам. Җыр бетүгә — тагын танцы. Ят кызны да үз ритмына ияртеп алып китте шул җор ритм. «Фәритне яткырырга вакыт, үземнең дә иртә торасым бар»,— дип, Кәрам хатынын да, малаен да алып китә башлагач, Фәезгә дә, кунак буларак, алар артыннан ияргә туры килде. Музыка һәм җыр тавышын су өстендәге баржа палубасыннан гына тыңлап утырырга калды.

Гаҗәп, кичәге киңәшмәдә кешеләр бронвахтада яшәүчеләрне кызганып, алар өчен баш ватып, бер-берсенең күпме кәефен кырып, бәхәсләшеп, ямьсезләнешеп утырдылар. Ә болар, ул сүзләрне бар дип тә белмичә, рәхәтләнеп, уйнап-көлеп яшиләр. Торыр җир юклыктан түгел, оҗмах төсле җылы урыннар тәкъдим итсәң дә, барыбер шушы бронвахтага килер төсле иде алар. Баягы чибәр кызны гына кара — зарлану, кәефсезләнүгә охшаш нинди нәрсә бар аның кыяфәтендә?! Бернинди андый галәмәт юк. Ул үзен иң бәхетле кеше итеп тоя торгандыр төсле һәм чынлап та бәхетледер. Шундый чибәрлек, шундый яшьлек — тирә-яктагы менә шушы иркенлек, табигать, Кама, июль киче — моннан да зур бәхет, моннан да тылсымлырак матурлык тагын кайда бар?! Һәм ул чибәр кыз нишләп Кама түгел икән? Ник сөйләшеп карамады әле Фәез аның белән? Бәлки сөйләшер дә иде — Кәрам тизрәк алып китте шул. Ник икән?

Дөньяда иң яхшы мендәр — хыял.

Йокларга яткач, яныннан Кәрам китәргә торганда, Фәез шаяртып сорады:

— Баржа мине каядыр алып китмәсме?

— Юк, төбе комга терәлгән аның.

«Алайса, Лебедев хаклы»,— дип уйлап алды Фәез. Ләкин алай түгелдер. Баржаның салмак кына чайкалуыннан сизә Фәез — бер урында гына тормый ул, кая табадыр йөзә, бара. Вакыт артта кала, ә Фәез алга атлыга, чакрымнар булмаса, минутлар, сәгатьләр артта кала, әмма барыбер тик тормый Фәез. Дулкыннар шыбырдавы, минутлар, сәгатьләр аша Фәез ай сукмагы буйлап Кама исемле гүзәл кыз артыннан йөзә...

Кызның тавышы да ишетелә бугай. Әйтерсең ул тәрәзә кага:

— Чык, син дә чык — әйдә, минем арттан...

Шулай ди дә ай юлы буйлап йөгерә... Әллә Фәез дә аның артыннан йөгерсенме?

Егет тиз-тиз киенеп, палубага күтәрелә дә ай сукмагына, судагы ак шәүләгә карый — кыз каядыр китә, югала, тик тавышы гына дулкын авазы шикелле ишетелә:

— Мине күрәсең килсә, суга сикер, шушы ай юлы белән бар — арыганчы, хәлдән тайганчы. Шуннан соң гына без кавыша алырбыз.

Тавышка гына ышану кыен, әгәр үзен күрсә, бәлки сикергән дә булыр иде. Ә болай кем эндәшмәс?

Фәез, хыял-мендәргә башын куеп, тагын йокларга ята. Каманың иркә тавышын, тәрәзә кагуын тыңлый торгач, йокыга тала. Ә төшендә һаман йөгерә, дулкыннарга баса-баса, ай сукмагы буйлап Кама артыннан йөгерә. Ул якынлашкан саен, кыз, су чылтыраган шикелле көлә-көлә, еракләша, Фәез якынлашкач китә дә, барып җитте дигәндә, тагы кача.

Төн буе шулай интектерде. Хәлдән тәмам тайдыргач, таң аткач кына Фәез бүлмәсенә үзе керде. Ишек ачылды, аның җиңел адымнары... Башын күтәрсә, ул түгел — каршында Кәрам елмаеп тора.

Хаклы түгел бугай Лебедев, түгел.

Чаллы урамнарында белдерүләр күренгәнгә байтак вакыт үткәч, инде аларга игътибар итүче калмагач, ниһаять, коймаларда, витриналарда булачак концерт турында яңа игъланнар барлыкка килде. Гидростанция төзүчеләрнең үзләре оештырган беренче чыгышы уникенче июльгә билгеләнә.

Кәрамнәр өендә бу хакта мәзәгрәк сөйләшү булды.

Кичтән әзерләп куелган ризыкны тиз-тиз капкалап, чәй эчеп, ике кисәк бутербродны (анысы көндезгә) кесәсенә тыкканда, хатынына ул салкын гына итеп:

— Бүген безнең концерт... Ак күлмәкне үтүкләп куярсың әле,— диде.

— Тәки катнашасыңмыни инде?

— Катнашмыйча, ай буе репетициягә йөргәч.

— Анысына да йөрмәскә буладырие.

— Кешеләр үтенгәч, тыңларга туры килде. Хәзер теләсәң дә ычкынып булмый инде.

— Ычкынып булмый дигән була, үзе оештырып йөрде.

— Кушкач...

— Кем кушсын хатынлы кешегә!

— Кем дип... ВЛКСМ комитеты. Син үзең дә комсомолка. Аның карары — синең өчен дә закон.

— Әй!

Бу ымлык ни аңлаткандыр — Кәрам аның мәгънәсенә төшенергә тырышмады, чөнки вакыты беткән иде. Ишек янына килгәч тә:

— Ярый, карчык, ачуланма, синең янына кайтмыйча әллә кая китмәм,— диде.

— Китәрсең дә...

Кәрам, яңадан килеп, хатынын кочаклап үпте дә чыгып китте. Артыннан уйлары иярә барды: «Чынлап, аның урынында мин булсам? Концертларга ул йөреп, мин өйдә утырсам? Миңа да бик үк ошамас бит бу?! Әйе, килешмәс, ансамбль җитәкчесенә әйтергә кирәк, бүтән кеше тапсыннар».

Бүтән кешенең тиз генә табылмаячагын да, аның аркасында концертның өзелүе мөмкинлеген дә белгән хәлдә, Кәрам үзен һәм хатынын тынычландырыр өчен генә ансамбль җитәкчесенә шалтыратты. Сүз күп булды, шулай да ул бер нәрсәне кабатлап тик торды:

— Хатын кызганыч, авырлы килеш өйдә утыра... Булмый.

Бүтән инстанцияләрнең файдасы тимәгәч, эш идарәнең баш инженерына барып терәлде. Кәрамны шунда чакырып керттеләр.

Фәез нәрсәдер укып утыра иде, Кәрам аның янына килеп җиткәч кенә, башын күтәрде.

— Син нәрсә, чибәр егет, бәяңне күтәрәсең, ә?

— Күтәрмим, болай...

— Башта нәрсә карадың?

— Башта хатын ул хәтле әллә ни әйтмидер ие. Үзең беләсең, аның кәефе көннән-көн начарая. Авырлы бит. Шул килеш көннәр буе берүзе утыра. Төнгелеккә дә калдырып булмый бит инде.

— Дөрес, ярамый — концертка алып кил.

— Малай берүзе...

— Берәрсенә калдырып торыгыз. Синең Чаллыда бабаң бар түгелме соң?

— Бар да...

— Соң?..

— Аек чагы туры килмәскә мөмкин.

— Әбиең?

— Үлде, бабай берүзе.

— Берүзе... Ә детсадка гариза бирдегезме?
— Әллә кайчан инде. Чират житми.
— Тиз арада постройкомга гариза яз, мондый хәлдә беренче чиратка кирәк. Ярдәм итәрбез. Ә хәзер бар, тап бер кичкә малаеңны калдырыр урын. Сине тыңларга кич белән үзем дә барам. Булдымы?
— Булды.
Кич.
— Жыр һәм бию ансамбле чыгышын башлыйбыз, иптәшләр.— Пәрдә ачылгач та шул сүзләр яңгырады.
Балта остасы һәм монтер Кәрам дип кем әйтер бу конферансьены? Гомер буе сәхнәдән кычкырып өйрәнгән диярсең, бернинди каушау, ашыгу галәмәте сиздермичә, кирәген генә әйтте дә салды.
— Ансамбль башкаруында жыр: «Ленин һәрвакыт исән!» Ансамбльнең житәкчесе — дирижер Олег Масленников.
Масленников халыкка борылып баш игән арада Кәрам чак кына арткарак барып басты. Күп тә үтмичә, икенче кырыйдагы бер кыз тавышы яңгырады:
— Солист Кәрам Марданшин!

— Ленин — безнең якты кояшыбыз,
Ленин — безнең сүнмәс таңыбыз.

Кәрамның йомшак, ягымлы тавышы тигез һәм ышанычлы яңгырый, күңелләргә көрлек, дәрт өсти. Соңыннан, тантаналы жыр бүтән моңнар, уйчан көйләр белән алышынгач, бераз гына ямансурак, ләкин ирләрчә сабырлык хисләре таратып, «Кайда сез хәзер, полкташ дусларым» яңгырады. Күпмедер жыр башкарылгач, пәрдә ябылып торды. Аннан соң нәфис сүз сөйләделәр. Яшь кенә бер кыз Муса Жәлилнең «Вәхшәт» исемле атаклы шигырен укыды. Бу вакыт күпләр күзеннән яшь тамчылары тәгәрәп төшүен күрергә мөмкин иде. Ләкин аларны карап утырырга кемнең дә вакыты юк — һәркем бер тойгы кичерә. Фәез дә үзенең бөтен тәне буйлап электр тогы узган төслерәк чемердәү сизә иде.
Бу шигырьне балалар укыса, тагын да көчле һәм гыйбрәтлерәк ишетелә. Вәхшәт һәм гөнаһсызлык, яшәү омтылышы белән канлы һәлакәт, кешеләр күмеләсе тирән баз белән хәзерге көн гүзәллеге күзгә-күз очраша кебек. Үлемгә каршы — яшәү, жимерүгә каршы — төзү өр-яңа йортлар һәм сарайлар рәвешле күз алдына килә. Аннары бию, атаклы «Яблочко». Аннары шундый ук шаян, ләкин мыскыллы шаяру катнашкан аксак корольнең сугыштан кайтуы... Аннары мөлаем сөенечләр балкыткан гүзәл кыз.
— Солистка Кама Сафарова. Ул татар халык көйләрен башкара. «Ай, былбылым!»
Бу сүзләр башта, ничектер, гажәп тә аңлаешсыз, юри генә, шаяртып кына әйтелгәндер төсле тоелды. Кама дидеме? Кама? Әйе, шул. Таныш кыз бу... Кама! Әйе, Кама бу, Кама! Син аның кыяфәтенә генә кара: болыт шикелле кабарып торган чәчләре күкрәгенә төшкән, башында укалы калфак... Энжеләрме әллә?.. Гидрострой салынып беткәч жемжем итәчәк утлар шикелле. «Кама! Син бит бу? Кәрам синең белән электән үк танышмы? Мин синең хакта аңа әйткәнем бар, нишләп ул сине белгәнлеген, синең кайда икәнлегеңне миңа әйтмәде икән? Әллә ул да сиңа гашыйкмы? Юк, мөмкин түгел! Сиңа миннән дә тилеребрәк гашыйк кеше дөньяда юк һәм була да алмаячак».
Кама, ни өчендер, Агыйдел камышлары турында, Агыйдел мәхәббәте, Агыйдел сагышлары хакында жырлый. Сеңелесе Агыйделне мактый. Шулай шул, үз-үзен жырлый алмый бит инде кеше!
Аннары, «Каз канаты» кыштырдаулары ишетелгәндәй, каурыйлар күлгә очып төшкәндәй тоела. Дөресен генә әйткәндә, канатлы кош

шикелле үзе очына Кама, үзе жилпенә — каядыр ашкына, иртәгә китмәкче була. Ә Фәез ирәр иде, дөньяның, вакытның теләсә кайсы читенә кадәр синең арттан барырга, шуны бөек шатлык санап, кирәксә арып егылырга һәм бөтенләйгә егылып калса да, үкенмәскә риза.

— Кама, чакыр син мине дә, алып кит син мине дә үзең белән, мәхәббәтем белән бергә! Ни күрсәк тә бергә күрербез! Ни күрсәк тә, бергә булгач, ул безнең бәхетебезгә әйләнер.

Бөтен зал, дөбердәтеп, аяк тибә-тибә, сызгыра-сызгыра, кул чаба, ә Фәез, жырчыга рәхмәт булып яңгыраган алкышларга кушылырга кирәклеген аңларлык та һуш җыя алмыйча, телсез калып карап тик тора. Менә кызны яңадан, кабат-кабат чакыралар, һәм бик тә, бик тә дөрес эшлиләр. Шулай шул — аны сәхнәдән чыгармаска, бер дә чыгармаска кирәк. Бераздан зал тынып, кызга аккомпанементлык иткән ансамбль дөпелди.

Кул буена кил, багырем —
Тынла сагыну сүзләрем...

Жырлап бетергәч, кыз тагын баш иде дә, йөгерә-атлый, тагын сәхнә артына китте. Зал тагын гөрләп кул чапты, үзсүзләнеп, жырчыны тагын чакырды.

Кыз чыкмас дип куркып өлгергән Фәез аны күрүгә урыныннан торды да тагын да катырак итеп кул чабарга кереште. Хикмәт, ул тору белән бүтәннәр дә, аягүрә басып, жырчыны алкышлый башламасыннмы. Кыз чыгарга мәҗбүр — музыкантлар ансамбле тагын нидидер көй чыгарып дөберди башлауга, Кама биюле-жырлы әсәргә күчте:

Сагынмамын димә, жаным,
Сагынырсың, туктале.

Әйтерсең юри әйтте ул аны, гүя Фәезгә карап әйтте. Ә Фәез йөрәге: «Тиле, болай да сагынган бит инде, туганнан бирле диярлек көтеп, эзләп арыган. Тагын ничек сагындырмакчы буласың?» дип типте.

Кыз тагын сәхнә артына китте. Озак-озак кул чапсалар да, инде бер-ике кат чыгып баш ию белән чикләнеп, бүтән жырламады ул.

Кәрам яңа номер игълан иткәч, халык тынды. Ләкин Фәезнең күңеле тынычланырга чамаламый иде. Киресенчә, кыз янына ничек барырга икән дип, план кора ук башлады егет. Хәзер кыз сәхнә киемен алыштыра торгандыр. Андый чакта янына бару килешмәс, бераз сабыр итәргә кирәк. Бәлки өстен алыштырмый да торгандыр, бәлки тагын чыгар әле? Юктыр, чыкмас, шул хәтле жырлап арыгандыр инде, болай да бик ялындырмады бит, үзен әллә кемгә куеп азапланмады. Биш-ун минуттан сәхнәгә менсәң, ул анда тыныч кына концерт беткәнне көтеп утырырга тиеш. Һәм Фәез аны озата барачак. «Ай, бәхет булыр иде озату! Дөресен генә әйткәндә, ул хәтле чиңга ашмаслык та хыял түгел икән бу. Менә, ун минут дигәнең үтте дә китте — сәхнәдә минутларны бии-бии озаталар... Вакытка кызык аккомпанемент... Ярый, биегәнне тагын карарга мөмкинлек туар — сирәк бәхетне ычкындырмаска кирәк».

Фәез шыпырт кына урыныннан торды да, иелә төшеп, ишеккә таба атлады. Урамга чыгып, сәхнә ягыннан ачылган ишеккә якынлашса, аптыраудан катты да калды. Баягы кыз — Кама узып бара! Я ходай! Фәез, аңына килгәнче, ким дигәндә йөз метр ара китте. Уйларга вакыт юк, нәрсә дә булса эшләргә, хәл кылырга кирәк. Хәл кылуын әйтү кыен, тик Фәез нәрсә булса да уйларга курыкса да, кыз артыннан иярде. Башта салмак кына атлады, ә аннары, артта кала башлагач, адымнарын тизләтә төште. Егет якынлашканны сиздеме, башка сәбәп беләнме — кыз да тизрәк атламакта. Фәез тизләгән саен, ул да тизли. Икесе дә башта тиз-тиз атлады, аннары икесе дә йөгерергә үк тотын-

дылар. Нәкъ узышу килеп чыкты; йөгерү дә — башта салмаграк, аннары — җан-фәрманга. Кыз Центральная урамыннан телеграфка таба борылды, егет тә, берәр өйгә кереп качмасын дип, җәһәт шунда таба бөтен көченә чабарга кереште. Бәхеткә каршы, кыз качмакчы булып, почмакта авыр-авыр сулап тора икән. Егет сөенеченнән: «Кама, тукта!» дип, кызның кулыннан эләктерә язгач, тегесе «Әнекәем!» дип бөтен көченә кычкырып та җибәрде, Фәезнең тагын капылт каушавыннан файдаланып, кулдан ычкынган кош шикелле пырылдап күздән дә югалды. Унга киттеме, сулгамы, алгамы, арткамы — егет абайламый калды. Кыз ярдан сикергән төсле тоелды аңа. Яр астына да төшеп карады, урам-тыкрыклардан, хәтта ихаталарга да кереп эзләп азапланды, шулай да файда чыкмады. Тылсымлы экияттәге төсле, күз алдында юкка чыкты кыз.

* * *

Фәез өенә соң гына кайтты. Ятып та тормыйча, тиз-тиз юынды да, кичәгедән калган минераль су белән вак-төяк капкалап, баш идарәгә ашыкты. Иң әүвәл комсомол комитетына керде. Исәнлек-саулык сорашу юк — ишектән керүгә, беренче сүзе шул булды:

— Наил, әйт әле, кичәге кыз кем иде ул?

Секретарь егет кап-кара күзләрен тутырып карады:

— Әйдә, Фәез, уз.— Үз бүлмәсендә беренче тапкыр күрүе иде аны.

— Кем иде ул кичәге кыз?

— Нинди кыз? — Наил баягыдан да гаҗәпләнебрәк, хәтта бераз мыскыллаган сыманрак көлде.— Нәрсә бар? Ни булды?

— Ничек нинди кыз инде?!. Кичә җырлаган кыз!..

— Кичә җырлаган кызларны дөнья буйлап эзли китсәң...

— Кичәге концертта дим мин.

— Кичәге концертта да кызлар берәү генә түгел иде. Бәлки, утырырсың?

Фәез утырмады, якынрак килде һәм, артык кабалануын әле генә сизеп, үзе дә көлеп куйды.

— Менә бит ничек килеп чыкты. Ярый, син гаҗәпләнмә инде. Ансамбльне оештыручы — син бит, Наил?

— Мин.

— Әйт алайса, каян таптың син ул Кама Сафарова дигән кызны?

— Ә! Менә ничек!

— Шулай шул. Я, кем ул?

— Белмим мин аны.

— Адресы?..

— Адресын белсәм!

— Менә юләр! Адресын белсән, үзең барыр идеңме? Син өйләнгән кеше, егет, койрыгын бозга каткан, шаяртма.

— Ялгыш аңладың, мин алай...

— Шулай да карап карар идеңме? — Наил җавап урынына елмайгач, Фәез янә сорады: — Я, кай төбәктә тора? Әйт, яшермә, адәм бул, зинһар.

— Кай төбәктә торганын да белмим.

— Гаҗәп, үзе оештырган ансамбль кешеләренең кемнәр икәнлеген белми. Бәлки син әллә нинди куркыныч кешеләрне җыйгансыңдыр?

— Бердәнбер куркыныч кеше шул Камадыр.

— Шактый куркыныч... Син аны каян таптың? Ничек очраттың?

— Кәрам алып килде.

— Кәрам? Безнең идарәдәге Кәраммы!

— Әйе.

— Алайса, мин нишләп синең белән сөйләшеп вакыт әрәм итәм,— иде дә ул жылдырым күк юкка да чыкты.

Тик, управляющий кабинеты янышнан баскычка таба борылганда, ны секретарь тавышы туктатты. Лазарев чакыра икән. Ашыгыч эшем бар иде бит дип караса да, нишлисең, начальствога каршы килеп булмый — керергә туры килде. Кабинетка үткәндә, секретарь кыз мәгънәе генә итеп:

— Анда милиция кешесе,— дип елмайды.

— Милиция кешесе?

Җавап көтмичә үк ишекне ачкач, Лазарев Фәезгә үзе эндәште.

— Давай, давай, тиз бул.

Бүлмәдә чынлап та милиция лейтенанты утыра икән.

Хәл-әхвәл сорашып та тормастан, Лазарев комсомол комитеты секретарен чакырырга кушты һәм ул кергәнче үк сүзгә керешге:

— Менә, сезнең каршыгызда район милициясе вәкиле Рөстәм Фролов.

«Булса соң, Фәезнең нинди катнашы бар анда?» — Башка килгән беренче фикере шул булды.

Наил кергәч, управляющий, үзенең гадәти сөйләшү ысулынча, кычкыра төшеп, төзелештә җәмәгать тәртибен саклауның әһәмияте турында озын гына нотык тотты. Ә лекциянең тәгәлләнгәнен чамалагач, Фәез «Монда минем ни хаҗәтем булды икән соң?» дип уйлап өлгергәнче, кинаяле төсләрәк итеп көлде:

— Хәзер иң мөһиме — Фәез Сәлимович. Концерт куючыларның күбесе сезнең идарәдән икән. Ә сез аларның эшен һәм ялын ахыргача матур итү хакында уйлап житкермәгәнсез.

— Ничек, уйлап житкермәгәнбез?

Бу сорауга җавапны милиционер бирде:

— Кичә төнлә концертта катнашкан бер артисткагызны хулиган куган...

— Нинди хулиган? Нинди кыз? — Фәез, кинәт кызарып, бөтенләй өнсез калды — коелды да төште. Кичәге... кыз артыннан йөгерү хәбәре, килеп тә житкән. Менә ни өчен чакырткannar!

— Нәрсә, гаҗәпме?

— Гаҗәп шул... бик гаҗәп. Монда ниндидер буталыш бар бугай.— Фәез тотлыкты, сүзләрен әйтә алмас булды. Хулиган... у-х-х...

— Аның да кем икәнен белергә тырышыгыз.

Ах, өстән тау ишелеп төште: «Әле белмиләр икән. Ә соңга таба карарбыз әле анысын».

— Әлбәттә, беләчәкбез,— диде лейтенант.

— ВЛКСМ райкомыннан да ярдәм сорагыз, бергәләп эшләгез,— диде Наилгә Лазарев.— Булдымы?

— Булды.

Шуның белән сөйләшү тәгәлләнде. Алгы бүлмәгә чыккач, Фәез бераз һуш җыярга дип тәрәзә янагына сөялсә, анда да секретарь янына җыелган хатын-кыз төнге вакыйга турында гәпләшә иде.

— Нәрсә дип куды икән ул аны?

— Билгеле инде, кызларны ник кусын?

— Әтәч!

Юк, моңа түзеп торып булмый. Фәез ишетсен дип, юри сөйләшәләр, мөгаен. Исемләп әйтергә генә кыенсыналар. Шулай, әллә кем булып чыкмадың, иптәш Насыйбуллин, әтәч булып чыктың! Управляющийга да чама белән аның исемен әйткәннәрдер, әлбәттә. Югыйсә, ник тәгаен аны чакыртсын? Болай беренче юлга кәефен бозмыйм дип кенә әйтми калдыргандыр, бәлки. Исемләп әйтмәсәләр дә, Фәезгә барыбер бөтенесе бармак төртеп күрсәтә бугай... Ишетелмәслек итеп кенә хихыл-

дыйлар: «Хулиган! Хулиган!» — диләр. Матур килеп чыкмады, бик тә ямьсез күренде бу уйлап чыгарылган мәхәббәт.

«Уйлап чыгарылган мәхәббәт» Фәезнең үзенә дә кызык тоелды һәм ул, аның мәгънәсен уйлый-уйлый, машинасына чыгып утырды. Юлда да һаман әчтән генә шул гаҗәп сүзне кабатлады: «Менә сиңа мәхәббәт! Хулиган мәхәббәте!»

Үз идарәсенә кергәч, секретарь кыз да авыз ерып каршылады, житмәсә:

— Фәез Сәлимович, ишеттегезме, кичә төнлә бер хулиган җырчы кыз артыннан куган.

— Ишеттем,— дип кенә куйды Фәез житди кыяфәт белән һәм кул селтәде. Тегесе кызыклы темага сөйләшеп начальнигының күңелен күтәрмәкче иде бугай, киресенчә килеп чыкканын абайлап, тиз генә тынды һәм бүлмәгә хәтле озата керде:

— Сезгә имза салырга. Плановыйдан, бухгалтериядән, ПТОдан. Һәр сүз саен — бер папка.

— Ярый, Жанна, карармын.

Көндәлек «камераль эш».

Ике-өч сәгатьтән соң гына диспетчерны чакырып кертте:

— Ничек, тәртипме?

— Беренче участокта кран юк. Калганнарында тәртип.

— Ә кешеләре нишли?..

— Сезне көттек.

— Домино сугалармы?

— Кәрт.

— Карта уйныйлар? Кем рөхсәт итте? — Беренче тапкыр һәм сәбәпсезгә шулай каты кычкыруын аңлап, Фәез шунда ук кайтып та төште,— ярый, ачуланма.— Диспетчер чыгуга, трубканы алды:

— Филиновмы? Син нәрсә? Участокта эш беткәнмени? Көпә-көндез «кәрт сугарга» кем рөхсәт итте?

— Кран юк бит! — дигән салкын җавап ишетелде.

— Раз билгеләнгән эш юк, бүтән эшкә күчерә торырга кирәк.

— Кая?

— Нефтебазага урын әзерләгез, барыгыз.

— Кирәкләр тотыпмы?

— Нәрсә бар, шуның белән. Хәзер мин дә чыгам. Килүемә — анда исегез дә калмасын. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды.

«Кешеләрне ялгыш өйрәттем, ахрысы. Иртән ярты гына сәгатькә соңласаң да, нинди дә булса звено рельстан ычкына. Филиновта бигрәк тә тиз».

Ярты сәгатьләп вакыттан соң мәйданга килгәч һәм анда һичбер җан иясе күзгә чалынмагач, бераз тынычланып, тимер баскычтан Кәрам эшләгән блокка төшеп китте. Кәрам белән Иван, алга-артка карамыйча, бик тырышып опалубка урнаштырып азапланалар иде. Фәез бер яктан опалубканы күтәргәндәй иткәч, болт тураеп, гайкалар бушады һәм ахыргача борасы гына калды. Кәрам бер яктан, Иван икенче яктан болтларны ныгытырга-каккаларга һәм борырга керешкәч, кәефләре дә җайлангандай итте.

— Безгә өч кеше кирәк икән,— диде Кәрам.

— Дүрт кеше дә комачау итмәс иде,— дигән булды Иван.

— Ярты кеше дә җитте бит әле менә,— диде Фәез.

Болар, әлбәттә, сүзсез тормас өчен әйтелә торган сүзләр генә. Кирәкле сүз, вак-төяк арасына кушылып, җай белән генә иярә торган була бит. Бу юлы да күңелдәгесе тәмәке тартырга утыргач кына әйтелде.

— Бу сиңа сәхнәдән җырлау түгел, шлюз төзү диләр моны,— дип, сүзне Фәез үз файдасына борырга тырышты һәм, ахрысы, ялгышмады.

— Кәрам үзе сәхнәдән җырласа, монда эше газлы аның,— диде Иван, иптәшенә ачыктан-ачык юхаланып.

— Ялагайланма,— диде тегесе,— барыбер бер тиен дә бирмим, башың чатнап хет челпәрәмә килсен. Аннары Фәездән сорады: — Ничек соң, ошадымы концерт?

— Кама Сафаровадан башкасы әйбәт.

Теләгенә иреште Фәез, Кәрамның күзләре капылт шар булды:

— Ничек диден? Кама ошамадымы сиңа?

«Кама! Димәк, Кәрам аның белән таныш». Шулай уйлады Фәез, ә үзе икенче сүз әйтте:

— Каян эзләп тапкансың син аны. Юньлерәк җырчы юк идеме?

— Менә сиңа мә! Беренче кешедән ишетәм. Син нәрсә, Сәлимович, колагына аю төкергәнме әллә?

— Мин генә түгел, тагын бар андыйлар.

— Яратмаганнармы?

— Билгеле инде, нәрсәсен яратасың аның.

— Ничек инде нәрсәсен? Халык күңеленнән ургып чыккан чишмә сафлыгын ничек яратмыйсың? Анысы җитмәсә, авыл кызларының табигый матурлыгы белән Кама камышлыгының зифалыгын бергә кушкан гүзәллеге, көләчлеге, шаянлыгы... тагы...

Кайнарланып тагын нәрсәләрдер санамакчы иде дә, Фәез бүлдерде:

— Ярар, җитәр, кайда соң ул кыз?

— Күрәсең киләме? — Кәрам шып туктады. Мөгаен, үзенең алдануын сизгәндер. Һәм урынына кире утырды. Шаккый вакыт сүзсез торгач, тагын Фәез сорарга мәҗбүр иде:

— Кайда соң ул кыз?

— Кайсы кызны әйтәсең? — диде Кәрам көттереп кенә.

— Кама Сафарованы инде, кемне булсын?

— Син аны уйлама да, көтмә дә.

— Болай булсаң, мин синең хатыныңа әйтәм.

Фәез Кәрамга ачыктан-ачык чәнчергә керешге:

— Ул өйләнгәндә матур кызлар сирәк иде. Как өйләнде, чибәр кызлар белән урам да тулды, и дөнья да тулды. Әкәмәт бу, искитмәле әкәмәт...

— Ярар, җитте сиңа. Иван алдында сөйләшә торган нәрсә түгел бу.

— Мин кемнән ким, ә? Кайсыгыздан ким мин сезнең! Сез икегезгә бер кыз карата алмыйча интеккәндә...— Артык уңышка ирешмәячәген сиздеме, бүтән дәвам итә алмады Иван һәм, сүз очын җуеп, тәмәкесен төкерек белән сүндерергә керешге.

— Кайсы урамда тора ул кыз?

— Кайсы кыз? — диде Кәрам тагы елмаеп,— нинди кыз таптырасың син миннән? Ә?

— Кайда эшли?

— Белмим.

— Түгәрәккә үзең алып килгәнсең бит.

— Мин сорамадым аның кайда яшәгәнен дә, кайда эшләгәнен дә.

— Алдакчы. Мин аны бронвахтада күрдем.

— Анда ул килеп кенә йөрде, каян икәнен белмим, иптидер менә.

Кәрам, әлбәттә, белми, хәйләкәрләнеп кылана гына, юри әйтми, янәсе. Әмма бер нәрсәне шәп чамалый, шуны сиздереп, Фәезгә күз кысты ул:

— Менә нинди шәп хулиган булып чыктың син, иптәш начальник! Ха-ха!

Шулай, күптән түгел Борис үзен көлке хәлгә куйса, хәзер — Фәез... Кешеләрдән бигрәк, үзеннән ояла. Ярый әле көндәлек мәшәкатьләр

кем әйткәндәй, тавык чүпләсә дә бетәрлек түгел — фикерне бүтән таб алып китәләр, башкага юнәлтәләр.

* * *

Иртәнге сәгать жиде.

Беренче эш итеп Фәез диспетчерлык ишеген ача:

— Я, ничек?

— Кичәгечә.— Диспетчер егет, аны күрүгә, жыясы номерларын жыймыйча, аягүрә тора.

— Маневрлы кран чыкмыймы? — ди Фәез, хәлне сүзсез төшенеп.

— Әйе.

— Филиновның ике бригадасы нефтебазада калсын.

— Әйтермен.

Аннары Фәез, утырмыйча гына, телефон номерлары жыя.

— Механизация идарәсеме? Кем бу? Сонечка! Дустым, ник безне болай жәберлисең син, ә? Ничек кем булыйм? Фәез.... Менә шул. Нинди үчең бар бездә? Кәефеңне кырдыкмы әллә? Иртәгә үк егет табарбыз — мыеклылары да күп, мыексызлары да буа буарлык. Тик кранны тоткарлама. Кем булсын синнән башка? Син бит — дөньяның тоткасы. Кайчан? Озак, озак, бик озак. Ул арада мин промбазаны салып бетерергә тиеш. Ярый, тырыш, тырыш, дустым, егетле буласың килсә. Хуш.

— Я, ничек? — ди диспетчер, Фәез трубканы куймас борын.— Шаяртуның файдасы тиярме?

— Иртәгә кран була.

Фәез аннары башка идарәләргә һәм заводларга шалтырата. Шулай ким дигәндә бер сәгать вакыт уза.

Икенче участокта бетон салалар. Анда Фәез озак тормый: «Барган атның башына суксаң, туктала гына».

Арматурачылар тузгыткан очкыннар белән күңеленә рәхәтлек сирпелгәнен тоеп, бераз торгач, машинасына утырып ераграк объектларга китә.

Промбазаның тимерчелек мастерскоенда корыч тавышлары чыңлап тора — димәк, монтажчылар килгән. Алар анда мичләр, мехлар, компрессор, шулай ук бүтән корылма һәм жайланмалар укмаштыралар. Тимер арканнар буйлап инде блоклар чабыша. Кичә генә тып-тын иде, тормыш әсәре юк иде биредә, ә бүген... Менә бит ничек. Бүтән объектларга да шулай әкренләп жан керәчәк инде. Үзең оештырган нәрсәнең кузгалып китүен күрү кызык һәм сөенечле, үзеңне дөнья яратучы кодрәт кебегрәк хис итә башлыйсың... Әнә Фәез ижат иткән нәрсә дә аның үз каршында кып-кызыл металл күтәреп жилтерәтә, ут төсле тимерләргә форма, кыяфәт бирә... Алары да, ниндидер механизмнарга кушылып, илаһи хәрәкәткә әверелә.

Проектка ул керткән икенче үзгәреш, түшәм калайлары белән тоташып, чылтыр-чылтыр килә... Утлы тишкеч калдырган тишекләргә тимер бармаклар кереп утыра, һәм алар ике яктан сәдәпләр белән нигытыла — калайларны шарнирлап беркетү дигән эмәл шул була инде. Егетләрнең неп-нечкә бетон матчаларда мәче шикелле оста сикергәләп йөрүен күрүе күңелле.

Анда эшләүче егетләр белән шундый кыска гына сөйләшү булып алды:

— Я, ничек, барамы? — дип сорады Фәез.

— Бара, иптәш начальник.

— Аңлашылмаган нәрсә юкмы?

— Күренми алай.

— Вак эш ләкин.

— Береккәч, зурая ул. Аздан жыела. Бригадир кайда?

— Калай бетеп килә, шуны әйтергә китте.
— Калай киләчәк.
— Безгә тиз кирәк бит.
— Барыбызга да тиз кирәк.

Автобазаның бүтән бүлекләрендә дә булгач, Фәез нефтебазага юнәлде. Филинов белән кул биреп исәнләштеләр.

— Я, ничек?
— Шулай, ташчыларга кәрәк тоттырдык.
— Барыбер эш.
— Ләкин акчасы азрак төшә бит... Эш хакы дигәннән, минем башка сагын бер уй килде бит әле.
— Әйдә, сөйләшик.

Бригада кешеләре экскаватор айкап узган чокырларны көрәкләр белән рәтләп чистарткач, чокырлар инде түгәрәк баз шикелле була башлаган. Нигез нык булсын өчен, аларга яңадан балчык тутырырга кирәклеге күренә иде.

— Без бу эшкә ашыгыбрак керешкәнбез, Фәез.
— Бригаданы эшсез тотмас өчен. Грунтны каян аласыбыз әле хәл ителмәгән,— диде Фәез, сүзнең кай юнәлештә башланасын сизеп.

Филинов шатланып елмайды:

— Проект буенча, грунт әллә каян, йөз чакрым җирдән китерелергә тиеш икән.
— Карьер якын түгел шул.
— Ә мин сиңа грунтны Чаллының үзеннән тапсам?
— Тапсаң, яраклы икәнен исбат итсәң, кем сүз әйтсен? Шәп булыр.
— Рационализация булырмы соң?
— Булуы да мөмкин, булмавы да бар.
— Бәхәсле булса, мин алынмыйм.
— Карале, Борис, син сүзне дөрес башладың да ялгыш бетермәкче буласың. Башыңа фикер килгән икән...
— Иҗади фикер.
— Әйе.
— Иҗади фикер — рационализация... Аның кыйбатмы, арзанмы икәне акча белән үлчәнә.
— Соңгы көннәрдә син миңа бер дә ошамыйсың әле, дустым.
— Анысы зыянсыз. Мин сиңа кыз кеше түгел. Мәхәббәттә аңлашасыбыз юк.
— Бүтәнчә аңлашырга туры килсә?
— Әйдә, аңлашабыз. Идарәнең баш инженеры буларак, әйт үз сүзеңне.
— Минем сүз генә җитми монда, банк нәрсә әйтер бит әле, аның рекламация бирүе мөмкин.
— Ә син үзең? Әгәр банк син уйлаганча эшләсә?
— Инструкция кушканча эшләр ул.
— Ә инструкциядә җирле карьерлар табу — рационаллаштыру билгесе, диелгән.
— Булмаска мөмкин дигән искәрмә дә бар.
— Димәк, эш синдә.
— Миннән тормас анысы.
— Ну вот, шулай итеп, мин эшкә тотынам.

Сәгать ун тулганда Фәез, барлык объектларны карап, яңадан идарәгә кайтты. Монысы инде «камераль эш» дигәне — ике сәгать буе документлар карау. Иртән һәм кич килгән хатлар, аларга җаваплар. Туктаусыз язышу — трест бүлекләре, подрядчиклар, поставщиклар, заказчылар белән бәйләнеш. Финанс нормаларына туры килми торган заказлар керсә, яки шуның кебек бүтән бәхәсле нәрсәләр килеп чыкса.

хатлар бигрәк тә ешая. Бүген дә ким дигәндә дистәләп хат язылды. Шулар белән өйлә җиткәнен сизми дә каласың.

Көндезге аштан соң тагын шәһәр буйлата сәяхәт. Монысы — сөйләшүләрнең рәсми булмаган ягы. Хат алыша торган кешеләрнең үзләре белән күзгә-күз очрашу: поставщиклар, заказчылар, трест бүлекләре белән дипломатик мөнәсәбәт. Эшнең яртысы шул мөнәсәбәтләрне оста башкаруга бәйләнгән дисәң, һич тә ялгыш булмас. Зарланырлык түгел, күз тимәсен — Фәез теләсә кем белән уртак тел таба белә.

Көндезге сәгать өчләр тирәсендә яңадан агымдагы мәсьәләләрне хәл итү өчен кабинетка кайтырга кирәк. Үз идарәсендәге бүлек кешеләре бу вакытны сагалап кына торалар: бухгалтериядән, план бүлегеннән имза салырга кәгазьләр, документлар күтәреп керәләр, югалган җеп очлары эзләп табыла. Аннары нинди заказлар кабул ителәсен, аларны башкару өчен кирәк әйберләрне ничек табарга һәм кайтарырга дигән йомышлар белән производство бүлегеннән керәләр... Әңгәмәбәхәсләр. Һәр көнне кичке бишкә кадәр. Аннары участок начальниклары, өлкән прораблар җыела. Монысы — кичке сәгать җидегә хәтле.

Баш кашырга да вакыт юк. Бу әле — эшләр бик җайлы барганда. Ә мәҗбүри бу программага өстәмә оперативкаларның санына чыга торган түгел. Идарәдә — атнага бер тапкыр, трестта — бер, район советында — бер, худка җибәреләсе объектларда бер тапкыр киңәшмә. Кайчакта көненә икешәр-өчәр кабат җыеласың. Максат — һаман шул: генеральный подрядчик белән ярдәмче подрядчикларның бердәм, төгәл эшләвенә ирешү. Шуңа тагын иң мөһим «һәм башка»ларны өстик: партбюро утырышлары һәм партҗыелышлар, семинарлар, укулар, постройком үткәрә торган җыелышлар...

Арганыңны да өйгә кайткач кына сизәсең һәм мендәргә баш тию белән йокыга таласың. Мендәр белән башны (аерылмас сөяркәләрне!) бер-берсеннән хәзер күп булса егерме минут вакыт аерып тора. Инде өйгә, өйгә!

Машинага утырыйм дигәндә, таныш тавыш ишетелде:

— Федя!

Артына борылса, Филинов икән. Аны бу вакытта идарәдә очрату гадәттә бик сәер хәл. Шуңа күрә гаҗәпсенеп куйды Фәез.

— Нишләп син монда? Бер-бер хәл булмагандыр бит?

— Сөйләшәсе килгән иде.

— Кичке унбер бит инде.

— Җибәр бу казна машинасын. Юлда сөйләшә-сөйләшә минем «Волга»да кайтыйк.

— Нәрсә хакында?

— Ну, табылыр сүз... Әйдә, мин — синең шоферың. Квартирыңа ук кертеп куям.

Фәез үз шоферына кайтырга кушты да, Филинов машинасына утырды. Аллы-артлы ике машина гөрләп барды — баш идарә бинасына хәтле юл бергә туры килде.

Артык арылганга күрә, Фәез Филиновның нинди йомышы барын да сорамады. Тегесе үзе башлады.

— Мин рационализацияләр хакында. Җыенысы дүрт тәкъдим булды бит инде.

— Көндез сөйләшергә вакыт тапмадыңмы?

— Җай килми бит. Синең анда кырык йомыш белән кырык кеше. Кайбер нәрсәне алар алдында әйтү дә кыен — ялгыш аңлаулары бар.

— Соң?

Филинов, сүз җаен ала алмыйча иза чигеп, шактый юл үткәч, болай диде:

— Минем ул тәкъдимнәр безнең идарәгә кырык мең сум бирәчәк.

— Әһә... Тәкъдимнәр тормышка ашырылгач.

— Кайчан булса да. Шунысы факт — дәүләткә файда.
— Мин алай уйлый алмыйм шул, гафу ит.
— Син миңа йомышымны әйтергә дә ирек бирмисең, алдан ук исәсең.
— Соң бит мин сизәм инде нәрсә сораячагыңны: рационализация — жади хезмәт, акча белән түләнә, дисең.
— Син түләмәскә үк ниятләмисеңдер ич?
— Юк, һич тә.
— Шулай булгач?
— Шулай булгач, син юкка борчыласың.
— Менә, ичмасам, мәсьәләгә якын ук килдек. Йомыш шул — син нда кул куй инде.
— Кул куелган.
— Син бер өлешен генә түләргә дип язгансың.
— Әйе, аванс.
— Ә мин тулы расчет хакында әйтәм.
Фәез, баш инженер буларак, идарәдә шундый тәртип урнаштырган де, шундый принцип: әгәр рационаллаштыру тәкъдиме участок жиэкчесе тарафыннан бирелсә, аның өчен ике тапкыр түләнә — тәкъдимең нигезе эш сызымнарына кертелгәч (монысы — идарәнең техника үлеге карамагында, заказчы һәм проектлаштыру оешмасы белән дә л килешә), аванс бирелә. Ә калган акча, тәкъдим тулысынча произодствога кертелеп, фактик-экономик эффект исәбеннән түләнә. Фәез ул хакта әйткәннән соң:
— Күптән түгел син дүрт йөз сум алдың. Шактый зур бүләк бу, инемчә,— дип куйды.
— Товарына күрә бәясе.
— Шулай анысы.
Филинов трасса буйлап барганда машинасын акрынайтты:
— Бәлки безгә генә кайтырбыз?
— Нишләп?
— Минем буфетта кызыклы әйберләр бар. Сүз дә бетмәде. Икәүән-икәү туйганчы әңгәмә коргач, ятып йокларбыз.
— Икәүдән-икәү? Ә хатының, балаң?
— Хатын китте минем,— диде Филинов, чак кына кызгану хисе издереп.— Баланы да алып китте.
— Бөтенләйгәме? Кая?
— Тольяттидагы элекке квартирга.— Бераз аптырабрак торгандай ткәч.— Бөтенләйгәдер инде,— дип уфтанды.
— Да, эшләр...
Фәез сүзен әйтеп бетерә алмый аптыраган арада, Филинов сүзне кенчегә борды:
— Вообще, синең белән иркенләп киңәшәсе килгән иде. Киттекме?
Дөньяда төрле хәл, төрле чак була, шуңа күрә каты бәрелмәскә неш табып, Фәез йомшак тавыш белән үз тәкъдимен әйтте:
— Мондый хәлдә киңәшмичә булмыйдыр шул. Мин риза, иркенләп йләшербез. Ләкин бүген вакыт аз. Әйдә, икенче серия — иртәгә.
— Ярый, шулай булсын, алайса, иртәгә.
— Үзең өйдән чыгып качма только,— диде Фәез.
— Егет сүзе бер булыр.
— Өйдә хатының калдырган жылы суында дамыни инде?
— Анысын уйлама... Ярый, сине туш уйнап каршыларбыз.
— Салют та булсын.
— Егерме биш артиллерия залпы белән, моңарчы яшәлгән еллаң санынча.
— Егерме жиде мәртәбә.
— Булды.

Сөйләшенгән вакыт тиз җитте. Звонокка кагылгач, ишек ачылуга, Борис балкып та чыкты.

— Килденме? Молодец. Әйдә, Федя, уз.

Залга узгач, Фәез сорады:

— Кайбер иптәшләр килмәделәрмени әле?

Борисның күзләрендә хәйләле һәм шул ук вакытта дусларча елмаю күренә:

— Сабырсызланма, дустым, сабырсызланма.

Сүз юктан әйтелә торган репликаларның бетүе булды, нииндидер тавышкамы, ишек ачылугамы борылып караса, кухня ишеге төбендә ике кыз басып тора икән. Фәез урыныннан торды. Борис исә, үз кешеләрчә, кызларны залга чакырды:

— Әйдәгез, мадленнар, танышыгыз. Бу — минем атаклы дустым Федя. Болар да дус, билгеле,— дип, кызларга ишарәләде.

Кызларның берсе ап-ак чәчле, юка гәүдәле, чибәр.

— Гета.

Икенчесе җирән, зур торыклы.

— Раина.

— Гета һәм Раина. Бик шатмын.

— Булды, даваегыз, киңәшик, леди һәм джентельменнар. Кичәнен көн тәртибе хакында.

— Хуҗа — кунакның ишәге. Боерыгыз, кызлар,— диде Фәез, дустының күтәренке тавышын куәтләргә тырышып.

— Мин хуҗамы сезгә?

— Чакырган кеше хуҗа.

— Мин чакырдыммы сезне? Ничек сез моны исбат итә аласыз? Кайда справкагыз? Прошу предъявить, леди һәм джентельменнар.

— Иранда инглизләр яши дисәләр, ышаныгыз, кадерле туташлар,— дип чәнечте Фәез.

Тазарак һәм озынрак кыз өстәл янына килеп утырып, Фәезгә карады:

— Ник алай дисез?

Кыскарагы һәм ябыграгы да калышмады:

— Географик-демографик ачыш! Тыңлыйбыз.

— Нигә дисәгез, ике ел эчендә... ике елмы әле?

— Дүрт ел,— диде Боря кухня ишегенә сөялеп, үз-үзен кочаклаган хәлдә.

— Менә шул дүрт ел эчендә безнең хөрмәтле инженерыбыз Персей огланнарын гидроэлектростанцияләр төзергә өйрәтеп кенә калмыйча, үзе дә алардан тел өйрәнгән. Шунысы кызык, фарсылар аңа үз телләрен түгел, инглиз телен өйрәткәннәр.

— Алай димәгез, джентельмен, инглиз теле халыкара тел ул. Аны белсәң, дөньяның бер почмагында да югалмыйсың.— Шулай дип, Борис сервант капкачын ачты.— Телне калдырып торыйк, сүз шешәләргә бирелә. Рәхим итеп, карагыз — кайсы ошый, кайсы сезгә күз кыса, шунысын ачабыз.

— Боларның барысы да безгә баш ия,— диде Фәез.

Кызларның озынрагы, тазарагы үзенекен әйтте:

— Менә бу җәлпәк гәүдәлесе сиңа охшаган, Боря, кукраеп утыра, һич баш иясе килми.

— Сүзгә бик остарып киттегез, леди һәм джентельменнар. Кайсын сайлыйсыз?

— Миңа шул җәлпәгә дә ярап торыр.

— Бу — итальянский бренди булыр.

— Ә менә монысы — Фәез кебек төз, ләкин нык гәүдәле.

— Анысына кызыкмагыз, ул — сухое вино.
— Эчтәлек һәм форма берлеге. Миңа шунысын ачыгыз,— диде Фәез.
Гета аны яклады:
— Миңа да шул ярап торыр.
— Димәк — бренди һәм...— Борис, шешәдәге исемне укырга азапла-
ып һәм тотлыгуын сиздермәскә тырышып,— гарәпнеке бу,— дип куйды.
Фәез үзенчә ярдәмгә килде:
— Мәсхәрә. Аңлыйсыңмы? Русча: позор яки издевка.
Хуҗа шешәләрне өстәлгә куйгач та юк-бар сүз дәвам итте. Ниш-
ләтәсең, мәҗлес шулардан тора бит инде — әйткәләшү, ирекле тәрт-
тәләшү... Шул рәвешле хәл итеп, Фәез белән Гетага сухое вино, Борис
белән Раяга коньяк салдылар.
— Ярый, джентельменнар вә ледиләр, безгә ни кирәк? Нәрсә өчен
ичәбез?
— Танышмак өчен.
— Без инде таныш.
— Ай-һай.
Фәез кул күтәрде:
— Болай, иптәшләр, һәркемнең күңелендә, иң тирән урында яше-
релгән иң кадерле хыялы өчен, шуның чынга ашуы өчен. Кешегә әйтеп
булмый торган уе, ихтимал, мәхәббәте өчен.
— Яхшы, кабул итәргә ярый моны, в общих чертах.
— Мәхәббәт өчен!
— Мәхәббәт!
Мәхәббәтнең хрусталь чыңы булуы бик ихтималдыр — шул чың
барысының да йөзенә елмаю булып күчте. Коньяк катылыгы чырай
сыттырганда исә кайсы киселгән лимонга үрелде, кайсы — алмага. Рая
сүзгә чая икән — коньяк тәме узганчы ук, күзләрен челт-челт йомга-
лап, шаяртты:
— Кара, бик йомшак икән бу, башка бер тамчы да менмәде.
— Әйттем мин сезгә, сухое вино эчегез дидем...
— Әйе шул, без уңдык — бокаллап эләгә. Менә без инде исердек
тә. Давайте, биибез, җибәр радиоланы.
Һәм башкалар һәм башкалар — шаян сүзләр, кыланулар. Барысы
да табигый, барысы да шәп. Ләкин утырдашларның кәефе күтәрелгән
саен, Фәезне ятсынуга охшаш бер хис һаман күбрәк били. Ә ахырга
таба борчый ук башлады. Үзе өчен кадерле, изге хыялына хыянәт иткән
төсле тоелды аңа. Борис аны монда юри, алдалап китергән бугай.
Шушы кызларның берсе, конкретрак әйтсәк, Рая белән таныштырмак-
чы, компания төземәкче булып чакырган. Димәк, ул Фәезнең кем икә-
нен һаман рәтләп белми һәм үз арбасына утыртырга чамалый. Матур-
лык ягыннан түгел, ул җәһәттән бу кызлар әллә ни ким-хур түгел, кем-
гадер, әйтик, Боряга — югыйсә, ник чакырган дисең! — хәтта бик
сылудыр да. Тик Фәезгә генә түгел. Матур күренмәү бер нәрсә. Ләкин,
шуның өстенә, әрсезлек бар бу кызларның сүзләре һәм хәрәкәтләрен-
дә, үрти торган, ачу китерә торган иркенлек бар... Моны алар үзләре
заманга хас шаянлык, үсеш, культура билгесе дип исәплиләр булса
кирәк. Ләкин андый үсеш Фәезгә кирәкми. Тыйнаклыкның грация
белән өртелгәнен ярата Фәез. Шундыйны эзли ул... Ә болар, болар...
Я, әйт инде син, адәм рәтле кыз төнге сәгать унда аракылы мәҗлес
корып утырамы?! Мондый очрашуга түгел, иң изге ниятле очрашуга да
күндереп булмый бит әнә Каманы. Эх, Кама, Кама! Син арттырыбрак
җибәрәсең, әлбәттә, арттырыбрак. Ә болар... Борис аркасында тау
түбән тәгәриләр түгелме соң?.. Сүз җаеннан сорап та белде Фәез:
тулай торакта тәрбиячеләр икән. Ә Борис ике-өч көн элек кенә хаты-
нын озатып, әйтерсең, аны оныткан да. Радиоланы ходка җибәрде дә
Гетаны биергә чакырды. Бая гына үпкәләшкән төстә әрепләшкән пар

хәзер, бер-берсенә елышып, иркә-иркә сүзләр алмаша. Гетаның башы — Борисның кулбашында... Әнә ул баш Борисның күкрәгендә ук инде. Ә Рая, кайчан чакырыр дигәндәй, Фәезгә астыртын гына күз ташлый. Көт әле, көт, үз кадереңне үзең белмәгән нәрсә, ди янәсе.

Борис та, Гета да Фәезгә ымлый:

— Раяны танцыга чакыр.

Инде Раясы да чытлыклана:

— Әйттем мин сезгә, сухойны эчмәгез дидем, коньяк эчкән булсагыз, исермәгән булыр идегез... минем кебек... Хәзер мәнә танцыга хәлегез калмаган.

— Әйе шул, рәт юк миннән.

— Егет кеше, имеш!

Кичәнең барышыннан канәгать булмаган Борис, Гетаны урындыкка утыртты да, мәҗлескә «ягулык өстәргә» тәкъдим итте.

— Болай бармый, леди һәм джентельменнар, күңелне күтәрмисез сез, киресенчә, төшерәсез генә. Шуна күрә миннән категорический тәкъдим: берәр рюмка коньяк күтәрергә! Каршылар юкмы? Юк. Бертавыштан. Бүтән тәкъдимнәр кабул ителми. Эчмәгән кеше дус түгел.

Бу юлы ялындыручы булмады. Фәез касә күтәргәч, хуҗа аны мактарга ук тотынды:

— Күрдегезме?!. Фәез дә каба икән, кызлар эчә дә эчә инде.

— Егетебез егетkә охшап китте,— диде Рая да.

Гета гына бәхәскә катнашмады — ул пластинкалар сайлый иде.

— Булды егетләр — татарча вальс! Үзебезнең җирле көй,— шулай дип, Борис тагын Гетаны биергә чакырды.

Әкертен генә килеп, Фәез Раяны чакырды. Шактый авыр иярә һәм ямьсез чайкала кыз. Тагын бер прозаик деталь: буе нәкъ Фәезнеке чаклы икән, әгәр чак кына озынрак та булмаса... Борыныннан коньяк исле җил дә өрә шикелле. Исе хәтта сулышны буа кебек.

Башын әле читкәрәк каерып, әле аска иеп, чиратны шулай да уздырды, геройларча түзде Фәез. Соңыннан твист башлангач, мондый кыенлык тумасына ышанып (хәрәкәтләр тиз һәм төрлечә, борынның борынга якын булуы мәҗбүри түгел), бу юлы көттермичә кузгалды. Дөбер-шатыр твист ботарларга-кисәргә керештеләр. Кыз аңардан да дәртлерәк һәм күңеллерәк, әйтергә кирәк, ашыгыбрак бии — хәтта музыканы узып... Кыз тәкъдим иткән темпка Фәезнең иярерлек чамасы бар барын да, музыка дигәненңе тыңламагач ничек була инде ул. Кыз үзенең бар осталыгын күрсәтмәкче булып пырдымсызлана. Шелтәләсәң, үпкәләве бар, шуңа күрә егет, бөтен дипломатик сәләтен туплап җай көтте дә, тиешле сүз эзләде һәм тапты да. Ләкин нәкъ шушы минутта, кыз ашыккан төсле, үзенен дә чак кына алгарак китүен сизде. Шуның аркасында — көтелмәгән хәл... Язмыш үзе әзерләгән диалог башлана:

— Биюегезгә караганда, сез шактый темпераментлы күренәсез.

Секунд та аптырап торылмыйча ташланган җавап:

— Тикшереп карыйсызмы әллә?

Шундый ук уйсыз секундта әйтелгән сүз:

— Ә бәясе күпме тора?

Һоп, килеп життек — шып туктаудан арба әйләнеп ат аркылы барып төшкән кебек... Фәез сизми дә калды һәм нәрсә килеп чыкканын хәзер тик хәтер белән генә күз алдына китерә... Булдымы бу хәл, юкмы? Шуны белер өчен яңагын тоткалады ул... Әйе, ничек кенә теләмәсәң дә танырга туры килә — булды бу хәл, Фәезнең ике як яңагына да ике мәртәбә чалт иттереп чапты Рая.

Борис белән Гета сәер тавышка һәм боларның идән уртасында хәрәкәтсез калуларына гаҗәпләнеп карап тик торалар. Ниһаять, хәл

алмашынды, Борис Гетаның кулларын салмак кына ычкындырып, берике-атлам якынгарак килде:

— Нәрсә бу? Ни булды?

— Әнә, сухой дигән аракыңнан сора, ул беләі — Рәхилә шул сүзләрне әйтте дә, тураеп басып, башын артка чайкады һәм, көяз кәҗә төсле тып-тып атлап, икенче бүлмәгә кереп китте. Бераз аптыраштан соң Борис телгә килде:

— Бу ни дигән сүз? Берни аңламыйм.

Фәез, елмаерга да, ачуланырга да белмичә Бориска һәм аның кулбашына янадан килеп башын куйган Гетага карап, шактый уңайсыз хәлдә калганын тойды.

— Ярый, мин гаепле, мәҗлесне бозган өчен гафу итегез,— диде һәм, ишек катындагы плащын эләктереп, чыгып та китте.

* * *

Һәр дөрес сүзне йөзгә дорфа бәреп әйтүнең егетлек түгеллеген Фәез яхшы белә. Алай гына да түгел, шул ысул белән иптәшләре арасында кыюлык күрсәтеп, ә тиеш урында, үзеннән югарырак даирә кешеләре арасында маэмай булып, арткы тәпиләренә басып боргаланган, тәмле телләнеп йөргән «үткен акыллы» кешеләрне җаны-тәне белән күралмый. Ләкин ул үзен бу юлы нәкъ шундый буш куыклар ролендә сизде һәм ике-өч көн буе кәефсез йөрде — төкерәсе килә, күңеле болгана иде.

Ныклап уйласаң, Фәез хаклы да. Әйтик, төннәр буе — ә бит аның да өендә эше, вазифалары бардыр — дөньясын онытып, нишләп ирләр мәҗлесенә йөри ул кыз? Билгеле инде... Кәеф чигү өчен. Тфү! Барыбер хаклы, әйе, әйе, шайтан алгыры, хаклы Фәез! Тик бер нәрсәдә хаксыздыр сыман — шуны туп-туры әйтә алуда. Ә әйтмәсәң ничек тәрбияләргә?

«Хәерле булсын, онытырга кирәк — файдалы анализ түгел бу. Онытырга».— Һәм Фәез, яңадан бөтенләе белән эшкә чумып, иртәнге җидедән төнге сәгать унбергә чаклы төзелеш ыгы-зыгысында кайнады. Шулай ук Бориска да күренмәскә тырышты — күренмәү җайсыз түгел: участокка эшләрне производство бүлеге рәсми тапшыра. Өстәмә сүзләр һәм йомышларын да бүлек аша җиткерү табигый хәл.

Ләкин идарәдә атна саен — планерка, анда, бүлек мөдирләре белән участок башлыклары да җыела. Борис та шунда керде. Пөзендә — мәгънәле елмаю. Башка участок начальниклары белән сүз беткәнче, тәрәзә янында тезелгән урындыкларның берсендә, тышка таба карабрак утырды да, бүлмәдә икәүдән-икәү генә калгач, Фәез каршына килде. Бер сүз юк — һаман елмаеп тик тора.

— Я, ничек анда синең? — диде Фәез бер дә сүз әйтми тормас өчен генә.

— Ярыйсы. Билгеле инде, диванда ауный-ауный үкседе. Көчкә юаттык.

— Мин аны әйтмим, участокта эшләр ничек бара дим?

— Ә! Анда! Бара, бер көй.

— Миңа бер көй генә кирәкми, миңа көннән-көн тизләү, эш күләмен арттыру кирәк. Синең чынлап та бер көй белән. Безнең идарәгә генә дә быел мең кеше эшкә алынырга тиеш. Бер ел эчендә өч тапкырга зураябыз, димәк. Синең участок шулай ук тиздән ике буласы. Син шушы хәлдә дә бер көй белән... Өйрәнчекләрне өйрәтүчеләр итеп тәрбияли алмасаң, син коллективыңны үзең генә үстерә алмаячаксың. Ә без сиңа кешеләр бирәчәкбез һәм заданиене икеләтә, өчләтә арттырачакбыз. Шуны үтәмичә кара — башың белән җавап бирәчәксең.

Фәез кайнарланыбрак китте, ахрысы, монологының чама белән

яртысында торып басканлыгыннан шуны аңлады. Сүзен әйтеп бетергәч, Борисның тын гына баш иеп торуыннан да тойды. Әллә нәрсә булды әле бу арада — тынычлык, тигезлек, тыйнаклык белән дан тоткан Фәезебез кызып китә һәм шуның белән иптәшләрен, бигрәк тә үзен рәнҗетә башлады. Борисның әйткәләшергә тотынмавы гына аны тагын тиешле түбән «отметкага» төшерде һәм ул кирәк тавышка күчте.

— Ә үзең ничек карыйсың?

— Миннән эш тормас. Карарбыз. Тик мин бүтән йомыш белән кергән идем.

— Шәхси йомыш булса, тыңламыйм.

— Эшкә бәйле.

— Соң?

— Без теге көнне иң кирәген сөйләшмичә калганбыз.

— Ул көнгеләр бүген юк.

— Ашыкма әле син. Мин бөтенләй икенче нәрсәне әйтәм. Теге тәкъдимнәр хакында. Үзең әйткәндәй, кырык мең сумлык дүрт тәкъдим...

— Ай-һай, акчаны яратасың син, Боря... Кызлар яраткан кебек.

Кырыс әйтелде бугай. Борис күзләрендә кинәт очкынланган үртәлү һәм ачу шуны күрсәтә иде.

— Нәрсә? Мин бит синнән әҗәт сорарга килмәдем. Ради Христа түгел, тем более. Үземә тиешлене даулыйм мин.

— Калганы тәкъдим производствога кертелеп, экономик эффектның нинди икәне эштә күренгәч. Шундый тәртип. Күпме әйтергә мөмкин инде?

— Син урнаштырган тәртип кенә ул.

— Юк, мин генә түгел, күп җирдә шулай.

— Син, әлбәттә, миңа карата тәртипле...

Чын-чынлап үпкәләү, рәнҗү бар иде Борис җавабында. Шуңа күрә Фәез аңа бу юлы йомшаграк әйтергә тырышты:

— Бүтәннәргә карата да шулай. Син аны үзең сизәсең. Дус булагак кына син мине бүтәнчәрәк эшләр дип уйлыйсың. Әмма дәүләт исәбенә дуслык юк. Булганы — үзебезнең исәпкә. Килештекме?

— Килешер идек... Фәез, бул әле кеше,— диде Борис түземлерәк булырга тырышып,— миңа акчаның бик кирәк вакыты — менә болай.— Ул муенын бармагы белән сызып күрсәтте,— до зарезу.

— Гафу ит, ярдәм итә алмыйм.

— Ләкин син юкка болай... Юкка. Минемчә, бу — ялган принципиальлек. Иҗади инициатива хакында кайгыртуга бик үк охшап бетми бу, шуның киресенә ныграк охшап тора.— Һәм Борис китәргә җыенды.

— Ачуланма, Боря.

— Тырышырмын.

Алар тагын да сирәгрәк очраша торган булдылар. Рәсми йомышлар бүтәннәр белән бергә чакта хәл ителә килде. Ләкин соңынтын, әкренләп, Борис тагын елмая һәм ачыграк эндәшә, хәтта сирәк-мирәк шаян сүзләр дә әйтә башлагач, Фәез аның үпкәләве бетәр дип уйлады һәм югала язган дустын яңадан тапкандай тойды.

* * *

Фәез — авыл малае.

Аның бәллүе — Табигать.

Остазы — Табигать. Ул һәрвакыт аның белән киңәшләшә.

Мәхәббәте дә — Табигать. Язгы һәм җәйге яшеллек төсле — мул, чиксез, серле.

Үзе калада яшәсә дә, машинасына утырып, җай чыктымы, ерак урманнарга, ерак болыннарга юл тота Фәез.

Тагын ял.

Бу юлы үзе генә түгел, бөтен төзелеш диярлек бара. Комсомол һәм бүтән җәмәгать әһелләре, яшьләрнең ялы турында кайгыртып, җәйге лагерьлар оештырдылар. Шул ысулдан көймәләр, хәтта катер да алынды. Атналар буе белдерүләр эленеп торса да, Борис Фәез тәкъдимен яңалык төсле кабул итте:

— Нинди прогулка?

— Көймәләр белән. Эстрадный оркестр бара, концерт, уен, җыр. Гомумән — яшьлек. Син үзеңне яшьләр кастасына кертәсеңме соң әле?

— Кертәм.

— Хатын киткәч ни...

Шулай итеп, җомга көнне кичке якта көймәләргә төялделәр дә Кама буйлата сәяхәткә киттеләр.

Фәез белән Борис янына Гета, ә Гета янына теге Рая елышты. Тагын бер кыз... Анысының исемен атарга курка Фәез. Камага охшаган чөнки... «Юк, түгелдер, охшаган гынадыр. Бүтән ...чөнки кыз бер егет янында утыра... Менә сиңа — ял! Ял итү кайгысы калдымыни инде болай булгач? Шайтан алгыры, көн югалды. Көн генәме соң, бәлки бөтен гомер... Югалды. Ләкин юктыр, Кама түгелдер бу. Әйе, охшаган гынадыр, шайтан алгыры».

Фәезебез үзеннән берничә генә кеше аркылы утырган кызның теге чакта яр буенда очрап, ә күптән түгел сәхнәдән җырлап акылдан яздырган кыз икәнен ап-ачык күргән килеш «танымаска» карар кылды: аннан башка егет белән йөри алгач, нинди Кама булсын инде ул?

Дустының өметсезлек тулы карашын күргән Борис, имеш, ярдәм итмәкче. Көймә борынында яткан Фәезгә иелде дә, бүтәннәр аңламасын өчен, сүзләрен речетатив төсле көйләргә кереште:

— Әкият юк ул, дустым, дөньяда, бар тик шушы кыз гына. Аның исеме — Камилә. Кама түгел. Хәтта шушы Камилә өчен дә конкурс — кайсыгыз җиңә, ул — шуңа.

— Күңелсезрәк килеп чыга түгелме соң алай?

— Ярлар сөю күңелле эш. Син дә җиңәргә тиеш, дустым, җиңәргә тиеш!

Ай, усал бу Борис! Сөмсере коелган Фәезгә әзрәк чырай кертте. Тик койрыкчы егет тә тик тормый, үчекләгәндәй, теленә салына, җай чыкса-чыкмаса да, кызга Камуля дип эндәшә, хәерсез!

Өч-дүрт сәгать баргач, елганың сульяк ярында, биек яр буенда, туктадылар. Өстә урманлы тау, аста — су. Борылма әчкәрәк кереп тора. Аннан сикерергә мөмкин... тик ят суда сикерү — урынсыз тәвәккәллек, башта тикшерергә кирәк. Югыйсә, җаныңны су төбендә калдырырга мөмкин. Мәхәббәт һәм су белән шаярырга ярамый.

Көймәдән беренче булып Борис сикереп төште һәм чылбырны ул эләктерде:

— Амазонкалар утравына килеп җиттек. Хәзер хатыннар патшалыгында рәхәт чигәчәкбез.

Гетага көймәдән төшәргә Фәез, Раяга — Борис, ә «Камуля»га, тфү чорт, койрыкчы егет булышты. Җитмәсә, «ят кыз» чая нәмәрсә икән:

— Болар амазонкалар эзләп килгәч, безнең кебек гади кызларга кем кала инде? — диде ул.

«Шулай ук гади кыз микәнни?»

— Кайгырмагыз, ледиләр, сезне менә дигән баһадирлар көтә — су төбендә.

— Рәхмәт, башта үзегез төшегез,— диде Рая.

— Исән чыкмасагыз, безгә үпкәләмәгез,— диде Гета.

— С легким паром! — дип котларга ашыкты Камилә.

Юк, бу кызга Кама дип эндәшә алмас Фәез.

Тирән чокыр буйлап, берсен-берсе үртә-үртә күпмедер баргач, ялан жиргә барып чыктылар. Ярты гына чакрым ары — арыш басуы. Палатканы шул басу күренеп торган җиргәрәк кордылар.

Озак та үтмичә, яр буеннан оркестр тавышы ишетелде. Бу — калган көймәләрнең килеп җитүе иде.

— Безне оркестр каршылыйсы урында, без оркестрны каршыларга тиеш, мәзәк килеп чыкты әле бу,— дигән булды Фәез күңелендәге көек тәмен басар өчен генә.

— Сукранма, картлач, әйдә, ал кармакларыңны тизрәк.

Дөрес әйтә Борис, кояш баерга бер сәгатьләп вакыт бар әле. Кызларны иярта алмыйча, баягы тирән борылмага үзләре генә килделәр.

— Монда безне корбан балыклары сагынган.— Фәез тиз-тиз суалчан саплап, кармагын суга ыргытты. Көймәнең икенче башында утырган Борис та шул эш белән мәшгуль. Фәез, аңа игътибар итмичә, кармак җебеннән бигрәк, су төбен күзәтә. Кармакны бер сала, бер чыгара торгач, сизми дә калган: дулкын акрынлап көймәне яр читенәрәк кагып чыгарган, имеш. Шунда Фәез суның яр буенда да тирән икәнен төшенде. Тик яр артык биек — ким дигәндә алты-җиде метр. Җайсызрак төшсәң... Чү! Нәрсә булганын төшенеп тә җитмәстән, ул кармакны өстерәп чыгарды — көймәдә ап-ак корбан балык сикергәли. Караңгы төшкәнче алабуга һәм кызыл канат та эләгеп сөендерде. Китәр алдыннан Борис кычкырды:

— Молодец, сазан иптәш, булдырдың!

Күпмедер утыргач, каяндыр тавыш килгәндәй тоелып, ярга карасалар, кызлар килгән икән. Камилә дә бар, ә койрыкчы егет юк!

— Су керә алмый калдык,— диде Фәез, каушавын җиңәр өчен.

— Керербез әле, картлач, иртәгә бөтен бер көн бар.

Балыкларны бала чактагы кебек итеп җепсәгә тезделәр дә палаткалар янына киттеләр. Анда инде җиде-сигез палатка калыккан һәм яшел мәйдан уртасында учак балкыган.

Балыкны егетләр үзләре чистартып, урданы үзләре корып, кастрюльне дә кайнарга үзләре куйдылар. Ә кызлар, палатка алдында җәймә җәеп, булган ризыкны шунда чыгардылар һәм, кайнаган ухага дүрт күз белән карап, көтеп тордылар.

— Хәзер... леди һәм джентельменнар... Сак кына сабырлык. Биш минут.

— Иллегә чаклы саныйбыз...

Һәм санадылар да. Озак та үтми, кашыкларга өрә-өрә, уханы гадәттәгечә мактый-мактый, ашарга керештеләр.

Аерым-аерым гына башланган шаянлыклар тора-бара олы бәйрәмгә әверелде — оркестр тирәсенә җыелдылар: уртак музыка һәм уртак учак тирәсенә.

Башланды җыр, башланды бию. җор уен һәм башка кыланмышлар. Фәез дә читтә калмады — ул да биеде, ул да җырлады. Караңгы төшкәч, аргач, дөресрәге — Камиләнең гел койрыкчы егет белән танцевать иткәнен күтәрә алмыйча, бәйрәмне калдырып, яңадан куыш янына килде дә сүнеп барган бәләкәй учакка чыбыклар өстәде һәм йомшак үләнгә чалкан ятты.

Адәм баласы төнге күккә караса, уйлана башлый. Дөньяның башка сыймас хикмәтләре шул ераклыклар белән бәйләнгән бит. Мәңгелек сер — йолдызлар каян килеп чыккан? Газ сыман эйберләрдәнме? Ә газлар үзләре каян?

Җир — безнең бәллүебез. Аннан ары — планеталар, кояш, тагын да арырак — безнең галактика, аннары — бүтәннәре...— башка дөньялар, томанлыклар... Ә алар нинди дөньяга барып тоташа? Галәмнең чиге булмаса, шул чиксезлек кая хәтле сузыла һәм аннан ары — тагын да ары нәрсә китә?

Сорауларның чиге юк. Алар кешенең бала чак акылын аеруча ның борчыйлар. Уйлап-уйлап та җавап табалмагач, соңынтын адәм баласы алардан кул селти һәм чагыштырмача уйсыз гомер кичерә. Ә туктый алмаса — алардан яңа Лобачевский яки Эйнштейн килеп чыга.

Җир өстенә аяк баскан «Аңлы кеше» сабый чагыннан ук уйга чумган. Нәкъ Фәез кебек, шушы ук йолдызларга карап хәйран калгандыр ул. Ничәмә гасырлар күзләрен шул ук йолдызларга шулай теки һәм шундый җавап эзли кеше. Ә төгәл генә җавап юк. Бераү әйтә аптырагач: дөньяны алла бар иткән. Ләкин икенчесе аннан: ә алланың үзен нәрсә бар иткән? — дип сорый. Мондый сорауны кую — законлы түгел, ди сиңа теолог. Сорау тудымы, син аңа җавап эзләргә тиеш буласың. Таба алмыйсың икән — димәк, теорияң фәнгә әверелми. Шул чакта инде Аңлы кеше икенче якка күз төшерә: бөтен галәм — бердәм, матди. Материя булган, бар һәм булачак, ул — чиксез. Ә поп яки мулла тота да сорый: шул чиксез материянең үзен нәрсә яки нинди сәбәпләр бар иткән? Нинди кодрәт? Шул кодрәтне икенче төрле әйтеп алла дип атыйбыз түгелме соң инде? Артык гадиләштерелгән шушы сорауга да кистереп кенә җавап бирү җиңел эш түгел шул. Менә шуннан китә дә инде мәңгелек бәхәс — философиянең төп соравы. Һәм ул бәхәс хәзер дә бара...

Шулай уйланып яткан чакта Борис килеп утырды да Фәезнең күкрәгенә кулын куйды:

— Адәм баласы нәрсә хакында уйга талган?

— Галәмгә карап кеше нәрсә хакында уйларга мөмкин?

— Кешелек нәрсә хакына яши, нинди максаты бар аның?..

— Андый максатны куеп буламы икән соң?

— Ә нишләп куймаска! Бигрәк тә менә безнең заманда, кешелек өчен җир кысанлана башлагач. Мәсәлән, океаннарны үзләштерү, бүтән планеталар табигатен үзгәртү — анда яшәр өчен... Ниһаять, безнең дөньяда җылылык бетәсен исәпләсәң... Гомумән — кешелекне, кешелек акылын саклап калу максаты...

— Акылны саклап калу — кешенең бурычы, ә максаты түгел.

— Леонарда да Винчи: «Файдалы үткән гомер тыныч үлем китерә»,— дигән. «Галәмдә кешенең нинди функциясе бар?» дип сорый философ Бакминстер Фуллер һәм үзе үк җавап бирә: «Сез һәм мин — Галәмнең аерылгысыз функциясе. Без — гаять нечкә мәгънәдә аңлашыла торган антиэнтропия», ди. Ягъни мәсәлән, безнеңчә әйтсәк, дөньяда җылылык җитми башлагач, аны кеше акылы җылытырга тиеш була. Кеше кояшны алыштыра. Без синең белән җылылык һәм яктылык иҗат итәбез икән, судан ут алырга җыенабыз икән, бу — шул процессның бер өлеше. Кешелекнең миссиясе — материаль һәм рухи стихияләр белән җитәкчелек итү. Менә синең белән минем максат кайда!

— Юк, киләчәк буыннарга яшәү шартларын тудыру, космик тормыш иҗат итү — хезмәт, ә хезмәт өчен түләү — бүләк түгел. Бүгенге кеше ул хезмәте өчен бүген практик файда ала алмый икән — космик тормыш та булалмый.

— Шулай итеп, син үз фәлсәфәңне ачып салдың инде, яңасе?!

— Минем теләгем шундый: үземә бирелгән бүгенге көн белән яшәргә, бүген үземә бирелгәнне алып калырга тырышу. Чөнки аның иртән булмавы ихтимал. Менә минем янда чибәр кыз бар икән — мин аның кадерен белергә тиеш. Сиңа да шуны тәкъдим итәм. Кара, Камилә чибәр иң. Иртәгә аның монда булмавы мөмкин.

— Тик шулай гына уйласам, мин дөньяда яшәмәс идем.

Борис шунда сикереп торды һәм, Фәезнең җавабын көтмичә, «ни әйтереңне беләм» дигәндәй кул селтәде дә якыннан узып баручы Гетага эндәште:

— Тета, тукта әле.— Тегесе туктагач, аны кочаклап үпте һәм Фәезгә баш какты.— Бу — минем бүгенге көнем. Иртәгә аның булмавы ихтимал.

Кыз белән тагын нәрсәләрдер сөйләшеп, көлешә-көлешә мәйдан уртасына кереп киттеләр. Фәез исә, нишләргә белмичә, аптырады да калды.

Караса, бая гына яшелләнеп шаулаган киңлек, еракларда зәңгәрләнеп балкыган гүзәллек хәзер соры ялангачлыкка әйләнде кебек. Мәхәббәт? Ул да юк. Күпме вакытлар хыялланып табылган бәхет — башка кешенеке... Дөньяның мәгънәсен шулай да табарга мөмкиндер шикелле әле. Матурлык бармы анда? Димәк, мәхәббәт тә бар! Кама исемле кыз да бар һәм Фәез аның өчен — ялгыш кына, соңлабрак очрашкан өчен генә бүтән белән дуслашып өлгергән (ләкин Фәез сизә — яратып өлгермәгән!) бәхете өчен көрәшәчәк. Көрәшәчәк һәм җиңәчәк — әкиятне бар дип исбат итәчәк!

Ышаныч белән бергә туып, яңа көн балкый.

Фәез, койрыкчы егетне бар дип белмичә, Камиләгә елмая һәм хәтта шаян сүз куша...

Палатка янынннан китеп, яңадан урап килгәндә, аның кулында ике сюрприз иде. Камилә янына килде дә тагын елмайды. Ләкин кыз:

— Әләй, елан! — дип кычкырып җибәрмәсенме.

Фәез каушавын җиңәргә тиеш иде.

— Елан түгел, тузбаш. Моныcы — кәлтә.

Егет, егетлеген итеп, тузбашны муенына куеп, ә кәлтәне куенына салып күрсәтте дә кире алды.

— Тапканнар шаярыр нәрсә,— дип зарланды койрыкчы егет.— Камиләнең Фәезгә сокланып каравын ошатмыйча.

Билгеле инде, ничек ошатсын!

Эшнең кая барасын сизгән Борис Фәезгә күз кысты:

— Леди һәм джентельменнар, хәзер кызык ясыйбыз.— Шулай дип, ул бүтән палаталар янына китте.

Фәез исә ирешелгән уңыш белән чикләнмичә, тузбашны бер кулы, кәлтәне икенче кулы белән кызга сузды:

— Табигатьнең ике могҗизасы. Икесен дә сезгә бүләк итәм.

Кыз, алырга да, алмаска да белмичә, кызарып тик тора. Ә койрыкчы — чырайсыз:

— Һа! Оригиналь бүләк — елан! Сез генә сәләтледер мондыйга.

Усаллыкка китсә, Фәез дә югалып кала торганнардан түгел:

— Еланга мохтаҗлык юк шикелле монда... менә дигән изге җан иясе күңелгә үрмәли...

— Фәез, сез...

Кыз бүтән сүз таба алмыйча интеккәндә, рәхмәт төшкере, Борис килеп житте. Буш консерва савытына хәмер салган. Көлә-көлә шуның белән тузбашны һәм кәлтәне сыйларга керешге. Рәван җаннар башта эчми аптыраса да, соңыннан авыз иттеләр һәм тора-бара кешеләрдән курыкмый торганга әйләнделәр. Дустының бу эшен ошатып бетермәсә дә, Фәез, дусты аңа ярдәмгә килгәнгә, сүз әйтмәде. Шаяру тукталгач, «бүләкләрне» тотып килгән җирләренә яңадан илтеп куйды.

Уен-көлке дәвам итте.

Аннары су керергә килделәр.

Башкалар сөзәк яр читендә чыпырдаганда, Фәез кичә күзләп куйган яр башына менде дә шуннан баштүбән очты. Күпмедер секундлар эчендә ул Камиләнең куркып кычкырганын ишетмичә калмады.

«Хәзергә шунысы житеп торыр»,— дип уйлады ул. Ә калганын ул Вакыт дигән кодрәткә тапшырырга булды.

*Дәвамы бар*

## Нури Арсланов

# Партияле кеше дилəр мине

...Кыләчәккә без зур стажлы
Фиркасызлар булып барырбыз.

*Һ. Такташ.*

Партияле диеп алданалар,
Аптырыйлар әйтсәм киресен:
— Ничек инде шушы башын белән
Беспартийный булып йөрисен?!

— Зур стажлы фиркасыз,— дим көлеп,
Төзәткәндәй дуслар ялгышын.
Ялгышмы соң?!
Мин һәрвакыт солдат,
Ил язмышы — минем язмышым.

Юк, ал да гөл түгел миңа дөнья,
Бик күп җанда сыкрар яралар...
Яраларын юлда бәйли-бәйли
Замандашлар яуга баралар.

Читтә каламыни Ил җанлы ир —
Шагыйрь урыны — алгы сафларда!
Алгы сафта барган кешеләрнең
Рухы төшми авыр чакларда.

Стенага китереп терәсәләр,
Коммунистны, диеп, атабыз! —
Юк, әйталмас идем мин киресен:
Бу инде, дип, сезнең хатагыз.

Юк, ялвармас совет шагыйре һич
Мескен булып дошман алдында!
«Зур стажлы» аның Такташлары,
Үлемнәрне җиңгән батырлары —
Җәлилләре булган чагында!

Партияле кеше дилəр мине.
Дөрес! — формаль карамаганда —
Партиясез шагыйрь буламыни
Бөек көрәш барган заманда!

1971

# Карпат итәгендә

Яулар булып килгән борынгыда
Бу җирләргә ханнар.
Бабаларым ат чаптырган монда,
Кылыч айкаганнар.

Онытырга күптән вакыт, юкса,
Онытылмаган, көфер...
Җуелмыйдыр, ахры, утка-суга
Тарих баскан мөһер.

Тик бит инде башка тарих туды:
Яңа, якты, яхшы!
Замандашлар, кашки аңа тугры,
Лаек булалсакчы...

Ә без бүки ясап «бабай»лардан,
Куркытабыз кайчак...
Безгә, ахры, сабый балалардан
Таман үрнәк алсак:

Әнә урам буйлап уза шаулап
Карпат балалары.
Казандагы кебек калам карап,
Сөеп мин аларны.

Бу кадәрле булыр икән, бәгърем,
Бала дисәң бала:
Ул уйлап та бирми,— князьләреңь,
Ханнарың ни аңа!

Кай илдә дә бер-берсенә охшаш
Бу ачык, саф җаннар:
Аларга тик булсын һава, кояш,
Урман, сулар, таулар...

«Искеләргә тимә — исең китәр!»
Дигән борынгылар.
Борынгының гариплеген бикәр
Кузгатмасын уллар.

Әле күптән түгел йөрмәдекме
Тездән канга батып,
Сөякләрдән таулар өймәдекме,
Карпатлардан артып?!.

Сугышлардан дөнья сыкрый-сызлый,
Авыр яралары...
Үстерергә иде бер дә бозмый
Газиз балаларны.

1971

## Гади бер фәлсәфә

«...Тәндә жаным ничә көн миһман икәнлер,
белмәдем...»

*һ. Салихов.*

Никадәрле олы булып кыланса да,
Гомер буе сабыйлыкта яши инсан!
Мин яшьләргә карыйм — сәер нарасыйлар —
Алар да картая инде, миңа ни сан!..

Килеп житәр бер көн котылгысыз сәгать,
Шаккатырмак булыр үлем дигән сантый;
Исем китмәс, ләкин,— алдан белеп торам,
Холкым белән гафилләрдән түгел андый.

Нигә кеше елап туа икән жиргә,
Алдан белеп тугангамы ни көткәнен:
Әлмисактан бирле ата-бабалары
Ирек теләп, хаклык эзләп интеккәнен?

Жанварлардан акыл белән генә өстен
Бер карасаң кеше дигән гажәп мәхлук.
Белмәгәннәр генә шушы хакыйкатьне
Үзеннән бик риза, үз-үзенә мәхбүп.

Белә торып мәңгелек юклыгын жирдә,
Рух төшерми кешелекле горур инсан.
Аз гомердә күп тәрәккый тели күңеле,
Шуңа жаны йолдызларга омтылучан.

1970

## Байрон рухы

Быел Лондонда, хәзерге грек хунтасы вәкилләре, Греция бәйсезлегенең йөз илле еллыгы уңае белән, Байрон каберенә венок куярга килаләр. Байрон булып киенгән бер инглиз алар каршына чыгып баса да:
— Бу — хөрмәтләү түгел, хурлау. Байрон рухы тираннардан берни дә кабул итмәячәк! — дип белдерә...

*Газеталардан.*

Грек ирке өчен һәлак булган
Бөек шагыйрь Байрон гүренә
Грек халкы азатлыгын буган
Кара полковниклар үрелә.

Бәйсезлеккә гасыр ярым, диеп,
Килгән алар венок куярга:
Шагыйрь исеме белән сату итеп.
Яхшы атлы булып уйнарга.

Гайд-паркта шуңа шомлы тынлык,
Инглизлар чытык чырайлы...
Көтмәгәндә Байрон үзе торып,
Гадәтенчә, җәнҗал чыгарды:

— Бу тантана һич тә минем рухка
Хөрмәт түгел, мыскыл бар монда!
Каушап калды башта кара хунта,
Ташландылар аннан «Байронга».

Тотарсың, бар, үлемсезлек рухын! —
Тыныч ятмый шагыйрь гүрдә дә:
Ул ирекле Элладаның туын[1]
Җәлладларга каршы күтәрә!

1971

## Язгы тамчылар

Кыш патшаны җиңеп килгән атлылар
Атларына бәллүр япма яптылар.
Түбәләргә эленделәр камчылар,
Камчылардан тамып тора тамчылар:
Тып-тып, там-там-там...

Юеш карны казый маллар җим эзләп,—
Җир теләге — колыннарын имезмәк,—
Күтәрелә сөттәй ап-ак томаннар.
Ә тамчылар тамарга бик комарлар:
Тып-тып, там-там-там...

Көзгеләрен суга салып сылулар
Кияүләре кем буласын юрыйлар.
Көзгеләрдә умырзая чагыла...
Күз яшедәй тама тамчылар гына:
Тып-тып, там-там-там...

Атлы яулар ни гомерләр көрәштә,—
Күтәрделәр байрак итеп кояшны.
Хуш исле җир җылынганнан-җылына —
Искитәрлек тамчыларның җырына:
Тып-тып, там-там-там...

1971

---

[1] Ту — байрак (төркичә).

## Кобзарь янында

Тукай кебек, син «көлмәксез» тудың,—
Күралмадың дөнья рәхәтен,
Колдан рәссам булдың, шагыйрь булдың,
Җырлап үлдең халкың хәсрәтен...

Бала чакта безнең Апушны да
Сине саткан кебек саттылар...
Саталмыйча тик кобзарьны гына
Олактырдылар — читкә аттылар:

Син атылган йолдыз булып төштең
Моңсу казакъ далаларына...
Кара язмыш — кара таштан үстең
Һәйкәл булып!
Олы җаныңа
Мин сокланам! Карыйм уйчан сынга,
Килгән саен көн дә «Каштан»га [1],
Күпме уйлар, күпме серләр, моңнар
Алып була икән таштан да!

Ни уйлыйсың:— Украинам! — димсең?
Син куеныңда азат җиреңнең,
Иң беренче син богавын чиштең,
Тозакларын аның җимердең.

— Халкым! — дидең, Тукай кебек син дә,
Шагыйрь итте сезне халкыгыз.
Үлем белми халык!
Шуңа җирдә
Мәңгелеккә сез дә калдыгыз.

1971

## Табигать белән тартышканда

Бөтен тәнем авырыксынып
тора оеп,
Шуңа бугай чырай сытык,
күңел боек...

Табигать, бу — үзеңне бел-
дергәнеңме:
— Мин көчле! — дип, кешедән бер
көлгәнеңме?

Бер биреп, бер алуларга
өйрәнгән син,—
Алып гүргә салуларга
көйләнгән син...

Чиреңне дә, шулай булгач,
алырсың бер:
Минем белән уйный торгач
арырсың бер!

1971

---

[1] «Каштан» — Трусковецтагы санаторий клубы. Тарас Шевченко һәйкәле шуның алдында урнаштырылган.

## Мин бик риза

Баштук, ахры, күзгә чалындым мин.
— Яшь,— диделәр,— яңа! — диделәр...
Ә картайгач:— Бу яшәгән саен
Гел яшәрә бара! — диделәр.

Таныдылар чынлап илле яшьтә,
Зурладылар фәкать алтмышта...
Берәүләргә ул да насыйп түгел,
Мин бик риза мондый язмышка.

Фирдәүсиләр, Гомәр Хәйямнар да,
Мирас итеп гаҗәп моңнарын,
Хикмәт куып, акыл утырганда
Язган, диләр, гүзәл җырларын.

Пәйгамбәрләр хәтта шулай икән,
Мин фәкыйрьгә нихәл итәргә? —
Бит җырчыга шагыйрь булыр өчен
Сират күпере кирәк үтәргә!

1970

## Илһамга

Нишлисең син, илһам дигән тинтәк,
Мине үртәп шулай итәмсең:
Шаян килен кебек алларымнан
Итәк кенә болгап үтәсең?!

Дәртем дә бар әле, көчем дә бар
Билләреңнән кысып кочарлык.
Җилкән итеп җиләс итәкләрең,
Дулкыннарда тибрәр, очарлык.

Форсатыңны җилгә җибәрмә син —
Кала күрмә кысыр, тол булып.
Әйдә чыңла, чыңла бар тавышыңа,
Җырларыма алтын кыл булып.

1970

## Мэрцишор

Тартыша торгач яз инде
Җиңеп чыккан кышны —
Молдаван кызлары мине
Бер почмакка кысты:

Мэрцишорны — яз билгесен[1]
Миңа тага берсе,
Аңкытып рәхәт яз исен,
Шомырттай күзлесе.

«Сезнең шигырьләргә дә мул
Уныш бирсен, ди, яз!»
Изге теләк була кабул,
Нури, син яз да яз!

Тага торгач яз бөтиен,
Мавыгып эше белән,
Үрелде дә миңа... җебен
Өзде теше белән.

Ымсындырдың, җепне түгел,
Үзәгемне өзден!
Әй сылу, талпынды күңел,—
Син яз иден үзен!..

1971

## Минем балдыз

Көнлисезме, кем дисезме,
Янымдагы бу чибәр кыз?
Минем балдыз!

Үземнең дә күзем төшә,
Тик кыланмыйм гына сансыз:
Ул бит балдыз...

Җизнәкәй, дип кенә тора!..
Ни әйтсәң дә бик куштан кыз
Минем балдыз.

Чибәрлеккә апасыннан
Биш кат артык, һич ялгансыз,
Хәйран балдыз!

Кайчак куллар озынайса:
Чалт! яңакка — әдәпле кыз
Минем балдыз.

Үзе тыйнак, үзе уйнак,
Минә диган минем балдыз —
Чукынган кыз!

1970

[1] Ефәк җепнең ике очында да нәни йолдызлар беркетелгән бу билгене молдаваннар 1 мартта күкрәкләренә тагышалар, йортка, бакчаларга эләләр — шулай яздан уңыш телиләр икән.

# Хафиз газәлләре

Әгәр күңлемне хуш итсә Ширазның бу гүзәл яры,
Аның бер миңенә бирәм Сәмәрканд вә Бохараны.

Сал, әй сакьи, шәрабыңны! Син ожмахта да күрмәссең
Ширазның Рукнабадын[1] һәм гаҗәп матур Мусалланы[2].

Бетерде, урлады сабрымны шат, куштан, чая кызлар,
Төрекләр урлагандай хан таҗын, бирмичә Ягъманы[3].

Минем бу гыйшкыма андый сылу буламы соң мохтаҗ?
Чибәргә һич кирәкми төрле иннек — йөз буяулары!

Йосыфтагы матурлыкның анык белдем көчен шуннан:
Оят пәрдәсен ачкан калдырып шәрә Зөләйханы.

Ачы сүзләр белән мине орыш — тиргә, булырмын шат,
Ишетсәм бал кебек татлы авазлы яр — Шәкәрханны[4].

Сүземне тыңла, дустым: чал хәкимнең хак киңәшләре
Җитәкләр тугры юлга яшь, бәхетле, дәртле җаннарны.

Кәеф кыл, җырла, бу хәят серен эзләп маташма син:
Бит ул бар дип тә белми хәтта хикмәтләр вә аңнарны!

Газәл яздың, күңелле тыңлавы, кат-кат укы, Хафиз,
Күгендә балкытыр тәңре сиңа җидегән вә айларны!

# Гомәр Хәйям робагыйлары

Мәзәксез һәм мәйсез тормыш нигә хаҗәт!
Курайсыз да моңсыз тормыш нигә хаҗәт!

Көн күзендә булган һәрни аз гомерле:
Кәеф-сафа кылсаң хәтта тормыш та шәп.

«Без булмабыз!» — Ә дөньяның исе китмәс!
«Югалыр эз!» — Ә дөньяның исе китмәс!

Без юк чакта да ул булган, мәңге булыр!
Бер ваемсыз яши бирер — исе китмәс.

---

[1] [2] Рукнабад елгасы буендагы гүзәл Мусалла бакчалыгы — Хафизның яраткан урыны булган. Аның кабере дә шунда.

[3] Чик буендагы Ягъма шәһәренә иранлы хан килеп хөкем йөртмәкче була. Ләкин төркиләр, аның таҗын урлап, ханлыктан мәхрүм итәләр.

[4] Шәкәрхан — Хафизның сөйгән яры.

Корьән шәриф сүзләренең күбесе хак:
Ләкин шул ук хикмәтләргә өнди арак.
Һәр жам безгә ача гажәп тормыш серен,
Күренер төбе — иренең генә тидереп бак.

Шәраб — хәким, сыналган ул хәкимлектә;
Аны эчсәң, юк-бар уйлар хәзер бетә.
Гажәп алхимик ул шәраб дигәннәре:
Гади кургашны да алтын комы итә.

— Нәрсә соң ул жырлар, жамнар, сылу тәннәр! —
Сабыйларның таштәтие — уенчыклар!
— Ә батырлык-ирлек, корбан, гыйбадәтләр! —
Яныл сүнгән учак, көлләр генә — чүп-чар!

«Килер үлем, чабып егар чалгы белән,
Авар жиргә башын иеп үскән үлән...»
Туфрагымнан мәй чүлмәге ясагыз сез;
Мин яңадан терелермен торып гүрдән.

Тормыш — базар. Син аннан дус-тиң эзләмә.
Тормыш — яра. Ана һич тә им эзләмә.
Гел көләч бул үзең, елмай бүтәннәргә,
Тик алардан көләч йөзне син эзләмә.

Син исергән икән — шатлан моңа, Хәйям.
Өзелеп сөйгән икән — шатлан моңа, Хәйям.
Килер үлем — бетәр барлык саташулар!
Бүген исән икән — шатлан шуңа, Хәйям.

Аһ, әгәр дә тынгы булса иде жирдә!
Аһ, әгәр дә тынгы булса иде гүрдә!
Һәйһат! — язгы үлән булып терелсәң дә,
Тапталырсың тагын туфрак белән бергә.

Минем каберем дә нәкъ үзем кебек булыр:
Тирә-якта шәраб исе аңкып торыр.
Якын килсә әгәр берәр юлчы аңа —
Тәмам сәрхуш булып юлын дәвам кылыр.

**Барлас Камалов**

# ЯЛЫКМАСЛАР[1]

ПОВЕСТЬ

## 8



Аккүлдәге Муса Җәлил исемендәге урта мәктәпкә быел гына килеп укыта башлаган Айрат Сәрвәров район культура йортында Казан артистларының «Вөҗданың — хөкемдарың» дигән спектаклен карагач, педагогия институтында укыган чагындагы гадәте буенча, тамаша хакында үзенең фикерләрен язды һәм район газетасы редакциясенә китерде. Институтның өлкән курсларында укыганда яшьләр газетасына еш язышa иде ул. Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театрының спектакльләре турында язганы булды, Академия театрының яшь башкаручылары турында портрет-очерклар бастырды. Шуна күрә район газетасы редакциясенә Айрат икеләнмичә килде. Редакциянең җаваплы секретаре — мәһабәт гәүдәле, мөлаем йөзле, телгә үткен Дәмин Сөләйманов аны кочак җәеп дигәндәй каршылады.

— Төкле аягың белән, яңа автор! — диде ул, күптәнге танышына эндәшкәндәй.— Хуш киләсез, Айрат иптәш. Түрдән узыгыз. Рецензиягезне хәзер үк, шушы минутта укыйбыз, фикерләшәбез дә — наборга! Труппаның хезмәте хакында эндәшми булмас, ничек итәргә соң дип утыра идем әле. Күктән көткәнне җирдән бирде булып чыга түгелме соң? Утырыгыз...

Азактан Дәмин Айратны редактор кабинетына алып керде. Гомәр Муллин да яңа хәбәрчене ачык чырай белән кабул итте. Танышып киттеләр. Гәп куертып алдылар. Сүз йомгагы сүтелә торгач, әңгәмә акрынлап кичәге спектакльгә барып ялганды. Шунда Дәмин Айратның шул постановка турында язып китергәнлеген әйтте.

Сәрвәровның гаҗәбенә каршы, Гомәр Муллинның тулы йөзендәге балку өреп очыргандай юкка чыкты. Әллә каян шыксыз җил исеп, тәнен каз тәне бөрчекләре каплады диярсең. Таза гәүдәсен авыр гына кузгатып, редактор креслосыннан торды һәм өстәл аша Айрат кулындагы кәгазьләргә үрелде.

---

[1] Дәвамы. Башы 8 санда.

— Бирегез әле, карап карыйк. Нинләр яздыгыз икән? — диде ул, карлыга төшкән тавыш белән.— Мактамагансыздыр дип ышанам...

Айрат кәгазьләрне аңа бирде, ниндирәк җавап кайтарыйм икән дип аптырый калды. Аннары гына:

— Спектакльне ничек аңласам, ничек кабул итсәм, шулай яздым инде,— диде һәм Муллинның укуын көтә башлады. Дәмин аның янына килеп утырды һәм кызарып киткәнен сизде. Җаваплы секретарьга бик җайсыз, үтә читен иде. Әйтерсең лә, ул яна танышын кычыткан арасына төртеп екты. Интеллектуаль кеше өчен Муллинның чапмаган да, юнмаган да гадәтләре бәрәнгене шикәр комы сибеп ашаган тәэсир калдырырлык иде шул. «Нигә дип турыдан-туры аның янына алып кердем соң әле мин бу иптәшне?!» — дип үз-үзен аяусыз тиргәп утырды ул бу минутларда. Аннары Гомәр Муллинның ташбакадай кыймылдавына чыдый алмыйча, ниндидер сәбәп табып, чыгып торасы итте.

Ниһаять, редактор кәгазьдән башын күтәрде, тик сүз әйтергә авыз ачмады. Киресенчә, аның калын иреннәре бөрешеп, очлаеп калды. Гүя ул сызгырып җибәрергә җыена иде.

— М-м... да-а!..— Беравыктан Муллин шулай мөгрәп алды.— Тудырып үстергән әниләргә дә, безгә рухи канатлар куеп чыныктырган, олы бәхет биргән Ватан-анага да ихтирам хисе, илсөярлек тәрбияли торган спектакль дисез инде, ә, иптәш Сәрвәров?

— Шулай дим, иптәш редактор. Сез килешмисезме әллә?

Муллин Айрат соравына игътибар итмәде.

— Сез коммунистмы, иптәш Сәрвәров?

— Әйе. Тик партия члены булуымның монда ни катнашы бар?

Гомәр Муллин Айратның эндәшүен янә колагына элмәде.

— Кайсы факультетны бетердегез, иптәш Сәрвәров?

— Тарих-филология факультетын, иптәш Муллин.— Редактор тәпченүеннән Айратта ризасызлык туа башлады.— Факультетның да бу очракта әһәмияте юктыр дип исәплим...

Муллин аңгәмәдәшен ишетми түгел, ишетә икән. Үзенә кирәккәч, Айратның сүзенә ялгап ук китте.

— Газета редакциясе өчен барысы да әһәмиятле, иптәш Сәрвәров, коммунист булуыгыз да, белгечлегегез дә... Сез ничек уйлыйсыз, спектакльдәге теге шома егет безнең тормышта шулай иркенләп йөри аламы? Шулай күкрәк сугып, демагогия белән дә шөгыльләнә аламы? Дөреслекме бу? Күпертелмәгәнме? Безнең тормышка куләгә төшерү түгелме?

Айрат редактор өстәле буена якынрак күчеп утырды.

— Мин язганнардан бу сорауларга җавап таба алмадыгызмы? Телдән аңлатып карыйм.— Айрат, дәрес башларга җыенган сыман, эчке туплану кичерде һәм сөйли башлады.— Мәгълүм булганча, һәр драманың нигезендә көрәш ята. Каршылыклар, характерлар көрәше. Сез әйткән «шома егет» Мортаза — намуслы кешеләр яшәгән җирлектә тамыр җибәрергә өлгергән чүп үлән. Андыйлар бар әле, очрый тора.

...«Вөҗданың — хөкемдарың» драмасында сүз ире һәм өлкән улы Бөек Ватан сугышында һәлак булган авыл карчыгы турында бара. Гомер буе гадел хезмәт белән көн күргән, һәрвакыт хаклыкка, дөреслеккә омтылып яшәгән Илназ әби җиде бала үстергән. Алар һәммәсе аякка басканнар, кеше булганнар. Берсе — токарь, икенчесе — инженер, өченчесе — хәрби хезмәткәр, чик сакчысы. Дүртенчесе — әлегә студент... Ананың күңеле бер генә нәрсәгә рәнҗи: картының васыятен җиренә җиткерә алмаган, балалары җиргә берекмәгәннәр.

Балалары аның килүенә шат, Илназ әбине күтәреп кенә алмыйлар. Ниятләре — өрмәгән җиргә дә утыртмаска. Әмма йөткеренгәләп торучы әбидән шикләнүчеләр дә, җирәнүчеләр дә табыла. Әниләренең уртанчы улы Мортазага барасы, анда беравык яшисе, җаен китереп кенә аны авылга кайтырга димлисе килә.

Әмма Илназ әбинең өметләре сабын куыгы шартлагандай юкка чыга. Мортазасы да, килене дә аңардан каһкаһәләп көләләр генә. Ана, аларга бәддога укып, өлкән улларына китеп бара...

Сәрвәровны беравык тыңлагач, редактор агай һавалы гына сорап куйды:

— Шулай да, кем, иптәш Айрат, спектакльдәге хәлләр чамасыз арттырылган дип санамыйсызмы? Артыгы күпертелмәгәнме?

— Гипербола түгел, һәрхәлдә. Сезнең термин белән әйткәндә, «күпертелү» бар, һәм ул сәнгать әсәрендә котылгысыз. Автор өчен тормыш материалы — иксез-чиксез киң дөнья. Әйтик, менә кояш ди. Ул яктырта, җылыта. Ләкин аның төп сыйфатын, аның ут икәнен раслар өчен, таркау нурларын ике ягы да кабарынкы линза аша бер җиргә җыярга кирәк. Шул чагында күз чагылдырырлык кечкенә бер нокта хасил була һәм ул төти башлый. Конкрет образның да асылын ачар өчен күп кенә сыйфатларны тыгыз бер бәйләмгә туплау кирәк, иптәш Муллин.

— Теләсәгез ни диегез,— Гомәр Муллин Айратка яны белән борылып утырды да өстәл тартмасыннан «Беломор» пачкасы чыгарды,— ул шома егет — гарип тип, безнең сәхнәдә яшәргә аның хакы юктыр дип беләм.— Редактор тәмәкесен яндырды һәм авызыннан бер дә алмас булды, тешләре белән кыскан килеш, суырды да суырды. Бу минутта ул авызына чүпрәк имезлек каптырган баланы хәтерләтә төсле иде. Ниһаять, папирос шүресе буйлап саркый-саркый юеш килеп тигәч, папирос чыжлап сүнде. Лычкылдаган төпчек көл савытына сылап куелды.— Гарип тип безнең әдәбият героемыни инде, я, я, әйтегез!

— Иптәш Муллин! — Айрат үзенең кечкенә мәкаләсен яклауны оныткан иде инде. Аны басмасалар да, бернинди зыян булмаячак. Автор да һичнәрсә югалтмый, газета да, укучылар да. Фәкать сүз принципиаль төс алганга күрә, Сәрвәров җиң сызганырга уйлады.— Медицина кеше организмындагы яки психикасындагы аномалияләрне ни өчен өйрәнә? Организмдагы нормаль процессларга карата файдалы нәтиҗәләргә килер өчен бит. Шулаймы? Язучы да тискәре типларны һәм күренешләрне сурәтләп, аларны идея-художество ягыннан анализлап, яхшылык үрентеләренә үсеп китәргә булыша. Аннары шунысын да истән чыгармыйк, әсәрдәге «шома егет»нең юлын кисүче унай геройлар да аз түгел.

— Шулай да...— Муллин җәһәт кенә с[/]з таба алмады.— Мин әйткәннәр ялгыз бер кеше фикере генә түгел, иптәш Сәрвәров.

Шулай дигәч, Айрат артыгын терәлеп торырга теләмәде.

— Язманы кире бирегез! — дип кырыс кына сорыйсы итте. Ә Гомәр Муллин язманы кире кайтарырга ашыкмады.

— Иптәш Баязитов белән сөйләшеп алыйк әле,— диде һәм телефон номерын җыйды. Идеология эшләре буенча секретарь Баязитов җавап бирмәгәч, агитация-пропаганда бүлегеннән белеште. Секретарь «Таң» колхозына киткән иде.

— Минем райкомга менәсем бар. Шунда бәлки хәл итеп тә төшермен. Бүгенгә калып торсын,— диде редактор.

Җылы гына күрешкән кешеләр салкын гына саубуллаштылар. ...Райкомда Муллин туп-туры Хафиз Кадергулов янына керде. Беренче секретарь телефоннан сөйләшә иде. Кул изәп, Муллинны түргә чакырды, ишарә белән урын тәкъдим итте. Сүзен тәмамлагач, Гомәр белән килеп күреште.

— Сиңа шалтыратыйм дип тора идем, Гомәр абый.— Хафиз өстәлендәге кәгазьләр арасыннан бер битне эзләде.— Күптән түгел генә «Гигант» белән сөйләштем. Кадыйр Исламов белән. Быел ашлык сату планын ике күләмгә җиткерергә сөйләштек, ди. Шулай итеп, алар бишьеллыкны дүрт елда үтәп куярга җыеналар. Фураж фондына зыян китермибез, хуҗалык кирәк-ярагына кала. Чәчүлек тулысынча салынды, ди. «Гигант» шулай ди. Кечерәк колхозлардан берәрсе түгел. Аның бер

планы да... Менә шуннан кеше укырлык, укып рухланырлык итеп куш бит бирәсе иде. Ашлык фронты геройларын күрсәтеп. Рәсемнәре белән. Кирәк икән, шигырьләр, җырлар белән...

— Эшлибез, иптәш Кадергулов. Була. Егетләрне бүген үк командировать итәм.

— Тик, зинһар, озакка сузмагыз, Гомәр абый. Район планны арттырып үтәде. Әмма дәүләткә сатарлык ашлыгыбыз тагын да бар әле. Спортчылар «икенче тын алу» диләр бугай. Безгә дә тагын бер җилкенеп алырга кирәк. «Гигант»тан биреләчәк материал бүтәннәрне дә дәртләндереп җибәрсен иде...

— Була, иптәш Кадергулов. Минем дә бер киңәшем бар иде.

— Рәхим ит.

— Иптәш Баязитов «Таң»га киткән икән, борчымаган да булыр идек. Безгә менә бер рецензия китерделәр. Редакция өчен яңа автор, быел гына Муса Җәлил исемендәге мәктәпкә килгән...

— Сәрвәровмы әллә?

Гомәр Муллин аптырап калды.

— Беләсезмени? — диде ул, гаҗәпләнеп.

— Беләм азрак. Коммунист иптәш бит. Учетка басканда сөйләштек. Аңа кадәр дә таный идем. (Хафиз Айрат хатынының этисе Юлдаш агайның сугышта үзенә катлаулы операция ясап, гомерен саклап калганын әйтеп тормады, билгеле.)

— Менә шул, Айдармы әле?

— Айрат.

— Ә-ә, әйе, әйе, Айрат Сәрвәров кичәге спектакльгә карата фикерен язган. Мактый, беләсезме?

Хафиз редактор кулыннан кәгазь битләрен алды һәм Гомәрдән кырт кисеп сорап куйды:

— Син, Гомәр абый, яманлап язар идеңме?

Муллин кәлтә сыман боргалана башлады.

— Андый да шома егетне сәхнәдә күрсәтергә ничек рөхсәт иткәннәр?! дигән кебегрәк фикерем бар минем. Укып чыгыгыз әле, иптәш Кадергулов, укып чыгыгыз.

Хафиз Айрат язганнарны игътибар белән укыды һәм авыз ачып көтеп торган Муллинга:

— Бик объектив һәм принципиаль язылган. Спектакльдәге житенкерәмәгән урыннарны да дөрес күрсәткән, ләкин моны орды-бәрде килмичә, такт белән эшләгән. Мин спектакльне карадым. Артистлар безнең районның үз колхозында булачаклар әле. Тамашачыга ориентир булыр...

— Басып чыгарыйкмы, иптәш Кадергулов?

Хафиз көлеп җибәрде. Рәхәтләнеп, эчкерсез итеп көлде.

— Редактор син бит, Гомәр абый. Кайчак сәер сораулар бирәсең, честное слово. Син редактор. Моны син хәл итәргә тиешсең.

— Райком әйткәч, басабыз...— Муллинның зур гәүдәсенә җан керде.— Басабыз...

— Син үзең дә райком члены, Гомәр абый. Газетада күптән эшлисең. Местәкыйль фикерләүдән курыкмаска иде, дигәнем.

Гомәр булдыра алганча ягымлы елмайды.

— Киңәшле туй таркалмый, диләр ич, иптәш Кадергулов. Киттем, сау булып торыгыз.

— Күп киңәшә торгач, кайчак туй булмый да кала ул, Гомәр абый. Исән бул!..

Редакциягә кайтып житүгә, Муллин Айратны эзләп мәктәпкә шалтыратты. Үзенә калса, авторны сөендермәкче иде. Сәрвәровны туры китерә алмады.

Ә Хафиз Гомәр Муллинның үз күләгәсеннән үзе шыгаеп йөрүе хакында ничәнче мәртәбә инде баш вата иде. Кайчандыр яраган, атнасына

бер тапкыр чыккан ике битле газетага күбрәк үзәк һәм республика газеталарыннан хәбәр күчереп баскан чакта әллә ни кыюлык, мөстәкыйльлек кирәкмәгән. Үз материалы дигәне бюро карарлары һәм сводкалар булган. Ә хәзер авыр бу агайга, авыр...

Ялгызы калса, аны Владислав мәсьәләсе борчый башлый. Теш сызлавы төсле бимазалаган хәлдә, аның теләсә нинди уйларын бүлеп, Одессадан килгән хат юллары күз алдына тезелә. Хафиз ул көтелмәгән сәлам хатының серенә төшенә алмый әле. Владиславка ни дип җавап бирергә дә белми. Әллә иң әүвәле әнисе Еленага хат язып салыргамы? Елена, Лена, Леночка... Яшьлек дусты Елена...

Владислав түземсезлек белән хат көтәдер, бәлки...

«...Мөмкин булса, тиз арада хәбәр бирүегезне үтенәм, чөнки мондый билгесезлек эчендә яшәүнең нинди газап икәнен Сез үзегез дә күз алдына китерә аласыз. Мәскәү газетасында Сезнең хакта басылган очерктан күренгәнчә, үлемегез турындагы ялгыш хәбәр әниегезне рәхимсез тетрәткән. Минем әниемнең дә ул хәбәрне шулай ук кичергәненә шигем юк,— дип язган Владислав.— Хәзер инде бу хәбәрне укыгач, әни яңадан чиксез борчылыр, дулкынланыр, елар. Августта ул Ригага ял итәргә китәргә тиеш иде. Шунда вакытта газетаны укымый калуы бик мөмкин. Сезгә бу хатны язганда, мин аңа да хәбәр иттем.

Әни Одесса өлкәсендә, район больницасында баш врач булып эшли. Менә аның адресы...

Үзем турында берничә сүз: Одессада диңгез училищесын тәмамладым. Хәзер чит илләргә йөзүче суднода өченче штурман булып эшлим. Сезнең турыда язылган газетаны Вьетнам Демократик Республикасына азык-төлек һәм медикаментлар илтеп кайткач бирделәр.

Минем бу юлларны үземә зур ышаныч белән язуыма сәбәп бер генә: очеркта исем-фамилиягез, туган елыгыз бик туры килә. Татарстанның Аккүл районында туган булуыгыз, педучилище тәмамлаган укытучы икәнлегегез, ике абыегызның фронтта һәлак булуы — барысы-барысы Сезнең минем әтием икәнлекне раслый. Әни миңа боларның һәммәсен бәйнә-бәйнә сөйли торган иде.

Әгәр мин ялгышкан булып чыксам да (дөньяда адашлар һәм охшаш язмышлы кешеләрнең булуы бик мөмкин), җавап бирми калмассыз дип ышанам. Аңлый күрегез: минем өчен бу бик тә мөһим. Түземсезлек белән җавап көтеп калам...»

## 9

Хафиз Елена белән тәүге очрашуын хәтерләде.

...Кышкы суык көн. Февраль салкыны. Өстән яумаса да, җәяүле буран юлга сай гына көрт сала. Хафиз ашыга, караңгы капканчы кайтып житәргә ниятли, тик кырык чакрым ара узганлыгы бик сиздерә, көрткә килеп кергән саен ул артка чигеп киткәндәй була. Аның өстендә кыскарып калган бишмәт, билен брезент билбау белән буган. Бүрек колакларын төшереп бәйләгән. Колакчынны энҗе бөртекләредәй елтыраган бәс сарган. Аягында ике кат йон оекбаш өстеннән киеп җибәргән чабата. Аркасында арыш капчыгыннан ясап аскан биштәр. Капчык сәлпәрәеп кайта, чөнки шып-шыр диярлек буш. Анда төп салган киез итек һәм бер-ике кисәк каткан кер — студентның әнисенә юарга алып кайта торган күлмәк-штаны. Киез итекне Хафиз юлда кими. Беренчедән, аны кигәч атларга авыр, адым үрчеми, тагын да ардыра. Икенчедән, Тәтеш белән Гөл-Төркем арасын киеп узсаң, киез итекләр «авыз ачачак», аннары кешелеккә дә киярга калмый дигән сүз.

Хафизның кызык бер гадәте бар: үзеннән алда тәпиләүче кеше күрдеме, ул аны куып житәргә тырыша. Сүзләре килешеп китсә, аның белән бергә атлый (алай юл кыскарак тоела), берәр төртмеш бәндәгә тап булса, аны тиз-тиз узып китә.

Түбән Агачбашы белән Гөл-Төркем арасында Хафиз ул көнне куып житкән кеше яшь бер кыз иде. Аның өстендә кибет пальтосы, аягында каты итеп баскан фабрика итеге. Башында мамык жептән бәйләгән юка шәл. Шәл астыннан арыш саламыдай аксыл-сары чәчләре чыгып тора. Аларга бәс кунган. Хәтта керфекләре дә бәстән агарышып калганнар. Кызның кулындагы бияләе дә кибетнеке, трикотаж. Кулына ул фанер чемодан тоткан. Чемоданы авыр булса кирәк, кыз бер якка янтаебрак атлый.

— Исәнмесез! Кая кайтыш? — диде Хафиз, кызны куып житкәч. Тавышын бик көр итәргә тырышты. Егет кеше арыганын сиздереп тормас бит инде.

— Я не понимаю по-татарски...— дип, кыз сагаеп кына җавап бирде. Аның зәңгәр күзләрендә үзен куып житкән юлаучыдан шикләнү галәмәте чагылып китте. Кичкә кырын басу юлында япа-ялгыз атлаганда ниндиир-ат килеп эндәшмәс...

— Алайса русча сөйләшик,— дип, Хафиз да русчага күчте.— Мин аны ипилек-тозлык булса да чамалыйм...

Юлдаш кызның күңеленә җылы керде. Бик матур, бик килешле итеп елмайды да Гөл-Төркем авылына баруын әйтте. Аккүл детдомыннан икән. Медицина сестралары мәктәбен бетергән, көздән Аккүл больницасында эшләп торган. Хәзер Гөл-Төркемдәге медпунктка эшкә җибәргәннәр.

Кыз студент егеттән исемен дә яшереп тормады. Елена атлы икән. Фамилиясе бик матур — Солнцева. Хафиздан ике яшькә кече булып чыкты.

Елена туп-туры авыл Советына барырга тиешлеген әйтте. Ул бу авылда беркемне дә белми иде.

Хафиз кайта-кайтышка башында исәп йөртеп алды: авыл Советында менә хәзер генә кемне күрә ала инде ул? Ут алмыйча, кичке ашны уздырмыйча, председатель Гакиләнең дә киләсе юк, секретарь кыз күрше авылныкы, анысы кичләрен бөтенләй килми. Гадәттә, андый чакта кәнсәләр тутырып малай-шалай ята. Гакилә апалары килеп, барысын бергә ыжгыртып чыгарганчы алар шунда әвәрә киләләр. Нишләп кенә бетмиләр! Маймыллыкның чигенә житәләр, артлары белән күккә менәләр, ачу да бер килмәгәе. Хәзер авыл Советына барса, Елена шулар өере уртасында тинтерәп утырачак.

Һәммәсен фикереннән кичергәч, Хафиз Еленаны үзләренә чакырды. Кыз, бу тәкъдимгә әченнән бик сөенсә дә, икеләнеп калды. Өйләрендә кемнәр бардыр, юлда очраган ят кешене иярте кайтуга кырын карамаслармы? Дөрес, Елена хужаларны борчымас. Чемоданында ун көнлек карточкасына алган ипие бар. Ярты литрлы банка белән чөгендер повидлосы. Берәр чынаяк кайнар чәй булса, бер почмакка урын салып бирсәләр, шул бик житкән. Ә иртәгә күз күрер. Квартирага да куярлар, урынжирен дә әмәлләшерләр. Кеше райздрав путевкасы белән эшкә килә лә! Ярты елдан бирле авылда ни сестра, ни фельдшер юк диделәр бит...

Хафиз, рус кызының әйле-шәйле торуын аңлап:

— Минем әни өйдә ялгызы гына,— дип юатырга ашыкты.— Берүзе. Әти фронтта. Ике абый бар иде, алар үлеп калдылар. Мин дә айга бер генә кайтып китәм... Быел педучилищены тәмамлыйм.

Алар икәүләшеп кайтып керделәр. Мәликә апа сыерлар фермасыннан (авылда аны МыТыФы дип йөртәләр, товарлыклы-сөтчелек фермасы дигәннәре) кайткан гына. Чусинкәсен дә салмаган, башыннан шәлен дә

чишмәгән. Утын күтәреп кереп, мич үрләтергә генә өлгергән. Ул Хафизны:

— Ай-й, улым, исән-сау кайттыңмы? Бик туңмадыңмы, балакаем? Битеңне өшетмәдеңме? — дип каршылады.— Бу бала кем була, сабакташыңмы? Безнең кеше түгелмени? Әйдә уз, наный, уз, чишен! Юл кайтып зарыккансыз. Уз, түргә уз! Мин мәнә па руски ни знайт шул инде...

Хафиз Еленаның кем икәнен әйтте, таныштырды.

— Безнең авылга килгән яңа духтыр буламыни инде? — диде Мәликәттәй.— Бик яхшы, бик ярый, әүвәл-ахыры хәерле булсын. Яшь бала икән шул әле, бигрәк яшь икән. Ата-анасы бармы, кем баласы ди, кайсы яктан?

Сүз шулай куерып китте. Елена үзенең Украинадан икәнен, балалар йорты белән Аккүлгә килүен, әти-әнисенең һәм туганнарының хәлен бөтенләй белмәвен әйтте.

Сугыш зилзиләсе бәреп кергәч, Еленаны пионерлар лагеренда ял иткән җиреннән алып озатканнар. Монда килгәч, җиденче классны тәмамлаган, аннары шәфкать туташы булырга укыган.

Чәй кайнады, бәрәңге פеште. Икмәк юк иде, өстәлгә көл күмәче килде. Сыерлы көнең — сыйлы көнең дигәндәй, Мәликә апа сөт һәм катык алып керде. Елена чемоданыннан ипиен һәм повидлосын алды.

— Һай, ризыкларына бер үк кагыла күрмәсен. Ни нады, балакаем, ни нады, спасибаның да бульшие, кирәкми, наный, үзеңә бүтән көнне ярап куяр,— дип, Мәликә апа теш-тырнагы белән каршы килгән иде, ләкин Елена ике дә уйламады.

— Әйт әле, Хафиз, алай ярамый ич инде.— Кыз Хафизның тәрҗемә итүен сорады.— Ни бары бергә булсын!

Мич узып, өйгә мамыклы җылы төшкәч, ашап-эчеп, азрак хәл алгач, тагын беравык сөйләшеп утырдылар. Улы кайткан хөрмәткә, уйга да килмәгәндә аның бусагасын атлап узган кунак кыз хакына Мәликә апа куыклы лампасын кабызган иде (бүтән көннәрдә мондый юмартлыкка юл куелмый, чөнки керосинның тамчысы изге су тамчысы кебек кадерлегә әйләнгән чаклар).

Ялгызы гына кайткан булса, Хафиз, әлбәттә, кич буе өйдә чыдап утырмас иде. Кәнсәләргә чыгып керер, ачыла калса, клубка сугылып чыгар, яшьтәшләрен күреп кайтыр иде. Бүген кымшанмады да. Әнисе янында Еленаны ялгыз калдырудан кыенсынды. Берсе русча белми, икенчесе татарча. Бармак белән генә күп серләшә алмассың.

Кышкы юлда кырык чакрымнан артык тәпиләү үзенекен итте. Хафизның күз кабакларына кургашын койгандай булды. Еленаның да алҗыганы күренеп тора иде. Мәликә апаның үзен әйткән дә юк. Көне буе мал-туар арасында кайнаша. Кайтарган азыкны салып, чыгарган суны эчерәсе дә савасы гына түгел бит. Сыерларга саламны ерак басудан, кар күмеп киткән эскертләрдән ташып ашатасы. Иртән йокыдан торганда ул иңнәрен күтәрә алмастай була. Тик зарланып та, назланып ятар җае юк. Сугыш вакыты! Күзеңне тырнап ачасың да янә фермага йөгерәсең. Әвәрәләнә торгач, буыннар языла тагын. Тамырларда кан тизрәк ага башлый. Сызлаулар онытылып тора. Кичен тамак ялгап, җылыга таргач, тәмам бөгеп салган төсле итә. Ястык магнитлап үзенә суыра диярсең!

Кунак кызга урынны түр караватка җәйделәр. Елена ишек төбендәге агач караватта гына йоклармын дип тартынып караган иде, Мәликә апа ике сөйләшергә урын калдырмады.

— Әйт үзенә,— диде ул Хафизга,— безнең татарда кунакка урын түрдән диген. Бер дә тартынмыйча, рәхәтләнеп йокласын. Иленнән-җиреннән төбе-тамыры белән йолкынган бала икән, бәгырькәем...

Хафиз әнисе әйткән соңгы җөмләне тәрҗемә итмәде итүен, әмма,

татарның гомер-гомергә килгән гадәте буенча, кунакның урыны түрдә булырга тиешлеген әйбәтләп аңлатты.

Күп тә үтмәде, өчесе өч җирдә каты йокыга талдылар. Тышта җил көчәйде, күк йөзен болыт каплады һәм кар ява башлады. Төн жылытты, тик таңга каршы күз ачкысыз буран күтәрелде. Иртә торганда, капка төпләренә киртләч-киртләч кар өелгән иде. Хафиз беренче эш итеп кулына көрәк алды.

Мәлимә апа яктырыр-яктырмас чакта ук фермага киткән, шулай да өстәл көйләп, хәзинәдә барын пешереп, ризык өстен каплап китәргә өлгергән иде.

Егет кар көрәп, сыерга, сарыкларга азык салып, абзар-киртә тирәләрен себереп кергәндә, Елена да торып юынган, киенгән иде инде. Хафиз аны бүген бүтәнрәк төсле күрде. Ял итеп, сафланып киткән кыз аңа тагын да мөлаемрак, тагын да сөйкемлерәк тоелды. Егетнең күзе текәлгәне Еленаның калын һәм озын толымнары булды. Кичә алай игътибар итмәгән иде шикелле. Толымнарын баш тирәли ураган идемени соң ул? Хафиз күңеленнән «Алтынчәч!» дип куйды. Шуннан соң бу сүзне русчага тәрҗемә итәргә кереште. «Золотой волос», юк, күплектә кирәк, «Золотые волосы», ә бер генә исем итеп әйткәндә? «Золотоволосая»мы? Әйе! Хафиз Еленага әллә шулай дип эндәшимме, чәй янына шулай дип өндимме дип тә ымсынды, ләкин бу уеннан бик тиз кире чикте. «Ярамас, ошатмавы бар, хәтере калыр, үпкәләр... Кунакчыллыгыннан файдаланып, бу татар малае артыгын әрсезләнә дип уйлар. Кирәкмәс, килешә торган эш булмас».

Хафиз Еленаны авыл Советына илтеп барды, председатель Гакилә апасы белән таныштырды. Күп тә үтмәде, башкарма комитет бүлмәсенә колхоз председателе Һәнүзә апалары да килеп керде. Медпунктны яңадан эшләтә башлауны, медсестраны квартирага урнаштыруны сөйләштеләр. Дөресрәге, баш катырып, озын-озак гәпләшәсе дә, әллә ни четерекле мәсьәләне хәл кыласы да түгел иде. Медицина пункты ялгыз тол хатын Галияттәйнең алты почмаклы өенә урнашкан, бер якны биләп тора. Фельдшер кыз Галияттәй белән бергә яши иде. Хуҗа хатын пунктны үзе ягып җылыта, үзе җыештыра. Шул рәвешле, Елена да Галияттәйдә яшәргә тиеш булды. Җитәкчеләр шундый карарга килделәр.

— Утынны ике-өч көнсез кайтартып житкерә алмабыз,— диде колхоз председателе Һәнүзә.— Кайтаргач, кисәсе-ярасы бар. Мичене тыккач, су сыгып теңкәнә тия әле ул. Өрә-өрә сулышың калмый, башыңа каба... Берәр олау арыш саламы китертик булмаса, юа-җыя торсыннар. Халык бармак бәйләтергә дә тилмереп күпме йөрде, тизрәк ачкан хәерле, Гакилә...

Бу хәтлесен, самоварга шакмак ваклагандай, кычкырта-сызлата булса да русча сөйләштеләр. Елена аңламаслык итеп аңлашырга кирәк сүз дә бар иде. Анысын Гакилә башлады. Ул:

— Бу балакайга азмы-күпме ризык та кирәгер бит инде, Һәнүзә кордаш? Әле сезгә килеп төштеме соң ул, Хафиз? — диде.

Хафиз кичтән юлда очрашуларын, кызның үзләрендә төн кичүен әйтте.

— Ипи талоннары бирербез инде,— диде Һәнүзә. Үзе медсестра кызга карап алды. «Бигрәк яшь инде, балакай» дип жәлләп куйды шикелле.— Хәзер хисапчыга әйтермен. Көнгә ярты кило булса да икмәк алыр. Сельмагтан биреләсе дүрт-биш кило онны ике атна көтәсе бар әле.

— Әй, аңа калгач, юк инде, кордаш! — Гакилә өметсезлек ишарәсе итеп кул селтәде.— Ул кадак он өреп очырырга гына бит ул...

Эшнең болай тиз һәм интегүсез юл алуына Елена сөенде һәм, Мәликә апага рәхмәтләр укып, кичен чемоданын Галияттәй йортына алып китте. Хафиз аны озата килде. Хафизга исә медсестра кыз мең-мең рәхмәт әйтте, педучилищега имин барып житүен, әйбәт билгеләр генә алуын

теләде. Икенче кайткач (март урталарында гына була инде, димәк), медпунктка кереп, хәл белешеп чыгуын үтенде.

— Онытып бетермә, Хафиз, яме. Мин монда әлегә ят кеше, яңа кеше әле. Ә сине күптәнге танышым дип санарга рөхсәт ит...

— Озакламый очрашырбыз,— диде Хафиз да. Кызның шулай якын итүе аңа бик ошады, канатландырып җибәрде. Күп кирәкмени соң адәм балаларына?! Юлда җил-җил узып китмичә, хәл-әхвәл сорашуы, җылы өйгә алып кайтуы, хәл-хәленчә кунак итүе Еленага җан терәге булды. Кызның ихлас күңелдән рәхмәт әйтеп, Хафизны үз кешегә исәпләп куюы егет кеше өчен куанычка әверелде. Гөнаһсыз яшьлек хисләре, гомумән, кешеләрне тизрәк фикердәш итүчән була, ахры...

Хафиз март уртасы җиткәнне көтеп тормады, киткәненә ике атна дигәндә авылга янә кайтып җитте. Мәликә апа, улын күргәч, баштарак ни әйтергә дә белми торды, имәнеп китте. «Ходаем ла! Укуын бетерергә дә бирмичә, сугышка алына микәнни?! Бәхилләшеп, саубуллашып китәргә кайткандыр, кырык чакрым җиргә ирекле баштан вакытлы-вакытсыз чыгып китмәс иде»,— дип шомланды. Яшен тизлеге белән миендә икенче уй да сызылып үтте: «Монысында да атасы каны. Үзе теләп сугышка китәргә кыбырсып йөриме әллә?»

Мәликә апаның шиге, сагаюы бөтенләй юкка булып чыкты. Хафизны әлегә армиягә алмыйлар, үзе дә, училище дипломына ия булмый торып, беркая да китәргә исәпләми иде. Әнисенең куркынып күзенә каравын, йөзеннән кан качуын күргәч, ул аны тизрәк тынычландырырга ашыкты. Мәликә апа, кинәт кипшенеп калган иреннәрен чак кыймылдатып:

— Бер-бер хәл булдымы әллә, балам? — дип сорауга, Хафиз бик тыныч, сабыр җавап кайтарды:

— Борчылырлык бер нәрсә дә юк, әнкәй. Беренче курста ук язган дәфтәрләр кирәк булып чыкты. Соңгы ел бит, имтиханнар каты булачак. Узган елдагыларны кабатлата башладылар,— диде.

— Аллага шөкер икән! — диде Мәликә апа да һәм җиңел сулап куйды. Аннан соң авыз эченнән генә нидер укынды.— Дәфтәрләр иске сандыкта...

— Ниләр майтарасың, әнкәй? Авырмыйсыңдыр бит? — Хафиз кичке чәй янында бик иркенләп сораштырган кыяфәттә утырды. Үзе өйдән чыгарга ашыга, Еленаны күрергә талпына иде. Сагынумы, күреп сөйләшәсе килүме, аның янында аз гына булса да басып торып, зәңгәр чәчкәдәй күзләренә, алтын чәч толымнарына күз сирпү теләгеме — кем белсен, Хафиз исемсез, тыелгысыз бер хис, атлыгу, ашкыну сизә. Тик мондый алгысып торуны әнисенә белдерергә ярамый иде. Еленаны күрер өчен генә кайтуын абайласа, ананың кәефе кырылачагы көн кебек ачык. «Сабагына зыян салып, арып-талып, өшеп-күшегеп, ике якка туксан чакрымга якын җир йөрү — ниткән эш ул, хода язмаганны!» — диячәк. Рәнҗеп, сыкрап кына калмавы да бар. Мәликә апа бер кызса-кайнарлана калса (үзе дә гел: «Аллаһы тәгаләдән күркәм сабырлыклар сорыйм» дип кенә тора), мунча ташыннан ким түгел. Ансат кына юатырмын, тынычландырырмын димә. Күпне кичергән хатын бит, аның йөрәгенә ни кан савылган... Ярсый башласа, елый-елый тезә инде. «Әй, раббем, синең каршыңда нинди гөнаһ кылганым булды икән соң? Күңелем гел генә изгедә, гел генә гаделлектә ләбаса. Сөлектәй ике балам чит җирләрдә баш салды, аталары мәхшәр эчендә теткәләнде. Кем булып кайтыр? Тагын ниләр генә күрәсем бар икән бу фани дөньяда?!» дип өзгәләнәчәк. Аның сабыр савыты шултикле тулган хәзер, артык бер тамчыдан да ташып китәр кебек.

Боларның һәммәсен белгәнгә, әнисенең көенечләрен чын йөрәктән уртаклашканга, Хафиз кәнсәләргә һәм клубка дәррәү чыгып китүдән сак булды. Иске сандыкны ачып, беренче-икенче курсларда язып тутырган дәфтәрләрен барлады, чыннан да, озакламый кирәк булачакларын ае-

рып, бер читкә куйды. Сайлый торгач, шактый җыелды. Җәяүлегә янчыкта авыр дигәннәр дә сон, шуларны алырга кайттым дип, авыз тутырып алдашкач, биштәреңә салып китми ни хәлең бар?!

Алдашу дигәне дә гөнаһсыз ялган инде, югыйсә. Хафиз шулай уйлады. Әни кешегә барысын ничек туп-туры әйтмәк кирәк? Аннан соң бит сабыр канатлары сынарга житешеп кайтып килүен ул үз-үзенә дә рәтлечутлы аңлата алмый иде әле. Елена кайт дип әйтмәде ана, хат-хәбәр салмады, чакырмады. Хафиз үз йөрәген үзе авызлыклый алмаудан кайтырга мәҗбүр булды. Әле дә түзде, Сигезенче март бәйрәменә үк чамалап караган иде, яхшысынмады. Хатын-кызлар бәйрәменә туры китереп кайта калсам, Еленага бүләккә дип бик шәп әсәр басылган журналны да пенсионер укытучы карттан сатып алган иде. Әсәренең ниндие диген! «Тапшырылмаган хатлар»! Хафизның төн йокыларын алган повесть. Татарчасының яртысын диярлек яттан белә ул. Һәр иртәдә алга таба күнеленә бикли бара. Шуның русчасын табуга әй сөенде дә соң! Сугышка кадәр үк «Октябрь» журналында басылган булган икән ләбаса!

Урамга чыгып баскач, Хафиз бер мәлне кай якка борылырга да белми торды. «Ягып җылыт, ачып суыт» дип йөртә торган клубта ут юк иде. Бу суыкта ягып та мәшәкатьләнмиләр аны. «Күк йөзен җылытудан ни мәгънә!» диләр. Ачып та маташмыйлар. Шуңа күрә сугыш вакыты егетләре — малай-шалай һәм кыз-кыркын уку өенә тәялеп ята. Домино сугалар, чират торып шахмат уйныйлар, аякларына суык үтә башлагач, өсталләрне, эскәмияләрне бер читкә өеп куялар да такмак әйтә-әйтә «көлтә җыя» башлыйлар. Өч пар да бөтерелә, дүрт пар да. Гариф күрүкләре сытылыр дәрәҗәгә житкән, ямьшәйгән гармунын алып чыкса, берәм-берәм дә биеп алалар...

Хафизның уку йортына да, идарәгә дә барасы килмәде. Анда аның күрер кешесе, сөйләр сүзе юк. «Исәнме-саумы, сәламәтме, наный? Иминаман гына яшисеңме? Авырмыйсыңмы, чирләмисеңме, сырхауламыйсыңмы?» дип, бер сүз белән сорыйсын егерме бер баскычлы итеп сорашучы учетчик абзый белән сөйләшеп утырсаң гына. Ләкин бу көнне, шул сәгатьтә тәмле телле Гыйният абый да тартмады аны.

Үзеннән-үзе яшереп, теленә китерергә тарсынып торган бер урын бар инде барын: Галияттәйләргә кереп чыгарга! Тик кыймый. Нәрсә дип керәсең? Көндез булса, бер хәер әле. Медицина кешесенә кемнең ни йомышы төшмәс? Кичен нәрсә диярсең? Сыныкка сылтаусыз ишек шакып булмый. Галияттәй — мең дә берне белә торган карчык. Кешене үтә күрә ул. Күреп кенә калса, сәдакасыннан дияр идең. Карап күзе күгәрсен. Күргәнен-белгәнен урам буена сибеп йөри әле ул. Иң башлап Мәликә күршесенә юыртып керер. «Һай, ахирәт, яшь җилкенчәкләрне әйтәм әле. Сугыш мазасы дип тормыйлар, тормыш нужасы дип белмиләр, чүкердәшәләр. Кичәгенәк Хафизың бездәге духтыр кыз янына кич утырырга керде бит, билләһи газыйм. Ул сөйләшәләр, ул көлешәләр. Бер сүзләрен дә тач туры китереп аңламадым, шулай да, ахирәткәем, пар күгәрчен дә бер, болар да бер»,— дип, югын да бар итеп тәтелдәр.

Анысы хак, шулай. Әмма Тәтеш тикле Тәтештән тәпиләп кайткач, юл буе хыялланып, Еленаны янәшәндә хис итеп атлагач, Галияттәйнең җил капкасы буеннан борылып китү дә егетлек түгел. Бүредән курыксаң, урманга барма, дигәннәр. Күрше карчыгы әнкәйгә сөйләр дип шүрләп калырга бишенче класс малаемы соң ул? Сөйләгәннән сүтелерлек булгач, кызлар янына кереп чыгам дигән уйны башыңа да китерергә кирәкми. Аннан ары шунысы да бар: Хафиз — Еленаның бу авылда беренче белеше. Чынлап баксаң, Елена үзе дә Хафизны бик көтәдер әле. Русчасы ничек була дип сорашырга татар сүзләрен ничек ишетсә, шулай язып куйгандыр. Гел язып куймаган булса да, Хафиз үзе әйтеп тә булыша алачак. Булышырга тиеш хәтта. Һай, шәп булды бит әле бу фикер. Хафиз аңа русча-татарча сүзлеген бирер. Өйгә хәзер үк кире кереп алмасымы?

Юк, ярамый. Иртәгә дә көн бар, алда — башланмаган якшәмбе. Галияттәй өенә кабат килергә менә дигән сәбәп булачак. Шулай икән, сүзлек бүгенгә запаста торсын. Запас кесәне тишми, ди торган иде аның бабасы... Я, ярый, тәвәккәлләп ишекне шакырга кирәк!

Чолан ишегең какканга җавап бирүче булмады. Йоклыйлар дисәң, иртәрәк әле. Аннары утлары да яна. Тагын бер шакып та тавыш-тын ишетелмәгәч, Хафиз, беткән баш беткән дигән сыман батыраеп, тәрәзәгә барды. Пыялага сыланып эчкә карады. Шунда барысын төшенде: Елена өйдә юк. Кем белсен, бәлки ялга каршы Аккүлгә киткәндер. Детдомда тәрбиячеләре бар, иптәш кызлары бардыр. Бәлки иптәш кызлары гына түгел, якын күреп йөргән егете дә бардыр.

Галияттәй өйдә. Ишек ачарга чыкмавының сәбәбе бер генә, намазлык өстендә утырып намазга оеган.

Хафиз көтте. Аягына суык үтсә дә чыдады. Болай бихәбәр китеп барса, тынычлана алмаячагын белә иде.

Ишекне янә шакыгач, Галияттәй чыкты.

— Кем бар, рәхмәт төшкере? Илина кызым, синме? — диде ул, йомшак кына.

— Мин идем әле, Галияттәй. Күршең Хафиз.

Карчык:

— Ә-ә-ә, синмени, балам! Әйдә, кер. Кайчан кайттың? Ни йомыш иде? — дип сораштыра башлады.

— Елена кирәк иде, өйдә юкмыни?

— Юк иде шул, бик хаҗәтмени соң?

— Күрәсе бар иде. Тиз кайтырмы икән?

— Вәт тәгаенләп әйтә алмыйм, балам.— Карчык, барсын сөйләсәм, килешерме дигән кебек, сүзсез торды да төенне чишәсе итте.— Үзеп әйтүе кыен. Борһан Гафурының хатыны бәбигә авырган. Котылмый торып кайтмастыр инде...

Хафизга, чыннан да, кыен булып китте. Ул, гафу үтенеп, тиз-тиз чыгу ягын карады. Уку өенә дә, идарәгә дә барып тормады, өйләренә кайтты. Җәһәт әйләнеп керүенә гаҗәпләнмәсен дип, әнисенә:

— Кино килмәгәнме дип караган идем, клуб бөтенләй бикле,— дигән булды.— Укып ятыйм әле азрак.

— Шулай ит, улым, шулай ит.— Мәликә апа бүлмәдә ниндидер эш белән мәшгуль иде.— Алланың биргәненә мең шөкер, ызба җылы, ут якты. Өченче көн кибеткә керосин кайткан иде, ике чирек алдым, әлхәмделиллаһи шөкер...

Бер-ике минут та узмагандыр, кулына хат тотып, Мәликә апа улы янына йөгереп чыкты.

— Син гел уйламаганда кайтып кергәч, зиһенем гел генә төтен булып таралды бит, балам. Әткәннән хат килгәнне дә әйтми торам икән ләбаса, һай, бу мингерәүлегем! — Кадерле хатны ул Хафизга сузды. Егет ябырылып укырга кереште.

Галиулла абзый хәлен яхшыга таба бара дип язган иде. Хафиз белә инде, әтисе зарлана торган кеше түгел, аның шыңшып бүтәннәр җанын кыйнау гадәте юк. Шулай да гарипләнүе рухына суккан. Күпме генә сер сынатмаска тырышса да, «Буразнага элеккечә нык басып булмас инде. Шул уй йөрәкне үтмәс пычак белән телгәли. Шулай да кайгыга хәсрәт яманы салып утырырга ярамас. Алай итсәк, дошман сөенер»,— дип язмый булдыра алмаган. Галиулла абзый дошманны шатландырмаска кирәк дигән фикернең кәгазьгә теркәлү тарихын да язып куйган.

«...Икенче операциядән соң борынны нык салган идем, дөресен әйтергә кирәк. Хирург Сердюк керде дә әйтә: «И-их, Кадергулов, сөмсерең коелган бит синең. Әвене янган татар кебек ятасың»,— ди. Мин әйтәм, әвен түгел, бәгырь яна, дим. Хәзер миннән какуй хлебороб чыксын, дим. Врач әйтә: «Выше голову! Фашист шатланмасын»,— ди».

Хафиз сизә иде: әтисенең хәле шәптән түгел. Кайтыр көннәрен уйлап, әнисен юатып яза, алдан хәзерләп куярга итә.

— Болай булгач, әти савыга да савыга инде! — диде Хафиз да.— Минә көннәрдән бер көнне дөбердәп кайтып та керер әле...

— Әй, улым,— дип көрсенде Мәликә апа.— Аягынны киссеннәр дә дөбердәп кайтып кер, имеш.— Ул тыела алмый елый башлады.— Дөбердәмәсә дә ярар, хәсре белән кайтсын гына иде. Түрдә утырып, акыллы киңәшен генә биреп торса да, ходага мең шөкерләр итәр идем. Үтте дә үтте, тагын да үтте ирсез көннәр үзәккә. Кан дошманына да ирдән аерылып калырга язмасын... Ирсез хатынга илерергә дә тилерергә генә кала...

Капка ачылган тавыш ишетелде. Кеше бар иде. Мәликә апа чоланга чыкты һәм кем беләндер сөйләшә башлады. Аннары кичке кунакны өйгә керергә кыстый башлады.

Елена кергән иде. Хафиз медпункт ишеген шакыганны Галияттәй әйткән. Яшьләр уйный-көлә бик шат күрештеләр, авыл һәм педучилище хәлләрен сөйләштеләр. Сүз иярә сүз китеп, фронт хәлләрен телгә алдылар. Совинформбюроның соңгы хәбәрләрен искә төшерделәр.

Сәгатьтән артыграк кич утыргач, Хафиз Еленаны озата чыкты. Әүвәле медпунктка кадәр бардылар, аннары Елена Хафизны озата килде. Хафиз тагын Галияттәйнең капкасы төбенә кадәр атлады. Сүзе дә чыга торды, кыш азагындагы чеметкеч суык та сизелмәде, вакыт үткәне дә тоелмады. Иртәгә күрешергә сүз куешып, саубуллашканда, Хафиз Еленага кичеккән бүләген тапшырды.

Шул китүеннән студент егет Беренче май бәйрәме җитми торып авылга кайта алмады. Юл өзеге, язгы ташу бер тоткарлык булса, имтиханнарга хәстәрлекнең көннән-көн кыза баруы икенче яктан бәйләп куйды. Укытучылар телендә һәрчак шул «имтихан» сүзе тәкрарланды, комсомол комитеты һәм профком әһелләре шуның белән авызланды. Яз яме күзгә күренмәс булды. Ләкин Елена Хафизның исеннән чыкмады. Бер ай ярым эчендә егет ана биш-алты хат язып салды. Җавап көтеп, ут йотты. Елена исә хатка саран булып чыкты. Шулай да кош теледәй генә бер сәлам хаты юлламый калмады. Хатындагы барча уе-фикере «Тапшырылмаган хатлар»га соклануыдан гыйбарәт һәм бу китапны бүләк иткән өчен Хафизга чиксез рәхмәт әйтүдән тора иде. Монысы да егетне куандырды. Ләкин ул Елена Солнцева дигән шәфкать туташыннан бүтәнчәрәк җавап өметләнгән иде. Тик ни хәл итмәк кирәк? Ярый әле, бөтенләй үк онытмавын белдереп, «Кайчан кайтасың?» дигән сорауны язарга тайчанмаган...

Хафиз ике-өч көнгә янә кайтканда, җир кибеп, үлән тернәкләнгән иде инде. Язгы чәчү колач алып өлгергән, яше-карты басудан кайтып керә алмый. Сабанчылар таң сызылуга кырга кузгала, кичке караңгы төшкәндә генә авылда була. Тик яшьлек үзенекен итте. Егетләр һәм кызлар клуб тирәсендә бөтерелми калмады, ун көнгә бер булса да кино да куелып торды.

Май бәйрәменә каршы төнне Хафизның һич онытасы юк. «Ул Ватанын саклый» дигән фильм күрсәтелде. Аннары, язылмаган закон буенча, җыр-биюе кичәсе башланып китте. Эскәмияләрне дөбер-шатыр күчереп йөргән чакта Хафиз Еленаны күргән иде, ә бераздан кыз юкка чыкты. Егет күңеленә кырмыска йөгерде. Шунлыктан ул, кордашлары белән азрак гәпләшкәндәй иткәч, кайтырга кузгалды. Еленаның илтифатсызлыгына үпкәсе купса да, Хафиз Галияттәйнең капка алдын читләтеп үтә алмады.

Җил капкага якынлашкач, ни күзе белән күрсен. Елена каршында Аккүл егете, Хафизның педучилищедагы курсташы Мәҗит Вәлиев басып тора иде.

Мәҗит — уполминзаг дип йөртелгән хәзерләүләр оешмасы башлыгының малае. Аны һәр шимбәдә ат белән килеп алалар, дүшәмбе иртәсендә

Тәтешкә кире китереп куялар. Әткәсе җигеп йөри торган туры айгыр әкияттәге тулпар сыман. Кайтып та өлгергән, Гөл-Төркемгә дә килеп җиткән. Мөгаен, шул айгырны җигеп элдерткәндер әле... «Минем сезнең авылга барасы бар әле, Хафиз. Күрәсе кеше бар»,— дип сөйләнгәне бар иде шул. Күрәсе иде дип өзгәләнеп торганы Елена булган икән!

Мәҗит белән Елена нидер сөйләшәләр, көлешеп куялар. Яннарына барыргамы, әллә ваксынмыйча гына «Чәнчелегезсәнә!» дип китәргәме? Алай китү иң җиңеле. Аның өчен бер дә егетлек кирәкми. Якын кил, сөйләш, хәл бел, әгәр удалой икәнсең! Мәҗит чын-чынлап Еленага өмет сузып йөри микәнни соң? Шулай була калса, курсташ дип тормаска, аңлаешлы итеп кисәтергә кирәктер аны. Төшендереп әйтеп кую артык булмый ул мондый эштә!

Хафиз эчендә мәчеләр тырнашканны чыраена да, тавышына да чыгармаска тырышты. Тегеләр янәшәсенә килеп туктауга:

— Хәерле төн! — дип кәефле генә сәлам бирде.— Нинди җилләр ташлады сине, курсташ?

— Исәнме, Хафиз! — диде Мәҗит һәм күрешергә кул сузды.— Җилләр дигәндә — яз җилләре инде. Ник дигәндә — иске белеш янына килү. Сезнең авылның сәламәтлек фәрештәсе — минем күптәнге дус ич. Балалар йорты безнең йортның күршесендә генә. Лена Аккүлгә килгәннән бирле минем күрше булып чыга. Шулаймы?

Елена көлеп җибәрде һәм Мәҗиткә:

— Анысы шулаен шулай да, бәхәстә кем хаклы, я әйт инде,— диде. Шул сорауда тылсым булды, ахры, Мәҗит озак тормады, Аккүлгә китәсе итте. Җигүле атын янгын сараена куйган булган икән, каравыл өенә юнәлде. Хафиз аны үзләренә өндәп, кунарга да чакырып баккан иде дә, Мәҗит кул гына селтәде. «Аккүлгә җил булып очам мин!» — дип кенә җибәрде.

Хафиз берни дә аңламый калды. Азактан чыдамады:

— Бу фокусларны ничегрәк аңларга кирәк? — дип сорыйсы итте.— Нинди комедия бу? Әллә фаҗига катнаш мәзәкме?

Елена кинәт җитдиләнде.

— Мөмкин булса, аңлатмаска рөхсәт ит, Хафиз.

— Юк инде, авыр булса да, төшендер, Елена. Татлы ялганга караганда ачы хакыйкать яхшырак бит.

— Минем аңа андый сүз әйтергә хакым юк иде.

— Нинди сүз, Елена?

— Әйтәм, ләкин миңа ачуланма, яме. Мине гафу ит.— Кыз башын аска иде, туфли борыны белән җирне тырнаштырды.— Мәҗитнең авылга минем яныма килүе икенче тапкыр инде. Дус булыйк, ди. Яратам, ди. Ә мин аңа яраткан бүтән кешем бар дидем. «Кем ул?» дип әрсезләнә, ышанмый. «Син аны беләсең, бик яхшы беләсең. Менә бүген... хәзер күрерсең, үзе монда киләчәк»,— дидем. Килерең ышанмый гына бәхәскә кергән идем, күземә күренәсеңме дип торам. Гафу ит мине, Хафиз. Ачуланма зинһар...

— Елена!

Шул төнне Хафиз гомерендә беренче тапкыр кыз кешене кочагына алды.

Хафиз педучилищены тәмамлагач, укытырга үз авылына билгеләнде. Дәрес сәгатьләре муеннан иде, өлгер генә: директор яшь белгечнең рус теле һәм әдәбиятын да, туган телне һәм әдәбиятны да укытачагын әйтте. Уку елы башланганчы да кул кушырып утырырга туры килмәде. Авылга кайтып төшүенә агитатор итеп билгеләделәр. «Ватан» колхозының стена газетасы редакторы итеп расладылар. Сугыш вакытында агитатор булу ул заемга яздыруны, фронтка җылы киемнәр туплауны, үзешчән сәнгать түгәрәкләренә мәҗбүри катнашуны, доклад һәм лекцияләр сөйләүне, мәктәпкә, авыл Советына, медпунктка кышлык утын хәзерләүдә җиң

сызганып катнашуны, урак өстендә, ашлык сугу вакытында басуга яки ындыр табагына эшкә чыгуны, тагын әллә ниләрне үз эченә ала иде. Хафиз да көнне төнгә ялгап тырышты. Елена шулай ук авыл активларыннан бер дә аерылмады. Алар бер-берсенә шулкадәр күнегеп, ияләшеп киттеләр, бер көн очрашмый калсалар, тормышларының кайсыдыр чите кыйпылган сыман тоела иде.

Хафиз белән Елена дуслыгы авылда төрле-төрле юрауларга, кинаяле сүзләргә дә сәбәп булды. Яшьләрнең карашы бер төрле, олы яшьтәгеләр бүтәнчәрәк уй йөртә иде. Авылдагы имеш-мимештән хафалана башлаган Мәликә апа эчендәген улына белдерми калмады.

— Төрле сүз йөри, балам. Елена белән синең арада берәр хәл бармы әллә? — диде ул, нык борчылып, ләкин үтә саклык күрсәтеп.— Кеше төрлесен сөйләр, мин дөресен белеп торырга тиеш...

— Без дус анын белән, әнкәй.— Хафиз елмаеп җавап бирде.— Әйбәт кыз ул Елена. Гадел, саф күңелле, тыйнак.

Шул сүзләрне ишеткәч, Мәликә апа тагын да ныграк пошына башлады. Шулай да бу халәтен улына сиздермәскә тырышты.

— Өйләнешергә уйламыйсыздыр бит? Тәүбә, тәүбә, әйттем исә кайттым... Авызымнан җил алсын!

Хафиз әнисен тынычландырды.

— Юк, әнкәй, юк. Башка андый уйның кереп караганы да юк. Сугыш бара, рәхимсез сугыш. Безнең җиңүебезгә шик юк, тик сугышның кайчан бетәсен өзеп әйтүе кыен. Алда бик зур читенлекләр булыр әле, әнкәй. Шулай булгач, өйләнешүләр бер читтәрәк торып тора...

— Шулай, улым, бик шулай...— Мәликә апага ансатрак булып китте. Ул җинел сулап куйды.— Вакыты җиткәч, насыйбы чыгар әле, балам. Өйләнү качмый. Аллаһы боерган булса, сугыш тынгач, эткәң кайткач, мена дигән бер татар кызы алырсын...

Хафиз әнисенең нидән пошынуын белә иде. Шул сәбәпле анын сызлавына сугып торасы килмәде.

— Дөрес, әнкәй, вакыты җиткәч, күз күрер,— дип сүзне очлап куярга булды. Ә күңеленнән ул Еленаны гомерлек юлдаш итеп сайлавына тырнак очы кадәр дә шикләнми иде инде. Бүтәнчәсен ул күз алдына китерергә дә теләмәде.

Мәктәптә Хафиз берничә ай гына укытып калды. Октябрь бәйрәме узуга, аны армиягә алдылар. Мәликә апа кыр кебек өйдә япа-ялгызы калды. Анда ул йокларга гына кайта иде дисәң дә зур хата булмас.

Хафиз сугышка китәр алдыннан Елена белән вәгъдә беркетте. Кыз аны көтәргә сүз бирде һәм дошманның тизрәк муены астына килүен, егетенең исән-сау әйләнеп кайтуын теләде.

Ә сугышның юлы озын, урау анын. Меңләгән, йөз меңләгән кешеләрнең өметләрен өзә, хыялларын челпәрәмә китерә, планнарын җилгә очыра. Кадергуловны да сугыш аяусыз рәвештә үз зилзиләсе эченә суырып алды һәм ул да җилле көндә «пәри туе»на эләккән йомычкадай бөтерелде. Башта Хафиз хатларны еш язды, үзе дә авылдан җавап ала торды. Ут эченә кергәч, хатлар сирәгәйде. Әтисенең авылга кайтып ирешүен дә, ул чакта авылда ниләр булганын да Хафиз дүрт-биш айга соңгарып кына белде. Туган әтисенең гомере киселүен, нича үлемнән калып әйләнеп кайтмый торып, бөтенләй ишетмәде. Мәликә апа бу хакта ләм-мим язмады.

Бер заман Хафиздан хат өзелде. Ана йөрәге шомлануның чигенә җиткәндә, аны тәмам аяктан егарлык хәбәр килде. Хафиз һәлак булды дип язганнар иде.

Һай, ул көннәр! Искә төшсә, йөрәкне көзән җыергандай итә, бәгырьгә теш сызлавы төшә.

Соңгы таянычны да мәңгегә җуюның кара хәсрәтен Мәликә апа аяк

өсли күтәрә алмады, түшәккә егылды. Елена аның яныннан китмәскә тырышты.

Көннәр узды, атналар үтте, бер-бер артлы айлар авышты. Хафиз хакында башка хәбәр булмады. Елена туган ягына — Украинага китәргә җыенды. Анда бәлки — исән калган булсалар — әти-әнине табармын дип өметләнде. Зөя буендагы бу авылда кала алмады. Монда һәр сукмак, һәр куак, мәктәпкә йөгерешеп баручы балалар — һәммәсе аның бөреләнә башлап та чәчәк атмаган шәхси бәхетен минут саен, сәгать саен исенә төшереп тора иде.

Күп гомер узгач, Хафизның госпитальдән язган хаты килде. Ул исән калган иде. Шуннан соң да Елена тагын бер язып, сорашып карады, тик Мәликә апа — гөнаһысын үз иненә алып — «бер хәбәр дә юк шул, наный»,— дип җавап язды.

Сугыш тынганнан соң да байтак вакытлар үткәч кенә кайтып, укытучылык эшенә башлагач, Хафиз Украинага, Елена туып-үскән өлкәгә ике тапкыр язып карады. «Солнцева Елена Семеновна дигән кеше юк» дип җавап бирделәр. Кадергулов мона гаҗәпләнде. Ул сугышка киткәннән бирле ни гомер үтте, күпме таңнар таңга ялганды инде. Елена, бик ихтимал, әллә кайчан кияүгә чыгып, бүтән тарафка китеп баргандыр, балалар үстерә булыр. Сугыштан соңгы чорда хатын-кызга талымлап торырга җай бар идеме? Алладан алтын кашык көтеп коры калганчы, агачына да куан, диярлек заман иде ич!

Инде менә ничә еллар үткәч, Елена исеме Хафиз колагында кабат яңгырый. Ул аның өчен яңадан туды. Ялгыз гына түгел, улы Владислав белән бергә пәйда булды...

...Хат алышу озакка китәчәк. Хафиз мондый нәтиҗәгә килде: бүген үк Казанга барырга, өлкә комитетына керергә, ике-өч көнгә рөхсәт алып, Украинага очарга! Туры китерә алса, беренче секретарь белән киңәшергә. Аңа барысын сөйләргә... Ә Еленага, телеграмма сугып, килеп төшәсен хәбәр итеп куярга.

## 10

Әхтәм өйгә кайтырга чыкты. Кәефе ал да гөл диярлек булмаса да, бик үк начар да түгел иде. Аны партия членлыгына кандидатлыкка кабул иткән җыелышка катнашучылар, башлыча, район ветлечебницасы врачлары һәм фельдшерлары (зооветснабның районара базасындагы ике коммунист учетта шунда тора.) Әхтәмнең характер ныклыгын сынап карадылар. Уйнап сөйләшкәннәрен дә белмәссең, чынлап сылангannaрын да аңламассың, барысы бергә дип әйтерлек:

— Синең гомереңдә иң зур вакыйга шушы бит инде, Билалов. Кунакка бүген чакырасыңмы, әллә җомга көнгә калдырып, куш ялга каршы иркенләбрәк сыйларга исәплисеңме? — диештеләр.

Әхтәм сер бирә торган татар түгел. Нечкә кара мыегын сыпырып елмайды да, энҗедәй тешләрен ялтыратып:

— Кемнең кайчан килергә дәрте бар, рәхимен кылсын. Ишек уйган, тәрәзә куйган. Миннән ачык чырай, бөртекле чәй,— диде.

— Алай гына котылырлык булгач, шушы буй-сынын белән тел талдырып сөйләшеп тә торма,— диде карсак буйлы фельдшер Ибрай һәм, Әхтәм Билаловның озын буйлы булуын исбат итәргә теләгән кебек, аяк очына басып, аның җилкәсенә кагылып куйды.— Мәй дигән ичмасам, шпирт дигән. База башлыгы бит син. Үзең эчмәгәнне беләбез, чурт с тобой. Карап утырырсың, без мескеннәр сыйланырбыз. Ярый безгә — майлы күзгә, чәй булмаса мәтрүшкә, диләрме?

Әхтәм телдәр Ибрайга бер мизгел эчендә күзенең агы белән генә карап алды. Лыкылдама дию иде бу аның. Ләкин телдән алай әйтмәде.

— Шпирт-флирт кешеләренең ил агасы булганын күргәнем юк әле минем, Ибрай. Күпме генә канат җәярлек адәм булсалар да, аракы күленең сасысыннан арына алмыйлар...

Әгәр Ибрай аның янында ялгызы гына булса, Әхтәм сүз әрәм итеп тә тормас иде. «Кит әле кибәннәр артына, кирәкле кишер яфрагы! Мин синнән дәрәҗәлерәкләр белән дә артыгын вакланмыйм»,— дип кенә җибәрер иде. Монда алай ярамый, төрле кеше бар. Җитмәсә, лечебница бухгалтеры шадра Каюм да һәр сүзгә колак салып тора. Бер дорфарак сүзеңне ишетсә, юкны бар итә, янгырны кар итә ул. Нечкә кеше, имеш. Культуралы. Нәзберек, нәзакәтле. Әле җыелышта да берсеннән-берсе төрткеле сораулар бирде бит...

— Иптәш Билалов, әйтегез әле,— дигән иде ул («сез» дип сөйләшкән була!),— партиягә моннан иртәрәк керү турында уйлаганыгыз булмадымы? Бу теләк сездә кырык алты яшь тутыргач кына уяндымы?

Әхтәм аның алдында авыз йомып калмады, билгеле. Тиз һәм дөрес җавап тапты:

— Уставта, партиягә фәлән яшькә кадәр генә алырга, дигән чик юк, Каюм иптәш. Монысы — беренчедән. Аннары, мин үземнең хәзерлегемнең тиешенчә түгеллеген белә идем, әчке дөньям белән мондый адымны атларга әзер булмаганмын. Хәзер теләк тә, әзерлек тә сизәм,— диде. Аңа куәт өстәгәндәй, җыелыштагы берничәсе:

— Дөрес!

— Шулай,— диештеләр.

Каюм сорыйсыларын ачыклап бетермәгән иде әле.

— Сез, иптәш Билалов, моннан шактый еллар элек үк, кандидатлыкка керергә җыенып, анкета тутырган идегез. Ялгышмасам, рекомендацияләр дә ала башлаган идегез шикелле. Ул чакта, әтисе рөхсәт бирмәгәч, кире чигенде, диюләре расмы?

— Әти рөхсәтеннән бигрәк, үзем әзер булмаганмын...

Каюм бөтенләй бүтән яктан китереп сорау куйды:

— Райсоюз мал-туарына ветеринария хезмәте сезгә нәрсә бирә, иптәш Билалов?

Бу төпчену Әхтәмнең саруын кайната башлады. Җыелышта утыручылардан да кайберәүләр бухгалтерга карап куйдылар: «Нәрсә дип тигәнәк булдың әле син?»

— Совместительство буенча эшләгән хезмәт хакын бирә,— диде Әхтәм кырыс кына.— Алай эшләргә хакым да, өстән рөхсәтем дә бар. Мин дипломлы ветфельдшер...

Устав һәм программа буенча сораулар булды, агымдагы халыкара хәл мәсьәләләрен сораштырдылар. Аннары Билаловны партия члены(г)ына кандидатлыкка кабул итү мәсьәләсе тавышка куелды. Барысы да уңай якка тавыш бирделәр. Каюм гына аларга кушылмыйча битараф калды. Җыелыш председателе: «Ялгыш кына кул күтәрми калдыңмы әллә?» — дип кайтарып сорагач, Каюм үз карарын телдән дә белдерде.

— Мин битараф калам, иптәшләр. Яклап кул күтәрергә ышанычым азрак. Каршы күтәрсәм, исбатлап бирә алмавым бар,— диде. Шуннан соң өстәп әйтимме, юкмы дип торды. Ахыргача принципиаль булырга кирәклек өстенлек итте. Каюм уендагысын ачып салды:— Минем фикеремчә, иптәшләр, иптәш Билаловның партия сафына керүдән төп максаты үз җирлеген ныгыту, көн итә торган плацдармын цементлау. Ул белә: укымышлы яшьләр күбәйде, институт тәмамлап кайтучылар арта бара. Фельдшер белеме белән Әхтәмнең базада озак тормавы мөмкин. Коммунист булгач, таләбе зур булса да, терәге дә нык булыр дип уйлый ул. Минем фикеремчә, иптәшләр, коммунистның коммунистлыгы, ул кайда гына эшләмәсен, үз интересларын кабыгын ярып чыгудан, халык интересларын масштабына күчүдән башлана. Әхтәм — мин моны аның күзенә карап әйтәм — үзе өчен генә яши торган кеше. Менә шуңа күрә бер якка

Аккулгә күчеп килгәннән бирле беләм, иптәшләр.

Җыелыштагылар Каюм Әшрәфҗановның мондый чыгышыннан соң үзара сөйләшеп алдылар. Ләкин позицияләре мәсьәләне кабаттан караргамы әллә диярлек дәрәҗәдә какшамады. Каюм артык зурдан кубып сөйләмиме икән дип санадылар.

Һәр кеше тормышка үзенчә карый. Бирәүләр, гомумән, кыңгыр басканны тыныч күңел белән күзәтә алмый, андыйларның кулына суга, йөзенә бәреп әйтә, фаш итә. Икенче бер иш кеше «Дөньяның бөкресен мин генә төзәтеп бетерә алмам. Миңа гына бик күп кирәкме әллә?» — дип, кул селти. Каюм алай итә алмый. Гадел җәмгыятьтә һәммәсе гадел булырга тиеш. Берәүләргә җелеге, бүтәннәргә күбеге булыр заманнар артта калган. Октябрь революциясенә илле ике ел тулды, Гитлерның муенын борганга чирек гасыр...

Ә Билаловны үтәли күрә ул. Каршы күршесе бит. Кирәмәт авылында муллалык иткән Шакир, Әхтәмнең атасы, кырыгынчы елда Аккулдан иске бер йорт сатып алды. Өе утынлык кына иде, аны шул җәйне үк сүтеп ташлады. Каралты тирәсе җиренең зурлыгы, урынның үзәктә булуы аның авыз суын китергән иде. Акчасы аз булмагандыр, күрәсең, каз өмәләре җитәрәк шундый йорт өлгертеп куйды, район үзәге халкы тел шартлатып, бот чапты. Иренә торган адәм түгел иде, беренче көздән алмагачлар утыртты. Чиясен, карлыганын үстерү дәртенә кереште. Остабикәсен дә, улы Әхтәм белән кызы Гөлфияне дә төпкә җигеп эшләтте.

Мәчет манаралары киселеп беткән, указлы муллаларның почеттан очкан заманы иде инде. Әмма Шакир югалып калмады. Агай-энегә башлык сыман булып, үлек юды-җирләде, кирәксенгән кешегә никах укырга да авырсынмады. Бакый дөньяга хәстәрлек мәшәкатьләре белән генә канәгатьләнмәде, фани дөнья шөгыле бервакытта да аның күз уңыннан китмәде. Пекарняда ат җикте, Аккул кибетләренә икмәк ташыды. Сугыш башлангач, шуннан да уңай һәм төшемле урынны эзләүнең кирәге дә калмады. Дөнья тоткасы — ипекәйгә бик күпләр соңгы киемнәрен дә саттылар. Мебель белән, урын-җир кирәк-ярагы белән исәпләшмәүчеләр аз булмады. Хәтта алты почмаклы өйләренең өч ягын өч потонга бирүчеләр дә булды.

Шакирның бүресе улады. Сәдакага килгәннәрең бер кырыйда торсын, чиле-пешле, балчыктай авыр икмәкнең пар кирпече пар алтын колагалка китергән көннәрдә ул йокламады. Яраланып кайткач, Әхтәмен дә (ярасы аягында иде) кабат борчучы булмады. Врачының да авызы булгандыр дип уйларга кирәк. Әхтәм Билалов хәзер үзе җитәкчелек итә торган базага склад мөдире булып урнашты. Шуннан артыгы кирәкми дә иде. Өйләнергә ашыкмады. Ашыкса да, әтисенең рөхсәт итмәячәген белде. Шакир хәзрәт аңа кырт өзеп болай диде: «Алланың рәхмәте белән апаң кияүгә чыгып, бер хәерле гаиләгә тап булмый торып, бу йортка килен кертергә рөхсәт юк. Мин үземнең күз нурыдай кызымны әллә кемнең бер чәчбиеннән битәрләтергә юл куя алмыйм. Килен төштеме, бала китерә башлый. Баласы булдымы, төп йорт малына бәбәк алартырга тотына. Җиде ятка уртак итәргә дигән малым юк. Киленкилмешәк рәхәт сөрсен дип бөкре үскәнче тырышмадым...»

Шакир карт теләгәнчә, боерган сәгать җитте. Гөлфияне Шәйморза мишәренә кияүгә бирделәр. Ул анда әйбәт тамырланды. Әхтәмне башлы-күзле итү чираттагы эшкә әверелде. Остабикәсен җирләгәч, үзенең дә сөяк-санагы сызлый башлагач, килен кирәклеге котылгысыз иде. Указсыз хәзрәт сүзенчә әйтсәң, язмыш тактасына чәчләре чәчкә бәйләнер дип теркәлгән булгандыр, Әхтәм Мостафа абзыйларда яшәп, азык комбинатында эшләүче Мәгъсүмәне очратты. Юашлыгын, тыйнаклыгын ошатты. Күңелендәгесен әтисенә дә сөйләде.

атихасы шул булды. Хәзрәт абзаң алдан күрде: кызның нәсел ыруы
ычыткан тамыры шикелле таралмаган. Үзе дә мангаенда ике күзе,
ердән, ире янсә каенатасы төксе караган саен зар елап, туган-тумача-
ына йөгермәскә яхшы. Котыртып торучысы юк. Аркаланырга атасы,
ркалэнергэ әнкәсе булмагач, башы иелгән була. Каршы әйтим дигән
агында да алдын-артын уйлый да телен тешли. Икенчедән, йорттан
ал ягага чыкмый. Бирер кешесе булмый. Дөнья малы йорттагы кеше
шаганнан бетми, читкә ташый башлагач житми. Читкә тама башласа,
өткәзермен димә...

Мәгъсүмә Шакир карт һәм Әхтәм теләгән килен иде. Никах укыгач,
Әхтәмнең үзен-үзе бугазлап ташларга житкән чагы булды булуын, тик
л бу хакта этисенә һични сиздермәде. Шакир карт абруена да, үз
вторитетына да тузан төшермәскә кирәк иде...

Шадра шайтан, Каюм, гомере буе тәрәзә пәрдәсе астыннан күзәтеп
шн икән, ә?! Кайда эшләгәненне, күпме алганыңны, нәрсә ашаганыңны,
айне ни белән эчкәнеңне генә түгел, ничек атлаганыңны, ни рәвешле тын
лганыңны белеп тора, әй! Белсен дә белдекле булып торсын иде. Торыр!
Эрә бит адәм имгәге, җыелышта түргә басып сөрән сала. Әтисе мәрхүм-
ең бигрәк тә белеп әйткән сүзләре бар иде. «Кеше ул, Әхтәм улым,—
и торган иде,— бар булсаң — күрә алмый, юк булсаң — бирә алмый».
Шулаен да шулай бит, кана.

Ярый әле, барысын белми. Югыйсә, бүгенге ише генә әтәчләнер
деме?

«Барысын» дигәнен Әхтәм япа-ялгызы гына белә. Әтисе моны аның
зенә дә бәхилләшер көннәре якынлашуын сизенгәч кенә әйтте. Нинди-
ер сылтау табып, Мәгъсүмәне аптекага җибәрделәр. Шуннан соң,
шекне бикләп, тәрәзәләрне ябып куйгач, карт үзенең серен чиште.

— Карт алмагачтан кыйблага таба бер адым киерелеп атлагач, бер
етр чамасы тирәнлектә булыр, кечкенә әрҗә бар. Анда синең гомереңә
китәрлек мал. Алтын беләзекләр, алтын балдаклар, бриллиант кашлы
езек, затлы колагалкалар, Гөлфия апаңа өлеш чыгар. Әмма ләкин
кияве йортына алып китмәсен, синдә сакласын... Кадерен белеп тот. Мин
үлгәч, бар җыйганымны җилгә очырма. Хәмер белән авызлана күрмә
ерүк. Ят хатын-кызга тагылма. Эһ дигәнче малыңны эт ялап ташлар.
Сизми дә калырсың. Касимский Ибрайның парахуты да итәк астына
ыйган, диләр... Авызыңнан җаның чыкканда да хатыныңа сер чишә
үрмә. Күзе туйганчы тыгынмаган чагында ачуы кабарса, сатачак...
Дөнья өч аяклы ул, аксап-туксап тора. Ә хатыннарга һәр даим дүрт
яклы булсын...

Әхтәм әтисенең васыятен нык тота. Дөрес, алтын-көмеш, асылташ
игәннәре инде алмагач төбендә түгел, киракса күз ачып йомганчы
лырлык җирдә. Әмма Шерлок Холмс кавымыннан булган ят күз дә
аба алмаслык урында. Турысын гына әйткәндә, атасыннан калган мал-
а эше теләлгәне юк әле аның. Хуҗалыгы — алпавытныкыдай.

Билалов юкка-барга шапырынмый, «Волга» алам дип хәлдән таеп
апмый, өере белән кунак сыйлап мактанмый. Мөмкин икән, аңсыз да
за икән — өенә кеше алып керми. Ишетеп белгән — бер хәл, күреп күз
ыздыру — үзгә. Помышы төшеп йортына килгән кешене капка төбендә
ейләшеп озату җаен карый. Эш урынында гәпләшүне хәерлерәк күрә.
зенең гозере килеп чыкса, ялынычы төшәр кешесенең өенә бара. Күч-
нәчен дә илтә, бүләген дә кызганмый. Бары ул дигәнчә булсын, фәкать
Әхтәм Билаловның сүзе аяк астында калмасын... Шадра Каюмның да
и сораса, шуның белән авызын томалар иде, өрмәсен генә иде. Юк,
-у-ук, тәкәббер хәерче шикелле ул Каюм. Дөреслек эзли, хаклык ярата,
меш...

диган булып, Әхтәм кирпеч заводы янына ук китеп барган иде. Заяг күпме җир урарга туры килде. Аның караве, җыелышта күнелен утырган юшкын кимеде кебек. Эт өрер, бүре йөрер. Бухгалтер Каюм төкерек чәчкәнгә карап тормадылар, партиягә кабул иттеләр. Шул хәт лесе дә зур кузыр. Аныкы өскә чыкмады. Югыйсә, авызына сугып жи бәргән малай шикелле йөрер иден. Шадра Каюмнан да кыерсыттырсаң Әхтәмлегең кай тарафларга җил булып исте диген инде...

Әхтәм капканы каерып ачып йортка узганда, хатыны Мәгъсума алъяпкыч итәгенә йомыркалар салган килеш өйгә кереп бара иде.

— Кайттыңмы? Озакладың бүген,— диде ул.

— Җыелыш булды.— Әхтәм моны сүз арасында гына әйтте шикелле.— Ничәне салганнар? — Йорт башын барыннан да битәр күкәйләр саны кызыксындыра иде.

— Унөч бүген, унөч...

— Теге паразит зыян салмаган, значит?

— Зыян сала алмаган, үзе эләккән. Якын җибәрми, бугазга ябышыр дай булып мыраулый, сыртын дугадай кабарта. Кыргыйланган гел.

— Аһа! — диде Әхтәм һәм, кадакка баскан шикелле сикереп, абзарга таба ашыкты.— Капкынга эләккәнме ыруы үчкере нәрсә?! Мин аны хәзер...

Тавыклары әвеслектәге ояга йомырка салса, көнозын карамый торганда, күрше мәчесе зыян итәргә өлгергән чаклар була. Быел гына да дистәгә якын йомырканы эчәргә өлгерде инде ул мәче.

Әхтәм балта-пычкысы, настругы-ышкысы куелган сарайга кереп китте. Киләбе белән чөйгә асып куйган сумалалы җептән озын оч кисеп алды һәм аны чалбар кесәсенә тыгып, әвеслеккә менде.

— Эләктеңме, дармоед! — диде ул капкынга алгы аягының бот төбеннән килеп эләккән мәчегә. Аннары кесәсеннән җебен алып элмәк ясады һәм песинең муенына ыргытты. Әхтәм аны капкыны-ние белән сөйрәп төшерде һәм җепнең очын сарай кыегы астыннан сузаеп торган бүрәнә өстеннән уздырып тартты.

Өйгә керер алдыннан ул кулын кат-кат юды. Сабын белән дә, комлап та, самовар агартырга дип төеп куйган кирпеч оны белән дә ышкып юды, ләкин һаман ниндидер ят ис килгән төсле булды. Трюмо тумбочкасы тартмасыннан «Шипр» одеколоны алып учына салды. Кырынгач та бу кадәр юмартланмый торган иде, бүген кулын да исле май белән юды.

— Җаны җәһәннәмдә разбойникның! — Дөнья бәясе эш башкарган шикелле, Әхтәм мактанып куйды.

— Нишләттең? — Мәгъсүмә имәнеп китте, тавышы яшелле-күкле булып чыкты.— Үтердеңме әллә?

Әхтәм берни дә юк диган кыяфәт белән өстәл янына килде һәм чәй ясарга үрелде.

— Астым разбойникны!

— Ә-ә?

— Астым дим.— Ире чәй агызырга дип алган кечкенә чәйнекне кире урынына утыртты һәм уң кулы белән муенына элмәк салган хәрәкәт ясап, имән бармагы белән түшәмгә күрсәтте.— Мать якасына! Кыйбатка төште ул... Ничә йомырканы эчте...

Мәгъсүмә авызына капкан ризыгын көч-хәл белән чәйнәп йотты. Шуннан соң да аш юлында төер булып торды әле. Ясаган чәен бер читкә этәрде. Ризык үтмәс булды.

— Мәче җәлләгән булып, кылтамакка әйләнеп утырма! — дип акайды аңа ире.— Тапкансың кызганыр нәрсә. Күзеңне ачыбрак кара, дөнья бу! Хут куйсаң, үз тиреңне тунарга да күп сорамаслар.

ның колагыннан һаман да булса шадра Каюмның сүзләре китми йөдәтә иде. «...Коммунистның коммунистлыгы, ул кайда гына эшләмәсен, үз интереслары кабыгын ярып чыгудан, халык интереслары масштабларына күчүдән башлана». Син күч, шадра шайтан! Сиңа күп кирәк. Телевизор колгасы бик туры да, аның да очына аркылы тимер сугалар...

Әхтәм, пижамасын киеп, хат ташучы күптән түгел генә китереп киткән газетаны караштырырга кереште. Гадәттә, дүртенче битләрне укырга ярата ул. Анда радио һәм телевидение программасы була, футбол хәлләрен язалар, кайчагында фельетон да укырга мөмкин. Тик шунысы читен: газета тотып яттымы, күз кабакларына таш асып куялармыни, йомылырга гына торалар.

Хәзер йокыга таласын уйлый-уйлый ук Әхтәм күзләрен йомды. Бераздан «бүрәнә сөйрәтә» башлады. Мәгъсүмә аяк очларына гына басып килде дә зал ишеген япты. Үзе тавык та чүпләп бетермәслек йорт эшләренә чумды.

Кичке тугыз якынлашканда, кемдер капка кыңгыравын җилле генә тартты. Әхтәм, чоландагы электр лампасын кабызып, аягына килбәтсез зур резин галошлар эләктерде һәм капка ачарга чыкты. Капка төбендә райсоюз складында эшләүче күрше чуваш басып тора иде. Ул шактый гына төшереп өлгергән, шулай да аягының тотрыгы китмәгән иде әле.

— Хәерле кич, Әхтәм Шакирыч! — диде күршесе һәм көрәктәй кулын Билаловның учына көчләп тыкты. Алай гынамы соң, Әхтәмнең кулын каты итеп кысты. Тегесе сер бирмәс өчен генә сүз әйтми калды.— Төнлә синең резиденциягә һичнинди церемониясез килеп төртелгән өчен гафу сорыйм. Олы җанлылык күрсәтсәнә, зинһар, кичер. Йомыш шул: иртәгә тугыз ноль-нольгә кадәр червонец кирәк. Артык та түгел, ким дә түгел, нәкъ червонец. Нәрсәгә дип сораштыру хокукым юк дип сана. Төпченеп тору синең тарафтан неэтично булыр иде. Моныс дипломатия инсафлыгына сыймаганын син белергә тиешсең. Бирми калу варианты шулай ук көн тәртибеннән чыгарып ташлана. Болай эшләү өчен объектив сәбәпләр дә, субъектив сәбәпләр дә юк дип беләм...

Әхтәм бурыч бирергә дигәндә чырай сытмый калмый. Авызы пешкәләгәне бар. Кулың белән бирәсең, аягың белән эзләп йөрисең. Юк шул дисәң, бирмәсәң, бер генә тапкыр начар буласың. Үз акчаңны үзең кабат сорап йөрергә калгач, сиңа ничә мәртәбә ачулары чыга. Әнкечеләр белән бөтенләй каберең якын булмасын. Артлары кызган чакта фәлән көнне, фәлән сәгатьтә артыгы белән китерә алам дип, пәйгамбәрләр исеме белән ант итеп теләнәләр. Ачуым да бер килмәгәе, урман бете шикелле ябышалар. Мөгаен, кызып алгач, акчаны тиз һәм ансат табар төсле булалар инде. Иртән — дөнья буш. Баш чатный. Кесәдән җилләр исә, бәгырьне хәмер кисә. Бурычка алган сумнар да парга әйләнгән... Көт син шундый кешенең әҗәтне тиз генә китергәнен...

Бу күршесе андый вәгъдәсез бәндә түгел. Анардан шикләнмәскә, шыгаймаска мөмкин. Җир тишегеннән булса да табып китерә. Ул җәһәттән тегәллеген белгәнгә, Әхтәм боргаланып бер сүз дә әйтмәде, нигә кирәк дип сораштырмады, «Хәзер алып чыгам», дип өенә кереп китте.

Чалбар кесәсенең уңын карады, сулын карады, акча юк кына. Ә бит анык белә: таушалган бер унлык бар иде. Бар иде, бар! Менә бакыр тиеннәр монда, кәгазь акча юк. Җыелыштан кайтуынча бер җирдә тукталмады, бер нәрсә дә алмады. Кая китәр ул унлык? Чөйдәге пинжәк кесәләрен айкады. Юк инде, юк...

Капка төбендә кеше басып тора. Әхтәм мыштырдаганны көтеп, күрше шунда кич кунмас ла инде... Йорт башы, ачкыч табып, комод тартмасыннан акча алды, тегеңә чыгарып бирде. Чуваш агай күнеллеләнеп, рәхмәт дия-дия китеп барды. Әхтәм өйгә кергәндә күзе-кашы җыерылган, зәһәрләнүдән мыек төкләренә тикле тырпайган, йөзенә явызлык

шул сорауны тукып типте.

— Кем иде ул? — Әхтәмнең бәгыре көйрәгәнен белмәгән Мәгъс гадәти бер кызыксыну белән сорап куйды.

— Илья! — диде Әхтәм, бар ачуын тышка түгәргә теләп.— Ник і гән, йомышы нәрсә дип тә төпчен. Бурычка акча сорап торды. Бирде диген. Бирдем.

Мәгъсүмә аптырады. Ни булды әле иренә? Көтмәгәндә нинди че тешләде?

— Тәмсезләнештегезме әллә, Әхтәм? — Мәгъсүмә иренең йөз текәлде. Әхтәмнең чыраенда буран уйный иде. Ул, кисәктән генә ха нына борылып, балта белән чабып өзгәндәй сорау бирде:

— Кесәдән акчаны син алдыңмы?

— Ниткән акчаны? Кайсы кесәңнән? Кайчан?

— Кып-кызыл акча. Унлык. Чалбар кесәсеннән. Мин яткач. Сор ларың беттеме? Беткән булса, җавап бир, алдыңмы?

Мәгъсүмә тораташ төсле хәрәкәтсез калды. Ничә ел бергә го итеп, Мәгъсүмәнең ире кесәсенә бер тапкыр да кагылганы юк. Кесә ак ру аның акылына да килми иде. Шунлыктан «Акчаны син алдыңмы дигән сорау яңагына чалтыратып, күзеннән очкыннар очырганнан артыграк булды.

— Беләсең бит үзеңнән рөхсәтсез бер тиенгә дә тотынмаганны. Ке ләреңә тырнак та тидермәгәнне дә беләсең. Ник алай рәнҗетәс Әхтәм? — Бар көчен җыеп, Мәгъсүмә шулай гына дия алды. Тамагын кайнар төер укмашып, тынын кысты, күзләренә яшь тулышты. Иренна менә-менә сытылырга җитешеп калтыранды.

— Рөхсәтсез тотынганың юк иде. Ә унлык кайда соң? Җилгә очка мы? Парга әйләнгәнме? — Әхтәм давылланып зал ягына үтте, диванн аргы башына барып утырды һәм бер тезе өстенә икенче аягын атланд рып, башын читкә борды. Ярсынуы чамасыз иде. Сул кулының ба бармагы тырнагын тешләштерергә кереште. Мәгъсүмә дә, аның кояш көндәге күләгәсе кебек ияреп, диванның бирге башына килеп елышт Питон елан үзенең корбанын суыра иде дип белерсең. Хатын бугазын калкынып торган төерне эретеп җибәрмәкче булып азапланды, ләк ул аны иза чиктерә бирде.

— Акча дигәндә, салам да селкетмәгәнемне ни гомер күреп яшис ләбаса, Әхтәм,— дип янә сүз катты ул, чөнки аңлашырга, ахмаклар буталчыкны ачыкларга тели иде.— Нахак сөйләгәнне күтәрүләре ач ның ачысы бит ул. Үз зарплатамны да сиңа кайтарып бирәм ич. С сатканның да, күкәй сатканның да акчасы синдә. Алманы икәү янәш басып сатабыз. Балны базарга ялгызың гына алып чыгасың. Анысы кагылганым да юк...

Хатыны хәйләлидер, шуңа тәтелди, шуңа шыңшыйдыр төсле тоелд аңа. Әткәсе мәрхүм: «Карак карганыр, уйнашчы елар»,— ди торган иде Бик дөрес әйткән!

— Моңа тикле кулың кыска иде, туры иде. Анысы хак,— диде Әхтә шырт-шырт тешләп өзгән тырнак кыйпылчыкларын идәнгә төкереп.— Бүген кытай фокусы күренде. Болайга киткәч, сум теткәзеп булма Нигезнең үчүе шуннан башлана...

— Әхтәм дим...

— Дәшмә! «Дөнья малы ашаганнан бетми, читкә ташый башлага төтми». Менә фокус шул була ул...

Ире әйткәннәрнең тулы мәгънәсе Мәгъсүмә аңына бераздан гын барып җитте. Шуны аңлап алу аны тагын бер сискәндереп җибәрде Әйтерсең лә, аның өстенә кемдер чиләкләп салкын су койды. Шул сис кәнү аңарда көйдергеч нәфрәт кузгатты. Еламсырап торуы кул белә

ырып алган сыман юкка чыкты. Тамагындагы төер кайдыр эчкә
эшеп югалды. Тавышы кайтты.

— Бу сүзләрне мин Азатка синнән акча урлап бирергә җыена дип ңларгамы, Әхтәм? — диде ул, диваннан капылт торып. Ире, әллә өстемә чып кунамы бу хатын, дип тә уйлап алды бугай, үзе дә сизмәстән, бер иткә тартылып куйды.— Шулай диюенме?

Әхтәм тиенгә-тиен туры җавап бирергә җыенмый иде.

— Теләсәң ничек аңла. Минем өчен факт шул: унлык җилгә очты.

— Әгәр бер гөнаһсыз Азатны да бу эшкә катнаштырып, миңа шундый яла ягасың икән, мин мәңге бәхилләмәм сине, Әхтәм,— диде Мәгъсүмә.— Бу тикле пычрак атуың өчен, соңгы сулышымны алганда да бәхиллек бирмәячәкмен...

Әхтәм эченнән: «Синең бәхиллегең белән тун тышлап буламы соң?!» — дип сүгенде, ләкин теленә бүтән сүз чыкты.

— Кем кемне бәхилләргә тиештер бит... Малы җилгә очкан кешеме, үтәнме... Әйт, алмадым диген.

— Ант итәм, Әхтәм, кесәңә ялгыш та орынмадым. Икмәктер миңа.

— Ипигә кагылма, юньсез!

— Ни хәл итим, аптырауның чигенә җиткәч әйтәм. Бүтәнчә каргана а белмим.

— Балам белән ант итәм, алмадым диген!— Әхтәм тәмам шашынды. Мәгъсүмәнең ипи тотуы аны шулай исәрләндерде. Малае хакына урлауын антлар итә-итә томалап калмакчы була дип, үзен-үзе өзгәләде ул.

— Итәм, балам белән дә ант итәм. Намусым чиста, йөзем ак.— Мәгъсүмә соңгы чик тилмерү белән шул сүзләрне әйткәч, нихәтле генә ыелырга тырышмасын, булдыра алмады, өстәл янына барып утырды а, беләкләренә башын салып, үкси башлады.

— Тикшер, кара, тенте әнә, ышанмаслык булгач. Әгәр кул сумкамда тыз сумнан артык акча булса, йөземә төкерерсең. Анысын кофта ал ип, үзең биргән идең... Тиздән ай була инде, тиенең дә киметкәнем юк...

Әхтәм йорт ягы тәрәзәсе буена барып басты. Мәгъсүмә бер читтән ның текә мангаен, ятсынып, ниндидер әшәкедән җирәнгән төсле кысылган иреннәрен күрде. Күз ачып кына йомган арада ул ире өчен дә, үзе өчен дә куркынып китте. Үзенең энә очы кадәр дә гаебе юклыгын белә орып, ипи белән, балаң белән ант тоту — түбәнсенү. Хаклыгыңны ничек расларга, гомер иткән иреңне ничек ышандырырга, аның шиген ни әвешле юкка чыгарырга соң?

Әхтәм тынды. Чамадан чыгуын искәреп алдымы, әйтер сүзе беттеме, артык эндәшмәде. Чишенеп ян бүлмәгә кереп ятты. Мәгъсүмә бик озак стәл янында утырды. Ул мингерәп калган иде. Башы буш, гүя барча уй-фикерен җилгәреп чыгарганнар. Алай да кеше төне буе сын шикелле утыра алмый ич. Торды. Казларын лапас астына япмаганлыгы исенә төште. Чучкага да төнлек азык салмаганын хәтерләде. Кулына кесә фонаре алып, ишек алдына чыкты. Инде тәвәккәлләп ишек алдында уйнарга җыенган казлар уянып кангылдаштылар. Мәгъсүмә аларны лапаска куып кертеп аргы бүлемгә япты. Юкса, бөтен җирне пычраталар.

Чыгарга борылгач, фонарьдан төшкән нур сузымында кинәт аның күзенә бер нәрсә чалынды. «Чү! Шул түгелме? Шул лабаса! Шул билләһи! Дүрткә бөкләнгән, таушалган унлык. Я алла, күпме сүзгә, нинди тамсезлэнүгә сәбәп булды. Бая мәче белән әвәрәләнгәндә төшергән инде моны Әхтәм. Кертеп бирим, тынычлансын...»

Секундның да ниндидер бер өлешенә генә Мәгъсүмәгә бик рәхәт, гаҗәеп җиңел булып китте. Өстенә бастырып куйган тегермән ташын кубарып алдыларммыни! Менә, ичмасам, йөз аклыгы расланды. Әхтәм оялыр, гафу үтенер. Кемдә булмый инде көйсезләнеп, кызып киткән чаклар. Хәләл тиеннәр, хәләл сумнар бит...

бирәм, ләкин Әхтәм дөрес аңлармы? Фаш иттем, кәкре куллыга әйләнеп баручы хатынымны караклыгы өстендә тоттым, бичарадан ничара, хәйләгә сабышып, тыштан тапкан төсле итеп, акчаны кире бирде дип юрамасмы?» Мәгъсүмә шундый икеләнү эчендә калды. Алай түгеллеген ул ничек расльй ала? Юк, берничек тә исбатларга көче житмәячәк. Әмма акчаны бирергә тиеш ул, бирергә! Теләсә ничек уйласын. Анысы үз намусына калыр. Барысы аның вөжданына куела. Йөрәгеңне ярып күрсәтер хәл юк...

Акча табылуны Әхтәм бик тыныч, хәтта, әйтергә мөмкин, чиктән тыш тыныч кабул итте. «Ярар, табылган — яхшы булган, мин хаталангаммын»,— дип әйтсә, гаиләдәге өермә тынасы иде инде. Иргә чыкканнан бирле азмы әр ишеткән, азмы шелтә күргән Мәгъсүмә күңелендә тагын бер яра җөе калса калыр иде,— ул җөйләрне берәү дә күз белән күрми, берәү дә бармагы белән капшап санамый — йортта гауга тынар иде. Мәгъсүмәнең йөзе ак, намусы пакь булыр иде. Әхтәм исә борчуларны басардай сүз әйтергә уйламады.

— Табыла тагын насыйп мал! Әллә кайда да булмаган икән! — дип мыгырданды да йөзе белән стенага борылып ятты.

— Монысы ни дигән, Әхтәм? — Мәгъсүмә янә үтә ачыргаланып сорамый чыдамады.

— Татарча әйттем бит! — диде Әхтәм һәм ятак җәймәсен башыннан ук ябынды. Аның Мәгъсүмәгә ышанмавы ачык иде.

Иренең ышанычы югалу, бөтенләй гаепсезгә аның карашында пычрак ниятле, кәкре куллы кеше булып калу ихтималы Мәгъсүмәне чыгырыннан чыгарды. Ул шушы минутта җир убылса, җир упкынына кереп китәр иде, якты дөнья белән мәңгегә бәхилләшүенә дә үкенмәс иде шикелле. Аның аңында «үз-үзеңә кул салу менә шундый вакытта буладыр» дигән фикер кабынып сүнде. Бик тиз сүнде, бүтән елтырамады да. Мәгъсүмә бармакларын шундый итеп йомарлады, тырнаклары учына батып керердәй булды. Ул, шомлы уйлардан, җан бизгәгеннән тиз-тиз арынырга теләп, башын чайкады. Аннары үз-үзенә катгый әмер бирде: «Мәлҗерәп калма, Мәгъсүмә! Бүгенгедәй кимсетүләр генә ябырылган идеме сиңа теге елны? Чиләбедән чыгып китүе ансат булдымы? Ярты жаның анда калды бит ул чакта. Аккүлдә тернәкләнеп китүе җиңел булдымы? Азатның дөньяда барлыгын Әхтәмгә әйткәч, азмы кыен ашадың син! Түздең бит. Хәзер чыдарсың да чыдарсың. Чыдарга тиешсең. Һөнәрең бар. Эшләп тора торган менә дигән хезмәт урының, һәр чакта ярдәм кулы сузучан коллективың бар. Танышларың, дусларың, өлкән киңәшчеләрең бар. Буеңны төз тот, башыңны күтәр!»

Өстенә плащын, аягына туфлиен киеп, башына ефәк яулыгын бәйләде дә Мәгъсүмә урамга чыкты. Әхтәм капка ачылып ябылган тавышны чылтырап келә төшүен ишетте, ләкин селкенмәде дә. Хатыны төнлекккә капкаларны бикләп йөридер дип уйлады. Болай фараз кылырга җае да бар иде. Күпме бергә яшәп Мәгъсүмәнең һичкайчан йорттан чыгып киткәне юк иде... Мәгъсүмә кермәде дә кермәде. Әхтәм аны болдырда утырадыр дип исәпләде. Шуңа җилкенеп, сүгеп кертергә җыенган хәлдә, чоланга чыкты. Анда да күренмәгәч, ишек алдына кычкырды:

— Мәгъсүмә! Кайда йөрисең? Йокларга вакыт...

Каршы тавыш булмагач, шалт та шолт ишек бикләрен эшереп, Әхтәм урынына ятты. Ул әле уңга әйләнде, әле сул янбашына борылды һәм үзалдына: «Йөрсен әле мәче башлы ябалак кебек төн уртасында! Киртә аша сикерә башласа, киртәдә кунар. Сыер да ашаган җиренә кайта. Кайтыр, җәһәннәменә олаксынмы?!» — дип пышылдап сөйләнде.

Бу вакытта Мәгъсүмә мәктәпкә, Мостафа абзыйлар квартирасына килеп җиткән иде инде. Әкълимә түти белән Мостафа абзый, аның сөнлап йөрүенә бераз гаҗәпләнсәләр дә, «Ни булды, сеңелем?» дип, чатыр-

ютыр сорашырга ябышмадылар. Баштарак, берни дә юк төсле, сүз рә-
зешенә китереп вак-төякне сөйләшеп утырдылар. Тора-бара «Әхтәм кияү
иләр майтара?» дигәнгә ялгап, Мәгъсүмә гаиләдәге бүгенге тәмсезлә-
гүне сөйләде. Азатның дөньяда барлыгы хакында Әхтәмгә әйткән елны
ук үз хәлен картларга да белгерткән иде. Картлар Азатны әйбәт беләләр
иде инде.

Әкълимә түти, гадәтенчә, Мәгъсүмәгә җаны-тәне белән теләктәшлек
итеп тыңлады. Күңеле тулышып, яулык чите белән күз тирәләрен дә
сөрткәләп маташты. «Әй, кыз баланың күрәселәре!» — Ул һаман шул
көмләсен кабатлый торды. Мостафа абзый исә тыңлап торды-торды да
уйга батты. Мәгъсүмәне юатмады, киңәш-фәлән бирмәде, чөнки хәлнең
катлаулы, чуалчык икәнен аңлый иде. Хикмәт, мәгълүм инде, югалып
табылган улныкта гына түгел. Эшнең нигезе Азатның баш калкытып,
Аккүлгә килеп чыгуында. Аның дөньяда барлыгында. Мәсьәләнең иң
куркысы — Мәгъсүмәнең соңгарып булса да баласы алдындагы гөнаһы-
ын киметергә тырышып, Азат дип җан атуында, хәзер инде ансыз яши
алмавында, хатыны күңелендә Азатның яңадан терелүе белән Әхтәмнең
пычакка-пычак килүендә. Акча дигәндә, ул инде Билаловның гомерлек
ире. Аңардан Әхтәмне кабер генә арындырыр... Сүз, әлбәттә, көндәлек
ихтыяҗга, тормыш хаҗәтенә китә торган сумнар турында түгел, сүз акча
орты хакында, кешенең кешелеген суырган байлык җыю хакында...

Мостафа абзыйның хәтереннән бер күренеш һич җуелмый. Күренеш
ип авыз тутырып сөйләрлеге дә юк аның болай. Бер балык күз алдын-
ан китми. Зур чөгә балыгы.

Әхтәм Мәгъсүмәгә өйләнгән елны булды бу. Ул чакта мотоцикл тан-
ык иде әле. Ә зооветснабта бар иде. Әхтәм яшь хатынының әтиседәй
үргән Мостафа абзыйны, шуңа утыртып, балыкка алып китте. Июнь
загы идеме икән, әллә август кергән көннәрме? Кармак та алмадылар,
сәтмәләре дә юк иде.

— Кәгазь кармакка тотабызмы, Әхтәм энем? — дип шаяртты Мос-
тафа абзый.

— Кармаклар биштәрдә, Мостафа абзый. Мукшы агай-энеләр шун-
ые белән дә гаеп итмиләр.— Әхтәм хәйләле елмайды.— Иделгә бара-
быз. Ундырь тирәсенә. Кунып кайтабыз...

Идел буендагы балыкчылар бригадасында биштәрдә килгән «туксан
атылы кармак», чыннан да, бик абруйлы булып чыкты. Атналар-айлар
уе Иделдә ятып, тирә-юнь авылларның кибетләреннән әҗәткә ала-ала
шаныччларын какшаткан агай-эне Әхтәмне күккә чөеп мактады. Моста-
фа абзый белән икесен дә уха белән дә, кыздырган балык белән дә сый-
адылар.

Иртәгесен иртүк балыкчылар башлыгы кәрзингә шыплатып чөгәләр
өяде. Аны капчык белән томалап бәйләде, астына үлән җәеп, мотоцикл
ишегенә урнаштырды. Балыкчы агай-энеләр:

— Сау бул, Әхтәм! Тагын кил, яме! — дип озатып калдылар.

Аккүлгә җитәрәк, яшь наратлык буенда, Әхтәм мотоциклын туктатты
әм кәрзинне җиргә алды. Мостафа абзый «Нишли икән бу?» дип торса,
Әхтәм беләк буе чөгәләрне ике кучкә аера башлады.

— Артыңа борыл, Мостафа абзыкай гынам! Кычкыртам! — диде
Әхтәм. Абзый борылды.— Монысы кемгә?

— Башлап йөргән кешегә, сиңа булсын! — диде Мостафа абзый
әм ялт итеп Әхтәмгә таба карады. Һай, шул чак аз гына, чирек минут
кына сабыр итсә, хәерлерәк буласы икән. Кайсын кемгә дип атауны
көткән Әхтәм күз явыңны алырдай зур бер чөгәне кулына тотып торган.
Юлдашы башлап йөрүчегә булсын дип ризалык кычкыргач, шул балык-
ны тиз-тиз үзенә дигән кучкә ташлады. Аптыраган иде Мостафа абзый
ул халгә. Ләкин аптырап кына да калмаган иде. Шул көнне үз тирәсендә
уалган бер кеше күңелендәге вакчыллыкны, гаделсезлек чаткысын,

туп-туры итеп әйтсән, әшәкелекне тойган иде. Хикмәт бер балыктамыни? Бөтенләй бирмәсә дә сүзе юк иде. Инде боларга уйлагач, үзеннән-үзе урлап шулай кылануы... Иллә дә ачуы чыккан иде Мостафа абзыйның. Дөрес, абзый бу хакта Әхтәмгә сыңар сүз дә әйтмәде... Тик менә ничә ел буе шул чөгә аның исеннән чыкмый.

Әле Мәгъсүмә «акча югалу» галәмәтләрен сөйләгәндә дә, Мостафа абзый күз алдында Әхтәмнең йонлач кулындагы чөгә балыгы торды.

## 11

Одессадан район үзәгенә кадәр Хафиз такси яллап килде. Көн матур, юл яхшы булгач, йөз километрга якын араны узу әллә ни озак һәм ялыктыргыч тоелмады. Шау яшеллеккә чумып утырган район больницасы шәһәрчегенә житкәндә, Кадергуловның кәефе әйбәт иде. Якягында яшел койма төсле тоташ куаклар үсеп утырган асфальт юл буйлап ул төп корпуска таба китте. Аңа стационарда дәваланучылар — соры халат кигән, аякларына ямьшәйгән йомшак туфлиләр элэктереп чыккан ир-ат, хатын-кыз һәм башкалар очрады. Поликлиникага килүчеләр дә үтеп-сүтеп йөри иде. Менә ак халат кигән озын буйлы, күе кара чәчле, йөз торышы белән чегәннең чибәренә охшаган бер ир (мөгаен, врачларның берсе инде) төп корпустан чыгып, Хафиз каршысына атлады.

— Исәнмесез? — дип сәламләде аны Хафиз.— Гафу итегез, Елена Семеновнаны мин кайда күрә алам? Әйтмәссезме?

— Баш врачны сорыйсызмы? — диде чегәнгә охшаган ир.

— Әйе.

— Ул хәзер операциядә. Берәр сәгатьсез бушамастыр. Сер булмаса, сез кайдан? Одессаданмы әллә?..

Хафизны облздравтан берәр кеше дип юрадымы, яисә газета-журнал кешеседер диебрәк уйлап алдымы, халатлы иптәш кызыксына башлады.

— Сез өлкәдәнме? Нинди йомыш белән? Бәлки баш врачның урынбасары белән сөйләшү дә житәдер, диюем. Әгәр шулай икән, рәхим итегез, ул кеше мин булам. Район больницасының партбюро секретаре да. Бодюль, Михаил Сергеевич.— Ул күрешергә дип кул сузды.

— Күрешик, алайса,— диде Хафиз да.— Кадергулов. Мин ерак-еракта. Елена Семеновнага үз йомышым белән килгән идем. Көтәрмен.

Хафиз эскәмиягә утырып, аэропортта алган газеталарны караштырмакчы булды. Берсенең битләрен ачты, икенчесенә күз төшерде. Карашы газета юлларына тезелешкән хәрефләрдә, ирене кыймылдый, сүзләр укыла, ә акылга бер мәгънә дә барып ирешми. Шушында, шушы минутларда газета укып утырып буламы соң инде?!

Ул урыныннан сикереп торды, газеталарны бөкләп тотты һәм жиңел плащын беләгенә салып, үзәк аллеяга юнәлде. Капка ягына илле адым, корпуска таба кире илле адым... Тагын капка тарафына, янә кирегә. Үтмәсә дә үтмәс икән бу вакыт дигәнең! Берәр сәгатьсез бушамастыр, диде. Әле нибары унбиш минут узган. Нибары унбиш минут!

Күптән инде, бик күптән Хафиз вакытның болай терәлеп торганын кичергәне юк иде. Ул бары тик кырык бишенче елның августында, Ленинград госпиталеннән чыгасы көнне, туган авылына кайтып китәр сәгатьләр якынлашкач, минутлар атламас булган чакны исенә төшерде. Ул көнне дә аңа баш врач кирәк иде. Дөресрәге, аңа баш врачның имзасы зарур иде.

Аннан бирле чирек гасырга якын гомер узган. Ә Еленаны күрмәгәнгә егерме жиденче ел! Таный алырмы Хафиз аны?

Ниһаять, зарыктырган минут житте. Асфальт түшәлгән аллеядан арлы-бирле йөренүче Кадергулов янына Елена Семеновна килеп чыкты. Ак халатлы хатын-кызның якынлашуы игътибарны тартып алды дисәң, хак булыр. Елена Хафиз күңелендә тамырланып калган сыйфатларның

бик азын гына үзендә саклап калган иде кебек. Тәбәнәкләнгән шикелле, бәлки таза, итләч гәүдә шундый булып күренәдер. Уелып кергән нечкә бил юк икән инде. Толымнар да сагынып хәтерләргә генә калган. Баш врач чәчен кыска итеп кистергән. Юк, бу — яшьлегендәге Алтынчәч түгел инде. Алай да күзләр, таулардагы күл суыдай зәңгәр күзләр, һаман элеккечә. Алар үзгәрмәгән, бары тик уйчанлана гына төшкәннәр...

— Исәнмесез!

— Исәнмесез, Елена Семеновна!

Күрешкәндә Хафиз тагын бер нәрсәне абайлады: докторның куллары әүвәлгечә үк йомшак, нәфис.

Елена Хафизга текәлде дә телдән калгандай булды.

— Танымыйсызмы? Хафиз мин...

— Танымыйммы соң?! — Еленаның тавышы хәлсез иде. Үзенә дә чак-чак ишетелде, авазлар кайдадыр эчтә, күкрәк читлеге эчкәресендә сүнеп кала иде. Баш врач Хафизның күкрәгенә капланды һәм тавышсыз гына елый башлады. Аның җилкәләре гаҗәп дерелди иде. Хафиз уңайсызланып калды, дулкынланып Еленаның иңнәреннән тотты, ләкин әйтер сүз дә, юатыр мәл дә таба алмады. Бәхеткә, якында кеше юк иде, бәхеткә, бу халәт озакка сузылмады. Елена бик тиз үзен кулга алды һәм, аяз көнне яуган яшылы яңгырны хәтерләтеп, күз яше аша елмайды.

— Әгәр Владиславның хаты килмәгән булса, әгәр газетаны эзләп алып укымаган булсам, менә шулай каршыма килеп бассагыз да, танысам да, сез дип исемегезне атый алмас идем... Катлаулы-катлаулы да, тагын мең тапкыр катлаулы бу тормыш... Һай, гафу итегез, әйдәгез өйгә... Юл уртасына бастык та калдык...

— Мин дә һаман өнемме, төшемме дип торам әле. Елена да кебек, түгел дә...

— Картайганмынмы?

— Олыгайгансыз...

Елена Хафизны төп корпустан уң якка, квартирасына алып китте. Баш врачның тору урыны больница территориясендә икән. Хәер, Елена Семеновна гына түгел, тагын бер гаилә — ирле-хатынлы Бєдюльләр дә шунда яши икән.

— Сез юынып чыгыгыз булмаса,— диде Елена.— Ни сорашырга да белмим. Мин чәй хәзерлим...

Чыннан да, алар икесе дә, күктән төшеп, маңгайга-маңгай бәрелешкән кешеләр хәлендә калдылар. Сүз җиләме җитмәде, фикернең очы очка бәйләнмәде. Бик күптәнге якын, үз кешеләр бер-берсеннән ераклашкан, ятсынган иделәр.

Чәй янында әңгәмә акрынлап эзенә төште.

— Газетадагы очеркны укыгач, сез, Елена Семеновна, минем хакта хәбәрдар инде,— диде Хафиз.— Үзегез турында сөйләгез...

Елена Семеновна суынып беткән чәен авыз итте дә яңартырга булды. Аннары күзләрен тутырып Хафизга карады һәм ялваруга охшатып:

— Мөмкин булса, Хафиз Галиуллович, «син» дип кенә сөйләшик, пожалуйста,— диде.

— Бик мөмкин.— Хафиз сүзнең юл алуыннан канәгать иде.— Миңа әтинең исемен азрак кыскартыбрак эндәшәләр. Галиевич кенә диләр. Ә син... (Менә бит ул елларның каһәрле тәэсире, ансат кына «син» дип тә булмый икән, терәлеп калды!) син элеккечә просто Хафиз диген, Елена.

— Алайса, менә шул, Хафиз.— Елена кулъяулыгын битенә җилпеп алды. Кояш тәрәзәдән китәргә өлгерсә дә, көн эссесе бүлмә эчендә дә ялыктыч тәэсирен сиздерә иде әле.— Мин үземнең хәлләрне ике-өч авыз сүз белән аңлата алам. Озынга сузмыйча гына. Сине иң кызыксындыргапы — Владислав мәсьәләсе бит, әйеме? Турысын гына әйт әле, шулаймы, Хафиз?

— Ул бик мөһим мәсьәлә, Елена. Әлбәттә, безнең игътибардан читтә калмас дип уйлыйм. Синең тормышыңның житди бер кисәге бит.

— Дөрес.— Еленаның йөзе житдиләнде, ләкин ул сүзнең зурысына керешмәде әле. Тиз генә керешеп китә алмады. Шуңадыр, инде ничәнче тапкыр Хафизны кыстарга тотынды.— Кайнарлатыйкмы чәеңне? Безнең як вареньеларын авыз ит әле. Я инде, тартынып утырма, юл килгән кеше ич син...

— Рәхмәт, Елена. Кыстата торган гадәтем юк. Мин бит һәр көнне диярлек колхозларда йөрим. Даулап та ашарга туры килә.

Елена Семеновна, әңгәмәнең бүтән тыкрыкка борылуына куанган шикелле, Хафиздан райкомда эшләү четереклекләрен сораштырасы итте.

— Бик авырдыр, Хафиз, әйеме? Район зур. Хужалыклар күп тармаклы. Мин үзебезнең район житәкчеләренә карыйм да аптырап калам. Бер генә дә тынгы күрмиләр. Ашлык сат, ит хәзерлә, яшелчә һәм жиләк-жимеш күп булсын... Сезнең эш шуның белән бәяләнә. Әлбәттә, әлбәттә, син беренче чиратта кешеләр белән эшләү диячәксең. Дөрес, алда әйткәннәрне кешеләр башкара ич инде...

Хафиз, жилкәсен сизелер-сизелмәс кенә сикертеп, башын бер якка кыйшайтты. Ничегрәк җавап бирергә дигән чакта ул һәрвакыт шундый хәрәкәт ясый иде.

— Авыр дип... эшнең кайсы жиңел инде, Елена? Безгә, район житәкчеләренә дә, ансат түгел, билгеле. Партия аппаратында эшләү кешедән зур көч куюны сорый. Шәхси пландагы кайбер нәрсәләр торып торган чаклар да бар. Безнең эшне бәяләү дигәндә, син дөрес әйттең шикелле, оештыру да, тәрбияләү дә — һәммәсе искә алына. Кешеләр белән эшләү четерекле дә, үтә мавыктыргыч та ул, Елена. Житәкченең үзенә дә күпне бирә. Бары тик ярты-йорты эшләмәскә генә кирәк. Безнең эш моны бөтенләй сөйми, кире кага. Алай гына дию дә аз, ярым-йорты гына яшәргә юл куймый. Жигелгән килеш черем итүчене трассадан алып бәрә...

Кызып сөйли башлавын искәрүгә, Хафиз шып туктады һәм көлеп куйды.

— Партработник хезмәте турында лекция ошыймы, Елена? Мин менә шундый күп сүзлегә әйләнеп барам хәзер. Картаю галәмәтеме?

— Син яшь чакта ук бик тәмләп, дәртләнеп, иренми сөйли идең, Хафиз.

— Шулай да кеше сөйләгәнне тыңларга ярата төшәм. Сүз синә, Елена.

— Гөл-Төркемнән мин кырык бишенче елның мартында киттем,— диде Елена Семеновна. Аның хәтерендә узган еллар сызлануы яңарды.— Синең һәлак булу хәбәреңнән соң үземә-үзем урын таба алмадым. Өстәвенә, әти-әни турында берни дә белмәвем йөрәкне телгәли иде. Туры Донбасска кайттым. Ул еллардагы хәлне күз алдына китерәсең инде. Тормыш хәрабә арасыннан баш төрткән үлән кыягыдай иде. Хәлсезлек, ләкин яшим дип әрсезләнү. Дөньяның рәтләнүенә өмет зур иде, билгеле, зур. Бар байлыгыбыз шул якты өмет иде... Кайтсам, Донбасста жан өшеткеч хәбәрдән бүтәнне ишетмәдем. Әти партизаннар отрядына киткән булган. Аның аксаграк икәнен әйткәнем бар иде. Хәрәкәттәге армиягә алмаганнар. Ул фашистларның жәза отряды белән булган бәрелештә үлгән. Әнине, мескенкәемне, партизан хатыны дип атканнар... Поселоктагы йортыбызны яндырганнар...

Елена Семеновнаның сүзе янә бүленде. Сугыш узган туган төбәгенә кайтып төшкән көннәр фажигасе күңелендә баш калкыткач, ул әле һаман да тетрәнә, жаны чымырдап куя иде.

— Шул... Кара күмергә калган йорт урынына, әнкәй мәрхүмә кабseparatorренә карап яшәсәң, акылдан язарга мөмкин бит дигән фикергә килдем һәм, Гөл-Төркемнән йолкынып купкан шикелле, туып-үскән поселогымнан да чыгып киттем. Одессага килдем. Анда әнкәйнең туганнан туган

сеңелесе бар иде. Мең бәла белән аларны эзләп таптым. Больницага эшкә урнаштым. Көндез анда эшлибез, төннәрен шәһәрне җимерекләрдән арындырырга йөрибез. Бераздан хәрабәләр урынына яңа йортлар салына башлады. Төзелешкә булыштык. Дөнья михнәте белән тарткалашып яшәгән көннәребезнең берендә минем тормышыма Владислав килеп керде...

Хафиз, игътибарын җыеп, сораулы карап куйды. «Ничек Владислав? Аңа кадәр кем?» — ди иде аның күзләре. Елена Семеновна бу сорауны бик тиз төшенеп өлгерде һәм шуңа җавап биргәндәй:

— Әйе, әйе, язмышыма Владислав килеп керде,— дип кабатлады.— Инде шул хакта сөйлим...

Елена Семеновна уң кулының чәнчә бармак очы белән ирен читләренә тиеп алды.

Елена моннан егерме елдан артык әлегрәк булып узган вакыйганы искә төшерде һәм заманында күңеленә ничек кереп урнашкан булса, шулай хикәяли башлады. Хафиз да уйлары белән сугыштан соңгы Одессага юнәлде һәм Елена Семеновна сөйләгәнне күз алдына китереп барды.

...Кырык сигезенче елның язы. Шәһәрдә әүвәлгедән имин калган һәм моннан бер-ике ел элек кенә утырткан куакларның җете яшел яфракка чумып, чәчәк атарга дәртләнгән чагы. Җиденче больницага балалар йортының кечкенәләр группасыннан өч яшен әлерәк кенә тутырган бер малайны китерделәр. Ул үлем алдында иде. Моннан бер сәгать чамасы гына элек паркта йөгереп уйнап йөргән сабый җан бирергә җыена. Уенга мавыгып, нәни кызчыклар курчакларына яфраклардан «сый» хәзерләгәннәр. Шунда бер очтан «кунакка килгән» Владиславка да ашатканнар. Чырае качкан һәм куркынган малай тәрбиячеләр янына йөгереп килгән дә эче бик-бик каты авырта башлаганын әйткән. Шундук ул укшыйукшый коса башлаган, аяк-кулларын көзән җыерган һәм күп тә үтми малай һушыннан язган.

Ашыгыч ярдәм машинасының җан өшеткеч сиренасы. Ак карга төренгән төсле ак палата, ак халатлы врачлар, сестралар. Алар арасында Елена Солнцева да бар.

Малай тынын чак-чак кына ала. Аңга килми. Дежур врач эшен тәмамлап киткән бүлек мөдирен чакырта. Күпне күргән мөдир диагноз куя — токсикоаллергик энцефалит. Гади телгә күчереп әйткәндә, мигә дә зыян салган каты агулану. Парктагы куакларга күптән түгел генә агулы химикат сипкән булганнар. Владислав, күрәсең, агулы яфракны ашаган.

Көн узды, кояш баеды, караңгы төште. Бүлек мөдире дә, дежур торучы врач та, сестра Елена Солнцева да ятим сабый караваты янынн китмәделәр. Кулларыннан килгәннең барысын эшләделәр алар. Берничә тапкыр кислород биргәч, малайның хәле уңай якка авышыр төсле дә күренгән иде, бу яхшыру да озакка бармады. Бала янә аңын югалтты, аны янә көзән җыера башлады. Төн уртасында сулышы тукталды, пульсы тынып калды. «Малай үлде бугай» — барысының да күңеленнән шундый шиксез уй сызылып узды. Әмма тәҗрибәле врач нәни йөрәкнең әҗәл белән тартышып, бәлки соңгы кат талпынуын тойды булса кирәк. Медиклар бу халәтне клиник үлем диләр.

Бүлек мөдире инфекцион больницага шалтыратты. Анда Ленинградтан консультациягә чакырылган профессорның — реанимация буенча зур белгеч барын белә иде ул.

Профессор бик тиз килеп житте. Ясалма сулыш алдыра башладылар. Йөрәккә массаж ясадылар... Бер мәртәбә... өч... биш... Минутлар тәүлеккә әверелде. Ниһаять, хәлсез, бик хәлсез тереклек очкыны кабынды. Хәрәкәтсез калган йөрәк кылкынып куйды, малайның ирennәре дә кыймылдады шикелле. Аннары сабый тын алды...

Бүлек мөдире биш тәүлек буе Владислав яныннан китмәде. Елена да һаман шунда булды. Ял итәргә кушып карадылар, карышты. Һәр сәгать

саен баланың тын алуындагы үзгәрешне билгеләп бардылар, кулда булган барлык чараны кулландылар. Тагын бер атнадан малайны больницадан чыгарырга мөмкин булды.

Владиславны киендерергә булышканда, Елена Семеновна аның күзләренә карады. Сабыйның зур соры күзләрендә әйтеп бетергесез моңсулык бар иде. Нәни күзләрдәге шушы сагыш Еленаның бәгырен әйләндереп-айкап ташлады. Ул Владиславны үзенә алды.

Елена Семеновнаның бу адымын атларга этәргән иң зур көч нәрсә иде? Аңа төгәл генә, түгәрәк кенә җавап бирү ансат түгел иде. Ятимне кызганумы? Аны канат астына алып, җан җылысы бирергә омтылу теләгеме? Якыннарын, яраткан кешесен мәңгегә югалткан хатын-кызның үзенә иптәшкә сусавы, тормышта юаныч табарга омтылуымы? Тирәннән уйласаң, боларның һәммәсе дә булгандыр. Югыйсә, кияүгә чыкмаган килеш асрамага бала алу — кеше гомерендә була торган катлаулы хәлләрнең берсе ләбаса.

Кардәш апасы, үзе тол калган килеш балалар үстергән хатын, бик ярдәмчел, йомшак күңелле кеше, Еленаны ныгытып кисәтте. «Һай, туганкай, барысын да кирәгенчә исәпләп карадыңмы соң? Ул бит курчак түгел, аның мәшәкате бихисап булачак. Бала кечкенә вакытта беләккә авыр, үскәч йөрәккә авыр. Үзең әле укыйсым бар, врач булам дисең. Эшләргә дә, укырга да, балакайны багарга да бик тә читенгә килерен уйлыйсыңмы? Уллыкка алгач, гомере буе җавап бирәчәксең. Аны кеше итәргә кирәк ич»,— диде.

«Җан биргәнгә — җүн бирер, дигәннәр. Чыдармын, апа. Картаймышлы көнемдә сүз кушар кешем булыр ичмасам», дип җавап бирде аңа Елена. Карары нык иде аның.

Шул кадәресен бәян иткәч, Елена Семеновна тукталып калды. Хафиз ни әйтер дип көтүе булдымы? Хафиз да сүзсез торды. Аның көрсенүле сулап куюы гына ишетелде.

— Әсинең улың итеп яздыруым,— диде Елена Семеновна, Хафизэндәшмәгәч,— шулай ук аңлашыладыр дип беләм... Һәрхәлдә, болай итүнең нигезендә ни ятканын төшенәсең. Каһәр суккан сугыш пыран-заран иткән хыялларымны шул рәвешле булса да чынга ашырмакчы идем, үземчә...

— Барысын да бик аңлыйм, Елена! — диде Хафиз һәм, өстәл янынан торып, папирос чыгарды.— Мин тартып керимче булмаса...

— Тәрәзәләр ачык, монда гына тарт.— Елена Семеновна өстәлгә кечкенә сай тәлинкә куйды.— Ир-атсыз йортта көл савыты юк... Владиславны Хафиз улы Кадергулов итүдә, беләсеңме, минем хыялны нәрсә үсендерде? «Тапшырылмаган хатлар»дагы Галия тапкырлыгы. Исеңдәме, ул повестьны Гөл-Төркемдә үзең бүләк иткән идең?

— Андый хәлләр онытылмый, Елена.

Бу минутта алар икесе дә бер нәрсә хакында — Владиславка ничек җавап язу турында уйладылар.

— Безгә бөтенесе дә ачык хәзер,— диде Хафиз һәм сүзен ярты юлда өзде. Ни әйтергә теләгәне аңлашыла иде. Шунлыктан Елена:

— Мин Владиславка хат яза башлаган идем инде,— дип ялгап китте.— Ике-өч тапкыр кулыма каләм алдым, тик менә терәләм дә калам. Беләм, мин моны алданрак эшләргә тиеш идем. Һаман иртәдер төсле булды. Егет үсеп житсен, уй-фикере ныгысын дип көттем. Аннан соң, чынлыкны ачсам, аның күңеленә ямьсез эз генә салырмын дигән уй туды. Әйтмәү хәерлерәк булмасмы дип икеләндем. Одессадан бу районга күчкәндә дә максатым Владиславны уллыкка алганны белүче кешеләрдән ераграк яшәү иде. Хәзер инде хәлләр болай булып киткәч, аңа барысын бәйнә-бәйнә әйтеп язарга кирәк. Ул миңа рәнҗемәс дип ышанам. Рәнҗемәс. Мин аның өчен берни дә кызганмадым. Аякка бастырдым. Кеше иттем. Олы җанлы, бик итле егет ул. Мине аңлар дип беләм. Әсиннән, Хафиз, һәммәсе өчен гафу сорыйм.

Икесенә дә гаять кыен булып калды. Эчпошыргыч тынлыкны Хафиз бозды.

— Минемчә, гафу үтенерлек урын юк, Елена,— диде ул, дулкынлануын ничек тә яшерергә тырышып.— Син зур эш эшләгәнсең. Турысын әйткәндә, батырлык бу. Хатын-кыз батырлыгы, гражданлык кыюлыгы. Ә Владиславка, әлбәттә, дөресен язарга кирәк. Диңгезче егет аңламый булмас. Язмыйк, бергәләшеп язмыйк.

Күңеле белән Хафиздан бүтәнчә җавап көтмәгән булса да, аның теләктәшлеген ишеткәч, Елена Семеновна иренен тешләп тә чыдаша алмады, күзләреннән бер-бер артлы яшь тамчылары тәгәрәде. Хафиз, һәрвакыттагыча, хатын-кыз күзендә яшь күрүдән кыенсынды.

— Тынычланырга тырыш, Елена,— диде ул, булдыра алганча йомшак һәм назлы итеп.— Тынычлан. Менә дигән егет үстергәнсең. Куанырга кирәк.

Әмма Елена Семеновна тынычлана алмый иде шул инде. Аның күңелендә ничә еллар дәвамында җыелып, басылып килгән хис тузгыды. Гүя ул хис тауларда озак вакыт кояш кызуы күрмәгән кар өеме иде. Дөнья булгач, һаваның төрлечәгә үзгәргән чагы була. Гомергә кузгалмас төсле булып күренгән бозлык та эри, тау елгасын ярларыннан ашындыра икән. Ә андый елга бер күтәрелдеме, юлындагы күпме ташларны тәгәрәтә, никәтле комны юып китә, кыяларга барып сугыла, үз юлына эреле-ваклы салават күперләре элә. Ялгызы бала үстергәндә, Елена Семеновна йөрәгенә азмы ташлар утыргандыр, азмы юшкын сарылгандыр. Ашкынгач, талпынгач, күпме кыяларга кагылып сыкрагандыр бу йөрәк!

Туйганчы елагач, Елена Семеновна яшь аша көлемсерәде. Ул үзен ниндидер гаепле кеше сыман сизә иде.

— Зинһар, гафу ит, Хафиз,— диде ул.— Йөрәккә әмер бирер хәл юк дигәннәре шушыдыр инде. Күпме авыруларны юатам, рухландырырга тырышкан булам, ә үз күңелемә йозак сала алмыйм.— Шулай диде дә ул кинәт ныгыды. Әйтерсең лә, күңеленә чыннан да бик салды.— Бер соравым бар, онытканчы сорыйм әле. Владиславтан хат килгәч, балаларың нәрсә диде? Мәликә апа беләме әле бу хәлне? Ул ни әйтте?

— Моны берәү дә белми әлегә. Сине күрмичә, ачыкламыйча торып, кемгә ни сөйлисең?! Фәкать өлкә комитеты секретаре белән генә уртага салып сөйләштек. Монда килергә рөхсәт аласы бар иде бит. Эшнең нинди чагы... Ә балалар зур инде хәзер. Бигрәк тә Ләйсән. Һәммәсен төшендерергә мөмкин. Монда килүемне өйдәгеләргә әйтүнең читенлеге юк, Елена...

Кичен Елена белән Хафиз Владиславка хат яздылар. Иртәгесен Кадергулов рейс автобусы белән китәргә җыенган иде, Елена Семеновна больницаның җиңел машинасы белән үзе озатып куячагын әйтте.

Юлда алар шул тикле гадәти сөйләшеп бардылар, һәр көнне күрешеп яшәүче кешеләр диярсең. Хәер, андый чакта сорыйсы сүзләр, үтенечләр, киңәшләр онытылып торучан була. Көтмәгәндә өскә ябырылган хәлләр һәм гайре табигый мохит урап алу бер мәлгә кешене мингерәтеп калдыра, күрәсең. Фикер тупланышына комачау ясый.

Билетлар теркәүне хәбәр иткәч кенә, икесе дә сискәнеп киткәндәй булдылар. Елена Семеновна машинадан бик зур сеткага сайлап тутырган көньяк җимешләре алып килде.

— Мәликә апага, балаларга безнең як күчтәнәче. Авырсынмый гына алып кайт инде, Хафиз, яме,— диде Елена Семеновна.— Безгә кунакка килсеннәр. Чын, чын. Ял итеп китәрләр. Күп итеп сәлам әйт үзләренә.

— Рәхмәт, Елена. Тапшырырмын.

Аэропорт дикторы самолетка утырта башлауны хәбәр иткәч, кул бирешеп саубуллаштылар.

— Хәерле юл, Хафиз!

— Бәхетле яшә, Елена!

— Читен булмаса, кайтып житкәч, бер-ике сүз язып сал әле, Хафиз яме?

— Язармын, Елена, көт, язармын...

Очкыч, жилгә каршы йөгереп, күккә күтәрелде. Башта ул канат жилпеми генә жирне күзәткән бөркеткә охшап торды, аннары, кечерәйгәннән-кечерәя барып, бик бәләкәй ноктага әйләнде һәм тәмам күздән югалды. Елена Семеновна исә аннары да бик озак кузгалмый торды әле.

## 12

Ләйсәннең сабыр канаты сынды. Таһирның берничә көннән бирле жанын кая куярга белмичә өзгәләнүен күреп тору ана галәмәт авыр. Дәресләр тәмамланып, унынчылар мәктәп капкасыннан шау-гөр килеп чыгып барганда, ул башын иеп, уйланып кына атлаучы Таһирны куып житте.

— Таһир, беравыкка гына сабыр ит әле.

— Нәрсә бар, Ләйсән?

— Бер атнадан бирле «Исәнме? — Саумы?» дан башканы сөйләшмичә, авызга су капкан шикелле йөреп булмый бит инде.— Ләйсәннең тавышында якын иткән классташын үгетләү генә түгел, инәлү авазы да ишетелеп киткәндәй булды.— Дуслармы без? Якын иптәшләрме? Әгәр шулай икән, ачыктан-ачык сөйләшик әле.

Таһир башта сүзгә саранланып маташса да, сөйләшә торгач, районүзәк уртасындагы бакчага төшеп житүләрен искәрми дә калдылар. Капкадан эчкә, үзәк аллеяга үттеләр, аннары стадион ягына каерылып кергән юлдан атладылар.

Куакларга табигать сары сулышын өрергә өлгерсә дә, зифа каеннар тиз генә бирешмәскә тырышып, яфракларын лепердәтеп утыралар иде. Гүя аларның да үзләре генә белергә тиеш эч сере бар. Яфраклар пышылдавына колак салудан өзелеп калган әңгәмәне тагын Ләйсән яңартты. Ул, башын борып, Таһирга текәлгән иде.

— Хәтерендәме, Таһир, яңа ел кичәсендә, чыршы әйләнәсендә парлап биегәндә, без бер-беребездән сер яшермәскә дип шарт куешкан идек?

— Синең белән сөйләшкәннәрне мин энәсеннән-җебенә кадәр истә тотам, Ләйсән, ләкин...

— Тагын шул «ләкин», «тик» һәм башкалар...

— Шулайрак килеп чыга бит, Ләйсән. Туп-туры әйтсәм шул: этинең үз-үзен тотышы борчый мине. Борчый гына дисәм дә дөрес үк булмый. Шул газаплый.— Егетнең әллә күңеле нечкәрде, әллә әйтер сүзен җаһәт кенә таба алмады, ул беразга тәрәлеп калды. Аяк астына иелеп, юлдагы чыбык кисәген алды да уң як балагына суккалап баргандай итте. Азаккача ачылсам, мин сөйләгәннәрне дөрес аңларсыңмы, гомумән, боларны сиңа сөйләү кирәкме икән дигәндәй, Ләйсәнгә карады.

Алда буш эскәмия күренде.

— Бер-ике минут утырыйкмы? — диде Таһир, ниһаять, үзен изалап торганнарны ачыктан-ачык уртаклашырга карар кылып. Ямьсез уйларын шартлатып өзгән сыман, Таһир кулындагы чыбыгын кырт сындырып читкә ыргытты. Утыргач, Ләйсәннең соравын, төпченүен көтмичә, сөйләп китте.

— Мине бугаздан алып газаплаган нәрсә шул: эти әнине ихтирам итүдән туктап бара шикелле. Ихтирам итмәдеме, бетте инде, кешенең күңеле суына. Әнигә авыр. Тыйнак холыклы ул безнең әни. Эти өчен, безнең өчен аһ итеп яши. Этине бик яратып та чыккан булгандыр, гомере буе безгә аның сәләте, белеме, карашлары киңлекне мактап сөйли, каләмле кеше, принципиаль кеше ул, ди. Хәзер аның үзенә карата суынганын сизеп, бик уфтана, кимсенә. Хурлана да, билгеле.

— Дәмин абый эчүгә сабыштымы соң әллә? Сүгенәме, сугышамы?

Таһир, әй, аңламыйсың ла син, диген төслерәк күңелсез генә елмаеп куйды.

— Түгел, Лэйсән, эш бөтенләй анда түгел. Аның бервакытта да чама белмичә эчкәне юк. Мәҗлестә ул — түр күрке. Кирәксә, шигырь укый, Есенинны, Блокны яттан шәп белә, Такташны ярата, Җәлилнең Моабит циклын сокландыргыч итеп укый ала... Кирәксә, җырлый, бии. Кешеләр аның белән гәпләшеп утырудан тәм табалар. Безне дә, әнине дә, ялгыш кына булса да, тәмсез сүз әйтеп кыерсытканы юк.

— Соң шулай булгач?

— Бүтән хатынны ярата башлаган бугай ул.

— Ә-ә? — Лэйсән сорау биргән килеш авызын ачты да калды.— Фәһимә апа кемгә ярамаган? Көне-төне эшли, больницада да, өйдә дә өлгерә. Бүтән хатын дигәнең кем?

— Ресторан буфетчысы Марзия апа. Аның квартирасыннан чыкканын ике тапкыр күреп, әнигә житкергәннәр. Бер юлы, чыннан да, кызмача да кайтты. Әни белән жилле генә әйткәләште дә...

Лэйсән чигә чәчләрен бармак очлары белән артка җибәреп, башын күтәреп куйды һәм, карашын еракка төбәгән хәлдә, сөйләп китте:

— Марзия апа, Марзия... Беренче карашка һич кенә дә начар уйламассың. Тымызык күлдә корт үйный диләрме әле? Ул да шулайдыр, алайса. Тик Дәмин абый аны ничек Фәһимә ападан өстен куя ала? Аңламыйм. Аңларга көчем житми. Аңлаудан баш тартам...

— Елгыр хатын ул, Лэйсән... Ә безнең әни ясалма төчеләнә белми. Күңелендә ни, телендә шул. Аннары мин үземчә болай да уйлыйм. Әни бит урта белемле медичка, фельдшер. Күп укырга, белем арттырырга вакыты да калмый. Әти эрудит ул. Бәлки шуңа да суынадыр, үзенә иш күрә алмыйдыр.

— Әйттең сүз! — Лэйсән эскәмиянең аргы читенәрәк күчеп утырды. Мондый сүзне кем сөйли дип, Таһирны ерактанрак торып карарга тели иде диярсең.— Беләм мин аның әдәбият-сәнгать нечкәлекләрен яхшы аңлаганын. Очеркларны да менә дигән яза. Лэкин... лэкин бит ул, шундый сәләтле икән, бергә тормыш иткән хатынына да булышырга тиеш. Минем әткәй әнкәйгә ничек ярдәм итә иде! Казанга барса да, Мәскәүгә юлы төшсә дә, «Менә, Гөлмәрьям, нинди шәп яңа китап алып кайттым. Башта син укы»,— ди торган иде. Пленумга, киңәшмәгә баргач, яңа опера тыңласа, яңадан көнен туры китереп, әнкәйне дә алып китә иде. Әнкәй өчен дип газета-журналлардан математика һәм педагогика буенча күпме мәкаләләр генә жыйды. «Бир әле бу эшеңне мин эшләп куйыйм, син укы әзрәк»,— дип, аңа ял бирергә бер дә онытмый иде. Гомере буе әнкәй белән киңәшеп кенә торды. Әнкәй авырганда, җыелышта сөйләргә дип язган докладын аңа биреп фикер сораганы әле дә хәтеремдә. Әнкәй укып чыкты да әйтте: «Кәефең кырылмасмы, Хафиз, докладың урта кул. Тыңлавын тыңларлар, бераүнең дә исендә калмас бит»,— диде. Беләсеңме, шуннан соң әткәй докладын өр-яңадан язды...

Лэйсәннең төп сүздән читкәрәк чыгуын исенә төшерергә теләгән кебек, Таһир:

— Кешеләр бөтенесе дә бер төсле булмыйлар бит, Лэйсән,— диде.

— Булмасыннар да! Кешеләр һәммәсе бер төсле булса, дөнья бик күңелсез булыр иде. Лэкин семьяда бер-береңә булышу, ярдәм итү мәсьәләсендә бөтен кешедә бер үк омтылыш яшәсә, начар булыр идемени? Әйт әле, Таһир, Фәһимә апаның редактор Муллин абый белән сөйләшеп караганы бармы икән?

— Нәрсә дип?

— Дәмин абый турында. Аның семьяга мөнәсәбәте турында.

— Юк.— Таһир баш чайкады.— Юк, юк. Сөйләшкәне юк. Сөйләшмәячәк тә. Мин әлегә аларга кушылып сүз катарга кыймыйм, шулай да әгәр әни минем белән киңәшсә, мин дә: «Нәрмә, әни!» — дияр идем.

— Ник?

— Якын кешеңне әләкләп йөр дә аннан соң тагын якын булмы?

Ләйсән, карашын очкынландырып, яңадан Таһир янына ук күчеп утырды.

— Өй эчендә нинди хәл булмас, сөйләмәсәң, беркем белмәс димәкче буласыңмы? Бөтен хикмәт тә шунда шул: гаделлек эзләү — әләкләү түгел, җан авазы, ачыргаланып кычкыру ул. Аны ишетмәү яки ишетергә теләмәү — җинаять. Семья җимерелергә торганда, авыз йомып утырыргамы? Кулыңдагы бәхетне ниндидер комсызның йолкып алуына риза-бәхил булып торыргамы? Шул булдымы эш?

Әмергә буйсынган шикелле, икесе дә урыннарыннан тордылар. Кайту ягына таба атладылар. Бакча капкасын чыккач, Ләйсән Таһирдан:

— Әгәр әткәй белән киңәшсәк? — дип сорады.— Ул безне аңлар. Киректә әниең белән дә сөйләшер. Ә, Таһир? Ник эндәшмисең? Бүген булмаса да, иртәгәдән калмый әткәй кайтып житә. Одесса өлкәсенә бик тизгә генә командировкага киткән иде. Аңлар ул безне, сине дә, мине дә... Аңардан тартынырга кирәкми, Таһир.

— Белмим шул, Ләйсән. Кадергулов абыйны мондый мәсьәлә белән борчу яхшы булырмы? Минем авыздан чыккан сүз икәнен чамаласа, эти ни дияр? Гомумән, сиңа сөйләп мин яхшы иттемме?

Ләйсән Таһирның тәвәккәл булуын тели иде.

Шуңадыр, бәлки, бер кавым артыграк батырланып та киткәндер.

— Беренчедән, мондый мәсьәлә, димә син. Райком секретаре өчен тормышта бернинди дә «тегенди», «мондый» мәсьәлә юк. Җанлы кешеләр язмышы гына бар. Әткәй үзе шулай ди. Аннары килеп, син үзең өчен шикләнмә. Әткәйнең сер сандыгы нык,— диде.

Кадергуловның «сер сандыгы»на килгәндә, кызы һичшиксез хаклы. Педагог тәҗрибәсенә партия работнигының такты да кушылган — шуңа күрә шундый. Ә Елена Семеновна белән очрашуын ул һич кенә дә сер итә алмады. Теләмәде дә. Күңеле кыткылдап, кымырҗып торды. Тау чаклы булып тоелган яңалыгын тизрәк кем беләндер уртаклашасы килде. Бу очракта иң элек кем белән уртаклашсын да кемгә сөйләсен? Әлбәттә, Ләйсәнгә, олы баласына, тормышны өлкәннәрчә аңлый башлаган, шулай аңларга тырышкан кызына. Дөрес, Ләйсән табигатендә әлегә аек акыл белән тыелгысыз ашкыну бил алыша. Бер карыйсың, ул гомер иткән кешеләрчә салмак фикер йөртә, һәммәсен бизмәнгә салып үлчи төсле. Икенче баксаң, бала да бала инде менә. Җилбәзәкләнеп китүе дә ихтимал, иркәләнергә дә каршы түгел, әтисенә аркаланып, аз гына борын чөереп куйган минуты да була. Ләкин сабыйлык кысасыннан чыкты инде ул. Аның белән тигез баскычтан торып сөйләшергә мөмкин һәм фәкать шулай гына сүз алып барырга кирәк.

Кешенең табигате кызык бит ул, әй! Баштарак олы кеше үзе балаларын рухландырырга, юатырга, фикер баетырга, нык тәпиләргә бастырырга дип җан ата. Баланың чабуга ябышып тәтелдәве кызык, тапкыр сүзе күңелгә хуш, хәреф таный башлавы — шатлык, буй тартуы — сөенеч! Гомер үтә торгач, күз салсаң, кеше дигәнең куанычны бүтәнчәрәк татуны өметләнә: баласы ингә-иң торып сөйләшерлек киңәшче булса икән! Баласыннан акыллы сүз, тотрыклы фикер ишетәсе килә. Бу инде кеше гомерендә икенче дәвернең ишек шакуы. Ул чагында баласы аны рухландыра, юата, фикер хәзинәсен аның белән уртаклаша. Картлар әйткәндәй, ата-ананың бурычка биреп торганын баланың акрынлап кайтарыр чагы җитә.

Шулай уйлап, Хафиз Казан аэровокзалына аяк басу белән, беренче эш итеп Аккүлгә, кызы Ләйсәнгә телефон шалтыратты.

Хафизның кәефе тагын да күтәрелә төште. Ул югында балалар исән-имин торганнар, өйдә һәрнәрсә үз урынында, үз җаенда. Монысы — әйбәт. Ләйсән күңелле сөйләште. Молодец, ичмасам, аның кызы!

Владиславтан хат килеп төшкәннән соң булган уйланулары, Одесса өлкәсенә ничек барып кайтуы һәм Елена белән сөйләшүләре, дингезче егеткә бергәләп хат язулары турында әтисе барысын да әйткәч, Ләйсән бер мәлгә аптырап калды. Мавыктыргыч, ләкин куркыныч һәм бик житди китап укыгач, шулай була. Шактый уйлап, әтисе хикәяләгәннәрне янә бер кат фикер сөзгеченнән үткәргәч, Ләйсәндә сораулар туды.

— Әткәй, сезнең Елена Семеновна белән яшьлектәге дуслыгыгызны әнкәй белә идеме? — Ләйсәннең беренче соравы шул булды. Әтисе биографиясендәге һәр адымны ул әнисенең тормыш юлына бәйләп, шул нисбәттән карарга күнеккән. Сорады да, түр стенадагы эстамп-сурәтләргә текәлеп, җавап көтте. Хафиз күңеленә ятышлы иде бу сорау. Ул кинәнеп елмайды һәм рәхәтләнеп җавап бирде:

— Әнкән белән дуслык, кызым, минем педучилищеда укыгандагы дәфтәрләр арасыннан табылган хатны бергәләшеп укудан башланып китте шикелле. Ул — Гөл-Төркемнән миңа Елена язган хат иде.

— Әнкәй бер дә көнләшмәдеме?

— Кемнән? Ник, ни өчен көнләшергә ди? Ул безнең ул еллардагы мөнәсәбәтләребезнең яшүсмерләрчә иң саф мөнәсәбәт икәнен яхшы аңлый иде. Аннары шул кадәресе дә бар иде бит: еллар үткән, юллар аерылышкан. Хатирәләрдән көнләшмиләр. Көнләшәләр икән, бу — акылсызлык галәмәте.

Хафизның бу көнгәчә кызы белән болай турыдан-туры һәм ачыктан-ачык мәхәббәт, сөю, көнләшү турында әңгәмә корганы юк иде. Әлбәттә, укылган китапларга, күрелгән фильмнарга, караган спектакльләргә кагылышлы рәвештә, газеталарда басылып килә торган диспут һәм фикер алышулардагы тормыш фактларына карата Хафиз үз карашларын әледән-әле әйтә килә. «Хаклык кем ягында?» дип ничәмә-ничә кат сөйләшкәннәре, караш уртаклашканнары һәм бәхәсләшкәннәре бар. Бүген исә иң четерекле мәсьәлә Хафизның үзенә турыдан-туры бәйле төстә кузгатылды. Форсаттан файдаланып, Хафиз төплерәк сөйләшү ягын чамалады. Ләйсәнне бу сораулар борчыпмы-борчый хәзер. Кызның Таһир белән дуслыгын да күптән белә ул. Яшьләр былтыр яздан бирле бер-берсен якын итеп йөриләр. Таһир Ләйсән янында ешрак була башлагач, кызы иптәш кызлары белән дә сирәгрәк очрашучан булып китте түгелме? Юк, юк, дус кызлары белән арасы суынды дию хата сүз булачак, әмма Таһир белән уртаклыкның көннәр үткән саен арта төшүе хак. Ләйсән дусларны бер табып та, бер кагып яши белми. Шуңлыктан дуслыкларының көчәя баруы бик табигый.

Хафиз егетнең исемен бүтәннәрдән аерып, басым ясап телгә алганы юк. Кирәкмәгәнчә янгыравы бар.

— Кем белсен, кызым, бәлки Елена белән дуслык елларында ачылган тойгылар әнкәңне көчлерәк ихтирам итәргә булышкандыр,— диде Хафиз, Ләйсәнгә җитди карап.— Ә яратырга өйрәнү, мәхәббәтне танырга өйрәнү зур эш ул, Ләйсән. Ярата белү — бәхетле булу, үз-үзеңне хөрмәтләргә, кешелек кыйммәтеңне белергә өйрәнү дигән сүз. Ярату дигән олы көч тормышны матуррак, мәгънәлерәк итә. Баштарак ул, бәлки, чын мәхәббәт үк тә түгелдер, көчле, саф мәхәббәт теләүнең бер чагылышы гынадыр. Шулай гына булса да, ул шундый чиста, әйбәт хис. Аңардан курыкмаска, качмаска кирәк. Әйтик, уналты-унҗиде яшендә бу хиснең тууы җитмештә чәч агару шикелле үк табигый хәл...

Әтисенең ник шулай бик бирелеп сөйләвен Ләйсән дөрес юрады. Таһир белән дуслыкка ым кага дигән нәтиҗәгә килде ул. Шуңа күрә аңа ничектер җайсыз булып китте, Ләйсән сүзне икенче тарафкарак борып җибәрергә теләде.

— Елена Семеновна тормышка чыкканмы соң, әткәй? — диде ул. Хафиз исә, шуны гына көткән һәм Елена турында сүзне дәвам итәргә җай өстәлүгә куанган шикелле, җавап кайтарды:

— Чыкмаган. Әле дә ялгызы яши. Ул дигән кеше очрамагандыр, күрәсең. Исәпкә бар, санга юк бәндә белән башын бәйләргә теләмәгәндер. Горур, акыллы, тормышта үз бәясен белә торган кеше ул, кызым. Андый кешеләр үзләрендә ялгызлык җәфасын чигенергә мәҗбүр итәрлек көч табучан була. Ә Владиславны тәрбияләп үстерүе дөньяда бөтенләй үк тармаксыз-ботаксыз калмаска теләүдән килеп чыккандыр.

— Аның бу килеш тә шулай калу ихтималы бар ич. Тик шулай да Владислав абыйны мин бик кызганам, әткәй.

— Ул кызганыч кеше түгел, Ләйсән. Яхшы тәрбия алган. Бик яхшы һөнәр иясе. Хатын укыдың, чамалап карагансың.

— Мин бу яктан әйтмим. Менә ул сезнең икәүләп язган хатыгызны ала һәм...— Кирәкле сүз тиз генә Ләйсәннең тел очына килмәде.— Һәм... аның күңелендә каты бер шартлау барлыкка килә. Ул шартлаудан күңелдә ни кала? Бушлык? Суыклык, рәнҗүме? Гомере буе алданып йөргәнлегеңне каһәрләүме?

— Син, кызым, артык ямьсез буяулар сайлап сөйлисең. Әлбәттә, Владислав өчен ул яңалык күңелле булмас. Шулай да аның мәсьәләгә тыныч карыйсына ышанасы килә. Ул инде тормышны күрергә өлгергән егет.

— Булса да...

— Билгеле, Елена Владиславка чынын алданрак әйтә алган булыр иде, тик аның да туган баласыдай күргән кешесен югалтудан куркуын аңларга кирәк.

Ләйсән, диван култыксасына терсәген кадап, ияге белән учына таянган хәлдә, тын утырды-утырды да, янбашына төртеп сискәндергән кеше төсле, капылт торайды.

— Сугыш... каһәр төшкере сугыш эзләре,— дип пышылдады.— Шул купмаган булса, кеше язмышлары бу кадәр ботарланып бетәр идемени!

Хафиз кызына гаҗәпләнү катыш сокланып карады. Әле хәзер генә Еленаны гаепләргә җыенган төсле үртәлебрәк утырган Ләйсән мәсьәләнең асылына төшенүен әйтеп салды ич!

— Шул шул, кызым. Сугыш зилзиләсенең шаукымы күпме гомер узгач та әле бер гаиләдә, әле икенчесендә яман шеш булып калкып чыга. Ул елларда ярылган снарядларның корыч ярчыклары киләсе буын язмышына да кадалып калган. Торып-торып шул ярчыклар кыймылдый, җаннарны сыкрата.— Шуннан соң Хафиз, онытып торган сөенечле хәбәрен кинәт искә төшергән кебек, бөтенләй бүтән, якты, шат тонга күчте:— Елена апагыз әбиегезне, сине һәм Рафисны кунакка чакырды. Киләсе җәйдә барып кайта аласыз диюем.

— Рәхмәт. Аны Аккүлгә чакырмадыңмы соң, әткәй? Син дә кунакка дәшәсең калган...

— Мин моны үзем генә хәл итәргә теләмәдем, Ләйсән. Сезнен белән киңәшүне кирәк санадым...— Хафиз кызына елмаеп карады. Чын-чынлап шулай әйтүе идеме, әллә Ләйсәнне сынап карамакчы гына булдымы, кызы аны төшенмәде. Ләкин ул бер нәрсәне сизенгәндәй булды: әткәсе Ләйсән каршына зур бер сорау куя түгелме соң? Аның тел төбендә кунакка чакырудан мөһимрәк мәсьәлә ятмыймы? Елена Семеновна әтисе күңелен астын өскә китергән түгелме соң? Әллә Ләйсән хаталанамы?

Ул бер мизгелгә эсселе-суыклы булып китте. Шул чакта, бәхеткә, телефон чыңлады. Райбашкарма председателе Нияз Гайсин шалтыратты. Алар сөйләшә башладымы, бел дә тор, трубканы тиз генә куймаслар...

Хафиз телефон шалтырагач өзелеп калган сүзгә кире кайтмады. Ләйсән ул теманы яңартырга гел теләмәде. Имәнеп калды кыз.

Кич житте. Көзге көннең эңгер-меңгере Аккүл өстенә күгелҗем-карачыбылдыгын корды. Озакламый, учлап сипкән төсле, күк гөмбәзендә эреле-ваклы йолдызлар җемелдәшергә керешге. Төн аяз. Салкынча җил

исә иде. Юлдан кайтып, өй рәхәтенә юлыккан Хафиз, иртәгә дә көннең аяз буласына куанып, үзе өйдә юкта килгән газеталарны карарга утырды. Лэйсән күрше бүлмәдә Рафиска математикадан мәсьәлә чишәргә булышты. Чак әрләшеп китмәделәр, чөнки энесе гап-гади кагыйдәләрне хәтерендә тотмый. Шулай булгач, билгеле инде, кыю атларга базмаган сукыр кеше төсле, әледән-әле тераля дә кала. Өчпочмакларның охшашлык билгеләре буенча бирелгән мәсьәләне чишә алмый утыра әнә!

— Әгәр иртәгә шушы билгеләрне яттан белмәсәңме,— диде аңа апасы,— әткәйгә әйтеп, сыртыңны каезлатам мин синең! Бусы — бер. Икенчедән, стадион синең өчен тыелган зонага әйләнәчәк. Мәктәптә аяклары гына түгел, башны да эшләтергә кирәк, Рафис галиҗәнаплары! Аңлашыламы? Менә шул...

Малай эшнең җитдиләнүен тоя иде. Тыштан бәйсезлек саклаган булып маташса да, Лэйсәннең эшне әткәсенә җиткерүеннән шүрли иде. Рафис әткәсенең гомердә кул якмасын, әлбәттә, белеп тора, ләкин аның каршысына басып, кырт кисеп куйган сорауларына җавап бирүе, аның оялтуын тыңлап тору — җәзаның нинди булачак. Боларның һәммәсен бик тиз исәпләп, Рафис Лэйсәнне тынычландырырга ашыкты, сүз бирде.

— Джентльмен вәгъдәсе, апа! Иртәгә кичкә өчпочмакларның охшашлык билгеләрен чикләвек урынына чиртkәнемне күрерсен. Әткәйне борчымаска кирәк.

— Тыкылдап бетердеңме?

— Юк әле, апа. Тагын бер важный сүзем бар. Стадион турында авыз ачма, ямә? Тупсыз мин — аяксыз-кулсыз, аңлыйсыңмы?

— Аңладым. Аның каравы, башың үз урынында булыр, аны эшләтерсең, Пеле! Спорт бит ул төп эшкә булышса гына спорт...

— Бетте, апа. Ут сызыгында тынлык урнаша. Солых килешүе төзелә.— Рафис, вәгъдәсен үтәргә ант итеп, геометрия дәреслеген үбә...

Лэйсән зал якка кергәндә, Хафиз район газетасының урта битләрен — «Гигант» колхозы игенчеләренең ашлык сатудагы тырышлыгына багышланган куш полосаны карап утыра иде. Район газетасы дигәндә, ул бер хәбәрне дә күздән кичерми калмый. Кулына карандаш тотып укый. Искәрмәләрен шунда ук билгеләп бара. Әйтәсе фикерен өстендә ук я редакторга, яисә аның урынбасарына телефоннан әйтә.

«Гигант»ка багышланган куш битне ошатканлыгы йөзеннән үк күренеп тора иде. Колхоз парткомы секретаре чыгышы турысына кызыл карандаш белән плюс билгесе куйган. Тупланманы йомгаклап язган өлешне дә яраткан. Ул турыда өндәү билгесе тора.

— Менә ичмасам Сөләйманов! Тамырларында журналист каны аккан кешенең каләме гап-гади саннарны музыкага сала! — диде Хафиз, махсус полосалардан канәгать булып.— Шәп чыгарганнар егетләр.

Лэйсән әтисенең Дәмин Сөләймановны мактавын бик тиз абайлады. Сүз башларга җай китерә алмыйча пошынганда, гаҗәп иплe әләмәк була түгелме соң бу? Тик суытмаска гына кирәк.

— Әткәй, син Дәмин абыйны гел диярлек мактап кына торасың, язуын бик яратасың бугай. Әллә Мәскәү газетасына үзең турында очерк язганы өчен артыгын да яратасың инде?

— Әйе шул, кызым, ошатам мин аның язуын. Үзем турында язганы өчен генә түгел ләкин. Минем алай үз каефемне өстен куймаганымны син әйбәт беләсең... Район редакцияләрендә яхшы журналистлар бармак белән генә санарлык. Сөләйманов профессиональ югарылыкта яза. Чын иҗат кешесе. Авыл хуҗалыгын бөтен вакыклары белән белә, кешеләрнең холкын, гадәтләрен нечкәләп өйрәнә. Иң мөһиме — тормыштан алганын художестволы итеп газета юлларына сала белә. Яхшы журналист, сүз дә юк!

Лэйсән әтисе янына килеп басты һәм өстәлгә җәеп салган газетага күз йөгертеп чыкты. Тик аның күңел күзе анда язганнарда түгел иде.

Авыз ачып башлаган сүзен ничегрәк дәвам итүне уйлады ул.

— Минә сез, эткәй, житәкче работниклар, күп чакта кешегә бер яклы гына карыйсыз.— Лэйсэн этисе йөзенә чыккан сорауны күргәч, ашыгыбрак сөйлисе итте.— Әйе, әйе, кайчак сыңар күз белән генә карыйсыз шикелле. Хезмәтен күрәсез дә «яхшы механизатор», «уңган терлекче», «шәп председатель», «әйбәт агроном» дисез. Минә әле генә Дәмин абыйны да «яхшы журналист, сүз дә юк!» дип мактадың.

— Димәк, жирендә, кызым.

— Ә кеше буларак ничек?

— Начар кеше түгел ул. Моңарчы, һәрхәлдә, шулай дип белә идем. Нигә алай дип сорыйсың әле?

Хафизның бу соравыннан Лэйсэн читенсенә калды. Әтисе соравын янә кабатлады:

— Нигә? Дәмин Сөләймановның начарлыкларын беләсеңме әллә? Берәр әшәке сүз ишеттеңме? Нәрсәгә таянып, аның кешелек сыйфатын шик астына куясың? Сөйлә әле, сөйлә, Лэйсэн.

Хафиз кызыксына калды. Лэйсэн гафу үтенгәндәй генә сөйли башлады. Шулай да иң әүвәл ике арадагы бу сөйләшүнең сер булып калачагына эткәсенең вәгъдәсен алды. Таһир исемен бу сөйләшүгә бәйләп, гомумән, теленә чыгармавын гозерләде.

— Аккүл зур кала түгел, эткәй,— диде Лэйсэн, бу хакта бар белгәнен сөйләп бетергәч.— Имеш-мимешләр бик тиз тарала. Фәһимә апага да, Таһирга да бик кыен. Атна-ун көннән бирле Таһир жанын кая куярга белмичә йөри. Мин күреп торам бит, укуының да рәте-коты китеп бара...

Нидер уйлап торгач, Лэйсэн, тагын яшүсмерләрчә чәчәләнеп, гомумиләштереп сөйли башлады.

— Ашлык урлаучыны хөкемгә тарталар. Машина жимергән кешене судка бирәләр. Гражданнарның тынычлыгын бозган хулиганга каты чара күрелә. Ә бу очракта шома гына үтәргә тиешме? Азынучы да, азындыручысы да сөттән ак булып калсыннармы? Дөресме соң шул, эткәй? Кеше бәхетен урлау, семья тормышын жимерү, күпме кешенең жан тынычлыгын бозу жәзасыз калырга тиешме?

Хафиз кызының фикерләрен бик житди кыяфәттә тыңлады. Аның чын күңелдән әрнеп, битараф кала алмаслык дәрәжәдә көенүдән сөйләвен аңлады. Әтисе Лэйсэнгә ни дип жавап бирә ала иде соң?

— Сине бер зур әхлакый проблема борчуга салган, кызым,— диде Хафиз.— Принципта мәсьәләгә бик дөрес карыйсың. Син әйткәннәрне ныклап тикшерергә, ачыкларга кирәк. Чара күрү хакында шуннан соң уйларга мөмкин. Интим мәсьәләләрне тикшергәндә, пар ат жигеп, кыңгырау чыңлатырга ашыгу дөрес булмас иде. Шулай да әйтим, мин моны тиешенчә ачыкларммын. Ә Таһирга канат сәлперәйтергә жай бирмәгез. Минем белүемчә, акыллы, фикерле егет ул. Теләктәшлекне бик аңлар һәм кабул итә белер.

## 13

Кошчылык фабрикасы корылышында эшләрнең торышы, тулаем алганда, аһ-зарга жай калдырмаслык булса да, механикалаштырылган күчмә колонна житәкчеләре райком теләгән темпны тәэмин итә алмады. Өченче кварталда алар планнан тыш та эшләр башкарырга вәгъдә иткәннәр иде, чөнки дөнья күргән һәр кешегә билгеле: октябрь-декабрь айларында салкын яңгыры, тездән пычрагы, чатлама суыгы — барысы бергә төзүченең чабуыннан тарта, балтырына таш булып тагыла. Ләкин вәгъдә сүздә генә калды. Колонна өченче квартал планын да очын очка чак-чак кына ялгап куя алды. Хикмәт нидә? Хафиз Кадергуловны шул мәсьәлә байтактан борчып килә. Октябрь башында ул төзелешкә килеп

чыкты. Урып-жыюны әйбәт тәгәлләп, дәүләткә ашлык, шикәр чөгендере, бәрәңге һәм яшелчә сатуны уңышлы үтәгәннән соң, иркенләбрәк калган чак иде.

Участокларны Илларион Захарович Зотов белән бергә урап чыктылар. Соңга таба начальникның кәефе кырылды, чөнки райком секретаре алдында ташчылар бригадасында эшчеләр белән сүзгә килде. Нигъмәтулла Нигъмәтҗанов тик торуларның тимер-бетон капламалар житмәгәнлектән килеп чыкканын күзгә бәреп әйткән иде, шул ярамады. Житмәсә, аягы керсә, башы кереп житмәгән Азат Ишбулдин да сүзгә кушылып маташа, дип гарьләнде.

Илларион Захарович Нигъмәтҗановның хаклы икәнлеген дә белә. Ләкин бит ул егет тәэминат начар дип кенә зар түкми, капламаларны бүген-иртәгә үк кирәк кадәр кайтарып житкерегез дип бугаздан ала. Зотов шуңа кабынып китте һәм Нигъмәтуллага кычкырынып ташлады. Бер уңайдан бүтәннәргә дә сабак булсын дигәндер, бәлки. Район башлыклары килгәндә, телләрен теш артында тотарга өйрәнсеннәр диюе булгандыр.

Хафиз, машинасына утырып, райүзәккә кайтырга кузгалгач та, начальник тиз генә тынычлана алмады. Кадергуловтан да тартынмыйча, үзалдына рәнжеп мыгырданды. «Авызыннан ана сөте кипмәгән, ә кычкыра! Тәпиеңә басып, башыңны суырып чыгарыр тегеләй, ирек бирсән. Юбилейлар хөрмәтенә көрәшәбез, имеш. Менә заманалар нишли... Гап-гади эшне көрәш дип йөртә башладылар...»

— Йөрәгенә барып кадалды, Захарыч, шуңа сукранасың. Нигъмәтжанов та, Ишбулдин да хаклы. Акланырга маташма. Кемнән дауласыннар алар? Аларның әйбәт теләгенә каршы төшәргә кемнең ни хакы бар? Тынычлан да уйла! Тәэминатны тиз арада ничек яхшыртып була? Без нәрсә белән һәм ничек булыша алабыз?

Зотов тиз генә эндәшмәде, ачуы сүрелмәгән иде әле. Аның колагында һаман Нигъмәтулла авазы яңгырап тора иде: «Без һәр минутны исәптә тотабыз, тәэминат кешеләре безнең вакытны тәүлекләп урлый! Нишлиләр генә соң алар?»

«Аларның нишләгәнен белүне миңа калдыр! — дип кычкырды ул.— Синең белгәнең — үз бригадагыз, ә минем жилкәдә — бөтен бер колонна. Шуны онытма, план өчен мин җавап бирәм. Ә син эшсез утырмассың, тыныч бул...»

Зотов Хафиз соравына кичегебрәк җавап кайтарды:

— «Татсельстрой»га шалтыратыйк әле... Сез шалтыратсагыз икән. Тәмугка күнеккән шайтан шикелле, минем зарлануга күнегеп беткәннәр инде анда,— диде.

— Хәзер үк сөйләшәбез, туры райкомга кайтыйк.— Хафиз шоферның жилкәсенә кагылып алды.

Илларион Захаровичның үпкәсе һаман язылып бетмәгән иде әле. Ул кабат Нигъмәтулла Нигъмәтҗанов әйткәннәргә кайтып төште:

— Юбилейлар дип, көрәш дип салмаклырак булсын өчен кушып жибәрә ул... Тел төбендә бер төен — акчаны көрәп алмак була. Тиеннәремә зыян салмасыннар дип сызлана.

— Йөкләмә үтәлсә, акчасын да шәп аласын белә ич ул. Моның ни гаҗәбе бар? — диде Хафиз. Зотов тагын да үртәлә төште.

— Бер сүз белән генә акча дисең! Узган кышны, Хафиз Галиевич, әйтсәм әйтим инде, бер бригада штукатурчылар ялладык. Әрмәнстаннан килгәннәр. Киселеп чыккан мастерлар. Акча сугарга килүчеләр, бер сүз белән әйткәндә. Торак йортны бер атна дигәндә курчак сарае ясадылар да куйдылар. «Кабул итегез!» диләр, ышанмый торам. Безнең атказанганнарыбызга тапшырсаң да, бер айсыз ерып чыгя алмаслар иде. Чынлап менә. Тегеләрне ни жилкендерә дисең? Акча! Сәгатьләр, минутлар белән хисаплашмыйлар, эшлиләр. Тәмәке тартуны да исәптә тоталар.

Ә куллары — алтын. Көнена унбиш-егерме сумны сыпырдылар шул. Атказанган исемең дә, мактау грамотаң да кирәкми аларга. Нишләтергә ул халыкны? Мактаргамы, әллә сүгәргәме? Чакырып алыргамы, артларына тибәргәме? Аккордлы наряд биргәндә дә шулай. Вакытын куясың, хакын билгелисең. Хакы нормативныйдан югары була, билгеле. Шартласа шартлый, ярылса ярыла, әйткән сәгатенә Сөембикә манарасын да өеп бирә... Сезнеңчә, нишләргә, Хафиз Галиевич?

Хафиз көлемсерәп тыңласа да, бик җитди җавап бирде.

— Алтын куллы гына түгел, бриллиант куллы булсалар да, шабашникларны үрчетү юлына басмаска, Илларион Захарович. Алын-ялын белми акчага табынган кешеләр дөнья тоткасы дип кем һәм кайда әйткән? Тәңкәне тәңре иткән бәндәләр куркыныч, Захарыч. Алар җәмгыять тәнендәге иске бозык, ямаң шеш. Мал хакында гына уйлаган андый адәмчекләрнең күзенә ак-кара күренми башлый. Ә менә эшләгән эшен илгә кирәк, җиргә күркәм дип башкаручы — бөтенләй бүтән. Ул иптәшнең тормышта акчадан тыш төп иманы бар, принциплары бар. Андый кеше дөреслекне, гаделлекне якты мәгънәсендә аңлый. Аларга атказанган исем дә бик кадерле, мактау кәгазе дә мөһим, чөнки алар тормышта тоткан урыннарын күпме акчага ия булулары белән түгел, җәмгыятебез тарафыннан ни дәрәҗәдә хөрмәт ителүләре белән дә бәялиләр. Мораль стимул андый кешеләргә көч өсти, дәрт арттыра...

Төштән соң партиягә кабул итү һәм персональ эшләрне бюрога хәзерләү буенча штаттан тыш комиссиянең утырышы булачак икән, Хафизның шунда катнашуын сорадылар.

Утырышта партия членнарына кандидатлардан алты кешенең кандидатурасын карадылар. Алар арасында механизаторлар да, терлекчеләр дә, район больницасыннан фельдшер хатын да бар иде. Ветераннардан торган бу комиссиянең фикере биш иптәшкә карата бердәм булды. Ә менә зооветснабның районара базасы директоры Әхтәм Билаловка килеп җиткәч, эш катлауланды.

Председательлек итүче Әхтәм Билаловка кагылышлы сүзне әйтте:

— Әхтәм Шакир улы Билалов район ветеринария лечебницасы каршындагы башлангыч партоешма җыелышында КПСС членлыгына кандидатлыкка күпчелек тавыш белән кабул ителгән. Әмма җыелышта бер коммунист Билалов иптәш кандидатурасын якламаган. Соңыннан ул үз карашларын җыелышка тулысынча аңлаткан. Бу хәл партия райкомы каршындагы комиссиянең игътибарын тарта һәм без иптәш Билалов мәсьәләсе белән өстәмә рәвештә шөгыльләндек.

Производство күрсәткечләре ягыннан дип әйтсәк, ягъни иптәш Билаловның хезмәт линиясендәге эшчәнлегенә килсәк, сүз әйтер урын юк. Һәрнәрсә кирәгенчә диярлек. Ә менә үз буйсынуындагы иптәшләргә карашы начар... Туп-туры әйтәм: начар, иптәшләр. Зооветбазада аңардан канәгать кеше юк. Шулай да берсе дә каршы эндәшми, эштән куам, дип өркетә икән. Уйлап карагыз. Складта эшләүче кызны ЗАГСка язылышырга җибәрмәгән. «Беләсең бит, җомгада безнең эш особый тыгыз»,— ди икән. Кешенең иң якты, иң куанычлы көнендә шулай дисеннәр әле! Шатлык бит ул кешеләр уртаклашса арта, ә ваемсызлыктан сүрелеп, тоныкланып кала. Каравылчыны тыңласагыз иде. Эттән алып, эткә салып сүгә. Җиңү бәйрәмендә генә булса да, кеше төсле сәлам биреп, котлаганы юк, ди. Ә каравылчы дигәнебез, иптәшләр, Ленинградтан Дрезденга кадәр сугышчан юл узган фронтовик... Игътибар итегез, кеше бернинди материаль ярдәмгә өметләнми, сүз әйбәт эндәшү, җан азыгы хакында гына бара... Иптәш Билалов кешелек сыйфатларын җуя башлаган, кыскасы. Без моңа гамьсез карый алмыйбыз...

Комиссия, Билаловны партия членлыгына кандидатлыкка кабул итүдән тыелып торырга, дигән нәтиҗәгә килде. Райком бюросына шундый фикерне ирештерергә дип карар кылынды.

яшереп тә маташмады, ә туп-туры:

— Сезнең әйткәннәргә колак салып торсаң, монда фәрештәләр җыелганмы әллә дип уйларлык,— диде кызарынып-бүртенеп.— Кем генә ялгышмый бу дөньяда? Ата баласында хата була ул. Ак кәгазь битенә сырлый китсәң, чүп өстенә чүмәлә дә тиз өелә...

— Шуңа күрә хатаңны әйтүчене атаң дип бел дигәннәр, иптәш Билалов,— диделәр аңа.— Ялгышын танымаган тагын шул хатага төшәр. Дөрес әйтмәгән булсалар, комиссия членнарының дәлилләрен кире кага аласыз.

Билалов аптырап кайтып китте. Гүя аны тукмап мингерәттеләр дә, ул ябышкан керфекләрен аерып ача алмый иза чигә. Башы, күз кабаклары кургаштай авыр, авызында сабын тәме иде. Бөтен дөньясын каһәрләде ул. Барыннан да бигрәк, үзен сүкте. «Нәрсәгә кирәк иде шушы яшькә житкәндә партиягә керәм дип кыбырсып йөрергә? Саулыгым-байлыгым дип мыштым гына яшәргә иде мина, тиле бәрән орлыгы ашаган мужикка! Базадан ычкынуым бар, янәсе. Көннәрдән бер көнне шундый хәерсез сәгать сугып, аннан ычкынсам да, кулымда һөнәрем юкмы, дивана... Авылдан авылга тәкә печеп йөрсәм дә, мохтажлык күрәсем юк лабаса... Әшрәфжан Каюмы шикелле туры бәндәләр өчкә-бишкә кәкрәйгәндә дә дымым кибәсе юк әле. Ул хәерче интексен!

Әштә дә аягын тайганны гына көтеп торалар икән. Монысын кояшлы көн кебек ачык белдем. Мин сантыйга шәп сабак булды... Инде сак булырга кирәк. Мәгъсүмә белән дә аеруча сак эш иткән хәерле. Хәл кылгыч көн житми торып, дальше-больше аңа каты бәрелдем юк. Әмма инде мәлжерәп төшүне дә көтмәсен. Хәттин ашкан ахмак булмаса, үзенә мөгамәләне бер төшенер. Төшенгәч, жилдән туган малае янына китеп елышыр әле. Китә белмәсә, жибәрә белермен... Гариза язып баргач, жыелышта кабул иткәч, кире борулары гарьлек. Мина ачуы чыкканы бере шуны йөзгә бәрер инде. Тик тормаган кешедә бәла бар, диләр. Мин тинтәк шундый булып чыктым, менәтерә...»

Әхтәм Билалов киткәч тә комиссия членнары байтак сөйләшеп тордылар. Урып-жыю кызып барган атналарда Хафизның ветераннар белән жәелеп китеп иркенләп сөйләшергә вакыты да, жае-уңае да булмады бит.

Кичләтеп беренче секретарь кабинетының ишеген Айрат Сәрвәров шакыды. Техник секретарь аны кисәтеп кертте: «Тиздән Хафиз Галиевичнең ерактан кайткан танышы киләчәк, иптәш Сәрвәров»,— диде. Әмма Хафиз үзе бер дә ашыкмый, кабаланган кешегә охшамый иде, Айратны бик жылы кабул итте.

— Әйдәгез, Айрат, хуш киләсез,— диде секретарь, укытучыны ишек буена килеп каршы алды һәм күрешергә кул бирде.— Узыгыз, утырыгыз.— Папирос кабын кулына алган иде, кире куйды.— Сез тартмыйсыз бугай... Я, ни хәлләрегез бар? Мәктәпкә, коллективка ияләшеп життегезме инде? Аккүл кешесе булып буламы? Назлыгөлнең кәефе ничек? Казан дип бик өзгәләнмиме?

Айрат, үз чиратында, иркенләп жавап кайтарды һәм якын күреп хәл-әхвәл сорашкан өчен Хафизга рәхмәт әйтте.

— Йомышыгыз бар идеме? — Хафиз әңгәмәнең булачак төп өлешенә үзе юл ачып жибәрде. Өлкәннәрдәге менә шул сыйфатны мактамас жирдән мактарсың, характерның бик күркәм бер сызыкчасы бит ул. Кеше ничегрәк сүз башлыйм икән дип торганда, судан тартып чыгарырга дип кул сузган кебек булә. Шуннан соң үтенече, гозере төшеп килгән кеше рәте-чуты белән йомышын юллый башлый. Айрат та кыска һәм ачык итеп:

— Мин үземне класс җитәкчесе булларак борчыган ике мәсьәлә буенча килдем, Хафиз абый,— диде.

Кадергулов дусларча шаяру катыш көлеп сорады:

— Шуларның берсе минем Ләйсән китереп чыгарган мәсьәләме әллә?

— Юк,— диде Айрат.— Ләйсән бик тырыш, әйбәт укучы. Менә дигән комсорг. Ярдәмчеләремнең берсе. Мин сезнең яныгызга райком секретарена дип килүем.

Хафиз урынына барып утырды.

— Тыңлыйм. Рәхим итеп сөйләгез.

Айрат иң әүвәле Рубин Туйкинның тәртипсезлегенә кагылышлы бәхәсне сөйләде.

...Райпотребсоюз председателе малае Рубин Туйкин мәктәп кичәсенә исереп килеп гауга куптарган иде. Иртәгесен Айрат аларның өйләренә дә барды. Тик Рубинның әнисе — район больницасының күз врачы — яшь педагогны өеннән куып чыгаргандай итте. Ул ханымның карашынча, аның баласы фәрештәгә тиң, андый гына сөрлегүләр кемдә дә була, Айрат, янәсе, чебеннән фил ясап йөри.

Әмма Айратны иң нык рәнҗеткәне бу түгел иде әле. Директор Хәниф Бикбаев, мәктәп даны дигән булып, гадәттән тыш тәртипсезлекне йомып калдырырга теләде. Айрат моның белән һичничек килешә алмады һәм мәктәп җитәкчесе белән каты бәхәскә керде...

— Мин, ихтимал, моның белән сезне борчымаган да булыр идем, Хафиз абый,— диде ул.— Мәсьәлә мәктәп кысасыннан чыгып бара. Бердән, Идрис абый Туйкин — район работнигы. Аңа карата райком сүзе тәэсирлерәк буласы шиксез. Икенчедән, директорыбыз Хәниф Гәрәевич белән минем принципиаль бәхәскә, очраклы рәвештәме, әллә махсус кызыксыныпмы, райкомның идеология буенча секретаре кушылды. Көндез иптәш Баязитов мәктәпкә килде һәм минем белән озак кына сүз алып барды. Ул баштанаяк директорны яклый, мине мәктәпнең яманатын сатарга теләүдә гаепли. Мин боларны әләкче булып сөйләмим, Хафиз абый, дөреслекне табар өчен генә әйтәм.

— Һм-м...— Хафиз маңгаен сыпырып куйды һәм көлемсерәде.— Гафур Баязитов белән Бикбаев күптәнге дуслар,— диде Кадергулов.— Баязитовны мәктәпкә үзе өндәгән булуы да бик мөмкин. Тик эшнең асылы анда түгел, Айрат. Мәсьәләнең төше педагогик принципта. Шул ноктадан караганда, мин сезнең тәкъдимнәрне дөрес күрәм. Туйкинның үз-үзен тотышын бәяләүне, әлбәттә, классташлары карамагына куярга кирәк. Идрис Саматович белән без монда сөйләшербез. Сәкинә Габделрәсүловна — партиясез кеше. Шулай да ул коллективта бит. Район больницасы коллективының үз членыннан баласын ничек тәрбия итүе турында сорарга тулы хакы бар. Ә Рубин, чыннан да, киртә аша сикерә башлаган. Район мәгариф бүлеге, комсомол райкомы шулай ук битараф калмас. Эчүчелеккә каршы көрәш караклыкка каршы көрәш шикелле үк рәхимсез булырга тиеш, Айрат. Яшь чәчәкне кырау аеруча тиз көйдерә. Яшүсмерләр шешәгә ябышкан һәр очракта тревога сугарга, барлык чаңнарны кагарга кирәк. Ә Бикбаевка мәктәп намусы өчен чын тырышу ничек икәнен аңларга бик вакыт...

Класс җитәкчесен борчыган һәм аптырашта калдырган икенче хәл Таһир Сөләймановның әтисенә кагылышлы иде. Айрат үтә сакланып, тәгъбирләрнең берәүне дә кимсетми торганнарын сайлап кына сөйләде. Шунысы факт: чыгарылыш класс егетенең җаны кыйнала. Мәктәпкә дә аптыраганнан гына йөри төсле. Дәрестә, җәмәгать эшләрендә онытылып та тора ул, рухланып, кабынып та китә. Иптәшләре дә моны сизә.

— Мин иптәш Сөләймановны бик аз беләм, редакциядә нибары бер очрашканым бар. Шулай да аны күреп, ачыктан-ачык сөйләшәсе килә,— диде Айрат. Үзе Хафиз йөзендәге реакцияне төшенеп җитмәде, икеләнеп куйды.

— Классташлары.
— Атап әйткәндә?
— Класс старостасы. Күрәсең, ул уртак борчылуларын миңа җиткергәндер.
— Әйе, алар күбесе борчылалар.— Хафиз утырган җиреннән торды да, кулларын чалбар кесәләренә тыгып, гадәтенчә, арлы-бирле йөренеп алды.— Мин моны беләм. Тик сезгә ул хакта Дәмин белән сөйләшми торырга киңәш итәр идем.
Айратның күзендә «Берни дә аңламыйм» дигән караш ялтырап узды. Ул аны теле белән дә әйтте.
— Ягъни? Белмәмешкә салышыргамы? Хәл бик җитди, катлаулы ич, Хафиз абый. Аннан соң бу бит район газетасы сотрудникының, коммунистның мораль кыяфәте мәсьәләсе дә...
Кадергулов йөренде-йөренде дә тагын килеп утырды.
— Сез әйткәннәр бөтенесе дә дөрес, Айрат. Дөрес. Минем сезгә сабыр итәргә кушуым нидән? Мин бу хакта Дәмин Сөләйманов белән берничә көн элек бик ныклап сөйләштем. Икәүдән-икәү генә. Ишекне бикләп. Райком секретаре булып кына түгел, фронтовик белән фронтовикча сүз алып бардым. Ирләрчә. Туп-туры. Һәрнәрсәне үз исеме белән атап. Минем моны берәүгә дә чәчеп йөрергә хакым юк, ә сезгә әйтми булдыра алмыйм, чөнки Дәминнең улы язмышы аша ул мәсьәлә сезне дә борчый... Бер мәл боргаланып бакты ул, гайбәт, диде. Аннары икърар итеп, хатынының минуслары туйдырганнан зарланды. Ахыр чиктә гаебен таныды, кабатламаска ирләрчә ышандырды. Ике төрле сөйләмәс дип уйлыйм. Дөресрәге, шулай дип ышанасым килә. Җитди кеше. Төбеннән, тамырыннан җитди... Ә сез аның белән кабат бер үк чүбекне чәйни башласагыз, яна ярадагы кутырны тырнап ачу гына булыр кебек, Айрат. Сез яшь кеше, аңа киңәшне дә тартыныбрак бирерсез. Ә Дәмин ярты-йорты дилбегә какканны гаменә элми. Үзе көчле кеше. Һәрвакытта аргументы бар, дәлиле кул астында. Буш сүз белән мавыкмаска тырыша... Аз гына сабыр итик, сыныйк иптәшне. Мин сезнең инициативагызны кысучы булып чыкмадыммы, Айрат?
Айрат көлеп куйды:
— Сез хәйләкәр дә була беләсез икән, Хафиз абый. Киресенчә, мин үтенергә теләгән нәрсәне сез инде үтемлерәк итеп башкарып та куйгансыз икән ич. Рәхмәт, Хафиз абый.

## 14

Сәрвәров киткәч, Хафиз озак кына Казан белән телефоннан сөйләште. Партия өлкә комитетының авыл хуҗалыгы бүлегеннән шалтыратканнар иде. Терлекләрне кышлатуга хәзерлек мәсьәләсе белән кызыксындылар. Хафиз өлкә комитетындагы иптәшләренең һәммә соравына тулы җавап бирде шикелле, дәгъва белдермәделәр.
Сәгать кичке алты тула дигәндә, педучилищедагы курсташы — Аккүл егете Мәҗит Вәлиев килеп керде. Ул туган-тумачасын күреп китәргә отпускыга кайткан иде.
Аларның күрешмәгәненә ун былтыр иде инде. Аралаша торсаң, ят кеше дә туганың була, сирәк күрешсәң, бер-береңә йөрешмәсәң, бертуганнарның да ераклашуы мөмкин. Әмма Мәҗит белән Хафиз икесе ике тарафта яшәп, озак күрешмәгән булсалар да, иске дус истән чыкмас дигәндәй, бер-берсенә карата тәмам суынган кешеләр түгел иде. Шуңа күрә дә Аккүлгә кайткач, Мәҗит курсташына шалтыратты һәм очрашырга теләге бөтенлеген белдерде. Хафиз бик рәхәтләнеп аны үзләренә чакырды.

очрашмаган дус белән көрешү икән, йөзгә кызыллык китермәслек итеп өстәл хәзерләргә кирәк иде ләбаса! Балдызы, аннан күреп кызы да, гомумән алганда, аш-су тирәсендә төшеп калганнардан түгел. Кунакны өйгә алып кайтканда, хәзинәдә бары һәммәсе әзер иде.

Өстәл артында иркенләп, тәм табып утырдылар. Кырыкның өске ягында булса да, буе-сыны сокланырлык төз, күзләре нур бөркеп торган, гаять ыспай итеп заманча киенгән, һәр сүзен үлчәп һәм кызык итеп сөйләүчән Мәҗит күңелле мәҗлестәш булып чыкты. Гөләндәм дә ошатты аны, Ләйсән дә этkәсенең яшьлек дустына бик тиз ияләште. Мәҗит абыйсының музыка дөньясын яхшы аңлавы Ләйсәнгә бигрәк тә ошады. Карасана, ничек сурәтле итеп әйтте ул: «Айның көмеш нур чәчүе, нишләптер, минем күңелдә Рахманиновның өченче концертын яңгырата башлый»,— ди. Гүя Мәҗит абыйсы музыканы хәтта күрә... Ә бик күпләр өчен бит музыка, саф җил, кошлар сайравы, офык аллануы берни дә тормый. Кеше бит, югыйсә, дөньяга мәхәббәт, матурлык һәм моң өчен килгән. Мәҗит абыйсы, мөгаен, боларның барчасын бар булдыгы белән тоядыр. Шуңа үзен бәхетле дә санындыр. Хатыным — актриса, диде. Бәлки Мәҗит абыйсының сәнгатькә шулай якынаюына хатынының йогынтысы да булгандыр?..

Музыкада теләктәш булганга күрә дә, Ләйсән Мәҗит абыйсы өчен озак итеп пианино уйнады. Алма апасын да җырларга кыстап караган иде, Гөләндәм, тамагына суык тиюен сылтау итеп, бу тәкъдимнән ару гына читләшәсе булды. Теләсә кайчан һәм теләсә кем өчен җырлыйсы килми аның. Килми!

Гөләндәм, ниндидер шөгыль табып, Ләйсәнне аш-су ягына чакырып алды. Ирләр өстәл артында икәү генә сөйләшә калдылар.

Баштарак сүз Мәҗитнең укытучылыктан китеп, химик инженер һөнәрен сайлавы турында булды.

— Казанда укытканда тагын бер ВУЗ бетерү мөмкинлеге кычкырып тора иде,— диде Мәҗит.— Тоттым да химия-технология институтының кичке бүлегенә кердем. Гомер дигәнең үтә тора ич. Биш ел тулып узды дигәндә, инженер дипломы алдым. Ә мәктәп, турысын әйтим, туйдырган иде. Олы кешеләр белән, формалашып җиткән гражданнар белән эшлисе килә башлаган иде. Шул теләк уяну өстенә директор белән дә зур каршылыкка кердек. Чирек азагы җиттеме, таштан юкә суйдыра башлый, йөз процент өлгереш таләп итә генә бит. Укырга аптыраганнан гына йөрүче кусәккә үзем ялварып, уңай билге куярга тиешме инде мин? «Бу килеш РОНО отчетны кабул итми!» — ди директор. Итмәсә нихәл кылыйм, намусыма каршы килеп уңай билге куя алмыйм, дидем. Шул бәхәс бер кабатланды, ике кабатланды, ахырда тәмам принципиаль төс алды. Мәктәптән киттем.

— Бу кадәресе бер сәбәп кенә булган, Мәҗит...— Хафиз кунагына дусларча рәнҗеп куюын сиздерде.— Мәктәпне бик яраткан кеше алай тиз генә башын алып китә алмас иде.

Мәҗит дустанә елмайды.

— Үзең дә киткәнсең ич, Хафиз.

— Минем мәсьәлә бүтән, Мәҗит. Сайлап куйдылар. Партия солдаты мондый очракта карулашып тора алмый.

— Һәрхәлдә, бу эшең хәерлерәк, Хафиз. Хәзерге яшьләр белән ми череткәнче!

— Яшьләр турында кирәгеннән артык гомумиләштерәсең, классташ. Аерым гарип-горабалар булу мондый карашка нигез бирми әле. Авылда да, шәһәрдә дә яшьләр бик нык үсте. Алар белән җайлап эшли белергә кирәк. Такт белән...

Мәҗит чырай чытып алды.

— Хәерле булсын инде! Мәктәптән киткәнемә үкенмим.

Бу темада бер аяктан баса алмадылар. Икесе дә сүзне бүтәнгә борырга кирәклекне сизәләр иде. Хафиз, кунагының моннан ике-өч ай элек кенә Голландиядә булып кайтуын белгәнгә, чит илдә күргәннәрен сораштырасы итте. Кунак аның сорауларына бик теләп җавап биреп торды.

Чәйләрен яңарттылар. Күптән күрешмәгән кешеләр гәпләшә торгач, әле бер сүз баш калкытты, әле икенчесе, өченчесе шуларга килеп үрелде. Беравыктан тормыш тоткасына — кара икмәккә әйләнеп кайттылар. Әйе, әйе, туп-туры мәгънәсендә арыш ипие хакында сүз куерды.

— Арыш мәйданын күрәләтә киметәсез бит, сабакташ. Дөрес эшләмисез, Хафиз,— диде Мәҗит катгый тон белән.

— Син хаклы.— Хафиз, кабыннан чыгарып папирос йомшарта башлады.— Соңгы елларда арышны кимрәк чәчтек. Чигенеп алуның сәбәпләре дә бар иде, билгеле. Бодайның шәп сортлары кызыктырды. Аңлатырга туры килде. Арыш бик кирәк безгә, Мәҗит. Дөнья базарында абруе зур аның. Арыш ипиенә күнеккәнлегебездән генә түгел, аның витаминга бай булуын да истә тотарга кирәк. Яшелчә һәм җиләк-җимеш исәпле яклар өчен бигрәк тә...

— Димәк, уҗым бодае белән арышның бер-берсенә комачауламавына ирешергә кирәк. Аларны тигез хокуклы итәргә. Җирнең дә әйбәтен билгеләргә, ашламаны да кызганмаска...

— Соңгысы сезгә бик бәйле, Мәҗит, химикларга. Мул уңыш тылсымы химия промышленносте кулында...

— Якын елларда минераль ашлама бик күп артасын син яхшы беләсең. Шунсыз булмый да. Әнә Голландиядә ничек! Алар тукларны дөньяда иң мул кертүчеләр. Шуңа күрә ил буенча әйләнәгә гектардан кырык бер центнердан артык бөртек алалар. Безнең гектарларның да юмартлыгын күпкә арттырасы бар әле.

Хафиз тәмәке көйрәтте һәм сүзне Мәҗит тоны белән үк дәвам иттерде:

— Уңышны күтәрүдә арка таянычы — туклар. Немец белгечләре болай дип саныйлар икән: җирне эшкәртүдән уңышның егерме проценты бәйле. Орлыкның сыйфатыннан — утыз проценты. Калган илле проценты исә минераль ашлама өлешенә туры килә...

— Реаль исәп, Хафиз. Киң колач белән төзелеш алып барган илдә гектарлар саны да арта бармый бит.

— Эш соңгы чиктә мул уңышлы гектарлар хуҗасы булган игенчеләр тәрбияләүгә кайтып кала дигән сүз, Мәҗит. Минем менә ни өчен яшьләр тәрбиясенә бармак аша караучылар белән килешәсем килми.

Мәҗит көлеп куйды.

— Дус күреп кенә тукмыйм әле дисең инде син мине. Әйдә, рәхим итеп суктыр. Кунак — хуҗаның ишәге дигәннәр ич...

Хәер, бәхәс куертмадылар. Сүз янә Хафизның гаилә хәленә әйләнеп кайтты. Бу мәсьәлә бик четерекле булганга, Мәҗит сабакташына теләктәшлек белдерүдән узмады, ялгыз яшәүнең читенлеген әйтеп, иртәме-соңмы бер карарга килү зарурлыгын колагына әйтеп куюны гына тиеш санады.

— Алда күз күрер әле,— диде Хафиз.— Минем яшьтә, балалар булган хәлдә, ансат кына хәл кыла торган эш түгел, Мәҗит...

Курсташына шулай дип бик тыныч кыяфәттә әйтсә дә, Хафизның күңелендә тынычлык юк иде инде. Райкомда, кабинеттагы өстәл тартмасында, Еленадан килгән озын-озын хатлар ята. Соңгы хатында Октябрь бәйрәме көннәрендә Аккүлгә, Гөл-Төркемгә килеп китәргә дә теләге юк түгеллеген аңлатырга тырышкан. Дөрес, Елена моны сизелер-сизелмәс

Хафиз аның уйларын чирек тоннан да аңламыймыни?!

Монда, Аккүлдә, Гөләндәм үзенең дөньяда барлыгын тойдырып яшь тегеннән сак кына язылган хатлар килә.

Әнисе Мәликәттәй дә аптырап калган. Моннан бер атна гына элек Аккүлгә килгәч, ул да йөрәгенең эчкәресеннән чыгарып болай диде:

— Елена хакында да бер сүзем дә юк. Үзең кара, Хафиз балам.

Теге елны Хафизның исәнлек хәбәре килгәннән соң да: «Яңалык юк гел искечә»,— дип хат яздыруы өчен вөҗдан газабыннан арынмаганлыгын да әйтте. «Авызымдагы язгыгым, бер хода үзе ярлыкай күрсен»,— диде.

Ноябрьның бише иде. Хафиз райкомга гадәттәгедән алдарак кузгалды. Йокыдан ук иртәрәк күтәрелгән иде. Күңелендә әллә нинди тынгысызлыкмы, сөенечме сизде.

Урамга чыгуга, салкынча җил аны дәртләндереп җибәргәндәй булды. Ул, башын югары күтәреп, тирә-юньгә күз салды. Дикъкатьне җәлеп иткәне шул булды — һәркайда байраклар иде. Райүзәк комачка төренгән, кая карама, лозунг һәм плакатлар, бәйрәм стендлары һәм электр лампаларын тезеп ясаган сурәт-чәчәкләр. Октябрь бәйрәме житте. Берсекөнгә район үзәгендә дә демонстрация һәм митинг булачак.

Партия райкомына килеп житәрәк, аның уйларын бер хатын-кызның чая тавышы бүлдерде.

— Хәерле иртә, Кадергулов абый! Исәнмесез! Бәйрәмнәр мөбарәк булсын!

Хафиз тавыш килгән якка борылды.

— Исәнмесез, сеңелем, исәнмесез! — диде ул җавап итеп.— Бәйрәм котлы булсын!

Теге хатын Кадергуловка каршы килде һәм күрешергә дип кул сузды.

— Сезгә зерә дә зур рәхмәт әйтәсем бар бит әле, абый җаным. Баламны тәки урнаштырдылар бит детсадка. Җаннарым рәхәткә тарды иң, Кадергулов абый. Эшкә кердем. Кошчылык фабрикасы төзелешендә дөбердәтеп эшлим. Һаҗәр дә кызын детсадка бирде. Ул да минем белән эшли... Исегездәме икән, сезнең янга икәү кергән идек теге вакытны...

— Хәтерлим, хәтерлим,— диде Хафиз. Үзе Рәхилә исемле бу хатынны сүз өстендә генә искә төшерде.— Әйбәт булган, яхшы итеп эшләгез инде, алайса. Матур яшәгез!

Рәхилә ай-кояштай балкып җавап кайтарды:

— Эштән курыккан юк ла анысы. Җимертеп эшлибез, Кадергулов абый җаным... Рәхмәт сезгә, хушыгыз. Менә эшкә китеп барышым...

— Хушыгыз, сеңелем!

Кабинетына кергәч тә, календарь битенә язылган сүзләрне укып алды: «Мәктәпкә, Сәрвәровка шалтыратырга».

Айрат үзе туры килде.

— Хәерле иртә, Айрат энем. Якынлашып килүче бәйрәмнең котлы булуын телим. Хафиз абыең борчый иде әле. Кичә кичен мин Казан белән, Юлдаш агай белән сөйләштем. Бәйрәм белән тәбрик итим диган идем, иртәгә үзләре Аккүлгә киләләр икән. Каршыларга машинаны райкомнан алырсыз. Монысы — бер. Икенчесе — алдан ук әйтеп куям — алтысында кич безгә кунакка рәхим итәсез. Дүртәүләп, дүртәүләп. Юлдаш агайга искәреп куйдым мин. Бәйрәмне бездә каршылыйбыз, әйе. Миңа Украинадан кунаклар кайтачак. Берсе — Юлдаш агайның коллегасы, хирург кеше, икенчесе — диңгезче егет, штурман. Танышуы күңелле булыр дип уйлыйм. Килештек, ярыймы?

Айрат өчен бу чакыру теләсә нинди изгелекләрдән дә артык иде. Турысын гына әйткәндә, райком секретареның телефон чыңы бигрәк тә

коелыбрак тора иде. Туйкин вакыйгасыннан соң директорның аңа карашы нык үзгәрде, мәктәп башлыгы Сәрвәровны өнәмәс булды. Алай гына да түгел, район партия активы җыелышыннан кайткач (анда партоешмаларның комсомол комитетларына җитәкчелек итү мәсьәләсе турында сүз барды), Хәниф абыйсы Айратка: «Мин әйткәнчә килеп чыкты. Туйкин әкәмәтләрен кат-кат телгә алдылар. Теләгегезгә ирештегез дигәнем. Әмма безгә бергә эшлисе бит әле»,— дип шактый төрттереп тә куйган иде. Дөрес, Айрат та авызына су капкан килеш калмады. «Эшләячәкбез, Хәниф абый! Бәхәсләшә-бәхәсләшә, бер-беребезнең кимчелекләрен төзәтә-төзәтә, дөреслеккә омтылып эшләячәкбез. Әлеге сүзләрегез белән ерактан уратып өркетергә уйламыйсыздыр бит? Шуны өзеп әйтә алам, мин бу мәктәпкә бер елга гына килмәдем. Эшләячәкбез!» — дип җавап бирде.

Соңгы араларда директор аңа карата битараф бер кеше сыман мөнәсәбәттә. Хатасын аңлавымы, әллә әле дә булса күңелендә бүтән уй йөртүеме?.. Директор белән күзгә-күз карап соңгы сөйләшүдән соң Айратның Хафиз агасын күргәне булмады...

Райком секретаре шалтыратканнан соң, Айрат дәрескә канатланып кереп китте. Күңелендә чын мәгънәсендә бәйрәм башланган иде аның.

Төш якынлашканда Хафиз, өенә шалтыратып, Ләйсән белән сөйләште, Гөләндәмнең килүен белеште. Кунак каршылау ансат кына булмый бит әле ул...

Ләйсән исә соңгы көннәрдә әллә нишләп үзгәрде. Елена Семеновна белән Владиславның кунакка килү хәбәре шулай үзгәрттеме? Бер карасаң, кыз тып-тын тора. Ул уйларына урала да сүзсез кала. Икенчеләп баксаң, тау елгасыдай шау-шулы ул. Уйный-көлә, теленә килгән үткен сүзләрне сибә. Мондый минутларда аның күзләрендәге моңсулык пәрдәсе иртәнге томандай эреп, юкка чыга. Түгәрәк йөзе нурга күмелә, бит урталары алсуланып яна башлый. Хәтта озын, куе кара керфекләре дә дәртләрәк сирпелгәндәй тоела. Ул да түгел, Ләйсән янә уйчанлана. Әйткән сүзне дә ишетми. Өй түрендәге бакчага, яфрак койган каеннарга текәлә дә, карашын бер ноктадан күчермичә, озак, бик озак итеп тәрәзә буенда басып тора. Әйтерсең лә куаклар белән сөйләшә, әйтерсең лә алар да аның күңел серләрен аңлыйлар...

Бүген ул иртүк торды, хәтта сәгать алтычы житкерә алмыйча аптырады. Өйне җыештырды, кунаклар алдында киясе киемнәрен барлады. Ахырда бер карарга килде: мәктәп формасы кимәскә! Елена Семеновнаны һәм Владислав абыйсын укытучылар күзенә карап утыручы кызчык булып түгел, йорт хуҗасы булып каршылыйсы итте. Чыны да шулай лабаса. Өченче ел инде әтисенең өйдәге кыңәшчесе, таянычы ул. Кунаклар да моны белергә тиеш...

Шулай да бу көннәрне уйлар өермәсенә Гөләндәмнән дә артык эләккән кеше булмагандыр. Украинадан киләсе кунакларны каршылауда булышуын үтенгәч, җизнәсенә бик рәхәтләнеп ризалык биргән иде ул. Шуннан соң тирән итеп, тармаклы-тармаклы итеп уйлана башлады. Җизнәсенең яшьлек дусты килә ич... Бу кадәресе ни дигән сүз? Елена Семеновнаның Аккүлгә сәяхәте Гөләндәм күңелендә әле дә булса сүнмәгән өмет чаткысын әллә кая өреп очырмасмы?..

Казан — Волгоград поезды көндезге бер тулганда Аккүл станциясендә була. Сәгать уникене суккач та, Хафиз машинасын чакыртты һәм тимер юл вокзалына юнәлде.

*Бетте*

## Галимҗан Латыйп

# Мәскәү яны

Мәскәү янын мактап туялмыйбыз,
Һавасы ла, урман-кырлары!
Йөрим дисәң, китерәп лә тора
Поездлары, асфальт юллары.

Мәскәү! Ялдамы син, эштәме син,
Гел кайгыртып тора ул сине.
Тәннәреңә сихәт һәм тынычлык,
Рәхәт бирә аның саф җиле.

Әйтерсең лә купшы наратлары
Зәңгәр күккә барып тоташкан.
Мәскәү яны кебек булсын иде
Бөтен дөнья, димен, тоташтан.

●

Иртәдән үк дингез зур мәйданга
Алып чыккан чая атларын,
Сыешалмый зәңгәр киңлекләргә,
Аргамаклар чайкый ак ялын.

Элэктереп тезген очыннан бер,
Утырып алсаң алар сыртына,
Чайкаласың,
Тирбәләсең генә,
Куркуларың бар да онытыла.

Ак яллардан бер ычкынып китсә,
Бер калтырап китсә кулларың,
Син алардан һич мәрхәмәт көтмә,
Әйләндереп сала ул, җаным!

●

М. Девятаевка

Аның гомере үзе бер легенда,
Көмеш кырау кунган чәчләргә.
Бер карасаң, өлкән,
Бер карасаң,
Биргесез ул кайбер яшьләргә.

Утларын да кичкән,
Суларын да,
Ялкыннары һаман бетмәгән.
Тоткын килеш фашист самолетын
Күпә-көндез күккә күтәргән.

Чигенүне белмәс ир-егеткә
Тоткында да күкләр ачыла:
Әсир итеп фашист самолетын,
Түкереп үткән Гитлер башына!

●

Яратылган иде җиргә
Гел изгелек өчен генә.
Әзер иде кешеләргә
Ширбәт кенә эчерергә.

Исеме телдән төшми хәзер:
— Әрәм булды,
Әрәм булды...
— Әрәм түгел,
Сагынмаклык,
Мәңгелек бер адәм булды.

●

«Картаясың,— диләр,— чәчләрең
Гел агара бара.
Бернича ел гына элгәре
Алар иде кара».

Агарсыннар чәчләр, беләмсең,
Андамыни соң эш.
Ни әйтсәң дә алар барыбер
Бакыр түгел, көмеш.

## Гөлгенә

*Җыр*

Гөлгенәм, бер генәм,
Сагынам мин сине.
Өнемдә, төшемдә
Яндырасың мине.

Җырларың, моңнарың
Чыңлыйлар колакта.
Ләкин син, Гөлгенәм,
Еракта, еракта.

Утларга янмамын,
Суларда батмамын.
Бары тик туктамый
Килсеннәр хатларың.

Гөлгенәм, бер генәм,
Мин сине сагынам.
Мәхәббәт утларым
Сүнмәскә кабынган.

## Җырчы чыршы

Кара диңгез ярларына
Һималайдан — ерак илдән,
Кемнәрнеңдер әмере белән,
Ят бер чыршы күчеп килгән.

Чыршы гади түгел икән,
Җырлый икән, көлә икән,
Туган-үскән иле аның
Төшләренә керә икән.

Боерган ди:— Җырла,— диеп,
Хаҗи Гәрәй — Кырым ханы,—
Беләсеңме, үз кулымда
Тотам мин,— дип,— бу дөньяны!

Ләкин чыршы явыз ханның
Боерыгын тыңламаган,
Хан күңелен күрер өчен
Уйнамаган, җырламаган.

Бармак янап, кисәткән хан:
— Асармын да кисәрмен! — дип.—
Күз яшеңне сараемда
Шәраб итеп эчәрмен! — дип.

Аннан гайбәт таратылган:
Җырлый белми икән чыршы,
Гап-гади бер агач бит ул,
Нишләп булсын ди ул җырчы...

Чыршы сарыга сабышкан,
Ләкин горур тоткан үзен.
Бер дә исе китмәгәндәй
Үткәргән ул гайбәт сүзен.

Бер көнне аның төбенә
Ике гашыйк, ике чибәр
Утырганнар ышыкланып,
Иркәләгән йомшак җилләр.

Ике гашыйкның сүзләре
Торган җанга рәхәт салып,
Тыңлаган урманнар, таулар,
Сайрар кошлар хәйран калып.

Кичкә керсә җырчы чыршы,
Онытып бар кайгыларын,
Таңга кадәр җырлый икән:
— Сине генә сөям, җаным!..

Ишетелә бу җыр бер көн —
Җиткерелә Гәрәй ханга:
— Мин боердым — тыңламады,
Ул җиткән башбаштак анда!..

Һәм җибәргән кешеләрен:
— Барыгыз да кисегез дип,
Көлен күккә очырырга
Яккан булсын мичегез,— дип.

Уйнаклый үткер балталар,
Зың-зың килә корыч пычкы.
Тик йомычка очмый бер дә,—
Ялчыларның коты очты.

Йомычка урынына шаулап
Бары тик җыр чыңлап тора.
Кушыла аңа урманнар,
Кыялар кушыла җырга.

Чыршы бүген дә исән-сау,
Шатлык җырын җырлый һаман.
Кара диңгез ярларына
Басмасын дип явыз-яман.

●

*А. Ф. Исаковка*

Туры килдек бер үк палатага,
Күргәннәре аның җитәрлек.
Дәрте белән
Ат чаптырып йөргән
Малайларны әсир итәрлек.

Кайчакларда кала да ул тынып,
Көнгә төнне ялгап уйлана.
Иртәгәсен кояш кебек балкып,
Яңа хыял белән уяна.

Докторларга ышанычы зур да,
Авыруына ләкин ышанмый.
Бер көн тормас идем мин биредә,
Сезнең урыныгызда булсам, ди.

Кырык җирдә кырык эшем көтә,
Күңелемдә кырык беренчесе.
Больницада аунап ятармыни,
Кулларын тик тотып «егет» кеше.

Бу дөньяны шактый кайгыртасы,
Матурлыйсы әле бар аның.
Шулай булгач,
Тынычлыкка салып
Тота аламы соң ул җанын.

Көндерде ул барыбер докторларны,
Даруга ул инде табынмас.
Чир дигәнең мондый кешеләрне
Егам диеп бүтән алынмас.

1970

## Әхмәт Рәшитов

# Дусларга

Кайсыгызның кулы жылы? -
Бәйлисе бар йөрәкне...

*Хәсән Туфан.*

Язмыш миңа мәрхәмәтсез булды,
Кара кайгыларга гел чолгап:
Юлга чыксам — бер ялгызым чыктым,
Озатмады беркем кул болгап.

Бураннарда калып адаштым мин,
Урманнарда төпкә абындым,
Курганнарда...
Илгә кайтмый калган
Туганнарны өзелеп сагындым.
Ник син болай моңлы бала, дисез,
Нидән, дисез, күңелең яралы?
Тугыз яшьтән миндәй ятим калып,
Артык кашык булып карале!

Юлларымда очрап киртәләргә,
Күз яшьләрем азмы түгелде?..
Бәхет вәгъдә иткән мизгелләрне
Күтәп алу әллә җиңелме?!
Кичте инде баштан төрле хәлләр,
Бирде инде тормыш кирәкне,
Әмма яуга, йодрыкларым төйнәп,
Ташланырга мине өйрәтте.

Үзсүзлемен, бәлки, кайчакларда;
Ак димәмен ләкин караны.
Бөгелмәмен...
Һәм шул холкым белән
Күрәселәр алда бар әле!

Үткәнем һәм киләчәгем өчен
Бар җиһанга зарым булганга,
Карурманнан качкан болан сыман,
Оран салам бүген урамда.

Беләм, җырым артык сагышлыдыр,
Моңайтадыр, бәлки, сезне дә.
Ләкин җырга матур ялган нигә,
Күңел алдый торган сүз нигә?!

## Яшьлек белән саубуллашканда

*Урамда очраган гади бер кеше алдында сөйләнәсе сүзләр*

Яшьлегемне уйлап торам әле.
Ул, моң-сагыш салып күңелемә,
Яулык болгый-болгый китеп бара
Бүгенемнән үткән көнемә.

Их, барасы юллар алсу чәчәк
Һәм барысы әле алда чак,
Романтика җилкәнендә җилеп,
Җил-давылга каршы барган чак.

...Бар хыяллар инде чынга ашкан,
Күкрәкләрдә — орден...
Илдә — дан...
Яшьләр, бәлки, бездән көнләшәдер,
Мин көнләшәм ләкин... яшьләрдән.

Яшьлек яшьлек инде.
Һәм безнең дә
Күңелдә ул изге,
Гел садә;
Шул чакларын кемнәр сагынмый соң,
Хатыннардан яшереп булса да.

Кайберәүләр, әйдә, хурласыннар,
Әй, ул тиле яшьлек, дисеннәр,
Гомер буе шундый тиле булсам,
Китмәс иде әле исем дә.

## Фәһимә Галиева

●

Җиргә ак юрган түшәп,
Кар ява ишеп-ишеп.
Шагыйрь бүлмәсендә чиллә:
Эшли изүләр чишеп...
Гасыр пәрдәләре аша
Шекспир кулын кыса...
Чү, шауламыйк, бу чакта ул
Фидакарь Фучик, Муса.

●

Юртак атың булса — юл яхшы.
Ә ярканат өчен төн якты.
Ярканаттан канат сорамыйм,
Җырламыйча бер көн торалмыйм.
Өнем барда көнем, төнем бар,
Өнем бетсә, җирдә нием бар?

Җилләр ачкан олы капканы,
Кемгә икән?
Чапкын аткамы?..

### Күзләреңнән алып...

Иңнәреңә салмыйм кулларымны —
Сарылмасын сиңа сагышым.
Күкри икән күкрәк — күкри бирсен,
Күзләремдә яшен чагылсын...

Авыр уйдан ачы яңгыр яусын —
Сагышларны күз яшьләрем юсын.

Иңнәреңә салмыйм кулларымны —
Сарылмасын сиңа сагышым...
Хатирәмне чигәм, төннәр буе,
Күзләреңнән алып нагышын.

Туфан Миңнуллин

# КУЛЪЯУЛЫК

хикәя

Авылга кайттым. Мин кайтып кергәндә өйдә абыйның кызы Әлфия үзе генә кулъяулык чигеп утыра иде. Абый белән җиңги кунакта икән, кич белән генә кайтачаклар икән.

Әлфия чигүен өстәл өстенә куйды да самовар яңартырга дип почмак якка кереп китте. Мин кулъяулыкны алып караштыра башладым. Килештергән. Чит-читләрендәге чигеп ясалган чәчәкләре бигрәк матур. Тукта, шушындый ук чәчәкле кулъяулыкны минем кайдадыр күргәнем бар бит. Кайда? Кем кулында?.. Җиңги чиккән кулъяулыкка охшаган түгелме соң? Әйе, әйе, шуңа охшаган. Мин ул кулъяулыкны яхшы хәтерлим әле...

## 1

Абыйны сугышка озату бәхете миңа да эләкте. Сугышка озату бәхет түгел инде ул түгелен, тик тугыз яшьлек малай өчен фронтка китүчеләр белән бер арбага утырып район үзәгендәге пристаньга бару шактый зур куаныч. Мондый чакта эч пошырып буталып йөрмә дип өйдә бикләп калдырсалар да, берни эшли алмыйсың.

Арбадагылар җырладылар, еладылар. Җиңги дә безнең арбага утырып барды, ул да елады. Җиңги елаганга мин сөендем, чөнки ул мине үртәп елатырга ярата иде, хәзер үзе мышкылдый.

Пристаньда, китүчеләр пароходка төялгәндә дә елады җиңги, абыйның муенына асылынып елады. Безнең авылдан абый белән бергә китүче Исмәгыйл исемле егет җиңгидән көлде:

— Ник елыйсың, Шәмсеруй, әллә Гата кыйнадымы?— ди,—әйттем мин сиңа,—ди аннары,— миңа кияүгә чыксаң,болай рәнҗетмәгән булыр идем. Күрәсең, Гатауллаң нишләтә.

Аннан соң, сөйләнә-сөйләнә, абыйның җиңеннән тотып сөйри башлады:

— Әйдә, Гата, соңга калабыз. Бик кадерле булса, Шәмсеруеңны кесәңә салып алып кит. Әйттем мин сиңа өйләнмә дип, тыңламадың.

Абый белән Исмәгыйл абый кешеләр арасына кереп чумдылар, без жиңги белән яр өстендә басып калдык. Шунда жиңги кинәт нәрсәнедер исенә төшереп кесәсенә тыгылды, аннан кульяулык тартып чыгарды. Миңа урынымнан кузгалмаска боерып, «Гатаулла, Гатаулла!» — дип кычкыра-кычкыра китүчеләрне, озатучыларны этә-төртә пароход янына йөгерде. Минем янга әйләнеп килгәндә аның яулыгы башыннан шуып төшкән, чәчләре тузган, кульяулыгы кулында иде.

— Оныткanмын бит, оныткanмын бит,— дип кабатлады ул бертуктаусыз.

Ул арада әллә кайдан Исмәгыйл абый килеп чыкты.

— Гатаны югалттым,— диде ул,— әллә кая олакты. Пароход китә бит.

Жиңги Исмәгыйл абыйны күрүгә аңа ташланды.

— Исмәгыйл, жаным, зинһар, шушы кульяулыкны Гатауллага бир. Оныткanмын. Эчендә йөз сум акчасы да бар. Зинһар өчен дип сорыйм, төшереп калдыра күрмә. Исән-сау әйләнеп кайтыгыз. Исмәгыйл, берүк бер-берегезне саклагыз, аерылмагыз.

Исмәгыйл абый кульяулыкка төрелгән акчаны кесәсенә салып китеп югалды.

Пароход кузгалып киткәч, без яр буйлап йөгереп бардык. Абый белән Исмәгыйл абыйны күрдек. Палубада басып торалар иде. Икесе дә кул болгадылар, абый нидер кычкырды, тик ни әйткәнен ишетә алмадык. Пароход Идел борылышына кереп күздән югалды.

## 2

Исмәгыйл абый кулын өздереп кайткан дигән хәбәр ишетелде. Жиңги белән икәүләп кичке ашка кычыткан турап утыра идек, бөтенесен атып бәрдек тә Исмәгыйл абыйларга чаптык.

Без барып кергәндә, өй эче кешеләр белән шыплап тулган иде инде. Гадәттәгечә, сорашалар, Гитлерны сүгәләр, Исмәгыйл абыйның буш жиңенә карап ах-ух киләләр, кызганалар.

— Бер елга ярты кул ничава,— ди Исмәгыйл абый,— бүтәннәр башларын да калдырдылар әле,— ди,— менә бу калганына бармаклар үссә элеккесеннән дә әйбәтрәк була,— дип, терсәктән өзелгән кулын селеккәндәй итә.

Ниһаять, сорашыр өчен чират жиңгигә житте. Бар сораганы абый турында инде. Нигә аерылыштыгыз? Тагын очрашмадыгызмы? «Бизвистие» дигән язу килде — ул ни икән? Үлеп гәүдәсен таба алмадылар микән, әллә плин төште микән? Кайтырына өмет бар микән?

— Гата белән Казанда ук аерылыштык,—ди Исмәгыйл абый,— шуннан бернәрсә белмим. Сездән адресын соратып хат язган идем, жавабы булмады. Син алай бик үк кайгырма, Шәмсеруй, «без вести» дигәннәре ни әйтсәң дә үлде дигән сүз түгел. Әллә нилэр була анда. Үлде дигәнең дә табылып куя,— ди.

Өч-дүрт көн үткәч, Исмәгыйл абый безгә килде. Жиңги белән сөйләшеп утырдылар, бик еш абыйны искә алдылар. Киткән чакта Исмәгыйл абый гимнастеркасының түш кесәсеннән кульяулык белән акча алып жиңгигә сузды.

— Гаеп итмә, Шәмсеруй, оныткanмын. Кая анда, баш-күз әйләнгән. Гатадан аерылгач, солдат киемнәренә киендергәндә табылды. Үз-үземне сүктем ул чакта. Аннан инде, исән-сау кайтсак, бер кызык булыр, Гатага шул вакытта тапшырырмын дип сакладым. Нишләтәсең, миңа алданрак кайтырга туры килде. Ачуланма инде, Шәмсеруй.

Жиңги, билгеле, ачуланмады. Кем белә, эченнән генә, бәлки, үпкәләгәндер, ләкин Исмәгыйл абыйга сиздермәде. Исмәгыйл абый киткәч, жиңги үзе чиккән кульяулыгына капланып бик озак елады.

Абый сугыштан исән-сау әйләнеп кайтты. Иң беренче булып безгә Исмәгыйл абый килеп җитте. Кочаклашып күрештеләр. Сораштылар. Абый чолганышка эләккән. Партизаннарга барып кушылган, ике ел хат яза алмаган икән.

Җиңги табын әзерләде. Мин абый алып кайткан күчтәнәчләр белән тамакны туйдыргач, баз өстенә эшләнгән алачыкка чыгып йокларга яттым. Бераздан ишек алдына абый белән Исмәгыйл абый чыктылар. Алачык янындагы бүкәнгә утырып тәмәке кабыздылар.

— Болай сөйләшик, Гата,— диде Исмәгыйл абый.— Без элек тә дус идек, дус булып калыйк. Булганнарның бөтенесен оныт.

— Ни сөйлисең? Нәрсәне онытырга?

— Беләсең инде.

— Нәрсәне?

— Шәмсеруйның кулъяулыгын сорап алдым ич.

— Нинди кулъяулык?

— Фронтка киткәндә. Казанда. Аерылышкан чакта. Акчасын бирдем. Кулъяулыгын миңа калдыр, дидем. Синдә болай да Шәмсеруйның кулъяулыклары күп, миндә бер истәлеге дә юк. Мин дә аны ярата идем бит, үлсәм-китсәм, үзем белән аның кулъяулыгы булсын, дидем.

Абыйның кәефе шәп иде, кычкырып көлде.

— Таптың сөйләшерлек сүз, әллә кайчан булганны,— диде.

— Син көлмә, Гата, көлке түгел. Сиңа әллә ниләр ишеттерерләр. Яраланып кайткач, синең хәбәрең юклыкны белгәч, бирдем мин ул кулъяулыкны Шәмсеруйга. Ничектер яхшысынмадым, дустыма хыянәт итәмдер кебек тоелды. Аннан соң, гаеп итмә, сугыш вакытын беләсең, тормыш авыр. Шәмсеруйга ярдәм иткәләдем. Утын, печән кирәк бит. Мин ир кеше. Кешеләр әллә ниләр сөйләделәр. Тик ышан, Шәмсеруйның да, минем дә гаеп эшебез булмады. Синең хатың килгәч, бергәләп шатландык. Син инде, зинһар өчен, кулъяулык турында Шәмсеруйның исенә төшермә. Ике арада калсын.

* * *

— Кайсы егеткә чигәсең бу кулъяулыкны?— дигәч, Әлфия кызарып куйды.

— Өйрәнәм генә.

— Өлгесен кайдан алдың?

— Сандыктан бер кулъяулык таптым. Шуннан күчердем.

Икенче көн авылда армиягә китүче яшьләрне озаттылар. Китүчеләр арасында Исмәгыйл абыйның да малае бар икән. Басу капкасын чыкканда, ул әтисе-әнисе белән саубуллашты да машинага менеп утырды. Машина кузгалып киткәндә, кесәсеннән кулъяулык чыгарып озатып калучыларга болгады.

Таныш кулъяулык!

## Газиз Мөхәммәтшин

# ТАБЫЛДЫК ХАТЛАР

ХИКӘЯ

Гаҗәеп тиз үсә, тиз төзелә, яңара һәм яшәрә безнең Казан! Бу төзүчеләрдә җен гыйлеме бар инде әллә! Күз ачып йомарга өлгермисең — таудай өй салып куялар, ә дигәнче яңа урамнар сузалар. Кыланышлары кырга гына сыймый — инде күккә дә үрмәли башладылар. Биш катлар гына туйдырды, диләр, хәзер өйләрне тугызар, ундүртәр катлы итеп салабыз, диләр. Ә өйләргә күтәрелеп карасаң, бүрегең генә түгел, башың да төшеп китәрлек.

Гаҗәп, гаҗәп! Әле кичә генә урамында маэмай малайлары песи малайлары белән куышып йөргән гап-гади авыл була. Ә бүген урам да, йортлар да юк. Иске өй нигезләрендә төрле чүп-чар, ямьшек җиз комганнар, көя ашаган ката куныччлары, шешә ватыклары, саргайган кәгазь-мәгазьләр генә аунап ята, ташландык бакчада рәт-рәт булып бәхетсез алмагачлар моңаеп утыра. Ә тагын бераздан барсаң, шәһәрнең асфальт җәелгән яңа урамы гөрләп тора...

Мин беркөн генә иске йортлары сүтелеп, ул йортларның хуҗалары җырлый-җырлый яңа фатирларга күчкән әнә шундый бер урамнан үттем. Бер иске нигездә аунап яткан төрле кирәкмәгән әйберләр арасында өр-яңа, сап-сары конверт күземә чалынгач, туктап калдым. Кешеләрнең иске нигезләре белән кызыксыну гадәтем булмаса да, конверт тышындагы: «Мәчтүрәнең уз кулына! Укып чыккач, яндырып юк итәргә!» — дигән серле сүзләрне укыгач, түзмәдем, кызыксынып конвертны кулыма алдым. Аның эченнән дүрт хат килеп чыкты. Аларның эчтәлекләре, бәлки, башкалар өчен дә гыйбрәтле булыр дип уйлап, мин аларны, ничек язылган булсалар, шул килеш, укучыларның игътибарына тәкъдим итәргә булдым.

Беренче хат.

*«Мәчтүрә!*

*Мин Сездән сорыйм миңа 10 ар сум акча җыеп бирүегезне. Сез 5 кеше, ә сезнең кайсыгыз элек 5 тәңкә биргән булса аннан 5 кенә тәңкә алыгыз һәм менә әлегә 10 ар тәңкә җыеп торыгыз, ә калган 15 әр тәңкәне соңынтынрак җыеп бирерсез. Минем материал як бик авырлашып китте шул, ни өчен дибәйтеп әйтеп әйтсәң. Ә бит сезгә кайчан түләсәгез дә барыбер, соңнан кимрәк бирерсез, ә миңарга хәзергесе көнемдә акча бик кирәк ышанасыңмы-юкмы үтереп кирәк. Мәчтүрә мин бик намуслы кеше һәм мин сез биргән акчадан беркайчан да баш тартмаячакмын, мин һич кайчан да кешеләргә начарлык эшләргә үземне мәҗбүр итмәм, менә бит әле хатта ки 5 әр сум алуымны да хәтеремдә то-*

*там кем икәнен белмәсәм дә аны син генә беләсең. Менә шул Мәчтүрә җыегыз һәм миңа тапшырырсыз, якшәмбе көнне 45 таңкә көтәм. Сиңа ышанамын инде Мәчтүрә миңа каршы килмәссең дип, ни өчен дибәйтеп әйткәндә мин дә сезгә яхшылык эшләдем ич. Үтенәм бу язуны утта яндыр, югалта күрмә, ату мондый эшләр өчен икебезне дә аркабыздан сыйпамаслар. Шулай итеп зинһарлап үтенәм минем кайгыма керегез инде, хәзергә 45 таңкә җыеп торыгыз, ә калган 15 әр таңкәне эшне булдыргач бирерсез. Мәчтүрәкәй бик нык сорыйм бу язуны берүк саклый күрмә тегеләргә тел белән генә әйт тә бер минут та саклама һәм җиргә ташлама акыллы хатын бул утка ягып яндыра күр берүк. Бу эшнең ахыры һәммәбез өчен дә хәерле була күрсен. Сезнең өчен мин эшләгән эш бик яхшы бит шуны уйлагыз мондый җай икенче туры килмәс ә 25 таңкә гүпчи күп түгел, чөнки бүтәннәр 50, 40, 30 арны алалар, шулай булгач күпсенмәгез анпан очсызга сезгә бирәү дә алып бирәчәге юк. Шулай итеп Мәчтүрә төрле аңлашылмаучылыклар килеп чыкмасын өчен бу хатны алу белән утка як һәм берәүгә дә әйтәсе булма, ә үзегезнекеләргә әйт якшәмбегә чаклы сиңа 45 таңкә җыеп бирсеннәр. Ирем бик каты авырып китте. Түшәктә ята миңа аны тиз арада терелтеп аяк өсте куярга кирәк. Ә әле минем бурыч түлисем дә бар ә аны сәламәтләндерергә бер нәрсәм дә юк. Бик каты үтенеп сорыйм, Мәчтүрә, мин сезгә яхшылык эшләдем сез дә миңа яхшылык эшләргә тиешле. Хатны яндыр һәм бер җирдә дә саклама мин сезне алдамам миңа ышанырга мөмкин мин сүземнән кире кайта торган адәм түгел мин бик намуслы кеше тормыш законнары шулай инде, хәзергә вакытлыча михнәт чигәм материал як бик авыр».*

Икенче хат.

*«Хәләбикә!!!!!.....*

*Әллә син мине дивана дип белдеңме?????*

*Бер холодильник өчен мин ни эшләп сиңа 25 сум бирим ди???!!! Әгәр алай булса, мин аны кеше төсле чиратка языльп та алам! Подумаешь көтәр идек әле. Форточкабызга калай тартма беркетеп куйдык та итне-майны рәхәтләнеп шунда асрыйбыз.*

*Ха-ха!!!!!*

*Мисез тавык дип белгәнсең икән!!!???... Син бит әйттең, мин бригадир дидең, теләсәң, чиратка чиратсыз язам, бер таңкә акча бирсәң, дип әйттең.*

*Үзеңнең авызың белән шулай дип әйттең ләбаса, тиле марҗа!!!!!*

*Бер сум гына булгач, мә, дидем, игелеген күр, дидем. Ә син тагын ни дидең, ә?????..... Таныш-белешләреңә дә әйт дидең. Мин әйттем, тагын дүрт кешегә.....*

*Бик әйбәт хатын икән, бәйрәмдә яки туган көнендә җыелышып берәр бүләк алып бирербез дип әйтеп уйлашып торадыр идек әле!....*

*Ә син???!!!...*

*Менә нинди икән!!!!!!...*

*Бер сумга чиратсыз гына чиратка кертәм диеп акча өчен генә яхшы атланган булып ялагайланып йөргәнсең икән. Чиратыңның бер дә рәтечираты юк икән. Алдакчы син, белдеңме???!... Кибеттә чиратсыз чират сатып акча җыеп ятасың. Подсуд җибәрергә кирәк сине!.....*

*Ирең пләмәннәй үгез шикелле тап-таза синең. Чиртсәң, каны чыгарга тора. Какой-такой авыру анда еще!!??? Акча баер өчен кирәк сиңа, бай хәерче!!!???????. Полированный мебель кирәк сиңа, машина кирәк!!! Ел саен я Сочида, я Кырымда типтерергә кирәк!!....*

*Егерме биш сум бирсәм, холодильник кына түгел — әллә кайчан үлгән атай белән анайны терелтеп китерәләр миңа!??? Биш кешедән сразы йөз егерме биш сум җыеп, тиз генә баеп китмәкче булгансың икән, тәре башшш!!!!! Баемый гына тор, яме???*

*Фик сиңа!!!...*

*Моннан өч көн элек тә анай колхоз базарына ит алырга баргач, мин Мәчтүрәгә чиратсыз холодильник бирәм дип, анайдан өч сум акча сорагансың. Ә үзең шунда күгәрчен күкәе шәе генә күкәеңә ике сум сорап күкәй сатып торгансың!!... Иреңне дә күргән, килосын алты сумнан кычкыра-кычкыра бөрешеп беткән мандарин сатып ята иде, ди... Йөриләр мөселман халыкларын страм итеп, ди!!!!.*

*Син икенче аңа ягыласы булма!!!!*

*Бирермен бирми ни мин сиңа биш сум — мә, көтеп тор!... Тоттырганнарые ди сиңа үчлап???!!!..??*

*Бер тәңкә дидең — биш тәңкә бирдем — и все!!!!!!*

*Мин намуслы, мин намуслы диеп мактангансың, значит, шулай булгач әйткән сүзеңдә тор — бишебезгә дә биш холодильник бир!!!!.....*

*Хатыңны мин укыдым да утка яктым. Син дә минекен укы да утка як, рас намуслы икәнсең!!!!!*

*Ә бүтән акча сорама.......»*

Өченче хат.

*«Мәчтүрә сез ни сәбәпле миңа мөнәсәбәтегезне үзгәрттегез һәм миңа шундый усал һәм начар хат салдыгыз, мин хәтта гарьлегемнән кычкырып җыладым. Мин бит сезгә изгелек эшләдем ә инде сездән дә изгелек көтү турында сүз чыккач сез кинәт үзгәрдегез әйтерсең лә гүяки мин үзем нишләптер гаепле булып калдым. Ә мин сезне бөтенләй икенче кеше дип уйлаган идем, әгәр сез алай икән, мин дә ышанмаячакмын. Әгәр акча бирмәсәгез, бу бит гадел булмаячак һәм мин теге кеше алдында дуңгыз шикелле булып калачакмын чөнки исемлеккә мин үзем генә кертмәдем бит, димәк, мин сезгә аллаһаппәр өчен бер тиенсезгә бу эшне җайларга тиеш булганмын. Ә сез шундый хат язгансыз әйтерсең лә мин гаепле сез миңа түгел, мин сезгә бурычлы булып түләми йөрткән шикелле. Ну ярый сез миңа шундый этлек эшләргә ягъни алырга гына ә бирергә түгел телисез икән мин дә иптәш сезне сыздырталам, исемлектән сызам да ыргытам. Кабатлап әйтәм мин әле үз гомеремдә берәүне дә алдамадым һәм әйткән сүземнән кайтмадым. Карагыз аны нахалка исемлектән сызам да ташлыйм и үзең әйткәндәй все ата нахалка саран крис. Хатны сакламагыз күңелсезлекләр китереп чыгармасын өчен һәм моның турында кем дә булса чит кеше белсә сезнең үзегезгә дә яхшы булмас язуны ертмагыз ә яндырыгыз!*

*Ә менә дүртенче — соңгы хат.*

*«Син үзең нахалка!!!!!....*

*Сыздың пычагымны исемлектән!!!!!*

*Холодильникны кичә апкайттык инде!*

*Ха-ха-ха-ха!!!!!.....»*

Менә шушы хатлар иде алар.

Яндыр, яндыр дисәләр дә, Мәчтүрә дә, Хәләбикә дә ни сәбәптәндер бер-берсенең кинәшен тотарга ашыкмаганнар. Бу нәрсә дә, хатларның, ахыр килеп, нинди сәбәпләр аркасында бер үк конвертка килеп керүләре дә, бу нигезнең кем нигезе булуы да минем өчен сер булып калды.

Аннан ары, бу икәүнең кайсы нахалка, яисә кайсысы кайсысыннан нахалрак? Мин бу сорауга да үзеп кенә җавап бирергә кыенсындым һәм табылдык хатларны укучылар хөкеменә тапшырырга ниятләдем.

Соңгы сүз итеп тагын шуны әйтим — бу хатлар ярый әле яңа йортларга күчеп китмәгәннәр — иске нигездә кирәкмәгән чүп-чар арасында онытылып калганнар! Әле шунысы бераз куандыра...

*1970*

# МИХАИЛ ЛЬВОВ ШИГЫРЬЛӘРЕ

*Танылган шагыйрь... Бу сүз күп нәрсәне эченә ала. Әдәбият дөньясы — зур дөнья. Пушкиннан башланып бүгенгә тоташкан араны гына алсаң да — анда күпме талантлар... Хәзер әдәбиятның чикләре тагын да киңәйде, күз карашы җитмәс дәрәҗәдә киңәйде. Шагыйрьгә танылу тагын да читенләште. Әдәбият дөньясы шундый киң, кайвакыт барысын да күрү мөмкин түгел шикелле. Ләкин талантлар барыбер югалып калмыйлар, биографияләренә күз төшерсәң, хәтта бераз гаҗәпләнеп торасың, чыннан да ничек югалмаган, дисең. Иҗаты белән бөтен совет укучысына танылган Михаил Львовның биографиясе кызык. Ул 1917 елда Башкортстанда Насибаш авылында туган. Ә бала чагы Лаклыда узган. Әтисе Дәүләтша Шаһи улы Габитов — укытучы, Татарстанның Норлат районыннан... Дәүләтша абзый революция хәрәкәтендә катнашканы өчен колчаклылар тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителә, соңыннан үлем җәзасы 20 елга төрмә белән алыштырыла. Әтисе кулга алынганнан соң һәм шул елларда әнисе вафат булганнан соң яшь Рифгать (аның элекке исеме шулай. Без, шагыйрьләр, аны үзебезнең арада Рифгать дип кенә йөртәбез) башта кеше кулында тәрбияләнә, аннан Златоуст шәһәрендә әбисе карамагында үсә...*

*Уку еллары... Златоустта җидееллык мәктәп, Миасс педагогия техникумы, беренче шигырьләр... 1935 елда Михаил Львов Чиләбедә «Безнең трактор» газетасы редакциясендә эшли, читтән торып Горький исемендәге әдәбият институтында укый. 1939 елда институтны Мәскәүдә тәмамлый. Институтка Бөек Ватан сугышы ялганып китә. Ул — танкист. Ул танкта, үз корпусы белән, Украина, Польша, Германия, Чехословакия җирләре буйлап үтә.*

*Мондый биографиядән баш калкытып шагыйрьлеккә күтәрелү җиңел булмагандыр. Танкистлар өчен бик характерлы бер сүз бар: прорыв. Львов та поэзиядә шушы прорывны ясый. Поэзия кырының да үз рубежлары бар, шагыйрь дә шул рубежларны үтеп килә. Иң кыены шунда: поэзия фронтының үз солдатлары арасында аны тавышыннан таныйрлык булсын... Бөтен ышаныч — талантта...*

*Львов безне 1950 елларда үзе тапты. Ә 1957 елда, без Мәскәүдә татар әдәбияты декадасын үткәрергә җыенып йөргән көннәрдә, яңадан килеп чыкты. Әтисенең нигезе белән, халкының җире белән очрашу — күрешү өчен, безгә булышу өчен килеп чыкты.*

*Казанда очраштык. Дуслык зур эштән — антологиядән, татар тарихында беренче тапкыр чыгарылачак антологиядән башланып китте. Антология — авыр хезмәт, зур хезмәт. Тәрҗемәчеләр кирәк. Львов — инициатор, оештыручы һәм тәрҗемәче.. Сәгыйть Рәмиев, Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Мөхәммәт Садри, Әнвәр Давыдов, Мәхмүт Хөсәен шигырьләренә антологиягә юлны башлап ул ачты. Шул хезмәттә таныштык. Шуннан бирле элемтәнең өзелгәне юк. Мәскәүдә татар әдәбиятының илчесе дип йөртәбез без аны...*

*Львов иҗатын мин күптән күзәтеп киләм. Баштарак ул миңа шигырьдә җиңелчә уйный кебек тоелды. Шулай тоелды. Бу, бәлки, эзләнүнең үзенә күрә бер формасы булгандыр? Әгәр шигырь юллары астында фикер, хис ята икән, нигә уйнатмаска шигырьне? Тукай да бит: «Шигырьне мин ат уйнаткан кебек уйнатам»,— дигән...*

***СИБГАТ ХӘКИМ***

## Безнең Атлантида

Ничә миллион халкы бар иде...
Югалттык без шундый бер илне,
Бөек Ватан сугышы барганда.
Насыйп түгел кайту аларга.

Безнең Атлантида — зур яра.
Юллар да юк, гид та юк аңа...

Әгәр дә мин уйларда янсам,
Авыр газапларда кыйналсам,
Үчтән тыялмасам үземне,
Фашисттан алмасам күземне,
Димәк, һаман борчый ул мине,
Мин онытмам мәңге ул илне.

## Госпитальдә

*Всеволод Аксенов истәлегенә*

...Чиләбедә. Госпитальдә концерт.
Зал тыңлавын әйбәт тыңлады.
Бик аңлап та, ихлас белән дә, тик
Кул чабулар никтер булмады...

Син уңайсыз аптырашта идең,
Бер яралы торып җаеннан:
— Гафу итегез инде безне,— диде,—
Без кулсызлар монда җыелган.

Кинәт сафта тәртип бозылгандай
Булып китте,
жавап тапмады
Моңа сәнгать, җаны сызланганга,
Хакыйкатькә башын гына иде,
Хөрмәт белән тынлык саклады...

НУРИ АРСЛАНОВ тәржемәләре

## Минем татар телем

Мин Казанда татарчалап сөйлим,
Ә сүзлегем ярлы шактый ук.
Карыйм җиргә татар күзе белән,
Рифгать дип һәр кеше атый күк.

Хәреф танырга да өлгермәдем,
Зур шәһәргә алып киттеләр.
Океандай тирән һәм дә ярсыз
Рус теленә гашыйк иттеләр.
Шул дингездә утыз ел буена
Моряк булып хезмәт итәм мин.
Корабымны сүзләр гаскәренең
Бәрелешенә һаман илтәм мин.

Татар теле ярларында ләкин
Чит кешедәй торам аптырап.
Гафу ит син мине, татар телем,
Син ничектер миңа ятырак.

Синең өчен малай булып калдым.
Мин һаман да үсмер этапта...
Әлифбадан аерылуыма
Язалмадым җыр да, китап та.
Татар теле,
Кичер мине!

Өстәлемдә — Җәлил.
Назыйм Хикмәт
Урын алган аның янында.
Ак канәфер чәчәк тоткан килеш,
Белоянис карый рамыннан.
Бернидән дә алар, беркемнән дә
Курыкмаган һичбер вакытта.
Рәсемнәре бергә торсалар да,
Минем өчен якын булсалар да,
Сугышмаганнар бер окопта.
Өч кыюны, әйе, бер уй-максат
Берләштергән, солдат иттергән,
Һәм аларны, бер мәрҗәнгә тезеп,
Өстәлемә тормыш китергән.

МӘХМҮТ ХӨСӘЕН тәрҗемәләре

## Билгесез солдат

Мин — билгесез. Мин — хәбәрсез үлдем.
Мәгълүм түгел исемем хәзер дә.
Җирнең үлмәс улы булып ятам
Кремль янындагы кабердә.

...Мәскәү буйлап минем килер юлым
Тантаналы булды бергә.
Генераллар форма киеп килде
Гүя миңа рапорт бирергә.
Җир тын иде. Ул көн флаглары —
Матәм чәчәкләре иделәр.
Ә күңелләр әйтте: «Иле буйлап
Илнең улы уза»,— диделәр.
Барча постлар миңа баш ияләр.
Ә табутым минем — лафетта.
Гәрчә җирнең гади җәяүлесе
Булсам да мин исән вакытта.
Бер солдатны бөтен дәүләт күмә,
Бөтен Мәскәү буйлап үткәреп.
Минем көлне Илнең Башлыклары
Кулларында килә күтәреп.
Барча йөрәк бердәм тетрәп китте,
Бөтен күзләр гүя яшь койды.
Чөнки иле, чөнки халкы исән
Булсын өчен солдат баш куйды.
Әйтеп үлдем: «Кордаш-чордашларым,
Сез билгеле булып калыгыз!
Яудан кайтып, сөйгән ярлар белән
Табыннарда утыра алыгыз...»

Минем туфрак жиңел булсын өчен,
Үз даннарын өстәп даным.
Ватанымның герой калалары
Килеп басты кaберем янына.
Ленинград та, Сталинград та шунда,
Шушында ук Мәскәү җире дә.

Ишетәм мин Киев сулышын да,
Һәм Брест та әнә бирелә.

Мин яңадан яраламдыр төсле
Мәңге сүнми торган бу утта.
Кочакларга сезне ашкынам мин
Яннарыма килгән минутта.
Арагызда сезнең кемдер — туган,
Кемдер — энкә, кемдер — ул миңа.
Мин югалдым яуда сезнең өчен,
Йөрәк сызды шундый юл миңа.

Юк, чәчәкләр кирәк түгел миңа,
Үлмәс җырлар кирәк үзләре.
Мәңгелек — ут, мәңгелек — мин монда.
Күзләр жиргә кояш даулагандай,
Локаторлар аваз аулагандай,
Утка баксын күнел күзләре!

ЗӘКИ НУРИ тәржемәсе

●

Казан вокзалында ялгызым
Басып торам. Юк, мин хан түгел,
Агулы ук түгел кулымда,
Һич мактамый аны бу күңел.
Мәскәүдәге Казан вокзалыннан
Ил эченә чумып китәм мин.
Казанга һәм Урал ягына
Бик тиз генә барып житәм мин.
Килеп чыгам өр-яңа көнгә —
Көннәр монда шундый шифалы.
Бу вокзал — бер гаҗәеп ачкыч,
Мәңге югалтмамын мин аны.
Шәхси, серле шушы ачкычым,
Күп йозаклар ача белә ул —
Кешеләргә минем сөюне,
Реальлелекне ачып бирә ул.
Якташларның йөрәк җылысын
Ачкан чакта җырлап тора ул.
Ракеталы чорда борынгы
Дага кебек чыңлап тора ул.

ГӘРӘЙ РӘХИМ тәржемәләре

*
* *

*СИБГАТ ХӘКИМГӘ*

Хәким дустым, игелекле дустым!
Үтенеч бар сиңа минем дә:
Нәкъ илле яшь тулган көнемдә
Котла мине Тукай телендә!

Котла мине Муса телендә син,
(Шушы телдә Муса көрәште,—
Моабитны шул тел тетрәтте.)

Мин дә сиңа җавап җибәрермен,
Җырларыма кушып йөрәкне.

Котла мине, котла, кадерле дус,
Күңелле көн — туган көнемдә,
Яшь чагында Ленин хөрмәт итеп
Тыңлап йөргән матур телендә!

Мине әти, чор һәм революция
Бөек Россиянең кулына
Тәрбиягә биреп үстергәннәр,
Ул сынау да булган улына.

Мин ышанам, дуслар, Россиягә —
Туры, гадел сүзгә — аңарга!
Мин сүз бирдем атам туфрагында
Изге Россиядә янарга!

## Ир кешеләр

Мәгъдән булу — мәгъдән үзе генә
Җитмәгән күк тимер итәргә,
Дөньяга ир булып туу җитми,
Чын ир кеше булып үсәргә!
Син тиешсең, мәгъдән кебек эреп,
Үз-үзеңне корбан итәргә,
Син тиешсең бөек сынау аша,
Утлар-сулар аша үтәргә!
Авыр итек белән җәен кыен,
Ә син солдат — тиеш түзәргә.
Соңгы үбешкәндә туган якта,
Пуля тиеп яраланган чакта
Син түзәргә тиеш,
Син җиңәргә тиеш, җиңәргә!
Ир кешеләр курку белми алар,
Үлемгә дә каршы баралар,
Үлә белеп үлгән баһадирлар
Гасырларда яшиләр алар.

МӨХӘММӘТ САДРИ тәрҗемәсе

**Мәхмүт Хөсәен**

# МӘХӘББӘТТӘ ЯНСА ЙӨРӘКЛӘР...

СОНЕТЛАР

●

Мәхәббәтнең бар үз кануны:
Буйсынмый ул һичбер акылга.
Алыштырмый ләшерен януны
Һичбер сыйга, һичбер алтынга.

Ишекне дә шакып тормыйча,
Туп-туры ул түргә ера юл.
Тынгылыгың жуя тормышта —
Әйтерсең лә төклетура ул!

Сихри утны, соңмы-иртәме,
Сөягеңә кадәр сеңдереп,
Бөтен шикне, барлык киртәне
Юлларыңнан ата себереп.

Мәхәббәт ул — әҗәл даруы,
Тугыз баллы хисләр давылы.

●

Йөзләрең — таң: яңа-нурлана,
Керә алсу-алтын төсләргә.
Күзләреңнән кайнар нур ява,
Йөрәгең бай, димәк, хисләргә.

Орлыгыңнан шытып хисеңнең,
Йолдызларга гыйшкың үрләсә,
Кояш үзе, ачып ишегең,
Бусагаңнан атлый гүргәчә.

Тылсымлы көч, әйе, хатын-кыз.
Ул теләсә, таулар чигенә!..
Яшәп кара ярсыз, хатынсыз,
Чәчләреңә бәсләр чигелә.

Җил-явымсыз, дымсыз — җир
ятим,
Хатын-кызсыз — егет-ир ятим.

●

Бала гына бит син үзең дә.
Ләкин минем шуңа ис китә:
Шәрап бармы әллә күзеңдә?
Карадыңмы — шундук исертә!..

Таң яктыра кебек йөзеңдә
Елмайсаң да кайчак ялгышып...
Магнит бармы әллә күзеңдә?
Карадыңмы — калам ябышып.

Йөзәсең син күңел күгемдә,
Көндез кояш, төнен ай булып...
Нәрсә бар соң синең күзеңдә?
Карадыңмы — булмый аерылып.

Минем өчен, әй, яшь гүзәлем,
Илһам таңы синең күзләрең.

●

Ак йолдызлар яуган кич иде,
Җем-җем итеп торды юл балкып!..
Үзәгемә кайнар хис инде
Иреннәрең аша шул вакыт.

Януыңның яшрен ялкыны
Бөтен тәнем буйлап йөгерде.
Онытылды кышның салкыны,
Керфекләрдә ак бәс эреде.

Ул кич җиргә, безнең күңелгә
Бриллианттай балкыш китерде!
Ул кич йөздек ләззәт күлендә,
Бәхетле пар аккош шикелле.

Гашыйк карлар кичтән явалар,
Гашыйк ярлар эчтән яналар!..

●

Нәрсәнедер яшереп каласың,
Чишкән чакта серләр капчыгын.
Күңелгә шик-шөбһә саласың,
Сөйләмичә эшнең хак-чынын.

«Берни дә бу сизмәс»,— дип узсаң
Ялгышасың — кайт ул уеннан.
Аңла шуны: нәни шик-тузан
Давыл булып куба соңыннан!

Учак сыман балкып уз яннан,
Тырнак астына кер туплама.
Инә очы тикле тузаннан
Тау кадәрле могор туктала.

Күңелдә кер, телдә чүп йөртсәң,
Кояш йөзен күрмәс күп иртәң.

●

Саргаешып бакча төбендә,
Сибелә дә яфрак сибелә.
Күңелемдә минем, телемдә
Син генә тик, әйе, син генә!

Бөртегенә чаклы чәчеңнең
Никтер миңа якын тоела...
Хәтерләтеп утны-яшенне,
Сулышымнан ялкын коела.

Син ничектер? Янам мин утта —
Сагыну белән газап иш икән!
Сине, иркәм, һәрбер минутта
Үз янымда кебек хис итәм.

Янымда син, мәңге җанымда —
Учагым да, ямьле таңым да.

●

Бер тымызык айлы кичен син
Күңелемә кереп урнаштың...
Шул мизгелдән минем өчен син
Мәхәббәттә нурлы чор ачтың.

Җылысында синең кояшның
Шау чәчәктә сизәм үземне...
Читкә этсәң, тиңем-юлдашым,
Төн томалар ике күземне.

Сукыраермын кинәт шул вакыт —
Тамырыннан гыйшкым йолкыныр...
Минем өчен тормас юл балкып —
Гомерлеккә кояш тотылыр.

Сине җуйсам, миңа көн бетәр,
Йөрәгемне кайгы көл итәр.

●

Хәятыңда хәләл хатыны —
Гаиләңнең мәрмәр нигезе.
Ул — мәңгелек ярың-якының,
Хисләреңнең зәңгәр диңгезе.

Яннарыңда ярың барында
Иң бәхетле син җир шарында!
Тәмен наның, ямен кояшның
Аның белән бергә тоясың.

Уңсаң ярдан, уңсаң хатыннан,
Гомерең гөл булып үрелә.
Ул бөркегән сулыш-ялкыннан
Сүнеп барган җаның терелә!

Син дип үлеп торса хатының,
Алтын булып балкый бакырың.

●

Каршы куеп җилгә күкрәген,
Текә тауга сукмак яра ир.
Учка кысып кайгы күкрәвен,
Тешен кысып җырлап бара ир.

Сынау килсә, төшми сынып ул:
Давылларда — яллы арыслан!
Җиденче кат тирен сыгып ул,
Җинеп чыга яудан-ярыштан.

Ил өчен ир — арка сөяге,
Хатын өчен — алтын багана.
Яныл типсә ир-ат йөрәге,
Хәвеф-хәтәр белми замана.

Толпар ялы җил дип тарала,
Ир-ат башы ил дип агара.

●

Бер күрүдә күңлем кол итте
Кояш сыман кайнар карашы!
Сөюемне ләкин көл итте —
Гомерлеккә калды ярасы.

Тәүге гыйшкым сыкрап сулудан
Әрнеп әйттем: «Бүтән сөймим яр!..»
Миңа хәзер яшен сугудан
Чатнап ауган ялгыз сирень пар.

Берәү мине сөя — лаек тин.
Күреп торам: үлеп ярата!
Кирәгеннән артык аек мин,
Артык салкын аңа карата.

Кабынмагач хисләр, нишләргә?
Әмер биреп булмый хисләргә.

●

Тылсымлы төн эри кашында,
Тере тюльпан — уймак иренең.
Иягеңнең нәкъ уртасында
Янып тора туты миңеннең.

Йөзеп йөри йолдыз күзеңдә,
Карашларың назлы, ягымлы.
Нинди магнит, белмим үзем дә,
Гел үзенә тарта җанымны.

Бит алмаңда ал таң сызыла,
Көмеш көзге — күңлең көрлеге.
Алмаштырмыйм мин хур кызына,
Син бит язның янар бер гөле.

Кара күе — күзең сөрмәсе,
Ә үзең син — сафлык хөрмәсе.

●

Ут йотсам да көләм-елмаям,
Сиздермим аһ-зарның исен дә.
Күңелем — яз тулы гөл-мәйдан,
Яктыра ай ачык йөземдә.

Чыраемны чытмыйм — елмаям,
Зарыксам да гел кан түкереп...
Илһам алып имин еллардан,
Балкып яшим зәңгәр төн кебек.

Газраилга хәтта елмаям,
Җор күрсәтеп юри күңелне.
Шук, янәсе, үзем, гел наян...
Юк, юлатмыйм җанга үлемне!

Холкым белән гел шат, гел шаян:
Елар чакта да мин елмаям!

●

Минем өчен олы агай син,
Ләкин гел үз була барасың.
Белмим, якын нигә алай син —
Әллә нишләтә күз карашың.

Нидер сизәм, үзем ничектер
Сизгәнемне әйтә алмыймын...
Күрешүне, зинһар, кичектер,
Оялам мин синнән, абыем.

Гел күрешмик дияр идем дә,
Күңел никтер сиңа омтыла.
Әллә ниләр кайный миемдә,
Агай икәнең дә онтыла...

Кочып алса гыйшык кояшы,
Истән чыга бөтен дөньясы.

●

Комын, дилэр, күптэн коелган,
Картлык йөри калгып өендэ.
Чыгарып ат, дилэр, уеннан
Януларны хистэ-сөюдэ.

Юк, килешмим! Тонык күзлэрем,
Чибэр кызлар күрсэ яктыра...
Өзгэлэнеп никтер үзэгем,
Ямансулап куям чак кына.

Ай, бу яшьлек! Ай, бу матурлык!..
Сихерле дэ, саф та, татлы да...
Яшен угы сыман атылып,
Яралый ул миндэй картны да!..

Картлыкта да гыйшык тилертэ,
Хислэренңе янар көл итэ!

●

Иң иске хис җирдэ — мэхэббэт:
Кыю кичэ суны-утны да!
Һэммэ ялкын анда, һэммэ дэрт —
Төкерэ ул төпсез упкынга!

Иң яңа хис җирдэ — мэхэббэт:
Ярып үтэ тауны-ташны да!
Ул мэңгегэ горур, мэһабэт —
Көлеп карый шашкын ташкынга!

Иң изге хис җирдэ — мэхэббэт:
Ул яшь килен сыман ояла...
Күпме сафлык анда, мэрхэмэт —
Тиңдэш ул иң биек кыяга!

Упкын, ташкын, кыя — барсы да
Күндэм бер кол сөю каршында!

1970—1971

Геннадий Паушкин

ОЧЕРК

# ЧАЛЛЫ ҖИРЕНДӘ

Чаллы. 720 кеше яши. 136 йорт, чиркәү, училище, су тегермәне, 18 кибет, җомга көнне базар, өч мәртәбә ярмарка була. Кама елгасы буенда пристань. Анда торучылар, иген игүдән тыш, бурлаклык белән шөгыльләнәләр һәм пристаньда эшлиләр.

*(Россия империясенең 1888 елгы географик-статистик сүзлеге.)*

## Иртә таң белән



Иртәнге әңгер-меңгер, күрше бүлмәдәгеләр инде аяк өстендә. Безне уятмас өчен аяк очларына гына басып, кухняга узалар, табак-савыт шалтырый — иртәнге аш әзерлиләр. Алар инде биредә ике айдан артык яшиләр, бәрәңгесен, суганын дисеңме, чәй-шикәрен дисеңме — барысын да булдырганнар, ашханәгә барып йөрмиләр. Яшьләрнең өлкә газетасы хәбәрчесе Володя белән без дә торабыз, күршеләр әзерләгән чәйне эчәбез — без әле монда яңа кеше, запасларыбыз юк.

...Без утырасы автобус әлегә юк, эш юктан эш булсын дип, белдерүләр тактасына күз салабыз. Әйтергә кирәк, бик гыйбрәтле бу белдерүләр, яшь шәһәрнең үзенә күрә визит карточкасы дияргә була аларны. Белдерүләрнең күбесе эшкә чакыра. Штукатурлар, малярлар, ашханәләргә табак-савыт юучылар, йөк ташучылар, радистлар, электромонтерлар, парикмахерлар — тагын бик күп төрле һөнәр ияләре. Менә монысы бөтән төрдәге белдерүләр: «Новокузнецск шәһәрендәге өч бүлмәле квартираны Чаллыдагы шундый ук квартирага алыштырам», «Салават шәһәренең үзәгендәге ике бүлмәле квартираны Чаллыдагы шундый ук яки бер бүлмәле квартирага алыштырам».

«Пермь шәһәрендәге өч бүлмәле квартираны...» һ. б. шундыйлар. Кешеләр Чаллыга ашкына.

һәр җирдәге кебек, монда да көлке белдерүләр дә юк түгел: «Кәҗәсен югалткан кеше ГЭС поселогының яшелләндерү бүлегенә мөрәҗәгать итсен. 15 йорт, яшелләндерү бүлеге». Бу белдерү ике айдан бирле эленеп тора икән инде, ә кәҗәне килеп алучы һаман юк, ди. Кәҗә бәясе штраф бәясеннән арзанрактыр, мөгаен.

Менә тагын берсе: «Вак бәрәңге сатыла...» Кызык: кибетләрдә бәрәңге тулып ята, кемгә кирәк булсын инде ул вак бәрәңге?!

Әмма тормыш тормыш инде.

Тукталышта халык күбәйде. Менә бер-бер артлы автобуслар да килеп туктады. Берсенә «КГЭС — Сидоровка»,— дип язылган. Бу без барасы маршрут түгел, Чаллыдан бөтенләй кире якка. «КГЭС — Гравзавод» — дигәне дә безнеке түгел. «ЗЯБ — КГЭС», «Орловка — КГЭС» дигәннәренә дә утырмыйбыз, кирәкләре чыга-нитә калса дип, блокнотларыбызга маршрут номерларын язып кына куябыз.

Урамның һәр ике ягына биш катлы йортлар тезелеп киткән. Әнә, П хәрефе кебек итеп салынган өч йортның берсендә яшьләр тулай торагы. Аскы катында — кафе. Йортларны төзелеш номерлары белән генә табарга мөмкин: 4/1, 4/2. Шунда ук — «Камгэсэнергострой» конторасы һәм кадрлар бүлеге.

Ишек алдына халык җыелган. Бу тирә Чаллыда хәзер иң җанлы урын. Халык өзлексез килә тора. Чемодан, рюкзак тоткан егетләр, кызлар эскәмияләргә утырганнар, бер-берсе белән танышалар, кадрлар бүлегеннән чыгучыларга кызыгып карыйлар. Юк, эш турында кайгырмыйлар алар,— эшнең монда очы-кырые юк,— тулай торакта урын алу — төп мәсьәлә.

4/2 номерлы йорт артында авыл ихаталары тезелеп киткән. Рәшәткә буенда сыер утлап йөри. Проспектта гына ул машиналар агымы, кешеләр ыгы-зыгы килә. Почмактан тыкрык белән кереп китсәң — тып-тын...

Тукталышның бер ягында — мәктәп, ә аннан ерак түгел, бетоннан һәм пыяладан ясалган гигант аквариумны хәтерләтеп, «Чулпан» кинотеатры тора...

Менә безнең автобус та килеп туктады. Без аңа утырып, парк янына кадәр бардык. Төштек тә Кама ягына таба атладык. Монда әлегә барлык нәрсә Чаллының авыл вакытын хәтерләтә.

Комсомолның шәһәр комитеты әлегә электәге урынында — ике катлы агач йортка урнашкан. Секретарь үзе дә монда булып чыкты.

— ВЛКСМ Үзәк Комитеты члены Вазих Мавликов янына бармый калмагыз,— диде ул.— Виктор Филимонов бригадасы белән дә танышыгыз...

Аннары Валерий Кузьмин кадрлар турында сөйләп китте. Кадрлар һәм торак мәсьәләсе — беренче чиратта хәл ителәсе мәсьәләләр. Төзелеш эшләре моңа кадәр күрелмәгән темплар белән барса да, барысын да тулай торакларга һәм яңа йортларга урнаштырып бетереп булмый бит. Ике мең ярым кеше тирә-яктагы авылларда торып эшли, мең ярымы — Чаллының үзендә кеше фатирларында яши. Ә халык һаман килә дә килә...

Эшләрнең күләме гаять зур. Җитмеш беренче елны гына да 240 миллион сум акча эшкә сарыф ителә. Бу — һәр эш көнендә бер миллион сум дигән сүз.

Быел монда төзүчеләр поселогы төзелеп бетә һәм яңа шәһәргә нигез салына. Илле алтынчы елга тикле 28 мең кеше яшәгән булса, хәзер инде Чаллыда аңа караганда халык саны бермә-бер артык. Ә 1975 елда Чаллы шәһәре 300 мең кешелек булачак. Менә бу үсеш дисәң дә үсеш!..

Бер биек бина тирәсендә йөрибез дә йөрибез, керергә һич тә ишек таба алмыйбыз.

— Ничек керергә монда? — дип сорыйбыз бер эшче егеттән.

— Тегендәме? — ди егет, ияге белән өскә ымлап.

— Әйе.

— Лифт белән! — һәм егет, кулларын селки-селки, ул лифтның бик әкрен генә өскә таба менәсен аңлата.

Күренеп тора: шаярта... Йорт әле эшләнеп бетмәгән, кайдан килсен ди лифт?!.

— Кран ягына чыгыгыз,— дип киңәш бирә егет аннары.— Анда ишек кебек бер тишек булыр, ул тишек каты кәгазь белән капланган булыр, шул кәгазьне төрттегез исә — юл ачык, рәхим итәсез...

Без ул ишекне таптык, кәгазьне этәреп эчкә кердек һәм үзебезне бик тирән таш коеның нәкъ төбендә итеп хис иттек. Бер адәми зат та юк, тик кайдандыр, бик югарыдан тоныкы кына булып: «Майна-вира, вира-майна»,— дигән авазлар гына ишетелә.

Борынгы заман кальгасындагы сыман, сакланып кына басмадан өскә таба күтәреләбез. Беренче кат мәйданчыгында стенага: «Бинаны чүпләмәгез, чисталык саклагыз!» — дип язып такта элеп куйганнар. Аяк асты тулы төзелеш чүп-чары, вак таш, кибеп каткан цемент эремәсе кисәкләре, йомычка... Күрәсең, егетләр шаярта беләләр...

Минем юлдашым Танюша — комсомолның шәһәр комитетында эшләүче кыз — төзелешләргә күп йөргән, мондагы монтажчыларны да яхшы белә. Ул җилкенеп-җилкенеп баскычтан өскә ыргыла. Мин аның артыннан өлгерә алмыйм — тыным кыса.

— Тукта әле, Таня! Ничәнче катны менәбез икән инде?

— Әнә бит стенага язылган. Алтынчы кат. Тагын алтыны менәсе кала.

Кара син аларны, рәхмәт төшкерләре, килүче-китүчеләр турында ничек кайгыртканнар... Һәр катны менгәч, язып куелган. «Җиденче кат» ...Күңелле булып китте: «Тугыз булды, тагын өч кенә калды!»

— Әйдә, Таня, азрак тын алыйк! Әнә, күрәсеңме, стенага да: «Ун. Уникенчегә дә җитәрбез! Әмма исеңдә тот: биеклек арткан саен, кыенлык та арта бара!» дип язганнар.

Безнең өстә дүрт почмаклы булып зәңгәр күк йөзе күренә. Әкренләп таш коеның соңгы мәйданчыгына җитәбез. Кемдер өстән безгә дәрт биреп тора:

— Әйдә, әйдә, кыюрак атла! — ди.

Иң өстә чардакка менү өчен тимер баскыч куелган. Көч-хәл белән анысыннан да менәбез.

— Исәнмесез!

— Сәлам!

— Биектә яшисез.

— Без һәрвакыт югарыда.

Танышабыз.

— Филимонов,— дип кулын суза озын буйлы, киң җилкәле, өстенә телогрейка кигән бер егет. Чырае яшь, ягымлы. Елмайганда бит уртасы чокырая. Мин гаҗәпләнеп Таняга карыйм: юлда килгәндә, аңардан бригадирның ниндирәк кеше булуын сорагач, ул Виктор Филимоновның яше инде шактый олы булуын әйткән иде...

Безнең янга озын буйлы, ябык кына бер егет килде дә, дикъкать белән безгә карап торганнан соң:

— Николай Мартынов,— дип кулын сузды.— Ә сез Мәскәүдәнме әллә?

— Пардон, мсье,— дип Николай, кулын күкрәгенә куеп, башын түбән иде.— Түбәнчелек белән гафу итегез, галстук тагарга онытканмын.— Һәм ул галстугын барлагандай итеп, кулын күлмәк якасына тидереп алды. «Одессадан килгән егет булырга тиеш»,— дип уйлап куйдым мин. Ә Мартынов маскасын киде дә эшенә тотынды.

Мин кырык метрлы бу биеклектән тирә-якны күзәтергә керештем. Дугаланып торган Кама елгасының ярлары көзге урманга төренгән, еракта шырпы тартмасы кебек кенә авыл өйләре тезелеп киткән, нечкә тасма кебек сузылган юллардан йөк машиналары йөгерә. Чаллы — электәге Чаллы — уч төбендәге кебек күренә моннан. Әнә элеватор, су кудыргыч башня, мәктәп, партиянең шәһәр комитеты биналары...

— Яңа шәһәр елга буйлап югары таба сузылачак,— дип сөйләп китте Филимонов.— Әнә тегендә таба, Боровицкое авылына кадәр, күп катлы йортлар тезелеп китәчәк. Алар белән завод арасында бер километр киңлегендә урман утыртылачак. Ә йортлар менә диган итеп салына. Кайсылары табигый таштан салынган кебек итеп тышлана, кайбере гранит яки мәрмәр кебек — күз явын алырлык... Ә юллар... Бетон һәм асфальт. Шәһәр белән завод арасындагы урманда — дачалар...

«Чыннан да,— дип уйлап куйдым мин.— Вакытның агышы тиз. Виктор сөйләгәннәр бик тиз чынга ашар. Күптәнме соң әле Әлмәт, Лениногорск шәһәрләре төзелә генә иде! Хәзер инде алар үзләренең унъеллык юбилейларын үткәрделәр. Ә мондагы темп тагы да куәтлерәк: дүрт ел эчендә яңа шәһәр һәм автогигант салу! Ялгышмасам, мондый зур темп, мондый зур төзелеш бөтен дөнья тарихында булганы юк...

Ул арада безнең янга Мартынов килеп басты.

— Без сала торган йорт,— диде ул,— алты-өч номерлы йорт — бөтен Чаллы өчен гыйбрәтле. Ул йорт Мәскәүдән кайтты. Безнең бригада аның детальләрен Мәскәүнең үзендә ясады һәм аларны җыярга да Мәскәүнең үзендә өйрәнде...

Николай Мартынов чыннан да Одессадан килгән булып чыкты. Ул Днепропетровск шәһәрендә туган. Урта мәктәпне бетергәннән соң, Одесса — Кишинев газ трассасында эшләгән. Анда... культмассовик булган.

— Бер дә көлмәгез,— диде ул, бик җитди итеп.— Массовик эше бик җаваплы эш ул. Трассада эшләгәндә, массовиктан башка эш бармый. Кеше иш белән генә тук яшәми...

Аннары ул илебезнең күп шәһәрләре буйлап сәяхәт иткән. Серпухов шәһәрендә электросварщик һөнәренә өйрәнгән.

— Мәскәүгә командировкага барган идем,— дип дәвам итте ул сүзен.— Ухтага китәргә тиеш идем. Кулыма газета эләкте дә бөтен планнарым җимерелде: Кама буенда автогигант төзелә икән! Тоттым да Казанга килдем...

Бу йорт түбәсеннән төшеп килгәндә, безне күзлек кигән ябык кына бер кеше туктатты.

— Каян килеп чыктыгыз сез монда? — диде ул, бик кырыс итеп.

Мин Таңгга таба ымладым: ул комсомолның шәһәр комитеты инструкторы, мондагы тәртипне ул белергә тиеш, янәсе.

— Әйе,— дип сүзен дәвам итте бу кырыс кеше,— электрод дигән нәрсәне күргәнегез бармы сезнең?

— Күз алдына китерәбез...

— Менә шулай... Электродның бер кисәге шушы йорт биеклегеннән төшеп, цементны тишеп керә. Беләсезме шуны?

— Алай икән...

— Әгәр дә башыгызга,— ул идәндә яткан кирпеч ватыгын аягы белән тибеп җибәрде,— шушындый таш кисәге килеп төшсә!.. Кем кушты сезгә монда йөрергә?..

Без «гаебебезне» танырга мәҗбүр булдык. Түбәнчелек белән гафу үтендек. Ниһаять, бу кырыс кешенең күңеле йомшарды. Таныштык. Ул мастер Юрий Матвеевич Сибяков булып чыкты. Үзе Чувашиядә туып-үскән икән. Элек Саратовта төзелеш эшендә эшләгән.

— Ничек соң анда — өстә? — дип сорап куйды ул.

— Бик шәп!

...Икенче көнне бу форт өстендә, дөрләп торган факелны хәтерләтеп, кызыл флаг җилферди иде...

## Горурлык

**Кешеләре якын, үз булып әверелгән, үзең тормышка аяк баскан җирне ташлап китү җиңел түгел. Минем өчен андый җир — Тимер-Тау шәһәре иде. Анда мин металлургия комбинаты салуга катнаштым.**

**Шулай да илебезнең автомобиль төзелеше гигантын салуга үз кулларым белән катнашу теләге көчлерәк булып чыкты. Менә инде елдан артык мин монда эшлим. Әллә ни зур вакыт түгел. Әмма шул вакыт эчендә шәһәрнең һәм бу якларның язмышы бөтенләй үзгәрде...**

**Безнең бригаданың үз горурлыгы бар. Чаллыда иң беренче уникекатлы йортны без салдык. Аның һәр каты безнең коллективның үсеш этабы булды...**

В. ФИЛИМОНОВ,
«Камгэсэнергострой» төзелеше идарәсенең СУ-31 монтажчылары бригадиры, КПССның XXIV съезды делегаты.

*(«Советская Татария» газетасыннан.)*

## Җәлил эшли торган бригадада

Әле төзелеп тә бетмәгән элемтә үзәге янына иртә таңнан ук халык җыела. Моннан вахта автобуслары кешеләрне эш урынына алып китә.

Мин шул урында урамны аркылы чыгам да түбән очка таба юнәләм. Бирегә биш катлы торак йортлар салына. Кайбер йортларга күченгәннәр дә инде: тәрәзәләренә пәрдәләр эленгән, балконнарында керләр җилферди. Салынып бетмәгән йортлар яныннан кешеләр урабрак үтәргә тырышалар — аларың балконнарыннан, тәрәзәләреннән төзелеш чүп-чары, такта, каткан цемент кисәкләре, кирпеч ватыклары сибелә...

Моны күргәч хәтергә шул төште: Италия шәһәрләрендә, борынгы Рим кешеләренең йоласы буенча, яңа ел алдыннан тәрәзәләрдән иске чүп-чар ташлыйлар икән. Янәсе, «яңа тормыш»ка алар ияреп кермәсен. Монда да ниндидер зур бәйрәмгә әзерләнәләрдер, шуңа күрә бар нәрсәне тәртипкә китерәләрдер, чистарталардыр кебек тоелды. Чыннан да бәйрәм бит: яңа квартирага күчүне кем бәйрәм түгел дип әйтә ала!..

миңа 7/6 номерлы йортны табарга кирәк иде. Дөрес, Филимонов бригадасы салган «небоскреб» түбәсеннән күрдем мин аны. Әмма югарыдан күргән нәрсәне түбәннән эзләп табып кара син!..

Азык-төлек сата торган кибетләр янынннан үтеп, бер бушлык җиргә килеп җиткән идем, юлыма бульдозер аркылы төште. Аны әйләнеп уздым да салынып ята торган бер йортның фасады каршысына килеп чыктым. Нәкъ шушы бит инде 7/6 номерлы йорт! Әнә ишек өстенә: «Бу йортны ВЛКСМ Үзәк Комитеты члены Вазих Мавликов җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр бригадасы сала»,— дигән язу кадакланган.

Бригадирны мин бик тиз таптым. Ябык кына гәүдәле егет икән. Танышу белән бер-беребезне әллә кайчан белгән кешеләр кебек сөйләшеп киттек. Мөгаен, минем ишеләр күп килеп йөридер монда: алдан сөйләшеп куйган кебек, ул үзләренең эш нәтиҗәләрен күрсәтергә, бригада членнары белән таныштырырга керешге.

— Монда Арча бригадасы эшли,— диде Вазих, тантаналы тавыш белән.— Барысы бергә бер районнан килделәр, барысы бергә эшлиләр, бергә торалар.

— Ә бергә-бергә күңеллерәк бит ул,— диделәр егетләр.

Әйе, мондый бригаданың булуы әйбәт, әлбәттә!..

Без бишенче катка күтәрелдек. Стена кырыена килгән идек, кранда утыручы кызның ачулы тавышын ишеттек:

— Вазих! Кранга йөкне кем беркетә?

Мавликов иелеп түбәнгә карады һәм, аны-моны әйтмәстән, баскычтан аска йөгереп төшеп китте. Ә кранчы кыз усал итеп миңа карап куйды.

Шунысы гаҗәп: монда кранчылар барысы да кызлар һәм барысы да ачулылар. Кызык: җир өстендә йөргәндә дә шундыйлар микән алар?

Вазих кран ыргагына бетон багана эләктерде. Кран угына асылган багана, баш өстемдә дуга ясап, аргы почмактагы төзүчеләр янына килеп төште.

Мин, төзү эшләрен карый-карый, юлымда булдым. Ике кыз, түгәрәк куыш калдырып, кирпеч тезәләр иде.

— Бу трубалар нигә кирәк? — дип сорадым.

Кызларның берсе — алтын кысалы күзлек кигәне — тураеп басты да гаҗәпләнеп миңа карады. Янәсе, шуны да белмәгәч, нигә эч пошырып йөрисең монда? Мине бу кыен хәлдән Вазих килеп коткарды.

— Вентиляция каналлары була бу,— диде ул.

— Әлеге күзлекле кыз кем ул? — дип сорадым мин, читкәрәк киткәч.

— Әлфинур Әхмәтова,— дип сөйләп китте Мавликов.— Казаннан килде. Анда беренче трестта, СМУ-3 тә эшләгән. Уку комбинатында өч айлык курсларны бетергәч, ташчы булып, безгә килде.

Әлфинурга карата әйтелгән бу сүзләр бик гадәти булып тоелды миңа. «Аның язмышы алай бик гадәти булмаска тиеш»,— дип уйлап куйдым мин. Матур йөзеннән, кырыс күз карашыннан нык характерга ия булуы күренеп тора аның...

Ташчылар монтажчылар белән ярыша. Рәттән генә эре панельле йорт салынып ята. Әмма Мавликов бригадасы ташчылары алардан калышмыйлар. Гаҗәп, ничек өлгерәләр икән: монтажчыларның бер-бер панельләре бөтен бер стена, ә ташчылар кирпеч тезәләр.

— Мондый өлгерлеккә кайдан өйрәндегез? — дип сорыйм бригадирдан.— Бал кортлары кәрәз ясаган кебек четерекле бит ул кирпечтән йорт салу.

— Биредә, төзелештә өйрәндек,— ди Вазих.— Бу йорт өлгергәч, леккә имтихан булачак. Срогына тәмамласак, димәк, бригада аякка басты, дигән сүз.
— Сезнең эшегез болай да аллага шөкер!
— Башта ничек булганын күрсәгез иде...
Мавликов бригадасына таштан йөз квартиралы биш катлы йорт салуны тапшырганда, тәҗрибәле ташчылар бармак белән генә санарлык була.
Эшкә керешәсе генә калган: нигез әзер, төзү материаллары әзер.
— Хәерле сәгатьтә,— ди Вазих,— башладык, егетләр! Әмма егетләр ашыкмыйлар.
— Төз җөйле итеп ничек тезәргә соң кирпечне? — дип аптырыйлар алар башта.
— Ние бар аның,— дип елмая Мавликов,— кирпеч араларындагы җөй нигездән алып түбәгә кадәр тигез булырга тиеш.
— Йорт салуның ние бар — мүклисе дә чутлыйсы,— ди берсе, төрттереп.— Тезеп күрсәт син, я!..
Вазих, җиңнәрен сызганып, эшкә керешә...
— Кара, кара, барып чыга бит!
— Ничек тигез бара!..
...Шулай итеп, төзелеш барышында өйрәндек,— дип сөйли Вазих.— Җөйләр дә тигез булып югары үрмәләде... Шулай көннәрдән беркөнне бригадага Ганс Нәбиев килде... Әнә ул үзе, почмакларны тигезли...
Дүртенче разрядлы ташчы дип таныштыра үзен Ганс. Шатлана егетләр, уен эшмени — тәҗрибәле оста! Эшләр ходка китәчәк хәзер!
Прораб эшкә куша моны.
— Ну, егет, күрсәт әле разрядыңны!
Нәбиев җиңнәрен сызгана һәм... ике куллап кирпечкә тотына. Прорабның гаҗәпләнүдән кашлары югары сикерә.
— Тукта, егет,— ди ул, фуражкасын баш түбәсенә чөеп.— Дүртенче разряд өчен буыннарың йомшак синең...
— Кирпечләр авыр бит. Силикат кирпеч. Берсе-берсе ярты пот бардыр...
— Әйе,— ди прораб,— силикат кирпеч — яхшы кирпеч. Һәркемгә тиз генә иярәшми ул. Башта өйрән...
— Ә хәзер,— дип дәвам итте Вазих,— Ганс әнә почмаклар коя. Почмакта тору бик җаваплы ул.
— Димәк, өйрәнгән?
— Дүртенче разрядны югалту белән килешәсе килмәде. Бөтен көчен биреп тырышты... Нижний Тагил шәһәрендә берьеллык ташчылар курсын бетереп эшләгән. Әмма соңрак һөнәрен алыштырган — заводта токарь булырга туры килгән. Электәге һөнәрен онытә язган.
— Бездә җан-фәрман белән эшкә кереште. Кыенлыкка бирешмәде. Беркөнне килә бу минем янга. «Почмакка куй әле!» — ди, ә күзләре ут булып яна. Тәвәккәлләдем. Ә хәзер иң яхшы почмак коючы... Әйдә, янына барыйкмы?
Нижний Тагил шәһәрендә аның семьясы, яхшы квартирасы калган. Ике кызы музыкага өйрәнә, пианинолары да бар икән. Үзе дә музыкант һәм әйбәт җырчы булып чыкты ул.
— Яратам музыканы,— диде Нәбиев һәм кинәт сүзен бүтәнгә борды: — Без күптән түгел үз бригадабызга Муса Җәлилне алдык.
— Муса Җәлилне?
— Әйе, Муса Җәлилне,— дип раслады аның сүзен Мавликов.— Герой-шагыйрьне бригадабызга член итеп алдык. Ул болай булды. Ничектер, бервакыт бригадабызга комсомолның өлкә комитеты

секретаре килде. Эшебезне мактады. Аннары әйтеп куймасынмы: «Күңелсез яшисез, дуслар. Хыяллана белмисез...» — диде.

Бу сүзләрдән без уйга калдык. Будкага җыелдык та тормыш хәлләребез турында киңәшкә керештек. Чыннан да, күңелсез яшибез: төзелеш мәйданы да тулай торак. Башканы белмибез. Ә җаны булган адәмгә ул гына җитәме соң?!

Хәбир Нәбиуллин — безнең комсорг — сүз сорады. «Шәп эшлибезме? — дип сорады егетләрдән. «Шәп»,— дип җавап бирделәр. «Әмма,— дип дәвам итте комсорг.— «Хыяллана белмисез дип кисәтteләр бит безне». «Беләбез. Аерым квартирада торырга хыяллана-быз». «Әнә, Алексеев өйләнергә хыяллана». «Ә Коляның бөтен хыялы — җәен каптыру!»

Мин сүз алдым. «Сүз ул турыда бармый,— дим.— Хыял диңгез кебек киң, баш өстендәге күк йөзедәй биек булырга тиеш. Түшәмгә төртелеп калырлык булмасын ул».

«Көй чыгарырга яисә шигырь язарга кушасыңмы? — ди Ганс.— Анысын да булдырабыз».

«Дөрес! — дип элеп алды комсорг.— Шигырь яки музыка!.. Менә мин Пахмутованы бригадабызга член итеп алырга тәкъдим кертәм».

«Ә ул үзе кайда?»

«Мәскәүдә».

«Ә аның өчен кем эшләр?»

«Бригадабыз белән эшләрбез. Аны үзебезнең кичәләребезгә чакырырбыз».

«Җырларгамы?»

«Безнең турыда музыка язар. Ә җырлавын үзебез җырларбыз. Килештекме?»

Ташчылар уйга калды...

«Ә бәлки, бригадабызга Муса Җәлилне язарбыз»,— дип тәкъдим ясады Равил Вәлиев. Барысы да аңа текәлде. Равил университет бетергән. Төзелешкә путевка белән түгел, үзе әйтмешли, «күңел кушуы» буенча килгән икән. Гади ташчы булып.

«Муса — үзе герой, үзе шагыйрь,— дип сүзен дәвам итте Равил.— Аның фамилиясен табельгә язый, һәм ул һәркөн безнең арада яшәр, эшләр».

«Чыннан да,— дип кушылды аңа комсорг.— Әйбәт тәкъдим бит бу!»

«Мусаны алыйк!» — дип бердәм кычкырыштылар яшьләр.

«Ә нәрсә,— дип каршы төште берсе.— Үз кесәбездән бишәр сум, димәк?.. Шул булдымы хыял?..»

«Тынлык! — дип кычкырды Нәбиуллин.— Хәзер аңлатам... Акча үз файдабызга тотылачак. Кичәләр, экскурсияләр оештырабыз, баян сатып алабыз, иң яхшы ташчы исемен алу өчен конкурс игълан итәбез... Я, килештекме?..»

«Яңа квартирага күчү көннәрен бәйрәм итәрбез,— дип дәвам иттеләр аның сүзен егетләр.— Туган көннәрне билгеләп үтәрбез. Культбудканы җиһазландырырга кирәк. Анда Муса Җәлил портретын эләрбез».

Бригада төзүчеләре шулай итеп: «Муса Җәлилне бригадага член итеп алырга һәм махсус Муса Җәлил сменасы булдырырга» дип карар чыгардылар...

Шул көннән башлап Муса Җәлил — Вазих Мавликов җитәкчелегендәге бригаданың даими члены. Җәлил аларның бәйрәмнәренә катнаша, аларның шатлыкларын уртаклаша, эшләрендә яңа уңышларга рухландыра, аларны яңа, матур, кызыклы тормышка чакыра...

Мин шулар турында уйлый-уйлый кайтыр юлга чыктым. Әлеге үзәге янына җиткәч, артыма борылып карыйм. Силикат кирпечтән салынган, панельдән җыелган якты йортлар!.. Әнә Мавликов бригадасы салып ята торган йорт. Ап-ак силикат кирпечләр арасындагы җөйләр тип-тигез булып ерактан ук беленеп тора! Матур төзиләр. Йортларның күренеше бәйрәмчә. Урамнар киң. Ләкин аларның әлегә исемнәре юк. Йортлар үзләре дә төзелеш номерлары белән генә йөртелә.

Мин хәзердән үк, үземчә, урамнарга биреләчәк исемнәрне күз алдыма китерергә тырышам. Ни өчендер гел мең шәһәрдә мең тапкыр кабатланган урам исемнәре генә хәтергә килә. Шәһәр башкармасы каршында, ай-һай, авыр эш тора!..

Бу эшне төзүчеләрнең үзләренә кушарга кирәктер, минемчә. Үзләренең туып-үскән авыл яки шәһәр исемнәрен кушсыннар, балачакларында су коенган елга-чишмәләрнең исемен бирсеннәр, сөйгән кызларының исемнәре белән атасыннар!

Моңа аларның хаклары бар!..

## Хезмәткә катнашу коэффициенты

Төзүчеләр янында көн бик тиз үтте. Ә кичке сәгатьләрнең очкырые юк кебек. Җитмәсә тагын, Мавликовтан ишетеп калган: «Хезмәткә катнашу коэффициенты»,— дигән сүзләрнең мәгънәсенә һич төшенә алмыйм. Үзеннән сорарга кыенсынган идем. Күршеләр дә кайтып җитми, ичмасам...

Аптырагач, иске газеталарны актарырга керештем. Күбесе инде укылган. Иң аста «Коммунизм байрагы» — район газетасы — ята икән. Аның битләренә күз салдым. «Эксперимент дәвам итә...»

Кызык, нинди эксперимент икән ул?..

Түбәндәге сүзләрне укыйм: «Коллектив әгъзаларына хезмәт хакын бүлгәндә, хезмәткә катнашу коэффициенты кертелде...»

Хәбәрче бетончылар турында язган. Бригадада егерме ике кеше булып, алар август аенда ике йортка нигез койганнар. Тариф буенча билгеләнгән хезмәт хакын эшләнгән эшкә һәм разрядларга карап бүлгәннәр. Ә премия һәм артык эшләнгән эш өчен тигән акча һәркемнең гомуми хезмәткә кергән өлеше коэффициенты буенча бүленгән...

«Хезмәткә катнашу коэффициенты ничек билгеләнә икән?..» Укуымны дәвам итәм, формула кебек коры һәм төгәл сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә тырышам. Әһә, менә ничек! Моны бригада советы һәркемнең намуслы эш дәрәҗәсенә карап билгели икән.

Бригадада барысы да яхшы эшләгәннәр. Бары тик Семков дигәне генә эштә булырга тиеш кайбер көннәрендә «күңел ачкан». Аңа хезмәт хакы тариф буенча түләнүен түләнгән. Ә премия бөтенләй тәтемәгән, чөнки бригада советы аның хезмәткә катнашу коэффициентын «ноль» дип билгеләгән. Ә Шакирҗанов хезмәткә катнашу коэффициенты буенча гына да, тариф белән түләнгән хезмәт хакыннан тыш, 126 сум 52 тиен өстәмә акча алган.

Менә нәрсә икән ул хезмәткә катнашу коэффициенты!..

Филимоновта да, Мавликов бригадасында да эшләр бердәм бара. Әлеге коэффициент турында да мин иң беренче башлап Вазихтан

ишеткән идем бит. Алар янына тагын барырга, әлеге «эксперимент»ны ничек гамәлгә ашыралар икән — белергә кирәк...

Иртәгесен 7/6 номерлы йортка тагын киттем. Мавликов юк иде, Равил Вәлиевне очраттым. Равил — үзе дә башлап язучы икән — минем сорауларыма каршы язганнан укыган кебек итеп сөйләп китә. Мин елмаям, күренеп тора: Равил миңа үз композициясен, үзе уйлаган сюжетны тәкъдим итәргә җыена. Сорауга турыдан-туры җавап бирми, түбән коэффициент алган кеше турында сөйләргә керешә.

Бу кеше, минем гаҗәпләнүемә каршы, Ганс Нәбиев булып чыкты. Мөгаен, Гансны Равил хөрмәт итә торгандыр — ул аның эшен, тормышын игътибар белән даими күзәтеп бара икән.

Бригада советы «үзбаш» йорт салучылар исемлеген төзегән. Алар беренче чиратта квартира алырга тиешләр. Бу исемлектә Ганс Нәбиев тә булган. Алар, сменадан соң калып, 200 сәгать эшләргә тиешләр икән.

Әмма мәхәббәт Ганс Нәбиевкә аяк чала. Юк, Гансның үз мәхәббәте түгел. Аның үз семьясы бар, ул хатынынннан башка берәүгә дә гыйшык тотмый. Хикмәт шунда, элек фамилиясе исемлектә булмаган Алексеев табельщица кызга гашыйк була һәм өйләнеп тә җибәрә. Ә бригада советы, аларның хәленә кереп, исемлеккә Алексеевлар фамилиясен өсти. Шулай итеп, Нәбиев чираты ераклаша.

Бу карар турында ишеткәч, Нәбиев бригадир янына килә дә таләп итә: я аны исемлектә электәге чиратта калдырсын, я ул эштән китә, янәсе. Бернинди үгет-нәсихәткә колак салмый — «я тегеләй, я болай». Җитмәсә тагын, батырлык өчен дип, «кәгеп» килгән.

Иртәгесен акылга утырып, гафу үтенергә дип килсә — терсәк кыска — «0,9» коэффициенты куелган.

— Безнең бригадада,— ди Равил,— түбәгә кем беренче булып җитә, шуңа — көненә унөч сумнан премия. Стимул! Берәрсе эчсә яисә эшкә килмәсә, премиядән колак кага... Менә хезмәткә катнашу коэффициенты шул инде. Кем гомуми хезмәткә тырышып, күңел биреп катнаша, һәр минутның кадерен белә — аның коэффициенты зур... Комсомол оешмасы көчле безнең. Комсорг Хәбир Нәбиуллин белән танышкансыздыр инде. Ул егет — Казаннан. «Теплоконтроль» заводында фрезеровщик булып эшләгән. Бала чакта поездлар йөртергә, машинист булырга хыялланган. Юдинодагы тимер юл училищесына кергән. Әмма аннан машинист булып түгел, тепловозлар ремонтлаучы слесарь гына булып чыккан. Шулай да тора-бара үзенекен иткән — машинист ярдәмчесе булуга ирешкән. Комсомол төзелеше турында ишеткәч, беренчеләрдән булып, монда килгән һәм яңа һөнәргә — төзүче һөнәренә өйрәнгән.

Безнең комсомолецлар әлеге «эксперимент»ны беренчеләрдән булып башлап җибәрделәр. Һәм ул үзен аклады да...

Әйе, мондагы яшьләр хыялланырга да, хыялларын тормышка ашырырга да өйрәнгәннәр. Хәзер инде бу мәсьәләдә аларны гаепләп булмый...

Рахмай Хисмәтуллин

# ТИРӘННӘН ЧЫККАН ШЫТЫМНАР

ОЧЕРК

*«Бер вакыйга минем хәтергә бик нык уелып калган: авыл хезмәт ияләренең иң өлкәннәреннән берсе, Чаллы районының «Гигант» колхозы председателе З. Закиров, Татарстан партия активының быел яз булган җыелышында чыгыш ясап, болай диде:*

*— Колхозчылар, партия активы җыелышына озатканда, миңа шундый теләк белдерделәр: «Зыя абый, әгәр җыелышта чыгыш ясарга туры килсә, партиягә һәм хөкүмәткә, халык турында гаять зур кайгыртулары өчен, бездән, игенчеләрдән, иксез-чиксез крестьян рәхмәте тапшыр».*

*Дөресен әйтим, бездә ихтирам йөзеннән «Зыя абый» исеме белән атап йөртелгән бу хөрмәтле кешенең чыгышын зур дулкынлану белән тыңладым».*

*(КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеевның «Октябрь» журналында (1970 ел, 9 нчы сан) басылган мәкаләсеннән.)*



Зыя абый көн саен таң белән кырларын бер урап кайтмаса, йөрәгенә тынгылык таба алмый башлады. Әле күптән түгел генә ул җитәкләгән колхоз җирләре хәзер инде зур төзелешләр астында кала. Йөрәккә бик якын әнә шул мәйданнарны ураганда күңелне сагыш, төрле уйлар били.

Биләмәслекмени?! Аның туган җиренә бик зур төзелеш килде. Әллә кайларда яшәүче әллә кемнәрнең йөрәкләрен тынгысызлап, гомерләр агышын үзгәртергә мәҗбүр иткән, яшәешне яңартып, ямьләндереп җибәргән яңа төзелеш килде. Яңа борчылулар, кайгырулар, мең төрле мәшәкатьләр, язмыш шуклыклары, ачы аерылулар, көтелмәгән кавышулар булып кыен төзелеш килде. Котылгысыз рәвештә иске карашлар белән бәрелештерәчәк каршылыклы дөнья килде.

Бу үзгәреш әле күнегелгән җирләреннән купкан кешеләрне, мең төрле халык арасына китереп, бер сокланырга, бер моңланырга мәҗбүр итәр.

туфракларын, авыл урамнарын, чирәмнәрен, йорт урыннарын да Кама автозаводы мәйданына биргән кешеләрнең, җирнең бөек хуҗаларының хәле ничек? Яңа җиргә чигенгәч тә, игенче антына тугъры калып, автозавод кешеләре өчен аш-су, икмәк-ит хәстәрләүчеләрнең хәле ничек? Нинди генә кыенлыклар булмасын, аларның бит бу җирне ташлап китәселәре юк...

Ә бирегә илнең илле ягыннан килгәннәре бу җирнең үз тарихы, үз игенчеләре булгандыр, аларның да үз моңы, үз традицияләре бардыр, дип, бу төзелешнең бəрен-че нигез ташларын алар, җирле халык, игенчеләр салган дип башларына китәрер-ләрме икән?!

Гомергә уйламаган әнә шундый уйлар башка килә. Ни әйтсәң дә, җаның-тәнең бе-лән яратып, егерме ел дәвамында аркылыга-буйга мең мәртәбә үлчәгән шушы кыр-ларда хәзер тирән-тирән чокырлар, аркылы-торкылы бетон юллар күргәч, күңел дә уйнап куя икән. Төрле хискә бата икән, гаҗәп икән бу...

Тик барысыннан да бер олы хис, бер горурлык хисе өстенлек итә. Бу хисен партиянең өлкә активы җыелышында да әйтми булдыра алмады ул:

— Ачыктан-ачык әйтим,— диде председатель,— исеме инде бөтен илгә таралып өлгергән «Батыр» белән күршедәш булу безнең өчен зур бәхет. Гүзәл Кама ярында автозавод төзү турындагы карар — безнең район өчен генә түгел, ә бөтен республика өчен дә горурлык.

Шушы җирдәге колхозны үрнәк хуҗалык итим дип йөрәк азмы сызды! Һәр карышы көрәш тулы. Ә менә бу арырак кыр... Бу урын аңа бигрәк тә газиз. Үзе бер гомер. Зыя абый истәлекле мәйданга атлады...

* * *

...Язгы чәчү вакыты иде. Производство идарәсе начальнигы аның сүзләрен тың-ларга да теләмәде.

— Юк, булмый, Зыя Закирович,— диде.— Сөйләмәгез дә. Хәзер үк төреннәрне күтәрегез. Сыналмаган ысул белән чәчтереп, игенне харап итеп булмый. Сезнең җир-ләр районыбызның дүрт-биш колхозына торырлык, барыбызның да төп башына уты-руыбыз бар.

Ул начальникның карарын йомшартырга тырышып карады:

— Коры килгән елларны халыкта элек-электән тирән күмдерүне хупларганнар бит... Әллә соң...

Әмма тегә кырт кисте:

— Юк, булмый. Катгый рәвештә тыям. Бу югалтуны без үз башларыбызны түләп тә кайтарып ала алмаячакбыз. Сүз куертмыйк! Сезнең кебек тәҗрибәле кешенең шундый юлга басуы һич башыма сыймый.

Начальник, үз сүзен үткәреп, ашыгып китеп барды.

Күп еллар эшләү дәверендә мондый әрләүләрне шактый ишетсә дә, бүген бер төркем механизаторлар, нәкъ менә шушы мәсьәлә буенча аның белән бәхәскә кергән кайберәүләр каршында җиңелеп калуы бик авыр булды. Нишлисең, инстанция... Чи-генде. Ә чигенмәскә кирәк иде. Бигрәк тә бүген, киләчәкнең язмышы — язгы чәчү хәл ителгәндә чигенмәскә кирәк иде.

Быел язның коры киләчәген алдан ук хәбәр иткәннәр иде. Район үзәгендә дә чә-чүгә нинди күрсәтмә бирергә белмичә аптырап калдылар. Ахыр чиктә, гадәттәгедән читкә чыкмаска куштылар: Элек ничек чәчелгән, шулай чәчелсен. Ә менә бу колхозда, «Гигант»та, бу инструкцияне тотмыйча, үзләренчә эшләргә булдылар. Председатель бе-лән килешә алмыйча йөргән кемдер (ә андыйлар һәрчак табыла!) бу хәлне: «Чәчүдә харап булабыз, тизрәк килеп җитегез», дип хәбәр итеп тә өлгергән. Идарә началь-нигының колхозга шул сигналдан соң килеп чыгышы иде.

...Начальник барда төреннәрне күтәртә төшәргә кушса да, Зыя абыйның күңе-лендә яшерен давыллар уйнады. Калын китаплардан башка халыкның меңәр еллар буе тупланып килгән алтын тәҗрибәсе дә бар түгелме соң? Нигә аңа шул тәҗрибәгә колак салырга рөхсәт итмиләр? Ни өчен яшь начальник аның бу инициативасын гаеп-

ләп киттеГ Кем хаклы соң? Нигә ул үзенең тәҗрибәсе, акылы кушканны тормышка ашыра алмый?

...Зыя абыйны идарәдә йомыш белән килгән картлар-карчыклар көтеп утыралар иде. Кайсына утын, кайсына бакча сөрдерергә ат, кайсына машина-фәлән кирәк икән. Ул көтеп утыручыларның барысын да өйләргә җаен тапты. Тик шәһәргә китәргә справка сорап килгән бер яшь егетнең генә үтенечен кире какты.

— Энекәш, мин сиңа укуыңны ташлап китәргә справка бирә алмыйм. Аннары, шәһәр үзе безнең якларга килә дип тора бит, ашыкмый тор...— диде ул.

Тыңлап, аңлатып, киңәш биреп, бүген шактый арыды Зыя ага. Ул өенә кайтып кергәч, хатынына:

— Уф, талчыктым, Мәрьям. Читенгә туры килде,— диде.— Районнан килгәннәр дә әрләп киттеләр. Йомыш белән килүчеләр дә күп иде. Картайтып бетерә, ахры, мине бу эш.

— И Зыя, сөйләмә инде, берәзлексез ничек йөтып барасың кеше сүзен. Авырыпнитеп, безне вакытсыз ташлап китә күрмә инде тагын. Күрәсең, үзем дә сыкрап торам. Кызларыбызны аякка бастырып бетерәк инде. Әле син кайтыр алдыннан гына Ленизабыз Казаннан шалтыратты. Быел да экзаменнарымны бишкә генә бирдем, ди, и тынгысыз да булды инде, сиңа әйтәм.

Кызлары турындагы хәбәр Зыя ага күңелен эретеп, рәхәтләндереп җибәрде, арулар онытылгандай булды. Ул аш янында гел шуларны гына искә төшереп утырды.

Шөкер, кызлары уңган, Әнүзәсе медсестра булып әйбәт кенә эшли, Энҗесе медицина институтында, Җәннәте белән Ленизасы педагогия институтында укый, Зенира тугызынчыда гына укый әле. Ленизасы ике институтны берьюлы тәмамлау турында хыяллана, әллә нинди түгәрәкләргә йөри. Көне-төне уку, зыянга булмаса ярый.

Бер баруда әтисе аңа:

— Нигә болай үзеңне бетерәсең,— дигәч, кызы:

— Соң, әти, син үзеңне кара, әни дә сиңа шулай ди бит. Без синнән үрнәк алабыз. Теләгәнеңнең ахырына җитмичә туктама, дип өйрәттең бит,— диде, елмаеп.

Кызык... Ул өстәл яныннан торып, киенә башлады.

Кырга, чәчүчеләр янына!

Ә Мәрьям апа:

— Бу ни хәлең, Зыя, чәй дә эчеп бетерми кузгалдың. Аштан соң бераз ял итеп ала идең бит,— дип сөйләнеп калды.

...Бүген Зыя ага җир сулышын йөрәкләре белән тойган крестьяннар ышанычыннан чигенгән.

...Фашистларга каршы сугышта утлар-сулар кичте Зыя солдат. Көнбатыштагы биш илне илбасарлар тырнагыннан азат итүдә катнашты, үз иленә кайткач, озак та тормый, егерме җиде яшьлек егетне туган колхозында председатель итеп сайладылар. Хәлсез, корылыклы ел иде бу. Өлкәнрәк кеше кирәк иде, бу тарта алырмы икән соң? — дип шикләнүчеләр дә булды. Шикләнергә урыны да бар иде. Унбиш елга кырык ике председатель алышынган.

Зыя бу шикләнүләрне йөрәге белән тойды. Еш кына ачыктан-ачык та каршы чыккаладылар. Тик сугыш кырында, дошман уты астында партия сафына кергән коммунист бу фронтта чигенүне башына да китермәде.

Еш кына ул, тирән уйларга бирелеп, авыл урамнары буйлап атлады... Ә авыл хәрабә... бомбага тоткан сыман. Элек балкып торган өйләр кыйшаеп, җимерелеп беткән, гөрләп утырган кайбер йортлар урынында бүген инде шайтан таяклары гына үсә... Сугыш халыкның җилеген суырган. Кибетләрдә тоз һәм шырпыдан башка бернәрсә дә юк. Ачлыктан йөзләре саргайган хатын-кызлар фермада бау белән сыерларны күтәртәләр, бәләкәй чана тартып, язгы баткак карларны ера-ера, симәнә ташырга ерак юлга чыгалар. Чирәм калыккач, юа, кузгалак, кычыткан ашы белән тернәкләнәләр.

Әнә шундый кешеләрне эшкә өештырырга кирәк.

Теләсә кем теләсә нәрсәне җимерә, тарката, вата.

...Әнә, әллә кайдан, ерактан зәгыйфь тальян тавышы ишетелеп китте. Бу аваз атлаган саен көчлерәк, дәртлерәк тоелды. Менә ул кул чәбәкләүләр, тыпырдап аяк басулар белән бергә кушылды.

... Зыя түзә алмады, шунда юнәлде. Ватык тальян көенә яшьләр уйнап-җырлап биилләр. Алар ап-ак итеп юылган гади ситса күлмәкләрен җәлләмичә тузанлы клубны дер селкетеп биилләр.

Ватык тальян булса да, моң бар, җыр бар. Үлән белән тукланган һәм чабата кигән булсалар да, кешеләр бар... Димәк, тормыш бар...

Авылдашларына бөтен планнарын ачып салып, киләчәк турында матур итеп сөйлисе иде. Ләкин тел әйтеп бирә алмаслык бу дәһшәтле елларда кешеләр матур сүзләргә түгел, ә практик эшкә ныграк ышаналар шул.

...Беркөнне Зыя, зират яныннан үтеп барганда, җимерелеп беткән коймаларга игътибар итте. Өмә оештырырга кирәк. Үлгәннәрне хөрмәт итмәү ярап бетмәс.

Өмә оештырылды. Койма тотылды. Авыл халкына бу — сусаган гөлгә җылы яңгырдай булды. Бик күпләр аңа:

— Яхшы кеше икәнсең, зур рәхмәт сиңа, улым,— диделәр.

Халыкның аңа карата күңеле йомшара, карашлары үзгәрә төште.

һәм алгы көрәш юлында кеше турында кайгырту — аның уңышларының сере булды.

...Тормыш акрынлап үргә үрмәләде. Районда, Закировның эшләре алга баруын күреп, күрше-тирәдәге кечерәк хуҗалыкларны аның колхозына куша бардылар. «Кояшны тәгәрәтердәй» дәртле ир җилкәсенә ун төрле йөк, ун авыл язмышы салынды. Уналты мең гектар җир биләгән бу зур хуҗалыкка «Гигант» дип исем куштылар.

...И ул берләшү вакытлары. Дәүләткә бик зур бурычлары булган Олы Шильнә, Илбакты авылларын әҗмәкәйләләр башта һич кенә дә үзләренә берләштерергә теләмәделәр. Җыелышта төнге сәгать өчкә кадәр тартыштылар. Ә Зыя ага, бу юлы да халык көченә ышанып, берләшү фикерен яклады. Әмма хәзергә әле бу берләшү әҗмәкәйләләргә күңелсезлек кенә китерде. Хезмәт көненә түләү шактый кимеде. Шуңа да карамастан, халык Закировны чит итмәде. Райком аны артта калган колхозны күтәрергә дип берничә мәртәбә икенче урынга күчерергә теләсә дә, колхозчылар җибәрмәделәр.

Шильнә ягын аякка бастырырга кирәк иде. Беренче тапкыр партком һәм идарә членнары белән анда барып төшкәндә, каралтыларда бер грамм да азык калмаган, терлекләр ач иде. Авыл янындагы салам да урланып беткән. Язгы юлларда кар эреп сыекланган, машина тәгәрмәчләре бата. Хәлне тиз генә төзәтү мөмкин түгел. Шильнәләр үзләре, берничә дә исләре китмичә (я, ходаа, бозылса да бозыла икән халык), ниндидер бәйрәм үткәреп яталар.

Күчмә идарә ашыгыч рәвештә бөтен халыкны җыйдырттьı. Җаваплы посттагыларның бер-икесен шунда ук әйныткычка да озаттылар.

Тиз арада берничә трактор колхоз үзәгенә җибәрелде. Ләкин алар юлда батып беттеләр. Әҗмәкәй егетләрен аякка бастыргач кына терлекләргә азык китерелде.

...Эшчән әҗмәкәйләләр белән бер колхозда инне-ингә куеп эшләү шильнәләләргә уңай тәэсир итте. Нићаять, аларда да иген уңышы күтәрелде. Соңыннан алар үзләре дә, Закировның таләпчән кулы безне аякка бастырды, югыйсә, харап була идек, диештеләр.

Колхозның җегәре арта торды. Санап бетергесез төзелеш эшләре башкарылды. Ун авылда 150 гә якын төрле биналар, балалар бакчалары, кибетләр, терлекчә йортлары, мәктәпләр, клублар үсеп чыкты. Шул ук Шильнәдә 260 урынлы өр-яңа клуб ачылу гаҗәеп бер тантанага әверелде. Җыелышта дулкынланып трибунага менгән яшьләр дә, картлар да председательгә чиксез рәхмәтләрен әйттеләр.

Өнә шулай бу авылларда культура да җир иданнән нурлы сарайларга күтәрелде.

* * *

...Шулай, рөхсәтсез булса да, Зыя ага үзенекен итте. Бодайны тирәнгә чәчтерде. Чәчтерде чәчтерүен... Әмма икенче көнне үк кайбер идарә членнары, ничектер, аны гаепләгәндәй читләшә башладылар.

Ә чыннан да, орлыклар тишелеп чыга алмаса? Ничек кеше күзенә күренерсең? Өлегә өмет шактый гына иде. Тик менә чәчүдән соң җиденче-сигезенче көннәрне төньяктан салкын сөбер җилләре бәреп керде. Һавалар кинәт алмашынды.

шытымнар өскә чыгып җитәрәк башларын иебрәк калганнар. Көчләре җитмәгән, ахры. Әллә салкыннан, әллә тирәнлектән... Калган энергияләре, бәлки, әле өскә бәреп чыгарга җитәр?.. Ә бәлки, җитмәс тә...

...Идарәдә партком членнарыннан берсе, Зыя ага белән бергә-бер калгач, шактый каты әйтте:

— Әнә, күршеләр белән бергә чәчкән идек, аларның тишелеп чыккан инде, ә без харап иттек игенне, бетердек,— диде.

Зыя ага башын иеп утыргач, чигенде дип уйладымы, ул тагын да батыраяя төште.

— Синең үзсүзлелек аркасында бу, иптәш Закиров. Моның өчен безнең баштан сыйпамаслар.

Аның тавышында ачу, үч алу, мыскыллы көлү тулы иде.

Тик Зыя ага каршында тавыш күтәргән бу иптәш үзе күп сөйләнеп аз эшләргә ярата торган кеше иде: нигә тегеләй түгел дә, нигә болай түгел, янәсе.

— Ярар, чәчүне харап иттем ди инде мин, алайса. Әйдә, парткомга куйыйк,— диде Зыя ага.

Партком утырышы башта авылдагы тәрбия эшен карады. Чәчү мәсьәләсе дә куелды. Ләкин партком членнарының күбесе, әле бит ни буласы билгеле түгел, монда берәүне дә гаепләп булмый, көтәргә кирәк, диделәр...

...Утырыштан соң Зыя ага яшь партком секретаре Биков белән фермаларны, авылларны карарга чыгып киттеләр.

Биков, секретарь булып килгәнче, Закиров белән Чаллыда очрашканда, бервакытта да аның маңгай җыерчыкларына игътибар итми иде бугай. Ә менә монда килеп, атна-ун көн яшәү белән, ул аларны күрде генә түгел, нидән икәнлеген дә аңлый башлады.

Эчтән яна, эчтән сыза Зыя абый. Үзенең эшен дәвам итәрдәй кадрлар турында кайгырта-кайгырта, беркемгә дә сиздермәскә тырышып, эчтән дөрли. Әнә колхоз үз акчасына Г. Зарипов, Г. Хәйруллин, М. Муллахмәтов кебек күп кенә белгечләр укытып чыгарган. Алар колхозны күтәрүдә җиң сызганып булышалар.

* * *

Икенче көн таңында бодай кырында күгелҗем ятьмә күренде. Күпләр шунда ашыкты. Бу ни бу? Бу бит бодай шытымнары шулай күгелҗем! Тишелгән, бәреп чыккан! Карагыз сез! Күрегез, орлыклар тирәннән шытып чыккан! Күңелне рәхәт, җылы шатлык дулкыннары биләп алды. Зыя абый, куанычыннан малайланып, кепкасын күккә чөйде.

Әй, бу шатлыкларның кабатлануы... Алар кеше күңелен нечкәртә, онытыла язган хатирәләрне яңарта икән...

...Моннан күп еллар элек Украина фронтында бер-берсен үлемнән коткарышкан капитан Воробейко белән, озак аерылышулардан соң, шушындый ук уҗым кырында очрашкач, шатлыклардан пилоткаларын күккә чөйгәннәр иде! Уңышлы атакадан соң иде бу.

Орлыклар шытуы... Дуслар очрашуы...

Эх, менә язгы чәчүдән соң ул дусны озакламый шаулап-гөрләп үтәчәк сабан туена чакырасы иде.

...Капитан Воробейко ни өчендер сержант Зыяны бик якын итә, аның белән кайгы-шатлыкларын уртаклаша иде. Иң җаваплы заданиеләрне Зыяга тапшыра. Ул кушса, Зыя иң авыр, куркыныч заданиеләргә дә бик рәхәтләнеп, шатланып бара һәм уңышлы үти иде. Аларның берсе украин, икенчесе татар булуы дуслыкларына аеруча мәгънә өсти иде.

Капитан аерылышканда: «Без мәңге дуслар булырбыз, мин сине мәңге онытмам»,— диган иде.

Еллар үтә торды. Алар бер-берләрен кунакка чакырышып ара да таба алмадылар.

Зыя ага тыныч хезмәттә дә җиңүче булып чыкты. Аның хезмәтен ил күрде. Ул ике мәртәбә ТАССР Верховный Советы депутаты булып сайланды. Ленин ордены белән

лаек булды...

Ә аның иске дусты капитан Воробейко кайда икән хәзер? Исәнме ул? Семьясы белән сабан туена чакырсаң, килә алырмы икән?

Ул килсә, ике милләт вәкилләре кочаклашып күрешерләр, фашизм өстеннән җиңү кукрәүләре тагын бер тантана итәр иде. Шушы якты тормыш өчен һәлак булган меңләгән көрәштәшләре хөрмәтенә бокаллар күтәрерләр иде алар.

...Хисләр ташыды. Сабый уҗымнарны сыйпап язгы җил исте. Бу минутларда Зыя абый белән килгән һәркем күңеленә хәтфә кырлардан нурлы шатлык агылды.

...Орлыклар шытып кына калмады. Күзен күршеләрнекенә караганда ике тапкыр артыграк уңыш алынды. Көтелмәгән хәл иде бу.

Икенче елны инде производство начальнигы үзе үк бу ысулны яклап чыкты, аны бөтен районга керттерде.

Ике-өч елдан соң тирән күмдереп чәчтерү — буразнада туган яңалык — бөтен республикага таралды.

* * *

Автозавод юлларыннан үкереп килгән машиналар тавышы, Зыя абыйны уйларыннан айнытып, бүгенгегә кайтардылар. Кулына алган туфрагын тагын угалап-угалап куйды. И җылы туган туфраккай! Ул инде кулны җылыта, иркәли... Димәк, язгы яшәү куәте белән уянган кырлар орлык сорый... Әмма инде бу җирләргә орлык төшмәс... Ә-ә, юк, дөрес түгел, авыр елларда Зыя абыйлар бу җирләргә чәчкән орлыклар бүген инде яңа төр куәт булып, автозавод төзелешләре булып калкалар.

Зыя Закировның тормышы тагын да киңрәк юл аша, җитмешенче еллар дөньясының кайнар көрәш мәйданы аша үтә. Удар төзелешкә күбрәк азык-төлек җитештерү! Бу көрәш тагын да яңачарак яшәү алып килә. «Гигант» колхозы хәзер өч совхозга бүленеп, авыллары озакламый ике урман арасындагы таулы калкулыкта шәһәрчә итеп өр-яңадан салынган яңа урынга — Такташ поселогына күчәчәк. Үзәк совхозның директоры (тагын үзәктә!) — Зыя Закиров.

Озакламас, халкыбызның эш сөючәнлек, түземлелек, хезмәт кешесенә олы мәхәббәт, башка милләт вәкилләренә зур ихтирам кебек гүзәл сыйфатларыннан бетмәстөкәнмәс кодрәт алып, автозавод күтәрелер. Бу күтәрелештә Зыя абыйның әнә шул, халкына хас күңел байлыклары, тирәнгә күмдерелгән орлыклар кебек, тормыш катламнары, каршылыклары аша тишелеп чыгар да, меңләгән күңелләрдә чәчәк атар, үлемсез рухи матурлык булып, халыкның үзенә кире кайтыр.

«...Хәерлегә, бәхеткә булсын бу яңаруың»,— дип, Зыя абый, учындагы туфрагын зурлап әкрен генә җир өстенә куйды. Күтәрелеп, тирән сулыш алды, тынычланып тирә-якны күзәтте. Кырларда төзелеш моторлары гөрелди... Калкулыклар, урманнар артыннан матур таңнар, гаҗәеп иртәләр алып килүче өр-яңа кояш, әлмәеп, күтәрелеп килә,

**Леонид Елькович,**
сәнгать фәннәре кандидаты

# ГРАФИК ПУБЛИЦИСТИКАНЫҢ СУГЫШЧАН ЖАНРЫ

«Крокодил» яки «Чаян» журналының яңа санын кулга алуга, сез аның сатирик рәсемнәре белән таныша башлыйсыз. Бу — ничектер үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Укырга кызыклы нинди материаллар бар икән, дип актарганда ук иң әүвәл күзгә рәсемнәр ташлана. Карикатура шундый инде ул, тиз тәэсир итүчән сәнгать төре. Ләкин сәнгатьчә шәп эшләнгән, партияле булса гына ул зур әһәмияткә ия. Шул вакытта гына карикатура көчле коралга, алгы сафтагы сәнгатькә әверелә.


Халыкара темаларга ясалган рәсемнәр, ягъни политик карикатура, график публицистиканың аерата мөһим, актуаль һәм сугышчан бер тармагы санала. Совет властенең беренче елларыннан ук ул революциягә хезмәт итә башлый. Һәм аннан бирле узган ярты гасыр вакыт эчендә совет карикатурасы искиткеч зур уңышларга ирешә, халыкара авторитет яулый. 1969 ел ахырында, «Сатира тынычлык өчен көрәштә» диган темага багышлап, СССР Сәнгать академиясе уздырган халыкара күргәзмә әнә шул хакта сөйли.

Күргәзмәгә җир шарының барлык континентларында яшәүче ике йөзләп карикатурачының биш йөздән артык рәсеме куелган иде. Америка художнигы Антон Рефрежьеның да, көрәшүче Вьетнам художникларының да сугыш утын кабызучыларга каршы тирән нәфрәт белән сугарылган ялкынлы рәсемнәре бар иде анда. Шунда ук Жан Эффель, Херлуф Бидструп, Эрик Липинский, Андраш Массарош рәсемнәре... Күршә стендларда совет графика осталары Кукрыникслар, Борис Пророков, Борис Ефимов, Виталий Горяев, Леонид Сойфертис, Юлий Ганфалар иҗат иткән әсәрләр...

Күргәзмә җәмәгатьчелек тарафыннан бик җылы каршы алынды һәм аңа югары бәя бирелде. Бу — сынлы сәнгатьнең башка төрләре һәм жанрлары арасында график публицистиканың урыны һәм мөмкинлекләре турында тагын да тирәнрәк уйланырга, кыюрак фикер йөртергә нигез бирә. Бу мәсьәләләрне ачыклау һәм анализлау практик яктан да зур әһәмияткә ия. Минем аларның кайберләренә генә булса да тукталып үтәсем килә.

Әле күптән түгел кайбер кешеләр арасында карикатура ул бер көнлек әйбер. Бәлки кирәкле нәрсә булса да, аның гомере кыска, журналның яңа саны чыккач кичәге рәсем онытыла диган фикер йөри иде. Кызганычка каршы, мондый карашның әле дә бетеп җиткәне юк. Мәсәлән, зона күргәзмә комиссиясе кире каккан кайбер рәсемнәр соңыннан халыкара сатира күргәзмәсенә куелды һәм югары бәягә лаек булды. «Сатира тынычлык өчен көрәштә» дигән күргәзмәдә исбат ителгәнчә, журнал битләрендә бер тапкыр күренгән политик карикатура үзенең сугышчан запалын югалтмый, үзенең көчен саклый һәм соңыннан күргәзмә стендларыннан актив тәэсир итә икән.

...Үткән елда, июль көннәренең берсендә, белгечләр «Крокодил» редакциясенә илебезнең төрле почмакларыннан килгән меңнәрчә карикатураларны һәм плакатларны карап чыктылар. Шуларның ике йөзе «Сатира ут сызыгында» дигән күргәзмә өчен сайлап алынды. Бу — тематик күргәзмә иде. Халыкара тормышның төрле якларын чагылдырган бик күп әсәрләр арасыннан күргәзмәгә Көньяк-Көнчыгыш Азиядә һәм Якын Көнчыгышта җинаятьчел империалистик агрессияне фаш итә торганнары гына алынды. Күргәзмәне оештыручылар материалларны урнаштыруның бик кызыклы, яңа формасын тапканнар. Башкаланың Кузнецк күпере урамындагы күргәзмә залының биек булуыннан файдаланып, алар экспозициягә газеталардан алынган һәм уннарча тапкыр зурәйтылган документаль фотографияләр куйганнар. Шулар фонында күргәзмәгә куелган төп карикатуралар һәм плакатлар бигрәк тә усал һәм нәфрәтле булып сурәтләнәләр.



Сүзсез рәсем. *Л. Бочкова.*

Күргәзмәнең төп эчтәлеген, гомуми рухын совет сатира осталарының «Правда» һәм «Крокодил» битләре буенча безгә таныш булган әсәрләре тәшкил итә. Алар белән беррәттән, союздаш һәм автономияле республикалар карикатурачыларының рәсемнәре дә куелган иде.

Һәр ике күргәзмәдә Казан художникларының, «Чаян» журналы карикатурачыларының актив катнашуы куанычлы хәл. Илдар Әхмәдиев, Лия Бочкова, Эрнст Гельмс, Леонид Насыров, Борис Старчиков һәм бу юлларның авторы әлеге күргәзмәләрнең беренчесендә дә һәм соңгысында да катнаштылар. Иосиф Бобровицкий, Юрий Денисов һәм Виктор Игнатьев карикатуралары беренче, ә Суфия Әбдрәшитова, Виктор Бунь һәм Иван Хантимеров әсәрләре икенче күргәзмәдә күрсәтелде. Унике «чаянчы»ның шундый зур күргәзмәләрдә катнашуы бездәге графика сәнгатенең үсеше хакында кайбер нәтиҗәләр ясарга, иҗади коллективның көче һәм «Чаян» журналының принципиаль позициясе турында сөйләргә дә мөмкинлек бирә.

Автономияле республиканың сатирик журналы битләрендә халыкара политик темага багышланган карикатуралар бастыру кирәкме! Барлык сатирик коралның көчен хуҗалык һәм культура төзелешенең конкрет темаларына юнәлтү урынлырак булмасмы!.. Мондый карашларны алга сөрүче кешеләрнең дә позициясе берьяктан дөрес кебек. Ләкин алар илебездәге коммунистик төзелеш проблемаларын Советлар Союзының халыкара тормышыннан, тышкы политикасыннан аералар. Шуңа күрә аларның позициясен ахыргача яклап булмый.

Дөрес, «Чаян» журналында басылган карикатуралар «кара грек полковниклары» яисә Алабама расистлары күзенә чалынмый. Аларны, ягъни Пентагон сугыш чукмарларын, иң усал, иң ачулы сатирик рәсемнәр белән генә үзгәртеп тә булмый. Сатириканың бурычы аннан гыйбарәт тә түгел. Карикатураның иң төп максаты җәмәгать тормышының теге яки бу күренешләренә карата билгеле бер караш тудырудан гый-

барәт. Карикатура укучыларга расистлар «мораленең» чирканыч табигатен, басып алучыларның кабахәтлеген, долларга хезмәт итүчеләрнең икейөзле булуларын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Ул совет кешесенең морале һәм әхлагы белән сыеша алмый торган һәр нәрсәгә — комсызлыкка һәм әрәмтамаклыкка, эчкечелеккә һәм ришвәтчелеккә, ялкаулыкка һәм гамьсезлеккә каршы нәфрәт тәрбияли. Монда Мәскәү өчен бер, Казан өчен икенче доза, икенче дәрәҗә булырга мөмкин түгел. Менә шуңа күрә дә «Чаян» журналының бөтен карикатурачылар активы халыкара тормыш темасын яктыртуга зур әһәмият бирә. Бу теманы эчке тормыш темасы белән бергә алып барганлыктан, журналга бу мәсьәләләрне төрлеләндерергә һәм системалы рәвештә яктыртырга, укучыга тәэсир итү дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлек бирә. Карикатурачыларның күргәзмәгә куелган рәсемнәре моңа мисал була ала.

«Чаян» художникларының өлкән буыны вәкилләреннән И. Бобровицкий һәм Э. Гельмс өчен зур, гомумиләштерелгән темаларга омтылу характерлы. Рәсемне ту-



Көньяк Вьетнамда һөҗүм операцияләре (партизанча төзәтмәсе белән)

*И. Хантимеров рәсеме.*

лаем дөрес аңлау өчен аның кайбер урыннарын, мәгънә бирә торган детальләрен сурәтләүдәге конкретлык та алар өчен уртак сыйфат булып тора. И. Бобровицкийның «Казына алмаслар» дигән рәсемендә җир казучы машинага утырган бер реваншист свастика ярдәмендә ГДР стенасын казып маташа. Һәр детале җентекләп эшләнгән бу рәсемдә төп мәгънәви деталь — фашист свастикасы. «Чаян» ветераныының сатирик графика өлкәсендә кырык еллык тәҗрибәсе булган художникның үзенә хас стиле бар. Бу композициягә дә, сюжетка да, рәсемнең барлык элементларын хәл итүгә дә кагыла. Ләкин рациональлек эмоциональлелекне киметү, графиканың бер төрле булуы исәбенә ирешелә. Болар тәҗрибәле һәм кызыклы художникның кайбер рәсемнәренә зыян китерә.

Э. Гельмс үзенең рәсемнәрен башкача, күпертеп һәм кискенләштереп ясый. Ул моңа образларны капма-каршы куюу аша ирешә. Күргәзмәгә куелган рәсемендә ул Америка милитаристларының ерткычка охшаш гәүдәсен һәм шунда ук американецны капларга тырышучы кыска буйлы эшкуарын күрсәтә. Художник аларны һәм чагыштыра, һәм каршы куя. Ә рәсем астындагы язу бөтен нәрсәгә ачыклык кертә:

— Карагыз, ул бит тынычлык яклы! Ә кулларын хәзер юар.

Аңа кулларын юарга кирәк, билгеле, чөнки алар терсәккә кадәр канга буялган. И. Бобровицкий белән Э. Гельмс иҗатындагы аермалык эмоциональлелектә һәм күпертеп күрсәтүчәнлектә генә түгел. Ул детальгә карата мөнәсәбәттә, рәсемнең шартлы булуында.

И. Әхмәдиев, В. Игнатьев, Б. Старчиков, И. Хантимеров «чаянчы»ларның урта буынына, потенциаль мөмкинлекләре әле тулысынча ачылып бетмәгән художниклар рәтенә керәләр. Аларның күбесе эзләнүен дәвам итә. Шуның белән бергә аларның үзләре ирешкән дәрәҗәне саклау өчен җитәрлек кадәр график культуралары да бар. И. Хантимеровның «Коньяк Вьетнамда һөҗүм операцияләре» дигән сатирик рәсеме художникка хас аңлаешлы график ысул белән башкарылган. Ышанычлы штрих, төгәл буяу, гади композиция, эчтәлекне әйтеп бирүдә ачыклыкка омтылу — болар барысы да аның стиленә хас детальләр.

Ә менә В. Игнатьев карикатуралары хәрәкәтчәнрәк һәм эчкерсезрәк. Ул бер генә минутка да альбомыннан аерылып тормый. Шуңа күрә аңа тормышны, заманны тирән тою һәм аңлау хисе хас. В. Игнатьевның халыкара сатирик күргәзмәгә кабул ителгән карикатурасы — халыкара темага ул эшләгән иң тәэсирле рәсемнәрнең берсе. Анда атом-төш һәм бактериологик кораллар, һәлакәтле газ баллоннары, ракеталар тутырылган җир асты арсеналы сурәтләнгән.

— Үсеп кенә җит, бу тәтиләр барысы да синеке булыр,— дип мөрәҗәгать итә ата үзенең улына. Ата дигәне — Көнбатыш Германия монополистлары, аларның шулай сөеп үстерә торган уллары исә — НДП. Киеме свастикалар белән бизәлгән баланың үскәч кем варисы булачагына аз гына да шик калмый.

Б. Старчиковның күргәзмәгә куелган сатирик рәсемнәре аның эчтәлекне тирәнрәк ачып бирергә ярдәм итүче яңа, тәэсирле график чаралар эзләвен күрсәтәләр. Шуларның берсе — «Израильнең импеРЕАЛИСТИК портреты» дигән иң яхшы рәсемен карап үтик. Америка илбасарларының Израильне тынычлык күгәрчене итеп күрсәтергә, агрессиянең империалистик асылын яшерергә маташуларын фаш итү өчен, художник карикатурачыларның гадәттәге материалы — графика белән генә канәгатьләнми. Ул офорт[1] куллана. Бу — рәсемнең эмоциональ тәэсир көчен генә арттырып калмый, бәлки график публицистика өлкәсендә линогравюра һәм офорт чараларын куллануның перспективалы булачагын да күрсәтә.

И. Әхмәдиев тегге яки бу график форманы карикатураның эчтәлегенә, төп фикеренә карап сайлый. Яхшы профессиональ хәзерлек үткән сәләтле художник рәсем ясауның төрле ысулларын әйбәт белә. Мәсәлән, халыкара сатирик күргәзмәгә аның линияләр белән ясалган «Дезертирлыкка каршы чара күрелде» дигән рәсеме куелган иде. Аның соңгы хезмәтләренә матур, килешле рәсем характерлы. Мисал өчен «Сатира ут сызыгында» дигән күргәзмәдә күрсәтелгән рәсемен карап үтик. Рәсем конкрет. Художник кинаягә урын калдырмый. Рәсемдә Америкадагы зур шәһәрнең таш

---

[1] Металлга кислота белән төшерелгән рәсем.

йортлары арасында әңгәмә алып баручы америка егете һәм әле генә Вьетнамнан кайткан очучы күрсәтелә. Алар үзара әңгәмә алып баралар:

— Икенче ел инде мин менә бу колледжга эләгә алмыйм.

— Мин аңа беренче әйләнештән үк, түбәннән очканда да эләктерер идем.

Күргәзмәләрдә катнашучыларның күбесе (С. Әбдрәшитова, Л. Бочкова, В. Бунь, Ю. Денисов, Л. Насыров) «чаянчы»ларның яшь буынына керә. Аларның сатирик графика өлкәсендәге эш стажлары ике елдан биш елга кадәр, башкача әйткәндә, әле башлана гына. Әмма аларның иҗаты турында да инде хәзер үк сөйләргә мөмкин. Бу — киләчәктә аларга шактый өмет багларга нигез бар, дигән сүз.

Аларның «Чаян»да ничек эшли башлаулары характерлы. Л. Бочкова белән Ю. Денисов беренче адымнарын бик кыюсыз башлаган булсалар, Л. Насыров, С. Әбдрәшитова, В. Бунь, киресенчә, үзләренең кыюсызлыкларын киң колачлы чая рәсемнәр белән ышыклыйлар кебек иде. Ләкин өйрәнчеклек чорын алар тиз үтеп киттеләр. Л. Бочкова белән С. Әбдрәшитованың иҗатлары турында күргәзмәләрдә алган дипломнары ачык сөйли. (Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, хатын-кыз сатирикларның мондый иҗаты белән бер Татарстан гына горурлана ала.) Ю. Денисов белән Л. Насыровка килгәндә исә, «Чаян» журналының соңгы ике-өч елда чыккан саннарын карасагыз, алар иҗади мөмкинлекләре зур булган, гадәттән тыш өметле художниклар дигән фикер белән килешми калмассыз.

Ә менә Леонид Насыровның иҗади язмышы безне шактый борчый әле. Болай бизәкле матур рәсем ясаучы, композицияне яхшы тоючы, чын-чыннан талантлы художник ул. Ләкин ул тышкы матурлыкны идея эчтәлеген ачуга түгел, бәлки рәсемне тышкы матурлыкка буйсындыру белән чиктән тыш мавыга. Ул үз талантын график тәэсир итү чараларын эчтәлекне ачуга юнәлтсә, журналда тагын бер истә калырлык рәсем барлыкка килә. Художник рәсемнең максатыннан һәм асылыннан чыгып эш итсә, аның һәр хезмәте күргәзмәдә күрсәтелгән «Төшү мәйданчыгы» рәсеме дәрәҗәсендә булачак.

Яшь карикатурачылар Балтик буе республикалары яки социалистик илләр художникларының тәҗрибәләрен һәм казанышларын тәнкыйтьчел үзләштерәләр. Шуның нәтиҗәсендә И. Әхмәдиев, Л. Насыров һәм С. Әбдрәшитова алга таба җитди адым ясадылар. Сәләтле график Ә. Утәгәновның кайбер иҗатсызлыклары, башкаларның тәҗрибәсен өйрәнү урынына аларга, бигрәк тә полякларга, охшарга, иярергә тырышуы белән аңлатыла.

Карикатура арсеналында сатира коралының тәэсирлелеген күтәрү ысуллары һәм чаралары бик күп. Рәсемнең тексты — шуларның беренчесе. Сатирик журналда басылган һәр карикатураның диярлек тагын бер авторы бар. Ул — теманы уйлап табучы кеше яки теманы һәм рәсемне тикшерүдә катнашкан бөтен коллектив. Художник исеме янында теманың авторын күрсәтмәү берничек тә акланмый торган аңлашылмаучылык кына ул.

Әгәр теманың авторы күрсәтелеп килсә! Ул вакытта егерменче елларда «Крокодил»да басылган күпчелек карикатураларда В. Лебедев-Кумач, А. Бухов, ә кайчагында В. Маяковский исемнәрен укый алыр идек. «Чудак» журналының танылган художниклары исеме янында И. Ильф белән Е. Петров имзаларын күрер идек. Сугышка кадәрге «Чаян»ны актарганда без һ. Такташ, К. Нәҗми, Г. Кутуй, Г. Гобәй, М. Әмир, Ә. Исхак, Г. Минскийның сатирик сәләтләрен белер идек. М. Җәлил эшчәнлегенең күп кырлы булуын аңлар идек. Сүз уңаенда әйткәндә, «Чаян»ның сугышка кадәр чыккан кайбер саннарында рәсемнәргә текст язган авторларның исемнәре дә (М. Әмир, Ә. Исхак — Карәхмәт, Г. Гобәй — Г. Г., Ф. Хөсни һ. б.) күрсәтеп барылган. Кызганычка каршы, соңгы вакытларда тема авторлары бөтенләй билгесез кала. Бу кимчелекне төзәтергә була әле. Шул эш белән шөгыльләнгән белгечнең хезмәте нинди кызыклы һәм мавыктыргыч була алыр иде. «Чаян» подшивкалары шундый тикшерүчене көтә. Совет сатирик графикасының актуаль бурычларын хәл иткәндә художникларның һәм язучыларның бергәләп эшләү традициясен яңарту нинди файдалы булыр иде.

«Чаян»ның сатирик графикасы киң яклау тапты. Ярты гасырлык тәҗрибәсе булган, коммунистик төзелешнең актуаль бурычларын хәл итүгә юнәлтелгән сатирик графика сугышчан совет сәнгатенең бер отрядын тәшкил итә. Тагы да үсү һәм камилләшү өчен бездә бик күп потенциаль мөмкинлекләр бар әле.

# ДАИМИ һӘМ ЭШЛЕКЛЕ ЭЛЕМТӘ

Атаклы рус язучысы Владимир Галактионович Короленко (1853—1921) безнең якларга шактый еш килгән һәм Казан белән бик нык элемтәдә торган. Әнә шул тыгыз элемтә, бер яктан, аның иҗатына материал бирсә, икенче яктан, җиде кешенең гомерен саклап алып калуга ярдәм иткән. Ул хакта алда сүз булыр, ә хәзер Владимир Галактионовичның Казанга һәм безнең якларга кайчан, ни өчен килеп йөргәнлеген искәртеп үтик әле.

В. Г. Короленко Казанга беренче тапкыр 1884 елда Якутиядән сөргеннән кайтышлый тукталя. Монда ул шулай ук сөргеннән кайткан абыйсы белән очраша. Элекке танышлары белән күрешә һәм, алар киңәше буенча, Нижний Новгородка китә. Анда «Зенит» пароход компаниясенә эшкә урнаша. Башта кассир булып, аннары пристань управляющие булып эшли. 1885 елда Казанда басыла торган «Волжский вестник» газетасы редакторының тәкъдиме буенча шул газетаның сотруднигы булып эшли башлый. Ай саен мең юллык материал язып тора. Шул ук газетада аның хикәяләре дә басыла. Тик анда озак эшли алмый. Газетаның тоткан юлы үзгәреп, аның авторитеты төшкәннән соң, шул ук елның ноябрендә «Волжский вестник» белән арасын өзә.

Ләкин Казан белән бәйләнешен дәвам итә. Үзе Нижний Новгородта яшәсә дә, Казанда басыла торган газета-журналларга хикәяләрен һәм очеркларын җибәреп, аларны төрле псевдонимнар белән бастырып баруны дәвам итә.

1887 елның июнендә Владимир Галактионович Красновидово авылына (хәзер бу авыл Кама Тамагы районына карый) Якутиядә сөргендә үзе белән бергә булып кайткан иптәше Михаил Антонович Ромас янына килә. Ромасны ул сөргендәге танышы буларак кына түгел, үзенчәлекле кеше буларак та якын итә. Владимир Галактионовичның «Художник Алымов» исемле хикәясендәге Романыч образы нәкъ менә шул Ромасны күз алдында тотып сурәтләнгән.

Красновидово Владимир Галактионович күңелендә шактый тирән һәм якты эз калдырган. Моның шулай икәнлеге аның 1887 елда язган көен дәфтәрендәге язмадан бик ачык күренә: «Елга[1] — көзге шикелле. Аргы якның болыны ялтыравык тасма булып сузылып киткән комлы ярга килеп терәлгән.


Еракта, сизелер-сизелмәс кенә, урман зәңгәрләнеп күренә. Нәкъ елга үрмәкүчләре сыман булып, төрле юнәлешләргә таба кара нокталар — балыкчы көймәләре шуышып бара. Ишкәкләр бер күтәрелеп, бер төшеп тора, алардан чәчрәгән су тамчылары очкын сыман ялтырап-ялтырап китә.

Уң яктагы зур тау, гигант балта белән бер чабуда кыеп төшергәндәй булып, елгага авышып тора. Баскычланып чыгып торган итәкләре яшел үлән белән капланган ул тауның башы пеләш...»

Шул ук көен дәфтәренә әдип әлеге тауда яшәгән атаман турындагы легенданы да теркәп куйган. Көймәче карт сөйләве буенча язылган ул легендада менә мондый юллар бар: «Ә тау, күрәсең, биек. Шуның башына ук менә икән теге. Ә аннан бик ерак җирләр күренә. Хәтта Лаешны да күреп була. Ә өске якта Югары Ослан да күренеп тора. Атаман, еракттан күрсәтә торган трубасын тотып, әнә тегендә менеп баса

---

[1] Сүз Идел турында бара.



икән дә карый икән. Түбәнгә төшеп килүче яки югарыга менеп баручы берәр судно күреп алдымы — хәзер үзенең кешеләре белән таудан төшеп китә торган булган...»

«Мин шул тауның маңгаена карап торам,— дип яза Короленко,— һәм теге яр астында, дулкынлы су буенда басып торган атаманның мәһабәт гәүдәсен күргән кебек булам...»

Бер группа иптәшләре белән Нижний Новгородтан килеп, 1888 елда Короленко Казанда журналистик-публицистик җәмгыять төзергә дә тырышып карый. Ләкин бу омтылышы бушка китә — җәмгыять төзергә полиция рөхсәт итми.

Короленко 1895 елда безнең якларда тагын берничә тапкыр булып китә. Ул елны «Мултан корбаны» дигән мәсьәлә буенча бик зур суд процессы була. Аның асылы кыскача түбәндәге хәлгә кайтып кала. 1892 елның алтынчы маенда Вятка губернасының Иске Мултан авылы янындагы урманда бер фәкыйрь сукбайның мәете табыла. Ул мәетнең башы кисеп ташланган һәм эчке әгъзалары йолкып алынган була. Менә шуннан чыгып, полиция бу кешене җирле халык — мәҗүси удмуртлар аллага корбан итү өчен үтергән дигән фикергә килә.

Бу эшне башта җирле полицейскийлар тикшерә. Тикшерү 29 ай буена сузыла. Нәтиҗәдә теге мәетнең Казан губернасындагы Мамадыш өязе кешесе Митюнин Конон булганлыгы ачыклана. 1894 елның кышында, Кононны үтерүдә гаепләп, Иске Мултан авылының ун кешесен кулга алалар да судка бирәләр. Суд Малмыж шәһәрендә ясала. Әлеге ун кешенең өчесе гаепсез дип табылып, кайтарып җибәрелә, ә җидесе гаепле дип, нәтиҗә чыгаралар һәм аларны төрмәгә утырталар. Төрмәгә утыртылган кешеләрнең яклаучысы булып судта катнашкан адвокат хөкем карары белән килешми һәм кассация бирә. Шуннан соң 1895 елның беренче октябрендә Алабуга шәһәрендә теге җиде удмуртка яңадан суд була. Суд аларны тагын гаепле дип таба. Удмуртлар алдына үлем куркынычы килеп баса.

Ихтимал, аларны шул хөкем карары буенча үтергән дә булырлар иде. Ләкин, крестьяннарның бәхетенә каршы, суд процессында катнашкан В. Г. Короленко, хөкем карары белән һич тә риза булмыйча, эшне яңадан карауны таләп итеп, судның гадел булмаганын ышанычлы дәлилләп, башта газетада язып чыга, аннары, Иске Мултан авылына үзе барып, җинаять урыннарын тикшерә, фоторәсемгә төшерә, гаепләнүчеләрнең авылдашлары белән сөйләшеп, мәсьәләне тагын да тирәнрәк итеп ачыклап кайта. Шуннан соң Короленко судның гадел булмаганын әйтеп, алдынгы юристларны һәм күренекле врачларны бу мәсьәләне ачыклашуда ярдәм итәргә чакырып, «Русские ведомости» газетасы аша бөтен илгә аваз сала: «Мин,— дип яза ул,— әле хәзер генә Алабугадан, суд тикшерүе үткәрелгән җирдән кайттым. Судтан соң мин Иске Мултанга бардым. Митюнинның башы өзеп ташланган гәүдәсе табылган ямьсез сукмакны карадым, серле һәм күңелсез драма булган урыннарны рәсемгә төшердем. Митюнинны Дмитриев Моисей шалашындагы өрлеккә асып куеп, шунда аның канын агызганнар, имеш, дигәннәр иде, анда да булдым. Казылып, актарылып беткән шалаш идәнендә, күпме генә эзләсәм дә, кан эзе таба алмадым... Мин һаман шул коточкыч, серле, адәм ышанмаслык хәл тәэсирендә яшим әле. Мин аннан хөкем карарын тыңлаганнан соң күңелемдә туган бик авыр хис белән кайттым. (Судта катнашкан башка интеллигент тамашачылар да шушындый ук авыр хис кичергәннәрдер дип уйлыйм.) һәм минем:

Юк, алай булмаган! Юк, егерменче гасыр алдында торганда безнең Ватаныбыз каннибализмнан азат!» дип кычкырасым килә. [В. Г. Короленко. «Мултанское жертвоприношение». 10 томлык җыелма әсәрләр. 9 том. Мәскәү, 1955 ел, 339 бит.]

Владимир Галактионович шәхси хисләренә бирелү белән генә чикләнми, мәсьәләне җентекләп тикшерә. Шул мәкаләсендә ул җирле суд хезмәткәрләренең эшне аннан-моннан гына карап хөкем карары чыгаруларын дәлилләп күрсәтә: «Мәетне,— дип яза ул,— бер ай буена ярып карамыйча тотканнар... Хөкемгә тартылган вотяклар [удмуртлар] суд эшенең нечкәлекләрен белмәгәнлектән, шаһитлар чакырту мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән булганнар. Яклаучыга алар суд булырга нибары ун көн кала гына мөрәҗәгать иткәннәр. Анда да яклаучыга власть тарафыннан ышанычсыз дип табылган шаһитлар белән генә канәгатьләнергә туры килгән. Хәлбуки, гаепләүчеләр үзләре суд тикшерүчеләрен каяндыр китереп чыгарылган төрле имеш-мимешләр белән генә ышандырганнар. Ул имеш-мимешләр дә имеш-мимешләрдән генә килеп чыккан булган әле...»

Шул ук вакытта Владимир Галактионович Вятка губернасының суд органнары тикшерү барышында, үзләренә кирәкле җавапны алу өчен, һич тә рөхсәт ителми торган чаралар кулланып эш итүләрен дә катгый итеп искәртеп китә. Мәсәлән, ул Мултан удмуртларыннан сорау алган вакытта аларны аякларыннан асып интектерүләрен ачыклый һәм бу нәрсәнең бернинди законга да сыймый торган кансызлык икәнен әйтә.

Короленконың менә шушылай бик борчылып, Алабугада чыгарылган хөкем карары белән дә килешә алмыйча язуы нәтиҗәсендә мәсьәлә Сенатка барып җитә һәм элеге җиде удмуртның эшен өченче тапкыр тикшерергә мәҗбүр булалар. Бу юлы суд Митюнинның туган ягында — Мамадышта үткәрелә. 1896 елның 27 маеннан 4 июненә кадәр дәвам иткән ул суд процессында Владимир Галактионович та катнаша һәм удмуртларны яклап чыгыш ясый. 29 майда Мамадыштан үзенең хатынына язган хатында шул көннәрдәге хәлләр турында ул менә болай дип яза: «Бүген утырышның икенче көне, ләкин миңа ун көн узгандай тоела инде. Залда, гаепләүче прокурорлар артында, хөкем палатасы прокуроры минем отчетны кулына тотып утыра. Башта ул анда язылганнарның барысын да җентекләп тикшереп-карап барган иде. Ләкин хәзер, күрәсең, шаһитләрнең элек сөйләгән нәрсәләрен нәкъ минем отчетта язылганча сүзгә-сүз кабатлап баруларына инангандыр — алай җентекләп үк карап бармый башлады. Берничә бик каты бәрелеш булып алды инде. Тәнәфес вакытында халык арасыннан бик күпләр минем кулымны кысты. Гомумән, халыкның барысы да дип әйтерлек безнең якта, ләкин безнең каршыбызда уникe сфинкс-присяжныйлар утыра... Ике тапкыр бик мөһим мәсьәләләргә кагылышлы сораулар бирә алдым. Гомумән, мин сөйләгән вакытта буталмыйм, бары бераз кызам гына икән. Шулай диләр. Бу эш кимендә тагын өч көнгә сузылыр әле. Бүген иртән без бик шатландык, полицияне бөтереп салдык. Шмелев тыелган чаралар куллануын һәм властен манифестта күрсәтелгән дәрәҗәдән арттырып җибәрүен танырга мәҗбүр булды. Тимофеев бөтенләй буталып бетте һәм ниндидер түзга язмаган нәрсәләрне лыгырдый башлады».

Ниһаять, мәсьәләне һәрьяклап тикшергәннән соң суд элеге җиде удмуртны аклый.

Ләкин еллар буена сузылган бу борчулы эш язучының үзенә дә шактый кыйммәткә төшә. Моның шулай икәнлеге әдипнең 1897 елның 24 январенда энесенә язган хатыннан бик ачык күренә: «Өченче елдан, ягъни Мултан эше башланганнан алып, үзган елның көзенә кадәрге вакыт эчендә, кирәгеннән артык тапчыгу нәтиҗәсе буларак, үземә сизелмичә генә минем нервларым шактый нык какшаган икән. 1895 елның көзе тулысы белән отчетлар төзүгә, мәкаләләр язуга һәм күңел борчуларына сарыф ителде. Аннары Мамадышка барырга һәм анда җиде көн ярым буена утырышларда катнашырга туры килде. Шул утырышларның соңгы көннәрендә миндә бик каты йокысызлык башланды...»

Бәхеткә каршы, Владимир Галактионовичның бу авыруы артык зыянлы булмый. Соңыннан ул савыга һәм 1921 елга кадәр яши, иҗат итә. Безнең якларга үзе килеп чыга алмаса да, Казан белән бәйләнешен өзми. Күп кенә Казан кешеләре белән хат язышып, хәбәрләшеп тора.

В. КЛИМЕНТОВСКИЙ

Гали Халит

# ТИЗЛӘТЕЛГӘН ӘДӘБИ ҮСЕШ ҺӘМ ИҖАТ МЕТОДЛАРЫ

Соңгы елларда галимнәр арасында әдәбиятларның тизләтелгән үсеше турында бәхәсләр активлашып китте. Дөрес, бу төшенчә үзенең тиешле ачыклыгын һәм тулылыгын алды дип булмый әле. Шулай да аның эчтәлеге һәм чикләре күпмедер дәрәҗәдә билгеләнде инде[1].

Тарихи һәм әдәби-эстетик үсешнең төп дәверләрен билгеле бер эзлеклелек белән үткән әдәбиятлардан тыш, тагын да әле аерым чорларда артта калып та, соңыннан аларны тиз арада куып җиткән һәм алдынгы әдәбиятларга хас төп билгеләр, типологик сыйфатлар белән бергә, үзләренең милли үзенчәлекләрен ачкан әдәбиятлар да бар. Кыска гына итеп әйткәндә, артта калып килгән һәм йомылып торган әдәбиятларның билгеле чорларда бик тиз арада сикереш ясап, күтәрелеп китүләрен тизләтелгән үсеш дип атыйлар.

Мәгълүм ки, Россиядәге күп кенә әдәбиятлар үзләренең үсеш, өлгереш дәрәҗәләре ягыннан байтак гасырлар дәвамында төрле баскычларда тордылар. Халыкларның беришесе, авыз иҗаты белән генә чикләнеп, язма иҗат эшеннән, хәтта укый-яза белүдән дә мәхрүм иде. Ләкин XIX йөз азакларында һәм XX йөз башларында Россиядә кузгалган халык хәрәкәтләре артта калган күп кенә милли әдәбиятларның да үсеш темпын тизләтеп, халыкларның рухи эшчәнлеген уятып җибәрде. Бу — зур сикереш иде. Әмма шулай да артта калган милли әдәбиятларның һәммәсе берьюлы күтәрелеп китә алмады. Чөнки изүче җәмгыять шартлары аларның барлык эчке, потенциаль көчләренә тиз арада гына ачылыр өчен кирәкле мөмкинлекләрне бирми. Капиталистик җәмгыятьнең тигезсез үсеш законы һәм милләтләрнең бердәм хокукка ия булмаулары аркасында, милли әдәбиятлар арасындагы тигезсезлек тә бетерелә алмый.

Тегеләй бу әдәбиятның тизләтелгән үсеше өчен берничә әһәмиятле тарихи-иҗтимагый һәм мәдәни-әдәби факторның бер ноктагарак килүе, очрашуы кирәк. Тизләтелгән процесс барлыкка килсен өчен, иң әүвәл, артта калган милли әдәбиятны алга этәрә торган тарихи шартлар өлгерергә, икенчедән, ул әдәбиятның үз язма традицияләре булырга һәм, ниһаять, яңа шартларда аның шул эчке мөмкинлекләре тиз арада ачылып, активлашып китәргә тиеш. Әнә шундый ике фактор булганда, бу әдәбият өчен бик кирәкле өченче фактор да — үзеннән алда торган әдәбиятларның тәҗрибәсен кабул

[1] Тизләтелгән процессның нигездә өч төрле формада булуы турында сүз йөртергә мөмкин: 1) билгеле иҗат методларының һәм әдәби агымнарның классик эзлеклелек белән бер-берсен бик тиз алыштырып килүе формасында (мәсәлән, XVIII һәм XIX гасыр аралыгында рус әдәбияты классицизм, мәгърифәтчелек реализмы, сентиментализм һәм романтизм этапларын үтеп өлгерә); 2) бу буын-звеноларның нинди дә булса өлеше төшеп калу формасында (мондый әдәбиятлар байтак); 3) билгеле бер тарихи чорда төрле иҗат методларының һәм әдәби агымнарның очрашуы, аралашуы яки янәшә яшәве формасында (моның бер мисалы — XX йөз башындагы татар әдәбияты һ. б.) — Г. Х.

иту мөмкинлеге дә кинәя. Татар әдәбиятына килгәндә, бигрәк тә XX йөз башында инде аның тизләтелгән үсеше өчен кирәкле шул өч факторның барлыгы сизелә иде. Россия чынбарлыгын биләп алган азатлык хәрәкәтләре, татар әдәбиятында күп гасырлар аша килгән язма традицияләренең яшәүчәнлеге һәм, ниһаять, дөнья күләмендәге алдынгы эстетик процесс белән, аеруча рус классик әдәбияты белән якын мөнәсәбәткә керү — болар һәммәсе әлектә һич күренмәгән киңлек һәм тирәнлек алдылар.

Тизләтелгән процесс кинәттән генә килеп чыкмый, әлбәттә. Һәрбер тарихи сикерешнең хәзерлек чоры булган шикелле, әдәбияттагы тизләтелгән үсешнең дә хәзерлеге була. Безнең әдәбиятка карата шундый әһәмиятле бер хәзерлек чоры итеп XIX йөз дәвамында көч җыя килгән һәм гасыр азагына табан формалашкан мәгърифәтчелек хәрәкәтен, аның белән тыгыз бәйләнгән мәгърифәтчелек әдәбиятын һәм мәгърифәтчелек реализмын күрсәтергә мөмкин. Әйе, без татар әдәбиятында нигездә XIX йөзнең соңгы чиреге белән 1905—1907 еллы революция аралыгында булган мәгърифәтчелек реализмы этабын тизләтелгән үсешнең хәзерлек чоры дип атыйбыз. Әмма кайбер белгечләр мәгърифәтчелек реализмында ук инде тизләтелгән үсешнең үзен күрергә һәм шул реализм белән бергә романтизмның да килүен, кушылуын татар әдәбияты өчен характерлы момент дип санарга телиләр[1]. Әмма бу закончалык татар әдәбиятына ни күләмдә туры килә һәм аны турыдан-туры тизләтелгән үсеш дип буламы? Әгәр дә мәгърифәтчелек реализмы XX йөз башындагы татар әдәбиятына гомумән хас күренеш дип саныйбыз икән, ул чакта инде бу реализмның романтизм белән кушылуы хакында тулы мәгънәсендә сөйләргә мөмкин, әлбәттә. Ләкин дә мондый кушылышны фәкать мәгърифәтчелек реализмы кысаларына гына куеп карау бәхәсле булып калачак. Чөнки без XX йөз башы дигән төшенчәне татар әдәбияты үсешенең нигездә 1905 елдан башланган тарихи бер чоры дип карыйбыз. Шуңа күрә бу чорда инде мәгърифәтчелек реализмы белән романтизмның үзара мөнәсәбәтен критик реализмнан башка күз алдына китерү читен булачак.

Мәгълүм ки, татар әдәбияты үзенең күп гасырлык язма традицияләре булган әдәбиятлар төркеменә керә. Ул традицияләрнең нигездә Көнчыгыш әдәбиятлары белән бәйләнгән булуы да билгеле. Һәм бу бәйләнешнең ике ягы — уңай һәм кире яклары булганлыгын да яшерергә кирәк түгел. Элекке татар әдәбияты үзенең берничә гасырлык тарихы дәвамында бертуктаусыз һәм бер юнәлештә генә үсеп килә алмады. Шулай ук анда тизләтелгән үсеш дип аталырлык сикерешле этаплар да күренмәде. Моның сәбәпләре дә ачык: Көнчыгышка бәйле патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләрнең нык, озак саклануы һәм рус самодержавиесенең колониаль политикасы татар культурасының, әдәбиятының һәм сәнгатенең өзлексез, прогрессив үсешен тоткарлады, аның бик искергән традицияләре саклануга җайлы шартлар тудырды. Шуның нәтиҗәсендә татар әдәбияты Европа тибындагы әдәбиятлардан, аерым алганда, рус әдәбиятыннан күп артка калды. Россиядә барган ярыш һәм алдынгы рус культурасы тәэсире белән бәйләнештә күтәрелгән татар мәгърифәтчелеге әнә шул чынбарлыкны аңлап хәрәкәт итәргә теләде. Моны раслаган фактлар байтак. Шулар арасыннан берсен генә искә алып үтик. 1893 елда «Мусульманин» имзасы белән «Кое-что о казанском мусульманстве» дигән бер әсәр басылган. Татар җәмгыятенең артта калуына борчылу белән тулы әсәр ул. Аның авторы бик аянык караш белән татарларның алдынгы халыклар сафына басарга тиешлеге турында сүз алып бара:

«...Татарлар — акыл үсешенә сәләтле халык һәм акыл хезмәтенә тырышлыкта һәм чын мәгариф башлангычларын үзләштерүдә башка халыклардан ким түгел...

Россия мөселманнарына Европача мәгариф кирәк һәм ул зарури. Күп миллионлы рус халкы арасында яшәгән бер төркем татар үзенең азиатчыл характерын саклый алмый... Үзегезгә эш башларга вакыт инде! Югыйсә, соң булыр, һәм сез, мөселманнар, әгәр дә үзегезне кайгыртуны башкаларга тапшырсагыз, күпне югалтырсыз» (10—11 битләр).

Мондый фикерләр нәрсә турында сөйлиләр соң? Алар, бик ачык итеп, татар халкының һәм милли культураның бу хәлдән тиз чыгарга тиешлеген аңлауны, алдынгы татар интеллигенциясендә үз халкын һәм милли культурасын үстерү ихтыяҗы, теләге көчәя баруын күрсәтәләр. Бу теләк-ихтыяҗның асылы, һичшиксез, тарих һәм рухи тормыш тирәннән үзгәрә баруын сизенә башлауда иде.

[1] Ю. Г. Нигматуллина. Национальное своеобразие эстетического идеала. Из-во Казанского университета. Рус телендә. 1970 ел. 62 бит.

XX йөз башында инде, 1905—1907 елгы рус демократик революциясе яктылыгында, татар әдәбиятының тиз арада үсеше өчен кирәкле яңа шартларны, мөмкинлекләрне аңлау алдынгы татар интеллигенциясе эшчәнлегендә тулы гәүдәләнде. Тукай кебек әдипләребезнең беренче чыгышларында ук шулай аңлау ярылып ята иде:

Барып керик хөрриятнең кочагына,
Тәрәккыйнең кукләренә очмагына,—

диде шагыйрь 1905 елда «Дусларга бер сүз» шигырендә. Революция белән башланган прогрессның, күтәрелешнең зурлыгына, матурлыгына ышаныч романтикасы иде бу. Һәм мондый романтика Тукайның бөтен иҗатын сугарды. 1906 елда язылган «Хиссияте миллия» мәкаләсе бу яктан декларация булып яңгырый шикелле: «Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаж. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, бардакханәдән чыкмаган (килмәгән мәгънәсендә — Г. Х.) яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә мохтаж.

Бу әйтелгәннәр булмаганда, безнең тормышыбыз күңелсез, үлек чыккан өй төсле моңлы, тынсыз, тавышсыз, рәхәтсез булачактыр»,— диелгән иде Тукайның ул мәкаләсендә. Күп тапкырлар искә алынган һәм һаман да алыначак бу билгеле сүзләрдә зур хакыйкать бар: шагыйрь революцион күтәрелеш яктылыгында милли культура, милли әдәбият язмышындагы тарихи прогрессны аңларга омтыла. Моның иң характерлы ягы — татар әдәбиятын һәм культурасын алдынгы рус әдәбияты югарылыгына тиз арада күтәрү өчен кирәшкә өндәвендә иде. Менә шул яңарыш, күтәрелеш аңы XX йөз башындагы татар әдәбиятының буеннан-буена үтте һәм аңардагы тарихи оптимизм идеясенең бик әһәмиятле элементы булып торды.

XX йөз башында татар әдәбиятының тизләтелгән үсеше шактый катлаулы һәм каршылыклы идея-эстетик күренешләрне мәйданга чыгарды. Бу күренешләр заманның яңа иҗтимагый-сыйнфый шартларына гына түгел, ә татар әдәбиятының үз традицияләренә һәм башка алдынгы әдәбиятларга бәйләнеше ничек булу ноктасыннан аңлатканда гына үзләрнең тулы мәгънәләрен ачарлар. Безнең әдәбият мәгърифәтчелек реализмы этабын тиешенчә үтеп тә өлгермәде, критик реализм, романтизм һәм тагын кайбер әдәби агымнар белән очрашырга тиеш булды. Очрашып кына калмады, ә аларның аралу, формалашу «газабын» һәм үзара мөнәсәбәтләрен, көрәш һәм бәрелешләрен кичерү чорына килеп керде. Ләкин, безнең кайбер белгечләребез уйлаганча, бу процесста мәгърифәтчелек реализмы төшеп, югалып калмады яки артка чигенмәде, ә критик реализмга һәм романтизмга аерылмас юлдаш булып, алар белән бергә үзенең традицияләрен һәм мөмкинлекләрен үстереп җибәрде. Шуна күрә XX йөз башындагы татар критик реализмы һәм романтизмы турыдан-туры мәгърифәтчелек реализмы җирлегендә үсеп чыкты дип карарга һәм мәгърифәтчелек реализмы үзе дә яңа дәвер кичерүе турында сөйләргә нигез бар. Шулай итеп, татар әдәбияты, тизләтелгән үсеш сферасына кергәннән соң, башка әдәбиятлар кыска яки озак вакыт эчендә эзлекле рәвештә, бер-бер артлы үткән агым-юнәлешләрне бер үк вакытта һәм бер ноктагарак җыеп «үзләштерергә» тиеш булды. Бу хәл, әлбәттә, татар әдәбиятындагы иҗат методларының формалашуында да, аларның үзара мөнәсәбәтендә дә бик үзенчәлекле сыйфатларны тудырды.

Бу чор татар әдәбиятында реализм һәм романтизм, мөстәкыйль юнәлешләр булараk та, бер-берсе белән кушылган, синтез тәшкил иткән хәлдә дә үзләрен күрсәттеләр. Әммә бигрәк тә синтез процессының торган саен көчәя барганлыгына игътибар итмичә булмый. Шуна күрә безнең әдәбият белеме, реализм һәм романтизм синтезы XX йөз башы татар әдәбиятына сәнгатьчә зур яңарыш һәм байлык алып килде, дип саный икән, бу фикердә, һичшиксез, хаклык бар. Шуның белән бергә, бу синтез безнең әдәбиятта ике методның үзара бәйләнешеннән, бер-берсенә тәэсиреннән туган сәнгатьчә төсмерләр байлыгын, төрлелеген генә биреп калмады, ә өченче бер башлангычның, юнәлешнең барлыкка килүенә дә нигез булды диясе килә. Безнеңчә, бу өченче башлангыч, гомумән генә алганда, әнә шул билгеле ике методның органик бердәмлегеннән гыйбарәт романтик реализм агымы иде. Бу инде синтез нәтиҗәсе, ягъни яңа эстетик күренеш, әдәби иҗатның үзенчәлекле бер тибы. Ул башка әдәбиятлар тарихында да булган.

Рус әдәбиятына карата гына түгел, башка әдәбиятларга карата да романтик реализм төшенчәсен куллану очраклы булмаска кирәк. Поляк поэзиясендә, мәсәлән, хәтта XIX гасыр урталарында ук инде, бигрәк тә А. Мицкевич һәм Ю. Словацкий иҗатында,

романтик реализм урын алганлыгын күрсәтәләр [1]. Шундый фактларны күз алдында тотканда, бездә дә реализм белән романтизм мөнәсәбәтеннән, синтезыннан өченче бер үзенчәлекле иҗат тибының мәйданга килү ихтималы бар шикелле.

Соңгы елларда совет әдәбият белеме романтик реализм төшенчәсенә билгеле күләмдә игътибар итте инде. Рус әдәбиятында, аеруча, XIX йөз азагында романтик реализм (яки реализм романтизациясе) көчәеп китте, диләр рус әдәбияты белгечләре [2]. Моңа мисал итеп Горький, Гаршин һәм Короленколарның шул чордагы иҗатларын китерәләр, хәтта Чехов шикелле язучыларда да моның булганлыгын әйтергә телиләр. Бигрәк тә Горькийга карата алганда, романтик реализм этабы аның иҗатында нәкъ социалистик реализм принципларына күчү алдыннан булганлыгы аңлашыла.

У. Р. Фохт фикеренчә, рус әдәбиятындагы романтик реализмның иң характерлы бер сыйфаты түбәннән, халык арасыннан күтәрелүче шәхес образын алгы планга чыгарудан һәм аның активлыгына игътибар итүдән гыйбарәт [3]. Язучылардан, мәсәлән, Короленко бу хакта үзе болай дигән: «Шулай итеп, массаның әһәмияте җирлегендә шәхеснең әһәмиятен ачу — реализмга алмашка киләчәк яңа сәнгатьнең бурычы менә шул» [4].

Яңа чорда, халыкның самодержавиегә каршы көрәше кызган һәм аның башында социализм байрагын күтәргән пролетариат мәйданга чыкканда, рус әдәбиятының халыкка, кешегә, шәхескә һәм заман героена мөнәсәбәтендә дә тирән үзгәрешләр барлыкка килүен М. Горький көчле итеп сизгән художник булды. Аның 1901 ел башында Л. Андреевка җибәргән хатларыннан берсендә мондый сүзләр әйтелгән: «Яңа кеше үсә, яңа тормыш, якты тормыш, ирекле тормыш иҗат итәргә үзенен хакы барлыгын, гәрчә тар булса да, әмма ачык итеп аңлаган шәхес үсә, һәм бу шәхес жылы тормышны, тук тормышны, күңелсез тормышны, тыныч мещанлык тормышын хәзер үк инде җанының бөтен куәте белән нәфрәтли белә» [5] Бу, һичшиксез, яңа чор күтәргән шәхесне, геройны яңача аңлаган эстетик концепция иде.

Димәк, рус әдәбиятындагы романтик реализмның төп мәгънәсен, асыл сыйфатын **халык массаларының әһәмиятен күрсәтү белән бергә шәхеснең ролен ачу** дип аңласак, XX йөз башындагы татар әдәбиятында да реализм белән романтизм синтезының шундый үк тенденцияне, юнәлешне тудыруын кире кагып булмас. Бигрәк тә унынчы еллардан соң, яңа революцион күтәрелешләр башлангач, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури һәм Галимҗан Ибраһимов кебек демократик язучылар иҗатындагы яңа идея-эстетик тенденцияләр безнең әдәбиятта романтик реализмның көчле яралгылары булуын күрсәтәләр. Аларда да халык белән бәйләнгән һәм халык арасыннан чыккан яки халык арасына барган шәхес образына, шундый геройга игътибар көчәеп, аның активлыгын алга куеп, югары эстетик пафос белән күрсәтү тенденциясе ачыла барды. Бу романтик герой тормыш белән нык бәйләнештә азатлык идеалына ашкынды һәм халыкны яклап, явызлыкка каршы көрәш илһамы белән рухланды. Дөрес, романтик реализм бездә рус әдәбиятындагы шикелле тулылык алып өлгермәде, әмма аның яралгылары яхшы ук тотрыклы төскә кереп, безнең демократик әдәбият традицияләренең иң алдынгы өлешен тәшкил иттеләр һәм социалистик революция елларындагы әдәбиятыбызда үзләренең көчле булып яшәүчәнлекләрен күрсәттеләр.

Кайбер белгечләр, романтизм белән реализм синтезына саграк карарга кирәклекне искәртеп, XX гасыр әдәбиятларында реализм белән романтизмның аерым метод буларак яшәүләре турында сүз алып бару урынлырак булыр иде, диләр [6]. Әлбәттә,

---

[1] М. Храпченко. О прогрессе в литературе и искусстве. «Вопросы литературы». Рус теленда. 1970 ел. 6 сан. 66 бит; Н. И. Балашов, Я. В. Станюкович. Развитие романтизма и реалистической тенденции в польской поэзии 1840-х годов (Поэма Словацкого «Беневский»). «Реализм и его соотношения с другими творческими методами» исемле җыентык. 1962 ел. 143—144 битләр.

[2] Кара: С. М. Петров. Литература романтизма и социалистический идеал. «Вестник Московского университета». Серия X. Филология. Рус телендә. 1967 ел. 2 сан. 12 бит.

[3] «Проблемы типологии русского реализма» исемле җыентык. 1969 ел. 78 бит.

[4] «Русские писатели о литературном труде». Т. 3. Рус телендә. 1955 ел. 626—627 битләр.

[5] Литературное наследство. Т. 72. Горький и Леонид Андреев. Неизданная переписка. Из-во «Наука». Рус телендә. 1965 ел. 83 бит.

[6] Кара: Д. Ф. Марков. Реализм и романтизм в болгарской литературе конца XIX — начала XX в. «Реализм и его соотношения с другими творческими методами» исемле җыентык. 206 бит.

XX гасыр башында романтик реализмның гына өстенлек алуы яки реализм белән романтизмның һәрвакыт мөстәкыйль булып калулары турындагы фикерләрнең берсе дөрес, ә икенчесе дөрес түгел дип раслау мәсьәләне хәл итми. Монда сүз конкрет милли әдәбиятлар җирлегендә барганда гына үзенең тулы мәгънәсен, эчтәлеген алырга мөмкин. Әмма гомуми куелышында ул фикерләрнең икесендә дә дөреслек бар. Рус әдәбиятына карата да, татар әдәбиятына карата да романтик реализмның мәйданга чыгуын дәгъва иткәндә, романтизмның һәм реализмның үзләренә хас «тумыш билгеләре» бетеп, ягъни аларның типологик сыйфатлары юкка чыгып, бөтенләй башка, гел өр-яңа метод кына калырга тиеш мәгънәсендә нәтиҗә ясау шулай ук тарихи чынбарлык белән исәпләшмәү булыр иде. Мәсьәләнең кыенлыгы да, кызыклыгы да шунда: бу ике традицион әдәби метод үзләренең генезисын, асыл табигатьләрен ничек саклыйлар, ничек тотрыклы булып калалар гына түгел, ә яңа шартларда ничек үзгәрәләр, ничек бер-берсен баеталар һәм нинди синтез бирәләр.

XX йөз башында иҗат методларының, әдәби агым һәм юнәлешләрнең үзара бәйләнеше, мөнәсәбәте мәсьәләсен реализм һәм романтизм белән генә чикләп калдыру шулай ук берьяклы булыр иде. Бу чорда әле тагын модернизм һәм декадентлык күренешләренең сизелерлек төскә керүен дә истә тотарга кирәк. Мондый агымнар, турыдан-туры реализмга һөҗүм итү белән бергә, үзләрен хәтта классик традицияләрне, бигрәк тә романтизмны дәвам иттерүчеләр, яңадан тудыручылар дип тә күрсәтергә теләделәр. Мәсәлән, символистлар иске дөньяның бетәргә хөкем ителгәнлеге турында сөйләүдән тартынмадылар. Алар буржуаз җәмгыятьтә кеше рухы авыру, гарип икәнлеген, капитализм аны таркалуга, патологиягә китерүен әйттеләр. Ләкин мондый хәлне алар чынбарлыкның иҗтимагый сәбәпләреннән түгел, кешенең шәхси табигатеннән эзләделәр, аның язмышы чыгышсыз һәм ул котылгысыз фаҗигага кичерергә тиеш дип карадылар. Моңа охшаш караш һәм тенденцияләрне романтизмда да табарга мөмкин, билгеле. Ләкин дә символистлар иң әһәмиятле бер нәрсәдән — романтикларның кеше ирекен яклап, явызлык белән актив көрәшү идеясенә теләктәшлек итүдән ерак тордылар. Кеше язмышын, кеше ихтыярын капитализм казыган явызлык чоңгылына ташладылар. Ирексезлек, коллык тойгысын кешегә иң характерлы бер сыйфат дип күрсәтергә маташтылар. Символизмга мондый бәя һич тә әле аңа теге я бу төстә катнашы, бәйләнеше булган язучыларның һәммәсенә дә тулысынча уртак иде дигән карар чыгарырга нигез була алмый. Шул ук символистлар арасында чын мәгънәсендә прогрессив романтизм белән бәйләнештә булган язучылар да бар иде. Мәсәлән, рус шагыйре А. Блок, символизмның күренекле бер вәкиле булу белән бергә, романтизм традицияләренә бәйләнеше көчле икәнлеген дә күрсәтте. Бу хәл аның иҗатында демократик настроениеләрнең урын алуы турында сөйли иде. Моңа охшаш икенче мисалны В. Маяковский язмышында күрергә мөмкин. Ул әдәбият мәйданына футурист буларак чыкты. Әмма аның иҗатына да заманның алдынгы идея-әдәби йогынтысы үтеп, шагыйрь халыкка кирәкле сәнгать юлына басарга теләде. Аңарда да революцион романтизм өстенлек алды. Шул рәвешчә, модернизм һәм декадентлык әдәбияты белән теге я бу күләмдә элемтәдә булган язучылар язмышында аларның критик реализмга яки прогрессив романтизмга мөнәсәбәтләре бик әһәмиятле роль уйнады.

Безнең әдәбият белеме кайвакытларда татар әдәбиятын модернизм һәм декадентлык йогынтысыннан читтә торган кебегрәк итеп күз алдына бастыра. Соңгы елларда критик реализм турында да, романтизм турында да байтак игътибарга лаек фикерләр әйтелде. Бу, һичшиксез, безнең әдәбият белеменең мәсьәләгә бик якын килеп, аның әһәмиятле якларын тирән итеп тикшерү юлына чыга барганлыгын күрсәтә. Әмма шуның белән бергә, безнең әдәбияттагы тизләтелгән үсеш процессы, реализм белән романтизмны гына көчәйтеп, мәйданга чыгарып калдырмыйча, XX йөз башының тарихи-иҗтимагый шартлары таләп иткән башка идея-эстетик күренешләрне дә тудырырга тиеш булды. Болар арасында декадентлык һәм модернизм тенденцияләре дә бар иде. Алар шулай ук очраклы булмадылар. Татар әдәбиятында барлыкка килгән гаҗәп катлаулы һәм каршылыклы атмосфера эчендә күп төрле идеологик настроениеләр очраштылар. Бу настроениеләр тарихи чорның гомуми сәбәпләре белән дә, рус әдәбияты дөньясына турыдан-туры бәйләнгән булу белән дә аңлатылалар. Ләкин татар әдәбиятындагы модернизм һәм декадентлык күренешләрен рус яки Европа әдәбиятларындагы шундый ук күренешләргә тәңгәл иттереп карау, бәяләү мәсьәләне

бик җинел хәл итү булыр иде. Ә чынлыкта исә монда да татар әдәбиятының үз җирлегенә бәйле үзенчәлекле яклары бар. Шулардан берсе — модернизм һәм декадентлык күренешләренең дә үзләренә генә хас кискен, ачык сыйфатлар белән чыкмыйча, шулай ук бик ерактан килә торган әдәби традицияләр аша яңа шартларда үзләренә җайлы урын табарга омтылулары. Безнең әдәбият фәнендә, мәсәлән, прогрессив, революцион романтизмның антиподы, капма-каршысы булган реакцион романтизм һәм аның декадентлык әдәбиятына тартымлыгы хакында кайбер фикерләр әйтелде инде. Димәк, бу төр реакцион әдәбият бездә дә романтизмны билгеле күләмдә үзенә җайлы җирлек итеп файдаланган икән. Шуның бер мисалы итеп, мәсәлән, Н. Думавиның 1913—14 еллар тирәсендә булган чыгышлары искә алынды. Инде М. Хәнәфи кебекләр символизмның төшенкелек, һәм үлем культын ачыктан-ачык яклаган, ин нечкәртелгән үрнәкләрен бирделәр. Бу, күбесенчә, безнең әдәбиятның бер романтик-лирик һәм фәлсәфи жанры булган нәсерда бик кабарынкы гәүдәләнде. Шулай ук империализм сугышы елларында ил һәм халыклар өстенә төшкән газапларга исе китмичә, тыныч матурлык һәм саф мәхәббәт белән тилергән әдәбиятның ниндидер күләмдә урын алганлыгына да күз йомарга ярамый. Бусы инде тормыш, тарих трагедиясенә аркасы белән торган акмеизмның бер чагылышы иде. Һәм әйтергә кирәк, мондый күренешләр критик реализм яки прогрессив романтизм позицияләренә нык басып торган язучыларга да вакыты-вакыты һәм урыны-урыны белән үзләренең тәэсирләрен ясадылар. Ә бу хәл инде аларның дөньяга карашында да, әдәби-эстетик принципларында да ниндидер каршылык һәм катлаулылык тудырмыйча калмый иде. Шул рәвешчә, XX йөз башы татар әдәбиятының тизләтелгән үсеш нәтиҗәсендә салына барган магистраль юлын карaганда, аның нинди елга-ярмаклар, тау-ташлар, чокыр-чакырлар, дала-яланнар, урман-куаклыклар, үзән-тугайлар аша үтүенә текәлеп игътибар итү соралганы аңлашылса кирәк.

Әйткәнебезчә, критик реализм һәм романтизм XX йөз башы татар әдәбиятында бер-берсенә якын тору һәм аралашу сәбәпле, һәр очракта да алар арасына таш стена куеп карау мөмкин түгел. Шуңа күрә дә бер үк язучы иҗатында бу ике методның характерлы билге-сыйфатларын табу һич авыр булмаячак. Байтак вакытлар безнең әдәбият белемендә, әйтик, Тукайны романтик шагыйрь дип атарга теләүләр дә гаҗәпләндермәс. Дөрес, вульгар социологизм тарафдарлары болай дию белән Тукайдагы романтизмны да идеалистик, мистик мәгънәдә күз алдына китерергә тырыштылар. Аннары, моңа каршы тенденция буларак, Тукайны саф реалист дип кенә бәяләү өстенлек алды. Чынлыкта исә Тукай гадәти мәгънәсендәге реалист кына түгел, ә романтик шагыйрь дә, дөресрәге, анарда бу ике методның гаҗәп көчле һәм табигый эретмәсе бар икән. Бу хәл шагыйрьне бер дә кимсетми һәм түбәнсетми, ә киресенчә, аның иҗатына гына түгел, ә гомумән бу чор татар поэзиясенә характерлы идея-эстетик бәйлекнең колачын, дәрәҗәсен дә күрсәтә. Критик реализмга да, прогрессив романтизмга да бәйле художник буларак, Тукай татар әдәбиятының башка алдынгы әдәбиятлар традициясенә, бигрәк тә рус һәм Көнбатыш эстетик дөньясына якынаюына, кушылуына киң капка ачып җибәрде. Татар поэзиясендә көнчыгыш-көнбатыш синтезы дип аталырга хаклы яңа эстетик процессның нигезен салды.

Кайбер белгечләр тизләтелгән үсешне һәр милли әдәбият өчен дә стандарт, уртак критерийлар белән үлчәү һәм барлык очракта да уңай нәтиҗә итеп кенә карау кирәкмәгәнлеген искәрталәр[1]. Һичшиксез, тизләтелгән үсеш процессы, әдәби юнәлеш-агымнарның, традицияләрнең чуарлыгын көчәйтүе белән бергә һәм шуның нәтиҗәсе буларак, гомумән теге я бу милли әдәбият җирлегендә идея-эстетик аерымлану, дифференциацияләрнең бик ачык төс алып җиткермәве дә мөмкин. Мондый хәл, әлбәттә, әдәби метод һәм агымнарның аерымлануыннан бигрәк, аларның үзара бәйләнешенә күбрәк тәэсир итә, синтез өчен җайлы шартларны тудыра. Шуннан инде әдәбият белгечләрен аптырата торган «каршылыклы» моментларның байтак очравы да гаҗәп түгел. Моның мисалларын татар әдәбиятыннан да табып була. Мәсәлән, Дәрдмәндне озак вакытлар «символист» дип атаганнан соң, хәзер инде «романтик» дияргә теләү көчәеп бара. Кайберәүләр ана хәтта «чикләнгән реалист»[2] дигән мөһерне сугудан да тартынмыйлар. Эш нәрсәдә соң? Беренче карашта Дәрдмәнд иҗаты-

---

[1] В. Коваленко. От общих схем к конкретному исследованию. «Вопросы литературы» журналы. 1969 ел. 2 сан. 54 бит.
[2] Дәрдмәнд. Сайланма әсәрләр. 1959 ел. 7 бит.

ның метод кырлары яки төсмерләре төрле һәм чуар булудан киләдер мондый бәяләр, дигән җавап белән генә дә котылып булыр иде. Ләкин болай куелыш берьяклырак. Беренче очракта мәсьәләнең сере бик тиз ачыла: вульгар социологизм тәнкыйте Дәрдмәндне буржуаз идеолог дип карагач, шуңа тәңгәл әдәби ярлыкны да ябыштырырга тиеш иде. Ә «символист» ярлыгы нәкъ шуңа туры килде дә инде. Аннан соң бу шагыйрьне «романтик» яки «чикләнгән реалист» дип атауларның билгеле күләмдә «символист» дип кимсетүгә каршы реакция булуын да истә тотарга кирәк. Менә шундый моментларны искә алган хәлдә, бу өч атаманың һәммәсе өчен Дәрдмәнд иҗатыннан теге я бу күләмдә кирәкле сыйфатларны табу мөмкинлеген дә бөтенләй үк кире кагып булмый шикелле. Чыннан да, Дәрдмәнднең шигъри дөньясында бик тирән традицияләргә бәйле символика да, романтика да һәм тормышка якынлык та бар. Димәк, аның иҗат методы, эстетик принциплар системасы гаҗәп катлаулы дип расларга була икән. Шуңа күрә аны турыдан-туры гына, гадәттәге типологик критерийлар белән генә, теге яки бу аерым иҗат методы бизмәненә салып кына үлчәү ярыйсы ук читен. Менә бу очракта инде язучының индивидуаль иҗат методы, эстетик принциплар системасы белән исәпләшмәү һич мөмкин булмавы аңлашылачак. Әдәбият белгече исә шуңа игътибар итәргә, шуның үзенчәлекләрен ачарга тиеш. Безнең фикеребезчә, Дәрдмәнд иҗат методын традицион романтизм нормаларына бәйләп карау дөресрәк булыр кебек. Әмма моның гаҗәп үзенчәлекле, индивидуаль яклары бар. Дөрес, доминантлык, өстенлек итүче сыйфатлар әйдәүче булып торалар, әмма һәр очракта да алар белән генә эш итү язучының иҗат дөньясын күз алдына тулы бастыра алмый.

Без монда, мисал өчен, Тукай һәм Дәрдмәнд иҗат методларына бәйле кайбер мәсьәләләрне гомумән генә карадык. Шундый ук сораулар башка татар язучыларына карата да туачак, әлбәттә. Әйтик, Сәгыйть Рәмиев һәм Галимҗан Ибраһимов иҗатларын бәяләү тирәсендә дә шул ук иҗат методлары ноктасыннан тиешле ачыклык алмаган яки бәхәсле булган мәсьәләләр байтак. Безнең уебызча, боларның күбесе XX йөз башы татар әдәбиятындагы иҗат методларының, бүтән алдынгы әдәбиятларда формалашкан типологик сыйфатлардан башка, тагын үз милли җирлегендә шушы тарихи чорның үзенчәлеге буларак туган билгеләренә, төсмерләренә тиешенчә игътибар итмәвебез аркасында читтәрәк кала, ахрысы. Әйе, тизләтелгән үсеш байтак кына очракларда иҗат методлары арасындагы бәйләнеш, аралашу һәм күчеш төсмерләре үзләренең бөтен кискенлеге, тулылыгы, куелыгы белән ачылырлык шартларны тудыра алмый. Чөнки монда төрле методлар, бер-берсен алмаштырудан бигрәк, бер-берсе белән бәйләнгән хәлдә мәйданга чыгалар. Әмма бу хәл, әйткәнебезчә, иҗат методларының, әдәби агымнарның типологик билгеләренә кискенлек һәм эзлеклелек белән өлгерү өчен җайлы булмаса да, индивидуаль әдәби стильләр формалашуга, ачылуга көчле этәргеч биргәнлеге күренә. Поэзиядә Тукай, Рәмиев һәм Дәрдмәнд шикелле шагыйрьләрнең яки прозада Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Ибраһимов һәм драматургиядә Г. Камал кебек әдипләрнең бер-берсеннән бик аерылып торган индивидуаль стильләре — безнең әдәбиятның нәкъ шул тизләтелгән үсеше тудырган җанлы сәнгатьчә үрнәкләре иде. Әлбәттә, индивидуаль стильләрне иҗат методларының формалашуыннан һәм үзара мөнәсәбәтеннән һич тә аерып карап булмый. Стильне методның формасы дип аңлау шушы яктан үзен, бәлки, аклый да торгандыр. Шулай ук методларның үзара бәйләнеше, синтезы ахыр чиктә индивидуаль стильләрнең ачыграк төс алуына бер җирлек, уңай шарт булып торуы да әнә шул эчтәлек белән форманың гаҗәп бер оригиналь һәм конкрет мөнәсәбәтен исбатласа кирәк.

XX йөз башындагы тизләтелгән үсеш нәтиҗәсендә татар әдәбияты мәгърифәтчелдидактик фикерләүдән һәм сурәтләүдән шигъри фикерне художестволы образга әверелдерү процессын гаҗәп кыска бервакыт эчендә үтте. Бу инде күренеш-сурәт[1] белән фикер-сурәтне[2] бер бөтенгә әйләндерү, ягъни шуның белән бергә стиль монизмына (бердәмлегенә) ирешү юлында зур тәҗрибә мәктәбен үтү дигән сүз дә иде. Шушы процессны һәм тәҗрибәне үтми торып, бер генә әдәбият та индивидуаль стильләр системасын тудыра алмый, һәм бу җиңел генә барлыкка да килми. XX йөз башындагы безнең әдәбият моның никадәр авыр булуын бик ачык күрсәтте. Әгәр дә без әдәбиятның тизләтелгән үсеш процессы

[1] Русчадагы «образ-картина» мәгънәсендә.
[2] Русчадагы «образ-мысль» мәгънәсендә.

бик катлаулы идея-эстетик ситуацияне мәйданга китерүен искә алып эш итсәк, бәлки, иҗат методларына, әдәби стильләргә һәм жанрларга бәйләнешле күп кенә мәсьәләләрне хәл итүдә үзенчәлекле якларны, хасиятләрне җиңелрәк аңлар идек.

Социалистик революциядән соң милли әдәбиятларның үсешендә яңа чор башланды, аларның тизләтелгән үсеше өчен электә булмаган гаҗәп киң һәм зур мөмкинлекләр ачылды. Иҗтимагый төзелеш бердәмлеге, идея-теләкләр уртаклыгы, милләтләргә һәм милли культураларга бирелгән тигезлек — болар һәммәсе әдәбиятлар үсешенә дә яңа юнәлеш, яңа темп бирделәр, элекке тигезсезлекне яки «стадиаль» төрлелекне алып ташладылар. Бу — искиткеч кискен һәм тирән революцион үзгәреш, сикереш иде. Шуның аркасында электә язуы да булмаган, тик авыз иҗаты белән генә рухланган халыклар, социалистик революциядән соң тиз арада язма әдәбият тудырып, социалистик реализм юлына чыктылар. Хәтта аларга һич тә, әйтик, мәгърифәтчелек реализмы, критик реализм яки романтизм этапларын үтү кирәк булмады. Алар, башка милләтләр тудырган алдынгы әдәбиятларның хәзинәсеннән үрнәкләр, өлгеләр алып, аларның традицияләрен үзләштереп һәм үзләренең фольклорын файдаланып, социалистик чынбарлыкка лаеклы әсәрләр тудыра башладылар. Шул рәвешчә, социалистик революция китергән тизләтелгән үсеш процессының характерлы тагын бер ягы — милли әдәбиятларның үзара бер-берсенә ярдәме көчәеп, үсеп китүдә күренде. Бу инде интернациональ мөнәсәбәт-бәйләнешләрнең өстенлек алуы һәм хәлиткеч идея факторына әйләнүе иде.

Социалистик революциядән соң әдәби традицияләрнең күп төрле катлам һәм төсмерләре гаҗәп дәрәҗәдә активлашып китте. Болар арасында, совет әдәбиятына кирәкле, файдалы булганнары белән бергә, яңа зарарлы һәм төшеп калырга тиешлеләре дә байтак иде. Кискен идея-эстетик көрәш барды һәм шул көрәш аша яңа әдәбият, яңа метод үзенә юл ярды. Бу процесс нигездә революциянең беренче ун елы эчендә үтелде һәм тизләтелгән үсешнең дә иң әһәмиятле сыйфатлары ачылды. Күпләгән милли әдәбиятларның социалистик реализм юлына басуы өчен ныклы җирлек тәэмин ителде. Егерменче еллардагы татар совет әдәбияты тарихы моны тулысы белән раслый.

Социалистик революциянең беренче елларында татар әдәбияты да традиция һәм новаторлык күренешләренең чуарлыгы һәм катлаулылыгы белән аерылып торды. Романтизм да һәм башка кайбер агымнар да үзләренең төрле төсмерләре белән активлык күрсәттеләр. Менә шундый хәлне күз алдында тотканда, бу чордагы совет әдәбиятларының күпчелегендә нинди иҗат методы өстенлек итү турындагы мәсьәләнең бәхәслерәк булуы да гаҗәп түгел. Кайберәүләр, совет әдәбияты үзенең башлангычыннан ук социалистик реализм әдәбияты булды, анда реализм өстенлек итте, диләр, ә икенче берәүләр романтизмның әйдәүче булуын дәгъва кылалар. Әлбәттә, бу инде традицион мәгънәсендәге романтизм гына түгел. Аның төп өлеше яңа чынбарлыкның җанлы тамырларына бәйләнгән булып, шул чынбарлыкны раслау көрәше белән рухланды. Ә бу тамырлар һәм көрәш рухы яңа тип романтизмның реалистик сыйфатлары көчле булуы турында да сөйләделәр. Татар әдәбиятына нисбәт алганда, романтизмның төрле төсмерләре белән бергә, романтик реализмның да яңа бер этап кичерүе һәм монда социалистик реализмның көчле башлангычлары формалаша баруы сизелде дип әйтергә телибез. Бу башлангычларның нидән гыйбарәт икәнлеген күрсәткән дәлилләрнең берсе — халык массалары арасыннан күтәрелгән гади кешенең революционполитик герой ролендә алгы планга куелуында һәм романтик гомумиләштерү аша сурәтләнүендә иде. Моның иң характерлы мисаллары Галимҗан Ибраһимов иҗатында бик калку булып чагылды. Аның «Безнең көннәр», «Яңа кешеләр», «Кызыл чәчәкләр хикәясе» кебек әсәрләрен романтик реализм үрнәкләре итеп карарга мөмкин.

Романтик реализмны демократик әдәбияттан совет әдәбиятына күчү чорында туган бер күренеш итеп алу белән без аны һич тә шул чордагы бөтен татар әдәбияты өчен универсаль, бөтенләе белән анда өстен күренеш дип тәкъдим итәргә җыенмыйбыз. Бигрәк тә Октябрьдан соң совет әдәбиятына килгән һәм социалистик реализм позициясенә баскан татар язучыларының иҗат тарихы төрле агымнар һәм юнәлешләр аша үтүе билгеле инде. Шуңа күрә романтик реализмны иң алдынгы әдәби агымнардан берсе дип, аны критик реализм һәм прогрессив романтизм синтезының бер формасы итеп санаганда, аның күләме дә, әчтәлеге дә байтак конкретлашыр. Тагын да, аны беришле алдынгы татар язучыларының социалистик реализмга үсү юлындагы ха-

рактерлы бер иҗат баскычы дип аңласак, аннан башка иҗат методлары һәм әдәби агымнар аша да социалистик реализмга юл барганлыгын ачык күрербез. Чыннан да, бер төркем татар язучылары критик реализм (Ш. Камал, Г. Камал һ. б.) яки традицион романтизм аша (М. Фәйзи, Ф. Бурнаш һ. б.) совет әдәбиятына килделәр, ә кайберәүләр гыйсъянчылык романтизмын үтәргә тиеш булдылар (һ. Такташ, Н. Исәнбәт һ. б.). Әлбәттә, бу искә алынган юнәлеш һәм агымнар арасына текә киртә корып булмый. Алар арасында бер-берсенә якынлык та, йогынты ясашу да көчле иде. Шуңа күрә бер үк язучы иҗатында, хәтта аның аерым әсәрләрендә вакыты-вакыты белән теге я бу методның, әдәби агымның характерлы билгеләре өстенлек алып чагылуы да табигый күренеш итеп каралырга тиеш. Шул рәвешчә, татар совет әдәбияты критик реализмның һәм прогрессив романтизмның алдынгы традицияләрен үзләштерү, үстерү һәм дәвам иттерү җирлегендә социалистик реализмга лаеклы новаторлык сыйфатлары, ана хас идея-эстетик үзенчәлекләр җитлегү, ныгу дәверенең беренчесен, гомумән алганда, 20 еллар уртасына кадәр үтте. Һәм бу дәвер татар совет әдәбиятындагы тизләтелгән үсешнең, һичшиксез, иң интенсив, иң авыр, катлаулы бер өлеше булды.

Социалистик революциядән соң безнең илдәге барлык милли әдәбиятлар өчен дә тизләтелгән үсешне үтү зарури идеме? Әллә ул элекгә артта калган әдәбиятларга гына кирәк идеме? Мәсьәләне болай куюревәлюция белән әдәбият арасындагы мөнәсәбәтнең нидән гыйбарәт икәнлеген аңлаудан читтә була алмый. Чөнки Октябрь революциясе барлык совет әдәбиятлары тарихында да тамырдан үзгәреш, сикереш тудырды. Бу үзгәрешнең төп юнәлеше, максаты сыйнфыйлык, халыкчанлык һәм партиялелек принциплары җирлегендә социалистик реализм юлына чыгу һәм тагын да югары идея-эстетик баскычка күтәрелү иде. Менә шул уртак максатка ирешү юлын берише әдәбиятлар тизрәк, ә икенчеләре берникадәр соңгарак калып үттеләр. Шуңа күрә аларның яна тизләтелгән үсеше бер ноктадан ук башланып, бер үк ноктада тәмамланды дип карау мәсьәләне артык гадиләштерү, схемалаштыру гына булыр иде.

Әгәр дә без тизләтелгән үсешне, гомумән алганда, әдәбиятның элекке хәленнән тиз арада югары күтәрелеп, заманның алдынгы идея-эстетик таләпләренә җавап бирүендә һәм әһәмиятле сәнгатьчә ачышларга ирешүендә дип аңласак, бу ноктадан иң алдынгы рус әдәбиятының да революциядән соң нииндидер күләмдә һәм аралыкта тизләтелгән үсешне үткән булуын икърар итәргә тиешбез. Чөнки совет әдәбиятының төп юнәлеше булган социалистик реализм эстетикасының өстенлеген тәэмин итү өчен, рус әдәбиятындагы күп кенә элекке, ягъни искергән агым һәм тенденцияләрне кысрыклап чыгарырга, кискен идея-эстетик көрәш дәверен үтәргә кирәк иде. Рус әдәбияты моны тиз арада үтте. Аның революцион һәм социалистик традицияләре бу көрәштә ныклы терәк булды. Ә татар әдәбияты, мәсәлән, рустагы шикелле, совет чорына социалистик реализмның әзер традицияләре белән килеп кермәде. Аңа элекке демократик традицияләр җирлегендә һәм рус совет әдәбиятыннан үрнәк алып, яңа, социалистик эстетиканы тудырырга кирәк иде. Шуңа күрә татар әдәбиятының социалистик реализм юлына чыгуы өчен кирәкле тизләтелгән үсеше рус әдәбияты белән бер дәрәҗәдә һәм бер үк төстә булуын дәгъва кылу мәсьәләнең тарихи дөреслеге һәм милли үзенчәлеге белән исәпләшмәүгә алып барачак.

Шулай итеп, чирек гасыр эчендә татар әдәбияты критик реализм, прогрессив романтизм һәм социалистик реализм кебек бай иҗат методларының барлыкка килүе, үсеше һәм үзара бәйләнеше шикелле катлаулы идея-эстетик процессны үтәргә тиеш булды. Бу чын мәгънәсендә тизләтелгән үсеш нәтиҗәсе иде. Бу нәтиҗә, җайлы иҗтимагый-тарихи шартлар булганда, артта калган әдәбиятлар тиз арада үз эчке мөмкинлекләрен ачып җибәрә һәм алдынгылар сафына баса алуын раслый. Бигрәк тә совет шартларында үскән әдәбиятлар моңа бай материал бирәләр һәм үрнәк булып торалар.

**Марсель Бакиров**

# ШИГЫРЬ ТАРИХЫНА СӘЯХӘТ

Мәгълүм булганча, фольклор шигыре язма поэзиядән шактый карт. Халыкта ритмик сүз — мәкаль һәм табышмаклар — бик күптән туган. Бабаларыбыз шулай ук җырлар чыгарган, зур күләмле дастан, эпослар да иҗат иткән. Ләкин шигырь төзелеше ул чорда хәзерге кебек силлабик системага түгел, э интонацион-синтаксик тәңгәллеккә нигезләнгән булган. Исеменнән үк күренеп торганча, аның ритмын оештыруда төп рольне үзара тәңгәл килә торган ритмик-интонацион кисәкләр уйнаган. Алар сүз тәртибе ягыннан да, җөмлә кисәкләре буенча да бер-беренә охшаган шигырь юлларын тәшкил иткәннәр. Фигыльләр исә һәрвакыт диярлек бер урынга — юл ахырына җыелганнар. Юллардагы иҗекләр саны, ягъни тезмәләрнең озынлыгы бертигез булмаса да, ритм әлеге охшаш җөмләләрнең яки фразаларның кабатлануы нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Галимнәр интонацион-синтаксик шигырьне Европа халыкларының күпчелеге өчен ритмик сүзне оештыруда башлангыч, примитив форма булган дип исәплиләр. Аның үрнәкләре мәкаль-табышмакларда да, шулай ук борынгы җырларда да шактый киң сакланган. Әмма эпик поэзиядә — героик әкият-поэмаларда һәм эпос-дастаннарда — архаик шигырь формаларының эзе аеруча тирән (мәсәлән, төрки халыклар арасында бик борынгы заманнарда ук иҗат ителгән «Манас» һәм «Коркыт дәдәм китабы» эпосларында). Менә IX гасырдан ук килә торган «Коркыт дәдәм китабы» эпосыннан бер мисал:

Калкубани йөрүмдән | турур идүм, (11)
Иелиси кара кызыллык атума | бинеридүм, (15)
Бабамунга бан эвиндән | чакарыдум, (12)
Арку бели ала тагы | авларыдум, (12)
Ала гейик, сыган гейик | ковар идүм, (12)
Тартанда бир охыла | нейлеридүм, (11)
Демренсүз охыла йигит сени | синар идүм, (14)
Үлдүрмеге йигидүм мен сени | кыйармыдум. (14)

Бу өзектә хәзерге шигырьгә хас булган инверсия дә, юлларны һәм рифмаларны төрлечә төзү күренеше дә юк. Монда юллар, төрле озынлыкта булсалар да, һичшиксез, синтаксик бөтеннән, бу очракта аерым җөмләләрдән торалар. Юлларда шулай ук сүзләр тәртибе дә, ярлагы хәлендәге рифмаларның-фигыльләрнең урыны да — бер үк, чөнки алар синтаксик тәңгәллеккә нигезләнгәннәр. Әмма шушы ук мисалда иске форма эчендә яңа форма элементларын күрү дә кыен түгел. Мәсәлән, тел сөрешенә, аның ритмик-интонацион төзелешенә буйсынып, текстның бер үлчәм тирәсендәрәк әйләнүе, аерым урыннарда стихияле рәвештә цезуралар белән ритмик буыннар калкып чыгуы һәм, ниһаять, көчле басымлы иҗекләр алдыннан ачык иҗекләр килергә омтылуы

(туру́р, бине́р, чака́р) әнә шул турыда сөйли. Бу инде борынгы [illegible] әлеге очракта эпик поэзиянең, нигезендә башлангыч хәлендә бернечә ритмик принцип булган дигән сүз. Һәм хәзер дә халык авыз иҗаты шигырьләре нинди дә булса бер метрик чара белән генә түгел, ә төрле метрик чараларның бөтен бер комплексы белән тудырыла. Икенче төрле әйткәндә, күп метрик ысулларның үзара тәэсир итешүе генә фольклор әсәрләренең ритмын тоярга мөмкинлек бирә.

Билгеле, халык иҗат иткән ритмик сүз арасында, бигрәк тә мәкальләрдә, бертигез озынлыктагы юлларга нигезләнгәннәре дә җитәрлек. Ләкин шигырьләребез нигезләнә торган силлабик системага карыйлармы соң алар? Безнеңчә, мәкаль ритмы белән язма шигырь ритмы арасында зур охшашлык булса да, алар арасында тулы тәңгәллек үткәрергә, күпләр уйлаганча, берсен икенчесенең үзгәрешсез дәвамы дип карарга мөмкин түгел. Ник? «Чөнки мәкальләр, мәгънәгә иң кыска шигъри сөйләм юлы белән ирешү өчен, мөмкин хәтле теркәгечсез һәм катламсыз төзелгәнгә, аларның мәгънәсе дә күбесенчә аваз ымлыклары (интонация), тыныш-паузалар һәм ритмик басым көчләре белән биреләләр. Шулай көйләм өчен булмыйча, ритмик сөйләм өчен булганга, аларда иҗек саны гына урын тотмый, ритм басымнары калку итеп әйтеләләр, аваз системасы да шуңа көйләнгән. Димәк, жанр буларак, мәкальнең шигъри үз алымнары бар, ләкин, моңа карап, аны нинди дә булса гыйльми вәзен системалары, әзер схемалар белән эш итә дип булмый. Ул бик табигый тел сөреше, сөйләмнең табигый басымы белән ритмлана» [1].

Бик дөрес әйтелгән сүзләр. Чыннан да, халык үз мәкальләрен әдәбиятчылар нормалаштырган теге яки бу шигырь системасы буенча иҗат итми. Аларда үзара укмашкан хәлендә силлабиклык та, тониклык та һәм үзенә генә хас булган башка төрле закончалыклар да бар. Халык үзенең тел сөреше белән бөтенләй котелмәгән ритмик конструкцияләр эшләп ташлый. Кирәк икән, силлабикасын да, без күнеккән башка кысаларны да җимерә. Кыскасы, фольклор шигыреннән башка төрләре кебек үк, мәкаль-әйтемнәр моноритмга түгел, ә күп төрле ритмнар катнашмасы булган полиритмга нигезләнгәннәр. Димәк, аларда әле канунлаштырылган билгеле бер уртак норма юк, ә теге яки бу шигъри системада файдаланырлык төрле «ритмик күзәнәкләр» генә бар.

Эстетик таләпләргә карап, халык иҗаты хәзинәсеннән теге яки бу метрик принципларны сайлап алу инде — язма әдәбият эше, ягъни китап шигыре бурычы. Менә ни өчен төрле метрик чаралар башта, тел сөрешенә нигезләнеп, фольклор шигырендә тусалар һәм һәркайсы стихияле рәвештә билгеле бер нормага омтылсалар да, алардан үзенә кирәген генә алып тәмам нормага салган, система дәрәҗәсенә күтәргән көч — язма шигырь булган. Чөнки нәкъ менә язма поэзиядә генә, табигый чаралар белән беррәттән, шартлылыкка, ясалмалыкка да нигезләнгән метрика тантана итә башлаган, гомуми ритмик система үсеп чыккан.

* * *

Язма поэзиянең фольклордан аерылып чыгуы һәм мөстәкыйль тармакка әверелүе — гасырларча дәвам иткән ритмик эволюциянең зур җимеше. Бу буленештән соң китап шигыренең, димәк, яңа туып килгән поэтик әдәбиятның махсус законнарга нигезләнгән үз үсеш юлы башлана. Ләкин тәүге чорда, бигрәк тә үзенең «бала» чагында, язма шигырь күзгә күренеп торган меңнәрчә җепләр аша анасы — фольклор белән бәйләнгән була. Чөнки яңа туган бала ана сөтеннән башка үсә алмаган кебек, борынгы язма шигырьнең дә башта фольклор «җиме» белән генә азыклануы, һичшиксез, объектив һәм зарури күренеш була.

Борынгы төрки язма шигырьнең төзелешенә нинди үзенчәлекләр характерлы соң? Ул нинди ритмик системага нигезләнгән? Дөресен әйтергә кирәк, бу сорауларның әле әдәбият белемендә ахырына кадәр ачыкланып беткәне юк. Алай гына да түгел, төркологиядә әле һаман борынгы фольклор шигырен дә һәм язма шигырьне дә «төрки

[1] Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләренең шигъри үлчәмлеге. «Совет әдәбияты» журналы. 1958 ел. 5 сан. 109 бит.

... карау өстенлек итә. Без моны ялгыш дип исәплибез. Мәхмүт Кашгариның «Дивани лөгатит төрк»ендәге (XI гасыр) парчалар, безнеңчә, төрки халыклар тудырган борынгы язма шигырьнең бүгенге көнгә килеп җиткән беренче үрнәкләре. Алар инде фольклор әсәрләре кебек полиритмга түгел, ә утырып җиткән билгеле бер ритмик төзелешкә нигезләнгәннәр, метрик нормага салынганнар. Иң мөһиме — аларның гасырларча дәвам иткән ритмик сайланыш нәтиҗәсендә туган шигъри системасы бар.

Ләкин безнең алда, һичшиксез, язма шигырьнең бала чагы. Моны без, барыннан да элек, иң архаик шигъри форманың — синтаксик тәңгәллекнең — ритмик чара буларак киң рәвештә саклануында күрәбез. Әмма Кашгари сүзлегендәге әлеге парчаларда инде бу форма нык камилләшкән, җөмлә һәм синтагма кисәкләренең урынын гына түгел, ә аларның санын һәм зурлыгын да тулысынча үзенә буйсындырган. Менә ни өчен монда һәр юлның, һәр цезураның, һәр ритмик буынның һәм һәр сүзнең диярлек үз ише, үз тәңгәлләре бар.

Түрлүг ⁝ чәчәк | йарилди, (7)
Барчик ⁝ йазим | кәрилди, (7)
Учмак ⁝ йөри | көрүлди, (7)
Тумлуг ⁝ йана | келгүсүз. (7)
(I.141) [1]

Этил ⁝ суи | ака ⁝ турур, (8)
Кайа ⁝ төби | кака ⁝ турур, (8)
Балик ⁝ тилим | бака ⁝ турур, (8)
Күлүң ⁝ таки | күшәрүр. (7)
(I.103)

Ирән ⁝ ариг | үрпәшүр, (7)
Үчин ⁝ кәкин | үртәшүр, (7)
Сакал ⁝ тутуп | тартишур, (7)
Күкси ⁝ ара | ут түтәр. (7)
(I.233)

Ирән ⁝ алпи | окиштилар, (8)
Киңгир ⁝ көзүн | бакиштилар, (8)
Камуг ⁝ тулмун | тукиштилар, (8)
Килич ⁝ кипка | көчүн сигди. (8)
(I.340)

Ажун ⁝ төни | көндезин | йәлкин ⁝ кәчар, (11)
Кимни ⁝ кали | сатсага | күчин ⁝ кәвар. (11)
(III.303)

Иң борынгы үлчәмнәрдән 7-7, 8-8 һәм 11-11 белән язылган бу мисалларда гасырлар буена эзләнгән ритмик төзелешнең табылуы һәм шагыйрьләрнең шуңа ахыргача турылыклы булуы сизелеп тора. Борынгы шагыйрьләр ритмик-синтаксик тәңгәллеккә шулкадәр нык омтылганнар ки, күпчелек строфаларда аерым ритмик буыннар гына түгел, ә алар эченә кергән аерым сүзләр дә хәтта үзләренең вертикаль парларына (мәсәлән, түрлүг — барчик) буйсынып килгәннәр. Нәтиҗәдә, шигырь юлларында, төп цезуралардан тыш, өстәмә, ярдәмче сүзбүлүләр барлыкка килгән, һәм ритмик буыннар тагын да ваграк кисәкләргә бүленгән. Бу инде ритм стихиясенең һәрьяклап идеаль тәңгәллеккә, ягъни мөмкин кадәр күбрәк парлы берәмлекләргә омтылуы дигән сүз. Иң мөһиме, бу — иң борынгы метрлар (строфа калыплары) системасының, ниһаять, тууы һәм тәүге чорда бөтен ваклыкларына кадәр саклanып тантана итүе.

Кашгаридагы парчаларның рифмалары да язма шигырьнең әле чагыштырмача яшь булуы турында сөйли торган дәлилләр. Аларда морфологик төрлелек тә, фонетик-акустик охшашлык та бик чикле. Рифманың йогынтысы әле төрле сүз төркемнәренә һәм сүзләрнең тамырына үтеп кермәгән диярлек, ул күбрәк фигыльләргә, аларның да кушымчаларына нигезләнә (йарилди — көрүлди, бакиштилар — тукиштилар, үрпәшүр — тартишур, күрдим — бардим, турмади — армади һ. б.). Дөрес, арада фигыль булмаган рифмалар да очраштыргалый. Бу, һичшиксез, алга таба бер адым. Тик бер үк характердагы сүз төркемнәренә нигезләнүләре белән алар әле синтаксик тәңгәллекнең турыдан-туры нәтиҗәсе булып торалар.

Йүгүрди | кәвал ⁝ ат,
Чакилди | кизил ⁝ от,
Көйөрди | арут ⁝ от,
Сачраб ⁝ әнин | уртанур.
(II.153)

Агди | кизил ⁝ байрак,
Тугди | кара ⁝ топрак,
Йәтшү | келиб ⁝ ограк,
Токшип | анин ⁝ кечтимиз.
(III.199)

[1] Җәя эчендәге саннарның беренчесе «Дивани лөгатит төрк» китабының (Ташкент, 1960—63.) том номерын, икенчесе исә ничәнче бит икәнлеген күрсәтәләр.

Уграк ⋮ ири | тиграк ⋮ йәми | аның ⋮ оглак.
Сүти ⋮ үзә | саграк ⋮ йөри | таки ⋮ аглак.

(I. 435)

Димәк, авыз иҗаты шигыре өчен генә түгел, ә фольклор йомыркасыннан чыккан борынгы язма шигырь өчен дә төп ритмик принцип — синтаксик параллелизм. Ләкин язма поэзиядә инде ул метр тәртәсе арасына кертелгән, ягъни шартлы законнарга буйсындырылган. Менә бу яктан караганда, борынгы төрки язма шигырь фольклорда эшләнгән архаик формаларның әдәбият сандалында чүкелеп яңартылган үзенчәлекле төре булып тора. Икенче сүзләр белән әйткәндә, ул — халык гасырлар буе иҗат иткән ритмик формаларның каймагы, аларның профессиональ сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән икенче тормышы. Фольклор шигыреннән аермалы буларак, аның инде язма поэзия өчен уртак норма булып әверелгән метрлар системасы бар. Алар, бер яктан, шигырь үлчәмнәренә, ягъни иҗекләр санына, икенче яктан, цезураларга һәм алар нәтиҗәсендә туган ритмик буыннарга нигезләнгәннәр. Димәк, шул чакта ук инде шигырьнең метры юллардагы иҗекләр санына гына түгел, ә сүзбүләрләрнең каян үтүенә дә нык бәйле була.

Кәлүм ⋮ куми | капса ⋮ кали | тамиг ⋮ итәр, (12)
Көрсә ⋮ ани | билкә ⋮ киши | сөзгә ⋮ бүтәр. (12)

(III. 151)

Тәгүр ⋮ мәниң | савими | билгәлигә ⋮ ай, (12)
Тинар ⋮ кали | ататса | кисрак сани ⋮ тай. (12)

(III. 173)

Бер үк үлчәмдә язылган бу мисалларның төрлечә яңгырау сәбәбе дә нәкъ менә шунда: метрның, иҗекләр саны белән генә канәгатьләнмичә, ритмик буыннар дулкынына да буйсынуында. Бу, һичшиксез, борынгы метрлар системасының безнең көннәргә кадәр килеп җиткән мөһим үзенчәлеге.

Борынгы язма шигырьнең метрларына, болардан тыш, тагын бер мөһим ритмик чара хас. Ул — тюркологлардан беренче булып профессор Хатип Госман игътибар иткән ачык иҗекләр системасы[1]. Бу системаның үзенчәлеге шунда: борынгы төрки язма шигырьдә строфаның билгеле бер урыннарыннан вертикаль юнәлештә ачык иҗекләр тезелеп төшә. Горизонталь юнәлештә караганда, андый иҗекләр, кагыйдә буларак, һәр ритмик буында очрыйлар һәм аларның билгеле бер иҗекләренә беркетелгән булалар.

Узу ⋮ бариб | өкүш ⋮ әвдим + — — ◡ + ◡ ◡ ◡
Телим ⋮ йүриб | күчи ⋮ кәвдим, + ◡ — ◡ + — ◡ ◡
Атим ⋮ бирле | тегү ⋮ әвдим, + ◡ ◡ — + — ◡ ◡
Мәни ⋮ көрүб | йәси ⋮ агди. + ◡ — ◡ + — ◡ —

(I. 179)

Алплар ⋮ ариг | алкишур, ◡ ◡ + ◡ ◡ + ◡
Куч бир ⋮ килиб | аркашур, ◡ ◡ + ◡ ◡ + ◡
Бир-бир ⋮ үзә | алкашур, ◡ ◡ + — ◡ + ◡
Изкәрмәзиб | ок атар. ◡ ◡ + ◡ ◡ + ◡[2]

Ус әс ⋮ кәрүп | йүксәк ⋮ калик | коди ⋮ чакар,
Билгә ⋮ киши | өгүт ⋮ берип | таврак ⋮ укар.

(III. 53)

◡ ◡ + ◡ ◡ ◡ + ◡ ◡ — + ◡
◡ — + ◡ — ◡ + ◡ ◡ ◡ + ◡

Әйтергә кирәк: бу кызыклы күренеш тә, һичшиксез, синтаксик тәңгәллек нәтиҗәсендә туган закончалык. Башта яралгы рәвешендә фольклорда барлыкка килеп, соңыннан ул борынгы язма шигырьгә үтеп кергән һәм анда ритмик кына түгел, ә метрик роль дә уйный торган куәтле берәмлеккә әверелгән. «Дивани лөгатит төрк»тәге парча-

---

[1] Хатип Госман. Татар шигыре. Казан. 1964.
[2] Ритмик схемаларда ачык иҗекләр «—», ябык иҗекләр «◡», метрик ачык иҗекләр «+» билгесе белән күрсәтеләләр.

ларның күпчелеге нәкъ менә шул берәмлекләргә — ритмик ачык иҗекләргә нигезләнүләре белән аерыла да.

Кашгаридагы метрик ачык иҗекләрнең хасияте нидән гыйбарәт соң? Аларга корылган борынгы төрки язма шигырьнең ритмик үзенчәлеге бу яктан нәрсәләр белән характерлана? Тюркологлар әлеге сорауларга ике төрле җавап бирәләр. Беренче карашның авторы Хатип Госман ачык иҗекләр системасын гомумән аруз күренеше итеп карый һәм, Кашгаридагы парчаларның ачык иҗекләргә дә, шулай ук цезураларга да бердәй нигезләнүеннән чыгып, борынгы язма поэзиягә аруз белән бармак (силлабика) синкретизмы хас булган дип исәпли [1]. М. Хамраев белән М. Кәримов исә әлеге парчалар «бөтенләе белән һәм тулысынча бармак метрына туры килә» дигән фикердә торалар [2].

Безнең уебызча, монда әлеге фикерләрдән теге яки бу дәрәҗәдә аерыла торган өченче төрле карашка да урын бар. Без үзебез аңа нигезләнгәндә төрки шигырь үсешендәге борылыш моментларын һәм хәзергә табышмак булып тоелган аерым нәрсәләрне янача һәм тулырак хәл итеп була дип саныйбыз.

Карашыбызны аңлатуны «Дивани лөгатит төрк»тәге метрик ачык иҗекләрдән башлыйк. Безнеңчә, алар башка иҗекләрдән барыннан да элек басымсыз булулары белән аерыла торган берәмлекләр. Аларның, кагыйдә буларак, сүзнең башына яки уртасына туры килүе дә, шулай ук күренекле лингвистларның борынгы төрки теле һәм аның диалектлары турындагы күзәтүләре дә менә шул хакта сөйли. «Уйгурда,— дип яза танылган немец тюркологы А. Габэн (ә Кашгари сүзлеге, билгеле булуынча, төрки телнең карлук-уйгур төркеме ядкарьләре исәбенә керә),— динамик һәм музыкаль басымның булганмы, юкмы икәнлеге хәзергә әле ачык түгел. Һ ә р х ә л д ә, с ү з э ч е н д ә г е а ч ы к и җ е к б а с ы м с ы з б у л г а н» [3] (ассызык безнеке — М. Б.).

Димәк, әгәр дә метрик ачык иҗекләр басымсыз берәмлекләр икән, аларның шигырьдә, һичшиксез, капма-каршы парлары — антиподлары да булырга тиеш [4]. Чынбарлыкта да бу шулай. Кайсы гына борынгы язма парчаны алма, ачык иҗекләр янында мотлак рәвештә басымнар торганын тоясың. Ә менә басымлы иҗекнең ябык булуы, ягъни тартык авазга тәмамлануы мәҗбүри түгел. Чөнки метрик ачык иҗекләрнең капма-каршы пары ябык иҗеккә корылмаган. Аның өчен магнитның икенче полюсы — бары басым гына. Шулай ук антиподларның бер үк сүзгә туры килүе дә зарури күренеш түгел. Аерым метрларда ачык иҗекләрнең икенче сүздә урнашулары да күзәтелә. Ләкин ритмик парлар бер үк сүзгә туры килгәндә дә, төрле сүзләргә бүленгәндә дә — һәрчак янәшә торалар. Шул ук вакытта басымнар ачык иҗекләрнең артыннан да, алдыннан да килә алалар.

Игләди́ | мәниң | аза́к,
Көрмәзи́б | очри | туза́қ,
Икләди́м | андин | уза́к,
Имләгéл | имди | туза́к.

(I. 361)

Йагы́ ¦ бәгдин | узу́клади,
Көрүп ¦ суви | азйклади,
Өлүм ¦ ани | кону́клади,
Агы́з ¦ ичрә | агу́ сагди.

(III. 351)

Йаши́н ¦ атиб | йа́шнади,
Тума́н ¦ туруб | ту́шнади,
Азги́р ¦, кисир | ки́шнәди,
Өгүр ¦ алуб | о́крашур.

(I. 238)

Ага́ ¦ бүктир | үзә, ¦ йурдим,
Бари́к ¦ йакиб | кийа́ ¦ көрдим,
Ани́ ¦ билиб | таки́, ¦ бардим,
Түгәл ¦ йаги | төри́, ¦ тугди.

(I. 424)

[1] Хатиб Усманов. К характеристике ритмического строя тюркского стиха. «Народы Азии и Африки» журналы. 1968 ел. 6 сан. 93. 97—99 битләр.

[2] М. К. Хамраев. Основы тюркского стихосложения. Алма-Ата. 1963 ел. 122—124 битләр.

[3] A. Gabain. Alttürkische Grammatik. Leipzig, 1941, p. 42. М. Рясяненның «Материалы по исторической фонетике тюркских языков» дигән китабы буенча китерелә. 1955 ел. 33 бит.

[4] Без ритмны, кайбер әдәбиятчылар аңлатканча, «бертигез вакыт араларында бер үк күренешләрнең кабатлануы» дип түгел (Г. Л. Абрамович. Введение в литературоведение. 1955 ел. 178 бит), ә капма-каршы күренешләрнең — антиподларның чиратлашуы һәм диалектик берәмлеге дип карыйбыз. Шигырьдә андый капма-каршы парлар берничә төрле: басымлы һәм басымсыз иҗекләр, озын һәм кыска иҗекләр, ачык һәм ябык иҗекләр, цезуралар һәм ритмик буыннар, шигырь юллары һәм юл ахырындагы паузалар...

Ағрук ⋮ агйр | ишинни | азнагука | йӳзӳрмә,
Айруп ⋮ өзүн | ошариб | азнагуни | тозӳрма.
III. 75)

Таңда́ ⋮ билә | кӳрсә мәни | өрдәк: ⋮ атар,
Ҡалва́ ⋮ кӳрӳб | кашга́лаки | сука́ ⋮ батар.
(I. 480)

Шагыйрьләр, образлар белән бергә, интонация дә, шул ук вакытта сулыш ритмы да иҗат итәләр, ягъни чорына, иҗат үзенчәлекләренә карап, шигырьләрне төрлечә яңгыраталар. Моннан 900 ел элек теркәлгән әлеге мисалларда да, безнеңчә, борынгы шагыйрьләрнең интонациясе һәм сулыш системасы лава шикелле булып катып калган. Шуларның эзенә төшкәндә, димәк, борынгы төрки язма шигырьнең һәм шул вакыттагы телнең табигатенә хас закончалыкларны ачарга мөмкин булуы бер дә гаҗәп түгел. Югарыда анализланган һәм конкрет мисалларда күрсәтелгән антиподлар системасын без борынгы язма поэзиянең метрик нигезендә яткан реаль закончалык дип исәплибез. Бу ни дигән сүз? Әгәр Кашгаридагы парчаларның метрын тудыруда басымнар да катнаша икән, ул шигырьләргә тониклык күренеше дә хас булып чыга түгелме соң?! Әйе, нәкъ шулай. Борынгы язма шигырьдә без **үзенчәлекле тоник башлангыч булган** дигән фикердә торабыз. М. Хамраев белән М. Кәримовның «Дивани лөгатит төрк»тәге поэтик парчаларның метрын «бөтенләе белән һәм тулысынча бармак метрына» кайтарып калдыруларыннан безнең карашыбыз менә шул ягы белән аерыла да.

Билгеле, тел гыйлемендә төрки телләргә зәгыйфь, саңгырау басым хас дип исәпләнелә. Ләкин бу һич тә борынгы язма шигырьдә басымнарның мөһим ритмик роль уйнавын инкарь итә алмый. Чөнки шигырь составында сүзләр грамматикадан тыш булган өстәмә бәйләнешләргә дә керәләр. Гади сөйләм стихиясендә сизелеп тормаган һәртөрле грамматик чаралар үзләре дә анда җанланып, калкуланып китәләр. Шулай ук аерым басымнарның йөкләмәсе дә бермә-бер арта. Төрки шигырь белгече, күренекле поляк галиме Т. Ковальскийның фундаменталь хезмәтендә бу турыда бик кызыклы фикер чагылып кала: «**Төрки өчен**,— дип яза ул,— **нәрсәне булса да басым белән әйтү (асылда) шул ук нәрсәне сүзмә-сүз, я булмаса бераз үзгәргән формада кабатлау белән бер**»[1] (ассызык безнеке — М. Б.). Моңа ышану өчен һәртөрле тәңгәллекнең идеаль үрнәге булган мәкальләргә игътибар итү дә җитә.

Тулу́м анутса, кулу́н болур,
Тулу́м унутса, болу́н болур.
(I. 221)

Көндә ирүк йок,
Бәктә кыйи́к йок.
(I. 100)

Алпла́р бирлә уру́шма,
Бәкләр бирлә туру́шма.
(I. 192)

Киле́м-ките́м бар,
Үле́м-җите́м бар.

Җаны́ң тынса, кулы́ң тынмый,
Кулы́ң тынса, җаны́ң тынмый.

Җи́кмәсәң дә, а́т яхшы,
Сөймәсәң дә, кы́з яхшы[2].

Тулысынча синтаксик параллелизмга, охшаш юлларның кабатлануына корылган бу мәкальләрдә басымнарның метрик-ритмик чара булып килүе ап-ачык. Әгәр шушы тезмәләрне кабатлану сыйфатыннан мәхрүм итсәң, ягъни берәр юлларын алып ташласаң, басымнарның куәте шунда ук зәгыйфьләнә. Алар бары аллитерациягә корылган, я булмаса логик басым таләп ителгән юлларда гына билгеле дәрәҗәдә сакланып кала алалар. Чөнки аллитерация күренешләренә дә, мәгълүм булуынча, шул ук закончалык — кабатлану күренеше хас. Андый күренеш булганда, бер үк яки охшаш сүзләр кабатланганда, басым үзенең куәтен хәтта бер юлда да күрсәтеп өлгерергә сәләтле.

---

[1] Т. Ковальский. К вопросам формального изучения поэзии турецких народов. Известия Восточного фак-та Азербайджанского госуниверситета. Баку. I китап, 1926 ел. 157 бит.

[2] Бу мәкальләрнең баштагы өчесе Кашгари сүзлегеннән, соңгылары Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» дигән китабыннан алынды.

Арыслан баласы арыслан булыр.
Ак булмаса да, пакь булыр.
Ир кадере йл белән.
Туган илең — туган анаң.

Һәм, киресенчә, тәңгәл моментлар булмаса, бер юллык мәкальләрдә тоник сыйфат бөтенләй юк дәрәҗәсендә.

Туй үпкәсез булмас.
Тел — кылычтан үткен.
Чиләгенә күрә — капкачы.
Бурычлының теле кыска.

Моннан нәтиҗә шул: **басым тулы куәт алсын өчен, поэтик сөйләмдә аерым сүзләрнең, һичшиксез, я горизонталь, я вертикаль парлары булырга тиеш.** Әмма бу парларның нинди булуы, ягъни тоник басымның нинди тәңгәлләргә нигезләнүе барыбер түгел. Метрик роль уйнасыннар өчен, басымнарның я иң кыска тәңгәлләргә — бер иҗекле сүзләргә — төшүе, я үзләренең антиподлары — ачык иҗекләр белән янәшә торулары шарт. Чөнки бер иҗекле сүзләр дә, шулай ук ачык иҗекләр дә тониклыкны көчәйтә торган берәмлекләр. Менә шушы таләпләр үтәлгәндә, «зәгыйфь басымлы» теләсә кайсы төрки телдә, могҗизалы көч булып, тониклык күренеше калкып чыга. Борынгы төрки язма шигырь, безнеңчә, нәкъ шушы закончалыкка нигезләнгән дә. Аның мәкальләрдә, лирик һәм эпик поэзиядә эшләнгән тоник характердагы заготовкаларны киң куллануы моның ачык дәлиле.

Биредә тоник башлангычлы шигырьнең ничек формалашуын күрсәткән аерым мисалларга да тукталып булыр иде. Әндый мисаллар бар, хәтта шактый борынгы чорга карагАннары бар. Мәсәлән, күптән түгел «Алтун йарук» әсәреннән (X гасыр) Хатип Госман тапкан борынгы төрки шигырь үрнәкләре шундыйлардан. Менә характерлы ике строфа:

Нә ада әрти | адайым, (8)
Көркле кйа | әкүкүм (7)
Өлмәк әмгак | нәчүкйн, (7)
Өнрә кәлип | әртүрдй. (7)

Сынтыда өнрә | өлмәкйг (8)
Булайып, ни | күнки ам, (7)
Көрмәйин әрти | муни таг, (8)
Улуг ачыг | әмгәкйг. (7)

Күренүенчә, шигырь иң борынгы 7 (8) үлчәменә һәм синтаксик тәңгәллеккә корылган. Шулай ук аның рифмалары да әле яралгы хәлендә генә. Ләкин нәкъ шул камил булмаган бетем өлешләрендә ачык иҗекләр системасы ярылып ята. Нәрсә дигән сүз бу? Бу — ачык иҗекләр системасы һәм, шуңа бәйле рәвештә, тониклык күренеше башта шигырьнең бетем өлешендә формалашкан дигән сүз. Менә шуңа күрә дә XVII гасыр филологы Исаак Боккийның «**рифма — ул тоник просодиянең (ритмның — М. Б.) баласы**» дип ясаган нәтиҗәсе, безнеңчә, бик урынлы (Исаак Боккий. О произношении или пении древних стихотворений. «Атеней». Москва. 1828 ел, 9 сан). Ул безнең төрки шигырьнең дә ритмик нечкәлеген ачарга ярдәм итә торган бик мөһим күзәтү булып тора. Соңга табарак инде тониклык күренеше рифма белән генә канәгатьләнеп калмаган, ә акрынлап строфаның башка өлешләренә дә үтеп кергән. Һәм, шулай итеп, тоник башлангычлы борынгы төрки язма шигырь барлыкка килгән.

Безнең тониклык күренешен яклавыбыз Ф. Коршның һәм Т. Ковальскийның борынгы төрки шигырьне силлабо-тоник дип исәпләүләре белән аваздаш түгелме соң? Бәлки, ул фәндә хаклы рәвештә тәнкыйтькә очраган әлеге карашны яңадан тергезергә маташудыр? Һич юк. Тониклык төшенчәсен без борынгы язма поэзиягә карата тар һәм үзенчәлекле мәгънәдә кулланабыз, ягъни ул төшенчә эченә бу очракта силлабо-тоник системаны кертмибез. Чөнки Кашгари парчаларында һәм борынгы поэтик үрнәкләрдә Корш белән Ковальский «күргән» стопалар юк. Аларның нигезендә, грамматик басымнарга буйсынып, һәрчак я так, я җөп иҗекләрдә калкып чыга торган ритмик басымнар да күзәтелми. Борынгы язма шигырь бөтенләй икенче характердагы берәмлекләргә — көчәйтелгән басымлы ритмик буыннарга һәм буынара ачыклыкларына корылган. Басымлы булсалар да, бу буыннар инде силлабо-тоника стопалары белән тиңдәш түгелләр. Чөнки аларның чиге һәрчак сүзаралыклары, ягъни цезуралар белән билгеләнә.

Икенчедән, аларның зурлыклары да төрлечә. Бер үк шигырьдә хәтта берничә төрле буын чиратлашып килергә мөмкин. Һәм шунысы характерлы: барлык метрлар өчен дә һәр ритмик буынның, димәк, һәр сүзнең көчәйтелгән басым алуы мәҗбүри түгел. Кайбер очракларда, бигрәк тә ике янәшә буынның берләшү тенденциясе сизелеп торганда, аерым ритмик буыннар тоник басымсыз да килә алалар. Нигә дигәндә, әлеге басымнар үзләренең яшәешләрен һәм метрик рольләрен сирәк булып урнашканда гына сиздерәләр. Шигырь юлында никадәр азрак килсәләр, аларның куәте дә шулкадәр зуррак була.

Инде хәзер борынгы төрки язма шигырьнең аруз белән нинди мөнәсәбәттә булуына килик. Безнеңчә, Кашгари парчалары аруз булып исәпләнә алмыйлар. Ник дигәндә, алар әле аруз йогынтысына эләгергә өлгермәгәннәр, э турыдан-туры төрки халыкның саф үз казанышы, үз шигырь төзелеше булып торалар. Шулай булгач, аларга берниди мөнәсәбәте булмаган шигырь системасының исемен бирү нигә кирәк?! «Төрки аруз» дигән термин әдәбият гыйлемендә гарәп-фарсы йогынтысында туган шигырь төзелешенә карата кулланылганлыктан һәм борынгы язма шигырьдән теге яки бу дәрәҗәдә аерылганлыктан, без Кашгари парчалары белән арузга нигезләнгән әсәрләрне бер-береннән аерып карау ягында.

Борынгы төрки язма шигырь белән төрки арузы арасындагы аерма нәрсәләрдә күренә соң? Иң зур аерма, әлбәттә, метрларының бер-беренә охшамаган булуында. Кашгари парчалары силлабикага һәм тоник башлангычка нигезләнгәнлектән, борынгы язма шигырьнең метрлар системасы да шушы ике сыйфатны калку итеп күрсәтүче берәмлекләргә буйсынган. Аларның иң үзенчәлеклесе һәм һәр ике ритмик принципка да турылыклы хезмәт итә торганы — цезуралар яки сүзаралыклары. Цезуралар үткәндә, строфа, һичшиксез, билгеле бер зурлыктагы ритмик буыннарга бүленә һәм шуның аркасында шактый озын юллар да ритмик яктан җинел, силлабик яктан тигез һәм төгәл булып яңгырыйлар. Икенче төрле әйткәндә, тагын да ваграк кисәкләргә бүленү нәтиҗәсендә, силлабиклык принцибы строфаның бөтен эчке структурасына, состав өлешләренә үтеп керә. Ә тониклык? Ритмик буыннарда сүзләр билгеле дәрәҗәдә мөстәкыйль яңгыраш алганлыктан һәм бер-берсеннән цезуралар белән аерылганлыктан, шигырьдә, һичшиксез, аерым басымнарның көче дә арта. Әгәр аларның горизонталь һәм вертикаль ишләре дә булса, яннарыннан, куәт өстәп, метрик ачык иҗекләр дә үтсә, силлабик принципка ритмик юлдаш булып, тоник башлангыч килеп кушыла. Борынгы язма шигырьнең метрлар системасында бу ике принцип ныклап кавышкан һәм «идеаль законга» әверелгән. Ә квантитатив-микъдари башлангыч алар фонында гына, өченче дәрәҗәдәге чара буларак кына гәүдәләнә. Аның мөстәкыйльлеге дә, әлеге принципларны икенче планда калдырырлык куәте дә юк. Шуңа күрә дә Кашгаридагы метрик характердагы шигырь юлларын микъдари стопаларга, ягъни квантитатив метрга бары шартлы рәвештә генә бүләргә мөмкин.

Аруз метрларына килгәндә, без моның киресен күрәбез. Аларда инде озын һәм кыска иҗекләр — төп антиподлар. Димәк, метрик ачык иҗекләрнең функциясе дә инде башка: озын иҗекнең пары булып килү. Тоник башлангычлы шигырьдә ачык иҗекнең басымсызлык сыйфаты төп рольне уйнаган булса, монда, киресенчә, аның кыскалык сыйфаты беренче планга күчә. Тоник башлангычлы шигырьдә ачык иҗекнең юлдашы, антиподы булып тоник басымлы иҗек калкып чыккан булса, монда аның ритмик пары булып озын иҗек килә. Шуның белән бергә, арузда ачык иҗек янәшәсендәге капма-каршы иҗекнең басымы да башка төрле: тоник түгел, ә музыкаль. Чөнки ул, беренчедән, һәрчак сузынкы, озын иҗекка төшә; икенчедән, тон ягыннан әйләнә-тирәсендәге, ритмик такттагы башка иҗекләрдән шактый югарырак була[1]. Һәм, ниһаять,— монсы инде аеруча характерлы — музыкаль басым табигый басымнарга һәр очракта да зарури тәңгәл килми. Чөнки аның грамматик басымнар белән бергә туры

[1] Моның белән ул берьюлы берничә мөһим функцияне башкара: үз тирәсенә башка иҗекләрне дә туплый, юлның такт-стопаларга бүленүенә дә ярдәм итә, ритмик-мелодик дулкын да тудыра.

*килүе мәҗбүри түгел.* Тукай шигырьләрендә, сүз басымнары белән исәпләшмичә, ачык иҗекләрнең я алдыннан, я артыннан калкып чыга торган музыкаль-ритмик басымнарның сере нәкъ менә шунда.

> Й́ матур! Мин | я́нмас идем, | я́ндыручы | бу́лмасаң;
> Та́ммас иде | җиргә яшьләр, | та́мдыручы | бу́лмасаң.
> Кы́зганыч хәл, | кы́зганыч хәл, | бик кыен бит, | би́к кыен;
> Би́рсәгезче | бе́р тиен тик, | тә́нкә түгел | би́т, тиен.
> Ни́ кылырсың, | ха́җи абзам, | то́тса мәскәү ⋮ ләр якаң?
> Ка́к ты будешь | о́твечать там, | то́тса мәскәү ⋮ ләр якаң?

Билгеле, мондый басымнар калкып чыксын өчен, шигырь, һичшиксез, көйләп яки ярым такмаклап укылырга тиеш. Аруз музыкаль шигырь булганлыктан, бу — аруз гыйлеменең, аерым алганда, тактиг (вак кисәкләргә — тактларга бүлгәләп уку) канунnарының зарури таләбе. Тактиг кагыйдәләре заманында мәдрәсәләрдә өйрәтелгәнлектән, элек аруз шигырьләре шулай (ярым көйләп, ярым такмаклап) укылган да. Һәм хәзер дә бу алым кыйраәт (сәнгатьле уку) сабагы үткән өлкән яшьтәге һәр кешегә диярлек таныш.

Шунсы характерлы, ярым көйләү, ярым такмаклау мелодикасының, дөресрәге, музыкаль басымга нигезләнеп укылучы шигырьләрнең ритмик үзенчәлеген иң беренче дөрес аңлатучы кеше дә бездә мәдрәсә тәрбиясен үткән әдип булды. Без монда Хәсән Туфанны күздә тотабыз. Ул әлеге басымнарның «табигый урынын югалткан»лыгын күрсәтеп бирде һәм аларны шартлы рәвештә «ясалма», «схематик» басымнар дип атады [1]. Без исә ул басымнарны, исемнәре җисемнәренә туры килеп торсын өчен, «музыкаль басымнар» дип алабыз.

Төрки арузда музыкаль басымнарның роле искиткеч зур. Аларны саклап, көйләп-такмаклап укыганда, озын-кыска иҗекләрнең чиратлашуы һәм үзара нисбәте дә шактый төгәл саклана. *Чөнки мондый мелодика шигырьнең алдан бирелгән ритмына буйсынып кына калмый, ә үзе дә аны тулыландыра, тексттагы ритмик чатаклыкларны тигезләп, төзек хәлгә китерә.* Икенче төрле әйткәндә, *музыкаль фактор арузлыкны тудыручы тел факторларына яңа куәт өсти* [2], *квантитативлык күренешен тагын да көчәйтә.* Ә менә шул ук шигырьләрне силлабик шигырь кебек итеп, ягъни хәзергечә, сөйләү интонациясе белән укыганда, аруз күренеше зәгыйфьләнә. Чөнки музыкаль басымнарны һәм тактларны (стопаларны) сакламау кайбер иҗекләрнең озынрак яки кыскарак яңгыравына китерә. Без боларның шулай икәнлегенә экспериментал фонетика аппаратлары ярдәмендә махсус тикшеренүләр үткәреп ышандык [3].

Төрки аруз метрларының борынгы язма шигырь метрларыннан тагын бер аермасы бар. Сүз күпчелек аруз шигырьләрендә буынара ачыклыкларның сакланмавы турында бара. Икенче төрле әйткәндә, *арузда цезураларның да, димәк, рит-*

---

[1] Х. Туфан. Шигырь төзелеше мәсьәләләре. «Совет әдәбияты» журналы. 1958 ел. 12 сан.

[2] Тел факторлары дигәннән, без монда метрик ачык иҗекләрнең кыска булып килүен, ябык һәм такт (стопа) ахырындагы ачык иҗекләрнең исә (озын сузык катнашмаса да!) озын булып яңгыравын күздә тотабыз. Гарәп-фарсы телләрендә һәм арузында да күпчелек озын иҗекләр нәкъ шундый юл белән ясала. Ягъни аларда да, иҗек озын булсын өчен, аның составына озын сузык катнашуы мәҗбүри түгел.

[3] Без шулай ук арузда көй-мелодика белән сүз-текстның ни рәвешле ныклы союзга керүен дә өйрәндек. Күпчелек көйләр арузның теге яки бу метрына ритмик яктан гаҗәп дәрәҗәдә тәңгәл булып чыкты. Ягъни көйләрнең тактлары да, озын-кыска тоннары һәм музыкаль акцентлары да шигырьләрдәге үз ишләренә — стопаларга, озын-кыска иҗекләргә һәм музыкаль басымнарга бик төгәл туры килеп торалар. Рудаки, Руми, Сәгъди, Хәйям, Хафиз, Нәвои, Җами кебек классикларның шигырьләренә көйләнгән һәм бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән мокамнар — моның ышандыргыч үрнәкләре. Тукай шигырьләренә җырланучы «Туган тел» («Анам кабере янында»), «Тәфтиләү» (орнаментсыз нигезе), «Пар ат», «Бәйрәм бүген», «Тотса мәскәүләр якаң» кебек татар көйләре дә аруз (текст) ритмы белән шактый аваздаш. Шуның белән бергә, бездә аруз шигырьләрен тактиг мелодикасына, һәр үлчәмнең үзенә генә хас моң-мелодиясенә нигезләп уку да киң таралган булган.

мик буыннарның да, зарури норма булып саналган даими катнашлыгы юк. Анда шигырь юлларын ритмик кисәкләргә бүлү ролен күбрәк башка чаралар — музыкаль басымнар һәм озын-кыска иҗекләрнең чиратлашу тәртибе — башкара. Менә шуңа күрә дә бу системага корылган шигырьләрдә цезураларга сүз атландыру алымы, ягъни буынара ачыклыкларына сүз белән күпер салып үтү кин таралган.

Тоник башлангычлы борынгы язма шигырьдә исә сүз атландыру алымы юк. Ул шулай ук халык иҗатына да хас түгел. Фольклор белгече Нәкый Исәнбәт, мәсәлән, мәкальләрнең «атланмасыз бөтен сүзле ритмик буын»нарга нигезләнгәнлеген күрсәтә («Татар халык мәкальләре»нә кереш сүз. I том. Казан. 1961. 197 бит). Яшь тикшеренүче Хуҗи Мәхмүтов та табышмакларга карата шундый ук нәтиҗә чыгара; аерым алганда, ул «буынара ачыклыклары сакланмаган табышмакларны (язма рәвештә иҗат ителгән китап табышмакларын исәпкә алмаганда) без берне дә очратмадык дип яза («Татар халык табышмаклары». Диссертация. 1969. 114 бит). Димәк, бу күренешне халык иҗатында очраткан тәкъдирдә дә, система рәвешендә түгел, ә аерым элементлар сыйфатында гына табарга мөмкин булуы шиксез. Аның каравы, аруз белән язылган иң беренче төрки әсәр булып исәпләнгән «Котадгу белег» поэмасында (1069 ел) һәр ун юлга уртача сигез сүз атландыру туры килә. Бу, әлбәттә, очраклы күренеш түгел, ә гарәп-фарсы метрикасының йогынтысы, төрки аруз формалашуга үзенчәлекле ритмик чара буларак ярдәм итүе дигән сүз. Төрки поэзия көнчыгыш йогынтысына эләккән ул чорда сүз атландыру алымы, ягъни, немец классик поэтикасы термины белән әйткәндә, «күперләр» куллану нәкъ менә гарәп-фарсы арузының бер сыйфаты булган.

Ләкин шунсы характерлы: цезуралы шигырьгә күнеккән төрки шагыйрьләр иҗатына сүз атландыру алымы механик рәвештә генә күчеп утырмаган. Алар аны үз зәвыкларына яраклаштырып, шактый үзенчәлекле итеп үзләштергәннәр: сүз атландыру кулланганда, стопа-тураклар арасына махсус рәвештә ике тартык аваз китерә башлаганнар. Бу — стопалар чиген сиздерү өчен шулай эшләнгән. Чөнки такт ахырында тартык аваз (ябык иҗек), тавыш юлын ябып, үзеннән соң аз гына пауза ясарга, я булмаса «ялган пауза» тудырырга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта ул кирәк урыннарда музыкаль басымнар куллануны да җиңеләйтә. Менә ни өчен «Котадгу белег»тә башланган бу үзенчәлек аруз белән язылган бик күп, бик күп әсәрләргә үтеп кергә һәм, буыннан-буынга күчә-күчә, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Гафур Гөләм, Мирза-Әликбир, Сабир, Сәмәд Вургуннар иҗатына килеп тоташа.

Әй пари рух ¦ соралар, биз ¦ га нигох ай ¦ лаб үтунг
Бир назар бир | ла гадони | под(и)шах ай ¦ лаб үтунг.
Гәрчи үтган ¦ да кирарсиз | күп кишининг | конина,
Бу гадо кунг ¦ ли учун мун ¦ ча гунах ай ¦ лаб үтунг. (Лотфыйдан.)
Кел, әй, дил бар ¦ ки, бустан вак ¦ ти булди,
Гул ачилди, | гулистан вак ¦ ти булди.
Килай нола, | бакиб гулдек | юзунгга,
Чу булбуллар ¦ га афган вак ¦ ти булди. (Атаидан.)
Чыкчы, и фик ¦ рем кояшы! | Китсен өстен ¦ нән болыт,
Бу үлек вөҗ ¦ данны җанлан ¦ дыр, җылың бер ¦ лән җылыт!
Мин адаштым, | тугры юлга | ул торып күн ¦ дермәсә;
Дүрт ягым гыйсъ ¦ ян уты, сүм ¦ мәс һич, ул сүн ¦ дермәсә. (Тукайдан.)

Ләкин югарыда язылганнар арузга цезуралар бөтенләй ят икән дигән сүзме соң? Юк, әлбәттә. Сирәк булса да, буйдан-буйга цезуралар сакланган аруз шигырьләре дә очрый. Тик аларда инде метрик ачык иҗекләр янындагы басымнар, борынгы язма шигырьдәге кебек, табигый һәм тоник түгел, ә музыкаль. Әлеге шигырьләр тоник башлангычлы шигырьләрдән нәкъ шуның белән аерылалар да. Менә Кандалыйдан, «Фәрхигә» поэмасыннан, аерым строфалар рәвешендә генә булса да очрый торган мисаллар:

Фáгыйлэтен, | фáгыйлэтен, | фáгыйлэт,
Сúна, Фэрхи, | күп сэламнэр | кáмилэт.
Кáйда китте | дэрттэ үткэн | éлларым?
Сáгышыңдин | таптый йөргэн | éлларым?
Сáндугачым, | кáрлыгачым, | бы́лбылым,
Тáшламагыл, | тóтса, Фэрхи, | кúл кулым.
Айгынам ла, | кéнгенэм лэ, | гэлгенэм,
Жáнгынам ла, | тэнгенэм лэ, | көнгенэм,
Жэүһэрем лэ, | гэүһэрем лэ, | нýргынам,
Сэрвием лэ, | жэннэтем лэ, | хýргынам.

(Әгэр аруз дип тэкъдим ителгэн шигырьлэр арасында тоташ көчәйтелгэн табигый басымга корылганнары очрый икэн, алар инде асылда тоник башлангычлы шигырь дигэн сүз. Тониклык теориясе төрки халыкларда кузгатылмый килгэнлектэн һэм монарчы эшлэнмэгэнлектэн, элек, чыннан да, шигырьне ачык иҗеклэренэ генэ карап, аруз ритмы белэн аңлату очраклары булган һэм хэзер дэ андый омтылышлар юк түгел.)

Димэк, борынгы төрки язма шигырь белэн төрки аруз арасында охшаш моментлар булса да, алар икесе ике төрле. Беренчесе — тоник башлангычлы, икенчесе исэ — музыкаль-квантитатив. Башкача эйткэндэ, Кашгари парчалары аруздан аерыла торган мөстэкыйль системага — силлабика белэн тоник башлангыч синкретизмына нигезлэнгэнэр. Бу — язма шигырьнең яшь чагында барлыкка килгэн иң беренче ритмик система. Төрки эдэбиятның саф үз казанышы буларак, ул, элбэттэ, үсэргэ һэм янадан-яна сыйфатлар белэн тулыланырга тиеш булган, бу — шиксез. Эмма, аерым тарихи сэбэплэр аркасында, аңа тоник юнэлештэ камиллэшү чорын үтэргэ туры килми. Фольклор шигыреннэн язма шигырьгэ күчү чорын үткэч, ул баштагы хэлендэ бөтен төрки поэзияне иилэп үсүдэн туктый. Чөнки язма эдэбияты булган, аеруча алга киткэн төбэклэрдэ нэкъ шул дэвердэ гарэп-фарсы тээсирендэ төрки аруз барлыкка килэ һэм тиз арада профессиональ эдэбиятның иң нечкэ, иң югары, иң модалы үрнэге булып эверелэ.

Даими норма буларак арузның чит йогынты тээсирендэ формалашуын танысак та, без, билгеле, төрки аруз эзергэ хэзер булып кына дөньяга килде дип караудан ерак торабыз. Төрки поэзиянең яна системаны үзлэштерү өчен жирлеге бар иде, йогынты-стимул булганда, куэт алып, аруз талэплэренэ ярашып китэрлек ритмик казанышлары бар иде. Менэ шуңа күрэ дэ төрки аруз — асылда гарэп-фарсы йогынтысы белэн үзебездэге жирлекнең бергэ кушылу нэтижэсе ул. Аруз гыйлеме һэм метрлар системасы — читтэн, э аңа жайлашу, тирэн тамырлар жибэрү мөмкинлеге тудырган жирлек — үзебездэн. Безнең карашыбыз менэ шундый.

Гали Халит та төрки поэзиядэ «аруз һэм төрки классик шигырь элементлары үзара керешкэннэр»[1] дигэн фикер эйтеп чыкты. Без бу фикер белэн бик телэп килешэбез. Төрки арузда ике башлангыч элементлары, чыннан да, очрашкан һэм үзара ярашкан. Мэсэлэн, гарэп-фарсы арузындагы кебек, борынгы төрки язма шигырьдэ дэ 11-11 үлчэме киң таралган булган һэм аруз йогынтысына элэккэн иң беренче төрки эсэрлэр нэкъ шул уртак үлчэмгэ салынганнар да. Шулай ук тоник башлангычлы шигырьлэрдэ эшлэнгэн ачык иҗеклэр системасы да аруздагы кыска иҗеклэр белэн типологик яктан охшаш булып чыккан һэм, кыскалык хасиятен саклаган хэлдэ, состав өлеш булып төрки арузны тудыруда катнашкан. Э басымнар? Тоник басымнар белэн музыкаль басымнар исэ, сыйфат ягыннан төрле булсалар да, урыннары ягыннан тэнгэл килгэннэр һэм беренчелэре икенчелэренең туууына да нэкъ менэ ачык иҗеклэр янынан гына үтүлэре белэн ярдэм иткэннэр.

Биредэ төрки арузның буш урында гына тумавы турында тагын да аерым мисаллар китереп булыр иде. Лэкин профессор Хатип Госманның алда күрсэтелгэн хезмэтлэрендэ классик шигырьнең милли жирлеге киң рэвештэ тикшерелгэнлектэн, мэсьэлэ инде шактый ачык дип уйлыйбыз. Һэрхэлдэ, монда шунсы бэхэссез: аруз систе-

[1] Гали Халит. Тукай и его современники. Казан. 1966 ел. 125 бит.

масы белән уртак тел табу өчен, аны үз итү, үзләштерү өчен, төрки халыкларның җирлеге, алшартлары булган, һәм бу табигый дә. Чөнки «теләсә нинди алымнар, чит йогынтыны үзләштерүләр, бигрәк тә шигырь өлкәсендә, эчке структур алшартлар булганда гына тормышка ашырыла ала» [1]. Бу — бик мөһим закончалык.

Инде законлы сорау туа: гарәп-фарсы йогынтысына эләкмәгән төбәкләрдә шигырь үсеше нинди юнәлештә барган соң? Бәлки, аларда ритм эволюциясе үзенчәлеклерәк, башкачарак дәвам иткәндер? Менә монда инде без, чыннан да, үзенчәлекле һәм шактый кызыклы фактлар белән очрашабыз. Тюркологиядә киң мәгълүм булганча, бу төбәкләрдә аруз системасы беркайчан да кулланылмаган. Аныклап әйткәндә, казакълар да, кыргызлар да һәм чувашлар да төрки арузны үзләштерүгә һәм үстерүгә катнашмаганнар. Менә шуңа күрә дә аларның классикларында — Абай Кунанбаевта, Сабит Мукановта, Аалы Токомбаевта, Константин Ивановта аруз өчен характерлы булган сүз атландырулар да, димәк, ике тартык алымы да юк. Аның каравы, аларның иҗатында борынгы төрки язма шигырьдән үк килә торган традицияләр ярылып ята. (Дөрес, бу төбәкләрдә язма поэзия шактый соң формалашканлыктан, тоник башлангычлы шигырьгә хас сыйфатлар аларда киң планда, бердәнбер система рәвешендә дәвам итә алмаган алуын. Ләкин төп ритмик принцип дәрәҗәсенә күтәрелмәсәләр дә, андый традицияләр шагыйрьләрнең үзенчәлекле алымына әверелгәннәр.) Казакълар, кыргызлар һәм чувашлар, гомумән, төрки казанышларның иң архаик катламнарын саклап калуда һәм бүгенге көнгә кадәр китереп җиткерүдә аеруча зур роль уйнаганнар. Шул исәптән, цезуралы строфаларда ачык иҗекләр һәм тоник басымнар системасын башкалардан киңрәк кулланучылар да — алар. Менә казакъларның борынгы авыз иҗаты хәзинәсеннән (а) һәм казакъ язма әдәбиятына нигез салучы Абай иҗатыннан (б) үрнәкләр:

а) Жама́н болса, жакы́н — жау,
Шаба́н болса, аты́ң — жау,
Шайнау́ болса, каты́н — жау,
Тартынша́к болса, түйе́ң — жау.
Тебеге́н болса, бие́ң — жау,
Күнде́ келсе, күйе́у — жау,
Жымыскы́ болса, жие́п — жау,
Те́л алмаса, улы́н — жау,
Ба́й алмаса, кызы́ң — жау.

б) Жайнага́н туың жыгы́лмай,
Жасканы́п жауда́н тыгы́лмай,
Жасаулы́ жауда́н буры́лмай,
Жау жүре́к жомарт кубы́лмай.
Кызары́п, сурланы́п,
Лүпелде́п жүреге́.
Өзгедән урланы́п,
Өзде-өзе́ кереге́.

Язма поэзияле төбәкләрдә исә мондый шигырьдә эшләнгән ачык (кыска) иҗекләр системасының төрки арузны тудыруда катнашканлыгын әйттек инде. Ул төбәкләрдә шулай ук тоник башлангычлы шигырьгә хас булган икенче мөһим сыйфат та — цезуралар системасы да — юкка чыкмаган, ә өлешчә үзалдына һәм өлешчә әлеге язма шигырь йогынтысында туган «саф» силлабик системада дәвам иткән. Борынгы язма шигырь төзелешенең әдәбият мәйданында күзгә күренеп кимүенең бер сәбәбе менә шушыларга кайтып калса, икенче сәбәбе, безнеңчә, аның аруз системасы белән бугалуыннан һәм кирәксез параллелизмнан аңлы рәвештә качу белән бәйләнгән. Метрик ачык иҗекләр арузның да асыл сыйфатына әверелгәнлектән, аларның параллель рәвештә тоник башлангычлы шигырьләрдә дәвам итүе, һичшиксез, уңайсызлыклар һәм урынсыз кабатлаулар тудырган булырга тиеш. Ике системаның шигырьләре бер үк урыннардан үтүче ачык иҗекләргә һәм бер үк үлчәүгә нигезләнгәндә, бу хәл хәзер дә нык сизелә. XII йөз шагыйре Әхмәт Ясәвинең хикмәтләрен бер төрле галимнәрнең аруз дип, икенчеләренең исә силлабик дип исәпләүләренең сәбәбе дә нәкъ менә шунда, ягъни ул шигырьләрнең тышкы яктан ике системага да охшаш булуында.

Билгеле, Әхмәт Ясәвидә силлабик характердагы ачык иҗекләр системасы даими сакланмаган шигырьләр дә җитәрлек. Чөнки ул, әлеге берәмлекләрнең арузда төп роль

[1] М. М. Гиршман. Стихотворная речь. Теория литературы. Мәскәү. 1963 ел. 322 бит.

уйный башлауларын аңлап, акрынлап алардан баш тартуга, ягъни буынара ачыклыкларын гына танучы «саф» силлабикага юнәлеш алган шагыйрьләрнең берсе буласа кирәк. Аннан бераз соңрак яшәгән Сөләйман Бакыргани шигырьләрендә дә без шушы ук хәлне күрәбез, тик аларда инде ачык иҗекләр системасы тагын да азая төшә. Ә менә Кол Галинең XIII йөз ядкаре булган «Кыйссаи Йосыф» поэмасында алар бөтенләй юкка чыгалар, чөнки бу вакытта буынара ачыклыкларына гына корылган силлабик система нигездә өлгереп җиткән була.

*Ләкин үз милләтләре формалашканда һәм әдәбиятларында романтик принцип активлашып киткән чорда, төрки шагыйрьләр борынгы төрки язма шигырь традицияләренә яңадан игътибар юнәлттеләр.* Чөнки бу чор шагыйрьләренә үз халкының үткәндәге әдәби һәм фольклор казанышларына әйләнеп карау, аларны кулланышка кертергә омтылу — аеруча хас сыйфат. Шул ук вакытта романтик рухлы шагыйрьләр һәртөрле иске канунчарны, нәрүгәләрне дә инкарь итеп чыгалар һәм көн үзгәгенә яңа, милли формалар тудыру таләбен куялар. Күпчелек шигырьләрен аруз белән язган Тукай ук инде «халыкның үз көе, үз вәзене, үз формасы илә язылганга», «халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятыбызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр» дип чыга (һәм М. Укмасый белән Сәгыйть Рәмиевнең силлабика белән язылган берәр әсәрен һәм үзенең «Милли моңнар»ын моңның иң беренче үрнәкләре итеп китерә). Сәгыйть Рәмиев үзе исә, шигырьләрен аруз белән чыгаручы С. Сүнчәләйне тәнкыйтьләп, шул ук чорда болай дип яза: «Шигыренез гаруз вәзененә туры килә, ләкин татар вәзененә бер дә килми», «зинһар, гарәпкә нәрүгегезне ташлагыз». Бу фактларда, билгеле, эстетик таләпләрнең борылыш моментлы да, «фагилатен»нәрдән генә чыгып арузны килмешәк дип кенә карау да гәүдәләнгән.

Менә ни өчен Дәрдмәнд белән Сәгыйть Рәмиев иҗатында ачык иҗекләре дә, цезуралары да һәм табигый басымнары да сакланган шигырь барлыкка килә. Дөресрәге, *татар шигырь төзелешенең бер тармагы яңадан силлабика белән тоник башлангыч синкретизмына нигезләнгән борынгы язма шигырьгә «әйләнеп кайта»*, Х. Госман сүзләре белән әйткәндә, «билгеле дәрәҗәдә борынгы традиция тергезелә». Ләкин бу инде йомык түгәрәк буенча гына үткәнне кабатлау түгел, ә спираль рәвешендә югарыдан үтә торган яңарыш. Аерым алганда, Дәрдмәнд белән С. Рәмиев тудырган шигырьнең метр-ритмнары баерак, басымнары куәтлерәк, интонацияләре тагын да табигыйрәк.

Әй, авыл, син | мéң шәһәрдән
Мéн кабат ямь | лé вә хуш,
Бéр кеше юк | бéр урамда
Нинди тын һәм | нинди буш.

Нинди иркен, | нинди рәхәт,
Нинди бар җир | гөл генә,
Синдә төн дә | юк, төнéң дә
Бéр болытлы | көн генә.

(«Авыл»)

Шáулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнéн кергән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөзәдер:
Юл бара ят йл карап...

Чыкты җилләр,
Купты дулкын —
Ил корабын җил сөрә!
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тартá безне җáн сорап?![1]

(«Кораб»)

Бу шигырьләрнең ритмы инде аруз рамкасын атлап чыккан: аларның график яктан рәмәл (— ◡ — —) метрына туры килүе акустик яктан бер строфада да расланмый (без моны эксперименталь юл белән тикшереп карадык). Һәм бу табигый дә. Ник дигәндә, аларның метрлары озын-кыска иҗекләр чиратлашуына түгел, ә бөтенләй башка берәмлекләргә нигезләнгән. Бу — әлеге шагыйрьләрнең башка байтак әсәрләренә дә хас закончалык.

---

[1] «Шаулый диңгез, чыкты җилләр, купты дулкын» кебек тезмәләрдә басымны беренче сүзнең тәүге иҗегенә төшереп уку да табигый булачак. Чөнки, эксперименталь тикшеренүләр күрсәтүенчә, бездә фонетик басымнар, ритмга һәм мәгънәгә буйсынып, сүзнең ахыргы иҗегеннән күчә дә алалар икән.

Дәрдмәнд белән С. Рәмиев тудырган шигырьне соңыннан башка шагыйрьләр әлеп-үстереп алып китә. Шуларның иң талантлысы һәм үзенчәлеклесе, әлбәттә, Һади Такташ булды. Бу очракта без шагыйрьнең, барыннан да элек, метрик ачык иҗекле шигырьләрен күздә тотабыз. Чөнки борынгы язма поэзия традицияләрен дә, тоник башлангычлы яңа шигырь интонациясен дә, шулай ук шагыйрьнең үз ритмнарын да бергә тупла-ган иң характерлы үрнәкләр — шулар. Менә «Җир уллары» әсәреннән бер мисал:

Йоклы́й алла, | йоклы́й җир-күк,
Ба́р табигать | йоклага́н,
Йоклага́н ай | да̄, бүген төн,
Ка́ф тавыннан | чы́кмаган,
Чы́кмаган...
Тик яна́р тау ⋮ ла́р бүген төн
Тукта̄мыйча | ӯт ата —
Ут ата ак ⋮ сы́л тетеннәр,
Бо́лганы́п ут ⋮ ла́р белән,
Нәкъ томан җир ⋮ гә ята...

Күренүенчә, өзектә ачык иҗекләр тәртибе бозылмыйча сакланган һәм күпчелеге янында тоник басымнар калкып чыккан. Ләкин алар инде урыннары буенча метрик түгел, ягъни һәр очракта да билгеле бер ноктаDARда гына килмәгәннәр, ә ачык иҗекләрнең я алдында, я артында калыкканнар. Ике урында хәтта ачык иҗекләрнең үзләренә төшкәннәр (монсы — ачык иҗекләрнең өченче функциясе). Ә менә басымнарның сан ягыннан метрик роле сакланган: һәр юлда (ялгаучы юлдан башка) алар икешәр булып килгәннәр. Шуның белән бергә, шагыйрь арузга хас булган сүз атландыру алымын да бик оста файдаланган. Әмма «күперләр» бер генә урында да табигый басымны бозмаган, ә киресенчә, тонны нәкъ цезура үтәсе урында сындырып, сүз басымын тагын да көчәйтү функциясендә килгән (тау ⋮ ла́р, ак ⋮ сы́л, ут ⋮ ла́р, җир ⋮ гә). Бу үзенчәлекле чаралар шигырьнең тониклыгын тагын да көчәйтәләр, тоник башлангычлы төзелештән аны чын тониклыкка якынайталар.

Такташны үзенчәлекле дәвам итүче Илдар Юзеев иҗатында да без шушы ук закончалыкларны очратабыз. Ярсулы хисләрен көчле интонация белән яңгыратырга кирәк булдымы, ул шундук тоник басымлы шигырьгә күчеп китә, аның борынгы формасын да, хәзерге мөмкинлекләрен дә оста итеп куллана. Менә «Тынлык белән сөйләшү» поэмасыннан фашистларның вәхшилегенә карата шагыйрьнең нәфрәтен чагылдырган юллар һәм җир-ана монологы:

Үтте тира́н, китте тира́н,
Яндыры́п, таптап, тала́п,
Бе́р сынык икмәк сорыйлар
Сабыйла́р күзгә карап.
Миллиа́рд ел яшәп

Тынгылы́к күрмәгән
Әнкәге́м чакыра́.
Ак болыт шикелле́
Чәчләре́м хакына...
Дәшегез, анала́р,
Уянсы́н балала́р.

Инде нәтиҗә чыгарырга мөмкин. Димәк, татар шигырьләрен сүз аралы (цезуралы) һәм ачык иҗекле төрләргә генә бүлеп йөртү җитми икән. Чөнки, беренчедән, алар үзара кушылган хәлдә дә очрыйлар, ягъни бу ике төр кысасыннан читкә чыгалар. Икенчедән,— монсы инде аеруча мөһим — ачык иҗекле шигырьләр үзләре дә асылда ике төргә бүленә: төрки арузына һәм тоник башлангычлы шигырьгә. Димәк, ачык иҗекләр катнашу гына әле М. Гафури һәм Г. Тукай әсәрләре белән С. Рәмиев һәм Һ. Такташ шигырьләрен бер үк система дип карарга нигез була алмый.

Икенче мөһим нәтиҗә шул: тониклык күренеше төрки халыкларның, шул исәптән татарларның, шигыренә ят сыйфат түгел икән. Иң беренче язма шигырь үк инде тоник башлангычлы булган һәм хәзерге поэзиядә дә мондый шигырь төзелеше билгеле дәрәҗәдә бар. Ләкин, безнеңчә, аның мөмкинлекләре әле ныклап өйрәнүне сорый, шигырь төзелеше үзе исә аңлы рәвештә һәм тагын да киңрәк куллануга мохтаҗ.

# ЧИТЛЕКТӘГЕ КОШ БӘХЕТЛЕМЕ?...

Туфан Миңнуллин профессиясе буенча артист иде. Ләкин театрда озак эшләмәде, әдәбиятка күчте. Баштарак кыска-кыска көлке хикәяләр һәм кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре язды. Шуннан күп тә үтмәде, олы сәхнәгә берьюлы ике әсәр чыгарды. Беренче әсәрләре белән үк яшь драматург тамашачының ихтирамын казанды, театр җәмәгатьчелегенең һәм тәнкыйтьнең игътибарын үзенә юнәлтте. 1968 елда Татар дәүләт академия театрында «Миләүшәнең туган көне», ә Татар дәүләт күчмә театрында «Нигез ташлары» исемле пьесалары куелгач, Туфан Миңнуллин өлгергән драматург буларак телгә алына башлады. Инде менә аның «Бәхетле кияү» (1969 ел) һәм «Күрше кызы» (1970 ел) исемле җыентыклары да дөнья күрде. Соңгы көннәрдә авторның тагын ике яңа әсәре сәхнәгә куелды. «Диләфрүзгә дүрт кияү» Әлмәт театрында, ә «Ир-егетләр» пьесасы Академия театрында уңыш белән бара.

Туфан Миңнуллин тормышның кайсы өлкәләрен һәм нинди геройларны ятатып сурәтли? Драматург буларак, ул укучыга һәм тамашачыга нинди яңалык алып килә? Югарыда әйтеп үтелгән җыентыкларга таянып, шул сорауларның кайберләренә генә булса да җавап бирергә тырышып карыйк.

Баштан ук шул кадәресен искәртеп узасы килә: Туфан Миңнуллин — сәхнә кануннарын шактый тирән үзләштергән, аның нечкәлекләрен сизгер тоя торган драматург. Шуна күрә аның әсәрләрендә сәхнә законнарына хилаф килгән нәрсәләр юк диярлек. Ә драма әсәренең үзенчәлекләре күп һәм аларның барысы да үзләренә зур игътибар таләп итә. Мәсәлән, шундый үзенчәлекләрдән берсенә конкрет тукталып узыйк. Сүз әлеге персонаж репликаларының җегәрлекле, образларның эчке һәм тышкы мәгънәсен ача алырлык булулары, диалогларның җанлылыгы, җыйнап әйткәндә, әсәрнең тел-сурәтләү ягыннан байлыгы, тегәл эшләнгән булуы турында бара. Бу — гаять әһәмиятле мәсьәлә, чөнки драматургның төп коралы — персонаж теле. Кайчак драматург үзара бәрелешкә керергә тиешле персонажларны да дөрес билгели, аның укучыга әйтергә теләгән фикере дә булмый түгел. Ләкин, тулаем алганда, пьеса да, андагы образлар да ышандырып бетерми, вакыйгалар ясалма чыга. Ни өчен? Чөнки драматургның тел-сурәтләү чараларын куллануда осталыгы җитеп бетми, геройның нәкъ менә шул моментта, шул хәлдә нәрсә эшләвен психологик нигезләүгә, нәрсә һәм ничек сөйләргә тиешлегенә ул әһәмият биреп җиткерми. Әсәрдәге хәрәкәтнең тыгызлыгына драматург тел чаралары ярдәмендә дә ирешә. Икенче төрле итеп әйтсәк, киеренке хәрәкәт тудыруда, вакыйгаларның тиз алышынуында һәм образларның җанлылыгына ирешүдә репликалар һәм диалоглар гаять әһәмиятле роль уйныйлар. Моңа Т. Миңнуллин зур игътибар бирә, һәм бу бик күңелле факт.

Яшь авторның икенче бер отышлы ягы шунда, ул вакыйга барышында образны көтелмәгәнчә, ләкин характер табигыйлеген һич тә бозмастан ача белә. Шуның белән аны тулырак һәм кызыклырак итә. Бу да драматург өчен зур нәрсә. Сәхнәдәге вакыйга-хәрәкәт алдан билгеләнгән схематик сызык буенча гына барса, тамашачы мондый спектакльләрне сүлпән кабул итә. Фикерне тулырак җиткерү өчен, драматург ситуацияне көтелмәгәнчәрәк, яңача бирергә тиеш Шул вакытта драма карау өчен кызыклы була, автор да төп теләгенә тулырак ирешә. Әлбәттә, мондый «көтелмәгәнлек» драматик характерның табигатеннән килеп чыгарга, андый ситуацияләрдә персонажның характеры тагын да баерга, үсәргә, эчке дөньясы тулырак ачылырга тиеш. Туфан Миңнуллин шул хакыйкатьне аңлау-үзләштерү юнәлешендә әсәрдән әсәргә үсә бара.

Инде саный башлаганбыз икән, дәвам иттерик. Туфан Миңнуллин драматургик материалны тормышның төрле өлкәләреннән эзли, төрле-төрле темалар күтәрергә омтыла. Образлар системасына килгәндә исә ул җылы, йомшак юмор белән өртелгән уңай герой образларын сурәтләүдә үзен иркенрәк сизә. Шундый геройлар аңа җиңелрәк бирелә. Һәрхәлдә, бу аның комедияләрендә шулай. Автор нинди дә булса хикмәтле бер ягы булган хезмәт кешесен, аның юмористик образын ятатып һәм җиренә җиткереп сурәтли. Ләкин бу әле Туфан Миңнуллин драматик характердагы образлар тудыра белми дигән сүз түгел. Беренче җыентыгы белән үзен асылда комедия остасы итеп таныткан автор икенче җыентыгында драма өлкәсендә дә зур мөмкинлекләре барлыгын күрсәтте.

Жыентыкларга кергән әсәрләр арасында проблемасының әһәмияте белән дә, күләме ягыннан да «Миләүшәнең туган көне» драмасы аерылып тора. Монда драматург әсәрләренең күпчелеге өчен характерлы булган актуаль проблема алынган һәм ул шактый уңышлы хәл ителгән. «Кеше кешедән, дус-ишләреннән аерым хәлдә, коллективтан читтә бәхетле була алмый!» Драматург уздыра торган төп фикер менә шул.

Драмада сурәтләнгән хәлләр вакыт аралыгы белән нык чикләнгән. Вакыйга Миләүшә исемле музыкант ханымга 25 яшь тулган кичтә, ике-өч сәгать вакыт эчендә бара. Геройлар саны да күп түгел, уенга 8 кеше катнаша. Дөрес, тугызынчысы да бар (Нурислам), ләкин аның вакыйгаларга катнашы юк дәрәҗәсендә.

...Рәссам Шәһит элек бергә укыган, дус булып йөргән иптәшләреннән йөз чөерә башлаган. Ул хатыны Миләүшәне дә алар белән аралашудан тыярга тырыша. Хәзер ул күбрәк дәрәҗәле, файдалары тиярдәй кешеләр белән йөрешә. Өстәвенә, Шәһит масая, гади кешеләрне санга сукмый, һавалана да башлаган икән. Миләүшәнең туган көненә багышланган мәҗлес барышында өүвәлге дуслар арасында шушы хакта кайнар бәхәс кубып китә. Бу бәхәскә бөтен персонажлар катнаша һәм һәр кеше әлеге мәсьәләләр турында үз карашын белгертә. Иң әһәмиятлесе шул: бәхәстә социалистик җәмгыятьнең төп, асыл принципларына нигезләнгән, коллективизм интересларына таянган караш җиңеп чыга. Моңарчы Шәһит урнаштырган тәртипләргә сүзсез генә буйсынып яшәгән, шуларга күнегеп барган Миләүшә дә үз хәлен ачык аңлый башлый. «Кешеләрсез яши алмыйм,— ди ул соңыннан.— Кирәкми миңа алтын читлек, читлектәге кош бәхете кирәкми миңа».

Бу фикер әсәрдәге ике образ ярдәмендә тагын да көчәйтелә төшә. Сүз аерым бер җылылык белән сурәтләнгән Әһлиулла һәм Харис образлары турында бара. Драмага бүгенге тормыш сулышын өрүдә, совет кешеләрендәге уңай сыйфатларны калку күрсәтүдә, кешеләр арасындагы эчкерсез мөнәсәбәтләрне олылауда бу образларның роле аеруча зур. Харис баштарак кызы һәм кияве белән горурлана, хәтта алар белән мактана да. Әмма инде кияве Шәһитнең, аңа ияреп, кызы Миләүшәнең фронтта утны-суны бергә кичкән дусты Әһлиуллага кырын карауларын сизгәч, ул түзми, хакыйкатьне турыдан-туры, ачык итеп әйтеп бирә. Харис хезмәт турында, бигрәк тә игенче хезмәте турында аек фикер йөртүче, «укыган» яшьләрнең йомшак якларын тиз сизеп алып, алар хакында уйлаганнарын турыдан ярып салучы, намуссызлыкны күреп чын күңеленнән ачулана һәм үпкәли белүче акыллы, олы йөрәкле һәм җанлы кеше булып күз алдына баса.

Безнең күп кенә драматурглардан аермалы буларак, Туфан Миңнуллин характерлар иҗат итүдә ак һәм кара буяулар белән генә эш итми. Әсәрдәге Шәһит, мәсәлән, бөтенләй юлдан язган, явыз кеше итеп кенә тасвирланмый, аның киләчәктә үсеп китәрдәй уңай сыйфатлары да бар. Нурислам һәм Фәһим кебек геройлар да йөз проценты белән уңай түгелләр. Иң әһәмиятлесе — алар җанлы кешеләр, аларның олы юлга алып чыга торган үз сукмаклары бар, үз теләк-омтылышлары, инанган идеаллары бар. Мисалга укучының һәм тамашачының мәхәббәтен яулап алган Әһлиулла образын алыйк. Сугыш елларында зур батырлыклар эшләгән бу инвалид агай үзенең гаҗәеп тыйнаклыгы белән сокландыра. Ләкин сугыштан соң ул, ничектер, артык мескен хәлгә төшкән һәм шуның белән хәтта Харисның да ачуын китерә. Әсәрдәге вакыйгалар барышында Әһлиулла кешенең беркайчан да үз горурлыгын җуймаска тиешлеген төшенә башлый. Шуның белән ул укучы һәм тамашачының симпатиясен тагын да ныграк яулый.

Бүгенге көн геройларын сәхнәдә күрсәтергә хыялланмаган драматург юктыр, билгеле. Бу омтылыш Т. Миңнуллинны да иҗади эзләнүләргә рухландыра. Ләкин уңай герой образларын җанландыруда автор һәрвакытта да буяуларны дөрес үк салып бетерә алмый. Моның мисалы — «Күрше кызы» дип исемләнгән драма, андагы баш геройлардан Хәлим образы. Пьесаның үзәгенә хезмәткә мөнәсәбәт мәсьәләсе куелган. Уңай геройларны бизәүче төп сыйфат әнә шул.

Зоотехник кыз Әминә исә хезмәтне яратмый, үз профессиясенә чирканып карый. Аның бар хыялы шәп кияүгә чыгып ир җилкәсендә рәхәт яшәүгә, ягъни кем ярдәме белән булса да үзенә алтын читлек коруга кайтып кала. Аңардагы бу нәрсәне кичә генә унны тәмамлаган Фания дә, башкалар да тиз күреп алалар. Тик әле вузда укыганда ук Әминәне ярата башлаган Хәлим генә сөйгәненең бу сыйфатларын күрми, күрсә дә, күрмәмешкә салына. Әйе, мәхәббәт кешене сукырайтырга мөмкин. Әмма шул ук мәхәббәт кешене югары күтәрә, аңа көч тә өсти. Чын күңелдән яраткан кеше сөйгәне өчен көрәшергә тиеш. Драматург та мәсьәләне, бәлкем, шулай куярга тырышкандыр? Ләкин бу яктан Хәлим без теләгәнчә ачылып бетми. Күп кенә мәсьәләләргә аек карашы булган, намуслы һәм акыллы бу егет соңга таба нигәдер җебеп, югалып кала. Сөйгән кызының күңелендәге бушлыкны, хезмәткә һәм үзенә мөнәсәбәтне ул һәркемнән дә соңгарак калып аңлый. Дөрес, пьесада Фания кебек кызыклы гына эшләнгән образлар бар. Ләкин, гомумән алганда, җыентыклардагы пьесалар арасында «Күрше кызы» драмасы йомшаграк эшләнүе белән аерылып тора. Мондагы персонажларның барысына да Т. Миңнуллин әсәрләренә хас булган характерлар ачыклыгы һәм бөтенлеге җитеп бетми. Авторның әйтергә теләгән фикере ачык түгел. Драматургның бу әсәре, ничектер, әдәби иҗатының башлангыч чорында язылган кебек бер тәэсир калдыра. Куанычка каршы, калган пьесаларда без мондый кимчелекләрне очратмыйбыз.

Пьеса характердан башлана, диләр. Хак сүз. Т. Миңнуллин әсәрләрен укыганда шуңар тагын да бер мәртәбә ышанасың.

Дөрес, ул иҗат иткән характерларның төрлесе төрле зурлыкта, төрле «калибрда». Мәсәлән, «Миләүшәнең туган көне» әсәрендәге персонажлар һәм аларга салынган идея йөге белән «Бәхетле кияү» пьесасындагы образлар һәм алар ярдәмендә әйтелгән фикер һич тә бердәй түгел. Ләкин шунысы бик әһәмиятле: Туфан Миңнуллинның күпчелек пьесаларында образлар җентекләп эшләнгән, аларның күбесе үзенчәлекле характер дәрәҗәсенә җиткерелгән. Автор характер бөтенлегенә ирешүнең әһәмиятен тирән аңлап эш итә, шул бөтенлекне тудыруда вак кына штрихлардан да уңышлы файдалана белә. Менә, мәсәлән, «Чакыру билеты» дип аталган скетч. Гаять төгәл һәм оста язылган әсәр бу. Үзе күләме ягыннан кечкенә генә. Шул кечкенә әсәрдә дә тулы канлы өч-дүрт образ тудырылган.

Скетчта алынган вакыйга гади, хәтта артык гади. Завод директоры Аптекашевка тантаналы җыелышка чакыру кәгазе килмәгән. Шушы нәрсә өйнең астын-өскә китерә. Дөресрәге, бу хәлдән Мәрфуга ханымның коты алына. Ничек инде, иренең замына билет җибәргәннәр, ә хуҗаның үзенә юк?!! Очраклы нәрсәме бу?.. Әнисенең шикләнүләрен кызлары да уртаклаша. Хуҗаның үзен дә эчтән корт кимерә башлый. Бары кияүләре Рафаэль генә сабырлык саклый. Шундый вак-төяктән дә «директорлык урынына куркыныч яный» дигән «зур мәгънә» чыгарган әбисе һәм шул коткыга бирелгән бабасы аңар көлке тоела. Ул аларга моның мәгънәсез бер шик булуын аңлатырга тырыша. Ләкин юкка гына. Аның бу сүзләре янган утка бензин сипкәндәй тәэсир ясый. Моңарчы тату гына яшәгән кешеләр арасында каты гына әйткәләшүләр булып ала. Барыннан да ныграк Рафаэльгә эләгә. Бу фатирга аның хакы юклыгы, йортка гына кертелгән кеше икәнлеге искә төшерелә, башка гөнаһлары телгә алына... Дөрес, ахырдан һәммәсе ачыклана. Билет килгән булган, ләкин ниндидер бер журнал арасында кысылып, күзгә чалынмый гына яткан икән. Барысы да иске эзгә төшә сыман, ләкин бу беренче карашка гына шулай. Бу гаилә тормышында моннан соң инде элекке мөнәсәбәтләр дәвам итә алмаячак. Кабатлап әйтәм, оста ювелирларча нечкәлек белән эшләнгән пьеса! Шуны ук «Комиссия», «Бәхетле кияү», «Бакча каравылчысы» комедияләре турында да әйтергә мөмкин.

Алдарак мин Туфан Миңнуллин җылы юмор белән өртелгән уңай герой образларын яратып сурәтли дигән идем. Мондый образлар итеп, күбесенчә, гади хезмәт кешеләре алына. Ниндидер, гадәттән тыш дип әйтикме, бер хәл килеп чыга да бу геройлар үзләрендәге күркәм яклары белән ялтырап алалар, нәзе җанлы, кирәк икән усал һәм хәтта «кире беткән» кешеләр буларак гәүдәләнәләр. Вакыйгаларда һәм ситуацияләрдә еш кына чак-чак арттырып җибәрүләр дә очрый. Шул шартлы вакыйгаларның сәхнә законнары мөмкинлек биргән күләмдә нәкъ менә «чак-чак» булуы, аларның асылда реаль җирлектән аерылмавы Т. Миңнуллин каләменең көчле ягын тәшкил итә. Шартлы хәлләргә куелган геройларның реалистик җанына һич тә зыян ясамыйча, бай характерлар иҗат итү осталыгы драматург иҗатының киләчәктә зур вәгъдәләр өмет иттерә торган бер юнәлеше. Менә, мәсәлән, «Бәхетле кияү» комедиясе. Яңа гына өйләнешкән ике яшь авылга ялга кайтып төшәләр. Кәләшнең сүзләренә ышансаң, аларның авылларында халык бик тә кунакчыл икән, кияүне монда өрмәгән җиргә дә утыртмаячаклар, янәсе. Ләкин киресенчә булып чыга: кунакка кайткан кияүне бар дип тә белгән кеше күренми. Авыл кешеләре түгел, хәтта әбисе белән бабасы да аңар юньләп игътибар итмиләр. Барысы да каядыр ашыга, нәрсәгәдер пошына. Кияү башына таяк белән орган кеше хәлендә, хатын да аптырап калган. Төнлә яңгыр явып узгач кына барысы да аңлашыла.

Чыннан да, Харис карт белән Нәфига карчыкның гомердә беренче тапкыр кунакка кайткан бердәнбер кияүләрен бар дип тә белмичә тыз-быз чабышып йөрүләре, беренче карашка, табигый дә түгел кебек. Моны яңгыр яумауга пошынудан, игеннәрнең көеп калу куркынычы туудан дип аңлату да җитеп бетмәс иде. Кызны да, кияүне дә иска-санга сукмыйча чабышып йөрүдән яңгыр явамы инде, югыйсә!? Әмма драматург вакыйганы шундый итеп кора һәм шундый җанлы образлар тудыра ки, мондый шартлылык, хәтта гайре табигыйлек укучы һәм тамашачыны кызыксындыруга, образларның күркәм якларын кабарынкы итеп күрсәтүгә ярдәм итә. Нәтиҗәдә гаять якты әсәр, авыл кешеләренең кунакчыллыгын, эш өчен янып-көюләрен, игенчеләрнең гүзәл сыйфатларын үзенчәлекле итеп, кабатланмас төстә сурәтләгән пьеса барлыкка килгән.

Яки менә «Бакча каравылчысы» исемле комедия. Монда да шартлы хәлләр һәм ясалма моментлар күп. Мәсәлән, корал тота белмәгән Хәсбиҗамал әби, атмый торган мылтык белән куркытып, «гринадирдай» ике ирне каравыл алачыгына ябып куя. Һәм иң кызыгы шунда, әби аларны бик тә яхшы таный: берсе — председатель, икенчесе — бригадир. Шулай була торып та, бары тик Әхмәтханга биргән вәгъдәсенә тугрылык саклап кына бу эшне эшли. Шундый шартлы хәлләр ярдәмендә бригадир Галимулланың ярамаган эше фаш ителә, Әхмәтхан һәм Мәдинә, Хәсбиҗамал карчык һәм председатель Нәҗипләрнең мөлаем образлары тудырыла.

Драматург характер иҗат итүдә көтелмәгән борылышлардан оста файдалана, дидек. Шуны Хәсбиҗамал әби образында да күрергә мөмкин. Әле генә Әхмәтханга «минем кәҗәм алмага тими ул, акыллы хайван» дип мактанган карчык, ике-өч минут та үтми, инде шул сүзләрен онытып, «алмага ялашкангә килә ул, мөртәт», дип сөйләнә. Үзенең сүз-фикерендә дә, эш-хәрәкәтендә дә ул нәкъ менә картларча, кискен. Әхмәтханга биргән сүзен тотып, председательләрне «кычкыртып» ябып куйган карчык кәҗәсенең тавышын ишетә. Ишетә дә,

«кәҗәмне ятимә иттереп капка төбендә интектерер хәлем юк» дип, мылтыгын аяк астына ташлап кайтып китә. Үзе әле генә ябып куйган кешеләрнең таңга кадәр бикле килеш утырачагын уйлап та бирми. Болар бар да табигый чыга, характер бөтенлегенә зыян ясамый гына түгел, аны тулыландыра, ситуацияне кызыклы һәм җанлы итә.

Җыйнап әйткәндә, күпчелек әсәрләрендә драматург Туфан Миңнуллин кызыклы һәм мәгънәле тормышны хезмәт ияләре арасында, хаклык һәм туграылык юлында табарга өнди. Димәк, олы бәхетне кайдан эзләргә икәнен күрсәтә. Моның өчен ул үз файдасына гына яшәргә омтылучы, бүтәннәр хисабына бәхетле булырга тырышучыларны фаш итә, аларга каршы яшәүнең һәм көрәшнең бүтән принципларын куя. Димәк, драматург ахыр чиктә зур эшләргә өнди, олы язмышлар белән кызыксынырга, җитди эшләр башкарырга чакыра. Инде Т. Миңнуллинга үз әсәрләрендә шул эшләрне башкаручыларны, шул олы язмышларның хуҗаларын үзләрен уртага куеп сурәтли башларга кирәк. Моңар аның сәләте җитәрлек күренә.

**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН.**

# КИЧКЕ УЙЛАР

Әдәбиятка төрле кеше төрлечә килә. Берәүләр күләмле ике-өч әсәр, я булмаса кечерәк бер җыентык чыгаралар да язучы булып китәләр. Икенчеләренә, исемнәре кеше теленә кергәнче, байтак тир түгәргә, азапланырга туры килә. Яшь прозаик Рәфкать Кәрамиев шул соңгыларына — «тир түгүчеләр» рәтенә керсә кирәк. Республика газета-журналларында аның беренче хикәяләре моннан ун еллар элек күренә башлаган иде. Тик аларны әллә ни мактаучы, күтәреп алучы гына булмады. Хикәяләр ярыйсы ук төссезләр, йомшаклар иде. Шулай да автор, өметсезлеккә бирелеп, югалып калмады. Эшче халкына хас тырышлык белән гел яза, өйрәнә торды. Акрынлап аның каләме шомара, осталыгы арта барды.

Болай эшчеләр арасыннан чыккан прозаик саналса да, аның иҗатында заводфабрика тормышыннан алып язылган әсәрләр хәзергә күренми диярлек. Бу яңа җыентыгына[1] кергән әйберләренең дә күбесе колхоз тормышына, бүгенге авыл кешеләренә, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләүгә багышланган.

Җыентык «Кичке уйлар» исемле повесть белән ачыла. Күләме белән артык зур булмаган шушы әсәрдә шактый актуаль һәм җитди мәсьәләләр күтәрелә, истә калырлык образлар сурәтләнә. Үз әсәрен кызыксынып һәм мавыгып укырлык итеп эшләү өчен дә Рәфкать Кәрамиев күп көч куйган.

...Кич. Кояш әкрен генә таулар артына тәгәри. Шәфәкъ куе кызыл төскә кергән. Күк йөзендә берничә кара болыт кисәге эселенеп тора. Балта остасы Шакир, көн сөен өйалды баскычына чыга да, терсәкләрен тез өстенә куеп, зур куллары белән түбән иелгән башын тотып, шул болытларга карап утыра. Алар моннан бер атна элек булып узган яшенле яңгыр турында искәртәләр. Алар Шакирның йөрәген әрнетеп, күңеленә шом салып торалар. Ул болыт кисәкләре бер заман, әлбәттә, таралырлар, югалырлар. Тик тол ир йөрәгендәге кайгы гына яшенле яңгыр болыты кебек таралырлык, үтеп китәрлек түгел...

Бу юллар шунда ук безнең игътибарыбызны биләп ала. Бер атна элек нинди хәвефле вакыйгалар булган? Яшь ир Шакир башына бер дә таралмастай нинди кайгы төшкән икән?.. Укучыларда шундый кызыксыну уятканнан соң гына, автор әсәрен җайлап сүтәргә керешә. Безне повестьтагы геройлар, алар башыннан узган гыйбрәтле хәлләр белән таныштыра башлый.

Ә ул хәлләр моннан унөч ел элек башланган икән.

Шакир исемле шахтер егет Кизеледән туган авылына кунакка кайта. Йөргән егетеннән тартып алып, авылның иң чибәр кызына өйләнә. Шаулатып, бөтен кешене шаккатырып зур туй ясый. Һәм хатынының әнисе Шәмсеҗиһан түти читкә китәргә ризалык бирмәгәнгә генә, Галия белән авылда торып кала. Нинди эшкә тотынса, шуңа кулы ятып торган тырыш егет бирердә дә югалып калмый. Колач җитмәслек нарат бүрәнәләрдән менә дигән йорт салып кора, каралты-кура торгыза, мал-туар булдыра. Һәммәсе житеш, булган кадәренә шөкер итеп, рәхәтләнеп яши бир. Тик һәрвакыт кешенекеннән арттырып эшләргә ярата торган Шакирга болар гына җитми. Аңа әле җиңел машина да кирәк икән, машинаның да теләсә-нинди тегенди-мондые гына түгел, иң шәбе, «Волга» дигәне булсын. Һәм ул тырышып-тырмашып машиналык акча җыярга тотына. Клубка чыгулар, кино караулар бетә, кием-салым, өйгә җиһаз алу кысыла, кунак чакыру, кунакка йөрүләргә дә чик куела. Шуның аркасында ул яраткан хатынының туганнары белән бозылыша, колхоз җитәкчеләре белән әчелешле булып бетә... Дөрес, тырыша, иза чигә торгач, барыбер үз дигәнен итә. Акчасын да туплый, каядыр барып әр-яңа «Волга»сын да алып кайта. Тик ни файда: Шакир гаиләсен интектереп акча җыйган арада, өйдәге хәлгә түзә алмый, хатыны Галия авырый башлый. Күпмедер вакыт урын өстендә ятканнан соң үлеп үк китә. Аксыл төстәге яңа «Волга»сы, берсеннән-берсе кечкенә дүрт баласы белән Шакир берүзе торып кала.

Күпме тырышты, күпме көч түкте Шакир. Ә менә ничек килеп чыкты. Машина

[1] Р. Кәрамиев. Кичке уйлар. Повесть һәм хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.

бар, Галия юк. Байлык бар, шатлык юк. Һәммәсе җитеш, куаныч юк. Әнә шуңа да, көн дә өйалдына чыгып, күктәге кара болытларга карап утыра икән ул. Бик кыскартып, артык гадиләштереп әйткәндә, повестьта шул хәлләр турында сөйләнә. Үзенең бөтен пафосы, бөтен яңгырашы белән ул кешеләр аңындагы шәхси милекчелек калдыкларына, комсызлыкка каршы юнәлдерелгән.

Билгеле, әсәрнең бөтен урыннары да бер дәрәҗәдә эшләнмәгән. Анда очы-очка ялганмаган эпизодлар, ышандырмый торган вакыйгалар очрый. Образларның эшләнешенә карата да искәрмәләр ясыйсы килә. Аерым геройларга характер бөтенлеге, эзлеклелек җитми. Автор бигрәк тә үз геройларын үсештә биргәндә, аларның бер халәттән икенче халәткә күчү моментларын сурәтләгәндә көчсезлек күрсәтә. Андый нәрсә Галия образында аеруча нык сизелә. Тел-теш тидерерлек урыннар Шакир образында да калган. Ахырга таба автор аны шул кадәр каралтып ташлый, авылның иң әйбәт, иң чибәр кызы Галия бу чаклы әшәке кешегә кияүгә чыгарга ничек риза булды икән дип аптырый ук башлыйсың. Әсәргә Шакир образын ачу өчен кертелгән кайбер эпизодлар да ышандырып бетерми. Шакирның бер төн каравылга бармый калуы була, Гарифҗан карт белән Галия шунда булуга карамастан, ферма сарыкларын бүре буып чыга. Килгән зыянны, ни өчендер, Шакирдан түләтәләр. Иптәше Гарифҗан карт ни караган? Нигә аннан да түләтмиләр? Аңлашылмый. Яисә әсәрдәге төп вакыйганы — Шакирның «Волга» дип җенләнеп йөрүләрен алыйк. Аның белән дә күңел ризалашып бетми. Авыл җирендә яшәгән кешенең җан ачысы белән машина өчен тырышып йөрүе шулай ук гайре табигыйрәк хәл. Кешенең комсызлыгын күрсәтергә моннан кулайрак нәрсәләр беткәнмени?!.

Әзли башласаң, әсәрдән башка характердагы кимчелекләр дә табарга булыр иде. Әмма ни генә булмасын, тиешенчә эшләнеп җитмәгән урыннар никадәр генә күп күренмәсен, алар повесть турындагы гомуми уңай фикерне юкка чыгара алмыйлар. Яшь прозаик актуаль мәсьәлә күтәргән, сәнгать чаралары ярдәмендә аны шактый уңышлы хәл иткән. Әсәр укыла, ул зур тәэсир көченә ия. Һәм аның төп кыйммәте шунда.

«Кичке уйлар»дан тыш, җыентыкка тагын алты хикәя кертелгән. Аларның төрлесе төрле характердарак. Арада агач тел белән язылган йомшаклары, тапталган темага багышланганнары, бернинди яңалык өстәми торганнары очрый («Кунак», «Кушаматлы Әбүзәр» һ. б.). Матурлары, тормышчан һәм җылы язылганнары бар. Минем үземә, мәсәлән, «Кайтмады» һәм «Шофер хатыны» дигәннәре күбрәк ошады. Беренчесе шәһәр тормышыннан алып язылган. Хикәя җиңел табигатьле Асия исемле бер хатын турында. Асия тормышта күңел ачып, мәшәкатьсез генә яшәргә уйлый. Аның хәтта бердәнбер улын багарга да вакыты калмый. Ләкин ахырдан хатынга шуларның һәммәсе өчен бик нык үкенергә туры килә... Өстәнрәк, ашык-пошыграк эшләнсә дә, хикәя болай ярыйсы гына тәэсир калдыра. «Шофер хатыны» яңа өйләнешкән яшьләр, алар арасындагы җылы мөнәсәбәтләр, самими хисләр турында. Гади һәм әйбәт кешеләр турындагы бу хикәя үзгә бер җылылык һәм ярату белән язылган.

«Кичке уйлар» — Рәфкать Кәрамиевның икенче китабы. Байтак кимчелекләре, җитешсез яклары булуга карамастан, ул авторның тагын да үсүе, бер адым алга китүе турында сөйли. Безнең арага тормышның үз эченнән яшь бер прозаик килә. Күңелле күренеш бу.

**Ф. МИННУЛЛИН.**

# КЕШЕ ҺӘМ ЯЗ

Галимҗан Латыйп туып-үскән, ул егет булган якларда мәһабәт Урал кыялары башта яссы тауларга, ә инде Чакмагыш тирәләрендә тәбәнәк кенә сыртларга, калкулыкларга әверелә. Базы суы ярларында, чәчләрен суда чайкап, куе шомыртлар, бөдрә таллар үсә. Ә «Чияле тау» чагылларында, сөйгәннәре белән очрашырга әзерләнгән кызлар шикелле, ак күлмәкләрен киеп, чуклы шәлләрен ябынган каеннар серләшеп утыра. Табигать үзе шагыйрьләр, рәссамнар үстерә, дип әйтәләр. Бәлки шулайдыр, бәлки түгелдер дә... Ләкин тыйнак матурлыгы белән бер күрүдә үк үзенә җәлеп итәрлек Базы буйлары шигъри йөрәкле кешеләрне байтак тудырган. Хәзер «Герой» исемле бер колхоз авылларыннан дүрт әдип чыккан: Галимҗан Латыйп, Гыйлемдар Рамазанов, Нур Гайсин, Вазыйх Исхаков.

—Моннан кырык елга якын элек күперелеп торган кара бөдрә чәчле, яшьлек дәрте ташып торган егет, аркасына зур арыш капчыгы асып, Дүртөйлә пристанена килә. Шуннан читләре чигелгән кулъяулыгына төрелгән барлы-юклы байлыгын җитткат саный да, акчарлактай ак пароходка утырып, Тукай нуры белән балкыган, Сәйдәш моңы белән илһамланган Казанга юл тота. Казан аны студент итә, Казан аны гражданин һәм солдат итә, Казан аны шагыйрь итә.

Галимҗан Латыйп утыз биш ел эчендә (аның беренче шигыре 1935 елда «Коммуна» газетасында басыла) егермеләп шигъри китап чыгарган автор. Бу — зур хезмәт. Хәзер менә минем өстәлемдә 99 гына битле яңа шигъри җыентык ята. Тышлыгына кызыл хәрефләр белән «Кызыл Яр» дип язылган. Ә өстәрәк — атакага ташланган җайдаклар сурәте... Мин аның күңелгә ныграк сеңгән, йөрәкне ешрак тибәргә

мәҗбүр иткән юлларын күңел дәфтәремә күчерә-күчерә укыдым.

— Буразналар исеннән дә
Тәмләрәк ис бар микән,— дип
Сөйләгән ул,— бу дөньяда .
Кайчан гына карасаң да,
Уйлары да, тәпие дә
Булган аның буразнада.

Бала чакларымны хәтерләдем, әле генә сабан төрене актарып киткән җылы буразнадан ялан аяк йөгерәсем килеп китте. Күкләргә күтәрелеп карадым — төпсез зәңгәрлектә сабан тургае сайрагандай тоелды.

Шагыйрь Галимҗан Латыйп, уйлавымча, балаларча ихласлык белән кешеләрне ярата. Чөнки:

Кеше күңеле — нечкә нәрсә,
серле нәрсә.
Кеше күңеле кешеләргә
нур өләшә...

Мин үзем лирик булмаган шагыйрь юк дип беләм. «Кызыл Яр» авторы исә сентябрь кояшыдай тыйнак, яз чәчәге умырзая төсле оялчан лирик. Ул тойгыларны, язгы елгадай, ярларга бәрә-бәрә тукми. Ул, чишмәдән кайтучы кызлар кебек, хисләрен чайпалдыра гына. Һәм шул җитә дә.

Каһәр суккан сугыш бетми...
Яна иген басулары,
Изге кабер ташы яна.
...Яна яшьлек. Яна гомер,
Мәхәббәт һәм хыял яна.
Сабыйларның һәм толларның
Сулгып-сулгып яше тама...

Китапта тойгыларны шулай уятырлык, рухны күтәрерлек һәм күзләрне ныграк ачтырырлык шигырьләр күп кенә. Аларның һәрберсенә тукталып булмый. Ә шулай да исемнәрен генә булса да әйтеп үтәсе килә: «Минем нәсел», «Якташлар», «Кешеләр нык тора», «Җыр үткәндә», «Барысы да синдә кала» һәм ...«Яңа доктор». Соңгысы аеруча кешелекле, югары гражданлык пафосы белән сугарылган шигырь. Ул — бөек рус язучысы А. П. Чеховның Сахалинга жан исәбе алыр өчен озын, азаплы сәфәргә чыгуы турында. Шигырь:

Алып килгән дә ул үзе белән
Изгелек һәм гөнаһ үлчәвен.
Жан исәбе алып йөргән көн-төн,—
Җәберләнгән җаннар исәбен,—

диган тирән мәгънәле һәм тәэсирле юллар белән тәмамлана.

Китаптагы «Кызыл Яр» дигән поэма да шагыйрьгә хас самими лирик дулкында язылган. Поэманың төп герое Зөһрә автор фантазиясе белән тудырылган образ түгел. Зөһрә — тарихи шәхес. Ул, патшалык һәм шәригать богауларын өзеп, җил-давылга каршы барган зур ихтыярлы кыз була. Гимназия тәмамлый, аннан татар-башкорт балаларына рус теле укыта. Гражданнар сугышы башлангач, мәктәп ябыла. Зөһрәнең бертуган агасы акларга каршы сугышта Бәләбәй шәһәрендә һәлак була. Кыз, әтисенә ияреп, Бәләбәйгә бара. Юк, ул анда һәлак булганнарның, революция корбаннарының кабероләренә чәчәк салу өчен генә бармый. Аның теләге зуррак һәм изгерәк: ул госпитальгә эшкә керә, аннары, кулына мылтык алып, күп кенә сугышларга катнаша һәм туган Уфасын азат иткәндә һәлак була.

Шундый геройларның берсен эзләп табып уңай әдәби образ тудырган өчен генә дә язучыга рәхмәтебезне әйтергә һәм ихтирамыбызны белдерергә тиешбез. Әсәрдә Уфаны азат итү турында сөйләнсә дә, аның пафосы тантаналы булса да, сагышлы әрнүле урыннар күп. Зөһрә Уфаны азат иткәндә һәлак була. Ләкин аның ал яулыгы, кызылармеецларның штыгына бәйләнеп, Уфага җиңүче булып керә.

Җир кан белән сугарылды,
Җир астында ялкыннар...
Вик кыенга туры килсә,
Алар тагын калкырлар,—

ди шагыйрь халыктагы сүнмәс рухны, бетмәс-түкәнмәс потенциаль энергияне раслап. Һәм ул раслап кына да калмый, ә изгелекнең, батырлыкның мәңгелек көч икәнен дә исбатлый:

Гомерләр дәвам итәләр,
Изгелек ятмый җирдә.
Батырлык белән изгелен
Икесе атлый бергә.

Ирек, бәхет чыганагы әнә шунда да инде.

Мин бу очракта, әгәр гадәти тәнкыйтьчеләр традициясе буенча эш итсәм, поэманың йомшак якларына да тукталырга тиеш идем. Аның, мәсәлән, гел «кавалерия маршы ритмында» язылуын, анда фәлсәфә урынына гел генә хикәяләү, хәтта: «Уңга селти, сулга селти, нишләргә дә белми аклар, эшләр яман, эшләр хөрти...» кебек йомшак шигъри тезмәдән торган юлларның булуын да күрсәтергә мөмкин иде. Чөнки «Кызыл Яр»ны укыганда кашым җыерылган чаклар да булды, әмма 99 битнең 90 бите мине канәгатьләндерде һәм илһамландырды, күңелемне җылытты һәм яктыртты. Шулай булгач, китап турында ничек җылы сүзеңне әйтмисең инде. Ә әсәргә анализ сүзен, аның поэтик эшләнешенә бәйле теге яки бу фикерне исбатлы да һәм төпле дә итеп безнең тәнкыйтьче дусларыбыз әйтерләр әле.

...Кем соң ул шагыйрь? Башкалардан кай ягы белән аерыла соң ул? Юк, бер ягы белән дә аерылмый. Шул ук кеше ул. Тик башкалар күрә алмаган нечкәлекне, гүзәллекне, тойгыны күңел күзе белән күрә белүче кеше ул шагыйрь. Һәр көн яңалык ачучы, һәрнәрсәгә сокланучы, гаҗәпләнүче кеше ул шагыйрь. Тормышта матурлыкны күрә һәм шуны образлы тел белән әйтә белгән һәркемне «Син бит шагыйрь» дип юкка гына мактамыйлар.

Булсын дисәң күңелләрдә
Һаман да яз,
Син үзең дә кояш кебек
Язлар яса.
Бу дөньяның ни яме бар,
Яз булмаса.

Галимҗан Латыйп китабында да шул язның ниндидер бер нуры, яңача елмайган бер яктылыгы бар.

**ИБРАҺИМ АБДУЛЛИН**

**Е. УТКИН. Минем романтикам. Шигырьләр һәм поэма. Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел.**

Менделеевск шәһәренең 1 нче номерлы урта мәктәбендә белем алган укучылардан алты кеше Бөек Ватан сугышы елларында Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек була. Шуларның өчесенә — Василий Белоусовка, Вилен Бурмистров һәм Петр Сафроновка бу исем Днепрны кичкәндә күрсәткән батырлыклары өчен бирелә.

Яшь шагыйрь Егор Уткин «Минем романтикам» исемле яңа җыентыгында басылган «Ант» поэмасын әнә шул кыю егетләрнең берсенә — Вилен Бурмистровка багышлап язган. Әллә ни озынга сузылмаган бу поэмасында ул шактый күп нәрсә турында сөйли. Поэманың беренче өлешендә без туган җиребезнең бәйсезлеге, халкыбызның азатлыгы хакына гомерләрен биргән батырларның каберләре алдында баш иргә килгән пионерлар белән очрашабыз. Аннан соң сүз Бурмистровның яшьлек еллары, яу кырына киткәч, якын дуслары белән иңгә-иң торып арысланнарча сугышуы турында сөйләүгә күчә. Туганнар каберлегенә килгән өлеге пионерлар белән шагыйрь безне әсәренең соңгы өлешендә яңадан очраштыра. Бу юлы алар өлкәннәр калдырган көрәш эстафетасын биек күтәреп барырга ант итәләр.

Батыр, тыныч йокла,
Аңа күкле азат илең бар.
Кабереңдә әнә ант итәләр
Кызыл галстуклы Виленнар.

Поэма шундый юллар белән тәмамлана. Бу юлларны укыганда без ата-бабаларының васыятьләренә тугрылыклы булып үсәчәк яшь көрәшчеләрнең көчле авазын ишетәбез.

Җыентыкка, «Ант» поэмасыннан тыш, шагыйрьнең соңгы елларда иҗат иткән кайбер яңа шигырьләре урнаштырылган. Ул шигырьләрнең күбесендә бүгенге авыл тормышы, үз язмышын гомерлеккә җир язмышы белән бәйләгән игенченең уй-хисләре, тойгы-кичерешләре шактый калку итеп сурәтләнә. «Минем романтикам», «Ындыр табагында», «Иген кыры авыл итәгеннән», «Намус диләр аны авылда», «Карлар», «Игенчеләр җырлый күзләрен», «Таяна иңеңә», «Хәле җиткән ындыр артына тик» һәм «Очрашу» шигырьләрендә лирик геройның туган җиргә, иген кырларына карата булган тирән мәхәббәте аеруча матур чагылыш тапкан. «Таяна иңеңә» шигырендә автор, игенчене, аның тынгысыз хезмәтен зурлап, менә болай ди:

Бу — үзе батырлык,
Матурлык.
Юлыңны үзгәртмә, чигенмә.
Батырлар галәмгә чыкканда
Таяна иңеңә синең дә.

Уңышлы тотып алынган һәм оста файдаланылган мондый поэтик детальләрне югарыда саналып кителгән башка шигырьләрдә дә байтак очратасың.

Шагыйрьне дулкынландырган һәм кулына каләм алырга мәҗбүр иткән темаларның икенчесе — тынычлык темасы. Күп кенә шигырьләрендә ул узган сугышның авыр газапларын, аның күңелләрдән беркайчан да китмәслек авыр яраларын күреп сызлана, бүгенге тормышыбыз хакына, киләчәк хакына кешеләрне уяу булырга, сизгер булырга өнди. «Орденнар кайталар», «Куеп иңне иңгә», «Дөньяны ул яңа күргән кебек», «Сакта тора Газинур», «Бир кулыңны, Хиросима», «Ак каеннар җирсеп шаулыйлар» шигырьләре укучыны ил язмышы, планета язмышы хакында уйланырга мәҗбүр итә. Яу кырында зур батырлыклар эшләгән сугышчылар турында, аларның бүген дә сафта калулары турында шагыйрь «Орденнар кайталар» шигырендә бик матур итеп әйтеп бирә:

Солдатка даның ни, чиның ни,
Исән-сау туган ил —
Шат алар...
Шуңа да батырлар әченнән
Бүген дә орденнар кайталар.

Егор Уткин, гомуман, кайнар йөрәкле, олы җанлы гади кешеләр турында күбрәк язарга тырыша. Аның бу әйбәт сыйфатын

«Очраттым мин», «Көтмәгәндә очраштык», «Әллә язлар уйчанлана» кебек шигырьләрен укыганда бигрәк тә нык тоясың.

Җыентык күңелдә куанычлы тәэсир калдыра. Ул шагыйрьнең моңарчы басылып чыккан китапларыннан, һичшиксез, уңышлырак булуы белән аерылып тора. Әмма аның бу җыентыгы да кайбер кимчелекләрдән азат түгел. Төп кимчелекләрнең берсе итеп авторның шигырьдә сүз сайлауга тиешенчә игътибар биреп җиткермәвен әйтеп үтәргә кирәк. «Кырык бернең июнь аеның соңгы кичәсе», «Күрше-күлән барып дәшкәннәрме», «Кайгы бәр кылганнар маңгай сырларын» шикелле сүз тезмәләре, мәсәлән, һич кенә дә татарча яңгырамыйлар, укучыга җиткерелергә тиешле фикерне аңлауга комачаулыйлар. Кайбер шигырьләрнең бертөрле характерда язылган булулары да җыентыкның күләгәле якларын арттыра төшә. Шундый шигырьләрдән «Яңгыр», «Кешеләр күңеленә», «Бүгенгәчә әле ишетмәдем», «Агачларга тияр-тимәс болыт ага» исемлеләрен китапка кертмәгәндә дә автор әллә ни оттырмаган булыр иде. Җыентыкка керәчәк шигырьләрне сайлаганда аңа, бәлки, редакторның да ярдәме кирәк булгандыр. Ләкин нәрсә генә булмасын, «Минем романтикам» китабы яшь шагыйрьнең үсә баруы, каләмен торган саен ныграк чарларга омтылуы турында сөйли.

**К. ЛАТЫЙПОВ. Ак карлар. Шигырьләр, җырлар һәм новелла. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.**

Кави Латыйпов поэзия өлкәсендә инде күптән эшләп килә. Аның матбугатта басылып чыккан беренче китабы бар. Былтыр ул «Ак карлар» исемле тагын бер җыентык бастырып чыгарды. Бу җыентыкта, шигырьләреннән тыш, шагыйрьнең Җ. Фәйзи, А. Ключарев, М. Яруллин кебек композиторларыбыз тарафыннан көйгә салынган җырларына да урын бирелгән. Җыентык «Сәлам сиңа, партия» җыры белән ачыла. Композитор Җ. Фәйзи көй язган бу шигырендә автор халыкларның партиягә булган кайнар мәхәббәтен гәүдәләндерергә омтыла. Ул җырны Маяковскийга, Вьетнамдагы вакыйгаларга, Греция халкының фашизмга каршы көрәшенә багышланган шигырьләр алыштыра. «Китап сүзе» шигырендә К. Латыйпов элеккеге Сембер губернасының Петряксин авылындагы татар мәктәбендә укытучы булып эшләгән Гайфулла Галиев турында сөйли. Бу мәктәпне В. И. Ленинның әтисе И. Н. Ульянов бештырган һәм Гайфулла Галиевны яңа ысул, үз ысулы белән укытырга өйрәткән, яңа демократик юнәлеш биргән. Барлык сөйләгәннәренә йомгак ясап, шигырьнең ахырын шагыйрь менә мондый юллар белән тәмамлый:

Баганалы юлга чыкты
Хәлфә Гайфулла эзе...
Сембер ягыннан килгән, ди,
Авылга китап сүзе.

Кави Латыйпов чуваш халкының тормышын, аның гореф-гадәтләрен яхшы белә һәм моны үз иҗатында файдалану юлларын эзли. «Альтук», «Иван бабай», «Ташларыңа башым иям», «Олы юлда бер шәһәр бар», «Настюк-Нәфисә», «Кодагыйлар» шигырьләрендә татар һәм чуваш халыклары арасындагы олы дуслык үзенең матур чагылышын тапкан. Башка темаларга язылган шигырьләрдән «Васыять», «Биш йөрәк бер кабердә», «Туганнар», «Дуслар сүзе», «Коючы Сабир», «Камышлардан киткән аккошлар», «Уха» шигырьләре дә күңелдә җылы гына тәэсир калдыра. Кызганычка каршы, китапка кергән башка шигырьләр турында моны әйтеп булмый. Хис һәм кичерешләргә нигезләнмәгәнгә күрә, аларның күбесеннән салкынлык бөркелеп тора. Ясалмалыкка корылган мондый шигырьләрне укыйсы килми башлый. «Хәтәр елларда», «Кылыч», «Җиңгием», «Чатка кадәр безне озаттылар», «Мыек Заһидулла», «Бәхет», «Кардиограмма», «Тамаша», «Нефть турында баллада» кебек декларатив, риторик шигырьләр укучы йөрәгендә бернинди дә хис уятмыйлар, алар бары тик җыентыктагы әйбәт шигырьләрнең тәэсир көчен генә киметәләр. «Күрше Сабирулла» новелласында да шагыйрь һәркемгә билгеле булган фактларны бер-бер артлы санап чыгудан уза алмаган. Әсәрнең сюжеты ясалма, поэтик яктан эшләнеше йомшак.

Әйтеп үткәнебезчә, Кави Латыйпов инде күптән яза. Шушы елларда ул Мәскәүнең М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлады. Димәк, аның иҗат тәҗрибәсе дә, әдәби белеме дә җитәрлек. Шуңа күрә киләчәктә укучының аннан матур-матур әсәрләр көтәргә тулы хакы бар.

**Ә. ГОБӘЙДУЛЛИНА. Минем дустым театр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.**

Нәшрият Татар дәүләт академия театры каршындагы музей директоры Әминә Гобәйдуллинаның «Минем дустым театр»

исемле китабын бастырып чыгарды. Кече яшьтәге мәктәп укучыларына адресланган бу китап театр сәнгате, сәхнә тормышы, актерлар хезмәте белән бәйләнешле күп кенә нәрсәләр хакында сөйли. Күп булулары өстенә, аларның байтагы балалар өчен ярыйсы ук катлаулы да. Шуны истә тотып, автор үзе кузгаткан мәсьәләләрне гади һәм үтемле итеп аңлатырга, мавыгып укырлык итеп эшләргә тырышкан. Китап әдәби формага салынып, повесть итеп язылган.

Ул кечкенә-кечкенә аерым бүлекләрдән тора. Һәр бүлек театр сәнгате, я булмаса актерлар эшчәнлегенә кагылышлы берәр мәсьәләгә багышланган. Ә ул мәсьәләләр, алда бер тапкыр әйтелгәнчә, шул хәтле күп, аларның һәммәсенә тукталу һич мөмкин түгел. Шулай да аеруча әһәмиятлеләрен санап узмыйча булмый. «Кылану сәхнәгә ят нәрсә...», «Игътибар...», «Без рольгә керәбез...», «Хәрәкәтләрнең төре...», «Артистның уены гади һәм табигый булырга тиеш» кебек бүлекләрдә сүз нигездә актерлар иҗаты турында бара. Бу бүлекләрдә автор нәни укучыларны артист хезмәтенең нечкәлекләре, үзенчәлекле яклары белән таныштыра, күп төрле дәлилләргә, кызыклы мисалларга таянып, бу хезмәтнең авырлыгына һәм җаваплы булуына басым ясый. **Артист хезмәте иң авыр хезмәт, эш сөймәгән ялкау кешеләрдән артист чыкмый, сәхнә өчен бөтен вакытын, шәхси тормышын багышлаган кеше генә яхшы артист була ала** — авторның югарыда исемнәре саналган бүлекләр аша укучыга әйтергә теләгән төп фикере әнә шул.

Китаптагы «Вакыйга... Кисәкләр...» дип исемләнгән бүлек безне сәхнә әсәрләренә конкрет анализ ясарга, аларны күренешләргә, аерым эпизодларга һәм кисәкләргә бүләргә өйрәтә. «Прогон һәм генеральный репетицияләр» дигәне, исеменнән үк күренгәнчә, спектакльне сәхнәгә әзерләгәндә ясала торган репетиция төрләре белән таныштыра. «Режиссер, художник, артист» һәм «Театр вешалкадан башлана...» дигән бүлекләр күбрәк информацион характерда язылган, аларда театрның җитәкче кешеләре, ул кешеләр башкарган вазифалар турында, шулай ук хуҗалык тормышына кагылышлы мәгълүматлар бирелә. Кыскасы, китап белән танышкан укучылар, театр турында булсын, актерлар тормышы турында булсын, кызыклы һәм файдалы нәрсәләр беләчәкләр.

Дөрес, күтәрелгән мәсьәләләрнең һәммәсе дә бер дәрәҗәдә яктыртылмаган. Үзе яхшы белгән, үзенә таныш булган нәрсәләргә автор кайта-кайта туктала. Икенчеләрен исә телгә алып кына уза. Аның игътибарыннан бөтенләй читтә калган әйберләр дә байтак. Китапта шулай ук коры акыл сатуга корылган яки беркатлырак язгыраган урыннар, авыр җөмләләр дә очрап-очрап китә. Әмма бернәрсә бәхәссез: хезмәт театр сәнгатебезгә, актерлар хезмәтенә тирән ихтирам һәм мәхәббәт белән язылган. Ул артист тормышы хакындагы җиңелчә карашлардан арынырга булыша, театр сәнгатен яратырга өйрәтә. Китапның төп кыйммәте әнә шунда.

Әгәр бездә мондый характердагы хезмәтләргә мохтаҗлык зурлыгын да исәпкә алсак, Ә. Гобәйдуллина башлаган эшне башкалар дәвам иттерсен иде, дигән теләк белдерергә генә кала. Сәнгатебезнең башка тармаклары буенча да балаларга адресланган шундыйрак һәм моннан да яхшырак китаплар язылсын иде.



# САЛИХ СӘЙДӘШЕВ ҺӘМ ТЕАТР

Салих Сәйдәшевнең музыкабыз тарихында мәңге җуелмаслык эз калдыруы — бәхәссез һәм һәркайсыбызга мәгълүм нәрсә. Ул иҗат иткән әсәрләрне үзебезнең халык кына түгел, башка милләт халыклары да яратып тыңлавы да билгеле. Бу турыда байтак язылды һәм сөйләнде инде. Һәм, әлбәттә, киләчәктә дә бик күп язарлар һәм сөйләрләр әле.

Шушы кечкенә истәлегемдә мин, Салихның әсәрләренә кагылмыйча, аның театрга һәм артистларга мөнәсәбәте хакында гына берничә сүз әйтергә ниятләдем.

Мин аны беренче мәртәбә 1921 елның июль аенда Оренбург шәһәрендә күрдем. Без, бер төркем артистлар, гражданнар сугышының төрле фронтларыннан җыелып, Оренбургта труппа төзеп эшли башлаган идек. Көннәрдән беркөнне безнең труппа, Мирхәйдәр Фәйзинең «Асыл яр»ы буенча репетиция ясап, ятим балалар файдасына спектакль куярга хәзерләнеп торганда, труппа җитәкчесе Габдулла Камал I, залга ымлап:

— Иптәшләр, бер генә минутка дикъкать! — диде.

Барыбыз да залга текәлдек һәм өстенә шинель, башына шлем, аягына ботинка кигән һәм обмотка ураган урта буйлы солдатны күреп, аның килеп җитүен көтә башладык. Менә ул ашыкмыйча гына килеп җитте дә, сөйкемле зәңгәр күзләрен оялчан гына сирпеп, Камал I белән кочаклашып күреште. Аннары Камал I:

— Таныш булыгыз, бу солдат — Казан егете, музыкант Салих Җамалетдин улы Сәйдәшев. Оренбургның музыка мәктәбендә калачак,— диде.

Моңарчы Сәйдәшев Төркестан фронтының политбүлеге карамагындагы музыкантларга җитәкчелек иткән. Ә инде Төркестан фронты Азиягә үтеп барышлый Оренбургта туктагач, Салих шушында калырга рөхсәт алган булып чыкты.

Камал I аны безгә тәкъдим иткәч, Салихның бит алмалары кызарып чыкты һәм ул, авыз эченнән нәрсәдер сөйләнгән кешедәй, иреннәрен тавышсыз гына кыймылдата-кыймылдата, безнең барыбыз белән дә кул биреп исәнләште.

Шул көннән алып Салих безнең белән якыннан танышып китте һәм безгә ярдәм итә башлады. Әлеге ятимнәр файдасына багышлап үткәрелгән кичәбездә «Асыл яр»ның антрактлары вакытында да халык коралларыннан төзелгән оркестрга Салих Сәйдәшев җитәкчелек итте. Ул кичәдә татар халык көйләреннән «Каз канаты», «Күк-

күгәрчен», «Эңгер-меңгер»не һәм Заһидулла ага Яруллин иҗат иткән «Туган маршы»н тамашачылар йотлыгып тыңладылар.

Кичәдән соң яшьләр биюле һәм җырлы уеннар уйный башлады. Шул чакта оркестрда катнашкан өлкән композитор Мөсәлим ага Вәлиев, халыкка мөрәҗәгать итеп:

— Хәзер Салих Сәйдәшев музыкасы — «Татар вальсы» башкарыла! — диде. Ул шушы сүзләрне әйтүгә, кулларын очарга талпынган бөркет канатларыдай җәеп, Сәйдәшев бер талпынып куйды. Аннары оркестр, бөтен залны таң калдырып, «Татар вальсы»н уйнап җибәрде...

Ачарчы төрлесе төрле фронт бригадаларында эшләп йөргән татар артистлары һәм артисткалары 1922 елның кышкы сезонына, ниһаять, үзебезнең мәдәни үзәккә — Казан дәүләт театрына кайттылар. Театрның музыка җитәкчесе булып Салих Сәйдәшев эшли башлады. Бу эшендә эшләү чорында ул Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе», «Ил», Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик», Гадел Кутуйның «Балдызкай», «Калфаклылар», Һади Такташның «Күмелгән кораллар»ына һәм башка бик күп драматургларның әсәрләренә музыка язып, рух, дәрт биреп, халык арасында аларны популярлаштыруда бик зур хезмәт куйды.

«Зәңгәр шәл»не сәхнәгә куярга әзерләнгәндә, ачарчы оркестр башкарган көйләргә беребезнең дә җырлаганы булмаганлыктан, безне оркестр белән җырларга өйрәтү өчен композитор бик нык азаплады. Бер үк көйне уннарча мәртәбә кабатлап та без канәгатьләнерлек итеп җырлый алмагач, ул, дирижер таягын пультка куеп, нотасын яба иде дә, кара бөдрә чәчләрен сыпырып:

— Бик шәп җырладыгыз. Инде азрак ял итеп алыгыз!..— дия иде.

Эченнән борчылса да, тыштан үзен бик сабыр тота, беркайчан да ачуланмый, авыр сүз әйтми. Йомшак табигатьле, аз сүзле кеше иде ул. Ләкин бер ачылып китсә, бик кызыклы вакыйгалар сөйләп, безне рәхәтләндереп көлдереп ала. Ә үзе беркайчан да кычкырып көлми, бары елмаеп кына тора иде.

Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендә Мәйсәрә ролен беренче мәртәбә артистка Оркыя Кушловская башкарды. Спектакльнең премьерасы бик зур уңыш белән үтте. Тамашачылар ярты сәгать буена пәрдәне яптырмыйча, алкышлап тордылар. Бу уңыш, бер яктан, әсәрнең яхшы язылганлыгыннан килсә, икенче яктан, музыкасының әйбәт булуына бәйләнгән иде. Спектакль тәмамлангач, Салих Сәйдәшев бик нык дулкынланып, артистларның грим бүлмәсенә килеп керде дә барыбызга да рәхмәт әйтте. Аннары, күкрәк кесәсеннән кульяулыгын алып, маңгаена бәреп чыккан эре-эре тир бөртекләрен сөртте һәм:

— Оркыя ханым, сез минем музыкага җан кертеп, моңлы тавышыгыз белән бүген аны тамашачыларга җиткердегез. Шуның өчен чын күңелдән котлап, музыканың беренче нотасын сезгә ядкарь итәм! — дип, нотасын Кушловскаяга биреп чыгып китте.

«Зәңгәр шәл» спектакле репетицияләрендә безнең белән шагыйь нык интеккәннән соң, Салих Сәйдәшев безгә нота өйрәтә башлады.

— Драма артистлары булсагыз да, музыканы аңларга, нота укый белергә кирәк сезгә. Бу нәрсә әсәрләрдәге җырларны башкаручылар өчен генә түгел, музыка фонында монолог сөйләгәндә дә кирәк булачак,— диде.

Аның тырышлыгы аркасында без ноталарны да укырга өйрәндек, музыканы да тирәнрәк аңлый башладык.

Безне музыкага якынайтырга тырышу белән бер үк вакытта, Салих Сәйдәшев үзе дә артистлар эше белән якыннан кызыксынып йөри иде. Мәгълүм булганча, Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» әсәрендә сүзсез рольләрдән торган байлар образлары бар. Бер дә бер көнне, пәрдә күтәрелеп, спектакль башланып киткәч, сәхнәдә безгә таныш булмаган бер бай-артист пәйда булды. (Без ул чакта сәхнә артында декорация ярыкларыннан карап тора идек.) Сары сакаллы, озын мыеклы, зур корсаклы кеше иде ул. Нишләр икән дип кызыксынып күзәтә башладык. Кыяфәте бик шәп, кеше хакын ашап симергән борынгы татар байларына, сукпан да каплаган дигәндәй, охшаган иде. Сәхнәдәге барлык байлар да дога кылып, кайсы кая утырышып беткәч, әлеге сары сакаллы бай артист «гы-ык!» иттереп, бөтен сәхнәне ярып кикереп куйды. Шул чакта күп ашаганга түзә алмыйча, аның корсагы ярылып киткәндәй булды һәм бөтен тамаша

залы шау килеп көлеп җибәрде, кул чаба башлады. Без дә, сәхнә артында туйганчы көлеп, пәрдә төшүен түземсезлек белән көттек. Ниһаять, пәрдә төште һәм без йөгерешеп әлеге «бай» янына килдек. Килдек һәм, аның Салих Сәйдәшев икәнлеген күреп, тагын да ныграк көлешә башладык. Ә Сәйдәшев, гадәтенчә, тыйнак кына елмаеп, «сакалын» кубарып тора иде...

Салих Сәйдәшев иҗат иткән музыкаль әсәрләрнең кыйммәте һәм үзенчәлеге, минемчә, шунда: алар милли булулары белән бер үк вакытта, башка милләт халыкларына да бик яхшы аңлашылалар. Аның әсәрләрен илебез халыклары гына түгел, чит ил кешеләре дә яратып тыңлаганга мисал итеп 1928 елның 8 сентябрендә булган бер концертны искә алып үтәсем килә. Ул елны Казанда физиклар һәм математиклар съезды үткәрелеп, шул съезд хөрмәтенә Салих Сәйдәшев әсәрләреннән төзелгән концерт бирелгән иде. Концерт бик уңышлы үтте. Аны карарга галимнәр генә түгел, бөек язучы Максим Горький һәм чит ил журналистлары да килгән иде.

Кунаклар концертның һәр номерын бик яратып, зур алкышлар белән тыңладылар. Концерт тәмамлангач, Максим Горький һәм чит илдән килгән кунаклар, сәхнә артына кереп, Салих Сәйдәшевнең һәм аның көйләрен җырлаган Асия ханым Измайлованың кулларын кысып, аларга чын күңелләреннән рәхмәт әйттеләр. Чит ил журналистлары Сәйдәшев музыкасының Европадагы музыкалар белән бер дәрәҗәдә торуын икърар иттеләр, ноталары белән кызыксындылар. Германия журналистлары шул кичне Салих Сәйдәшев белән Асия Измайлованы Берлинга гастрольгә килергә дә чакырып киттеләр...

Салих Сәйдәшевнең башка композиторларга хәер-хак һәм ярдәмчел булуын аеруча басым ясап әйтәсем килә.

Ватан сугышы елларында Сәйдәшевләр семьясы белән без күршеләр булып яшәдек. Минем иптәшем композитор Шакир Мәҗитов ул елларда үпкә авыруы белән җәфаланды. Әнә шундый күңелсез көннәрдә Салих Сәйдәшев еш кына безгә кереп, Шакирның хәлен белеп, юатып, аны иҗатка рухландырып чыга торган иде.

— Син, Шакир дус, күңелеңне төшермә. Авыруың үтәр. Дошманны җиңгәч, дөньялар рәтләнер. Башкалар дошманга каршы мылтык тотып сугыша, ә без, әйдә, шул сугышчыларны җиңүгә дәртләндерерлек матур көйләр языйк! — ди торган иде.

Яңа көй иҗат итсә, шундук аны алып кереп, Шакирга тыңлата, кайбер көйләрен хәтта уйнап кына түгел, җырлап та күрсәтә иде. Шакир язган көйләрне дә бик теләп тыңлый, аларга карата үзенең фикерләрен әйтә, дусларча киңәшләр бирә торган иде.

ФАТЫЙМА КАМАЛОВА,
Татарстанның халык,
РСФСРның атказанган артисткасы

# ҖИР ШАГЫЙРЕ



Җиргә агроном кирәк дигәнне мин күптән белә идем. Минем өчен бу ачык нәрсә. Ә менә җир белән эш иткән кеше шул җирнең шагыйре булырга тиеш дигән уй миндә соңрак туды. Авылдан чыккан хисләрем, соңгы егерме ел эчендәге күзәтүләрем шуңа китерде... Агрономы һәм шагыйре... Җир кешенең рухи бай булганын ярата.

Ринат Рәхимов — шагыйрь, өченче китап авторы. Кызык, безнең шагыйрьләр Ринат иҗатын тикшерүгә багышланган секция утырышын Казанда түгел, Казан янындагы колхозларның берсендә — Ринат председатель булып эшләгән «Ильич» колхозына барып үткәрделәр. Ул үзе дә килер иде: аты бар, машинасы бар. Юк, безнекеләр аңа омтыла. Тарта бит. Тормыш тарта... Яңа университет бетергән шагыйрьләргә үзенә күрә бер чакыру бу. Редакция, нәшрият коридорларыннан — кырга, тормыш эченә...

Монда секция утырышы да башкачарак уза. Ринат Рәхимовның яңа шигырьләрен укыйлар. Бәхәс, тормыш һәм поэзия турындагы бәхәс аларны урамга алып чыга, фермаларга илтә. Ринат ягында аның дүрт еллык агрономлык, алты еллык председательлек тәҗрибәсе. Ринат ягында ел саен мулрак уңыш бирүче кырлар, дәлилгә — игеннәр, дәүләтчә акыллы эш итүче кешеләр, кадрлар... Шагыйре әйбәт булып та игене уңмаса, минем каләм тибрәтергә кулым бармас иде. «Ильич» колхозы — районда алдынгыларның берсе.

Өч җыентык... Шагыйрь үз колхозында бикләнмәгән. Колхозындагы конкрет эшләрдән башлап, бүген дөньяда барган бөтен вакыйгалар да аны борчый. Ләкин шул төрле характердагы шигырьләр эчендә мин бер төркем шигырьләргә — тулы бөртекләрдән торган кешеләргә юлыктым һәм сөенеп куйдым, шагыйрьне танып алдым. Аның җирне яратуы шуларда. Дөресрәге, шагыйрь өчен җир, кеше һәм табигать — фәлсәфәсенең нигезе. Шигырьләрен ул «Җир ярасы» дип атаган. Хисләренең ачы, киеренке, килешмәүчәнлеге исеменнән күренеп тора. Җиренең матурлыгы хакына ул бөтенесенә бара. Шунда шагыйрьнең гражданлыгы, йөзе. Ул шигырьләрнең потенциаль көче шуларда, шул бөртекләрдә.

Председательләрнең урак өстендә һәрвакыт кесәләрендә арыш яки бодай... Игеп турында сүз чыкса, алар кесә төпләреннән шул бөртекләрне алып, учларында сикертәләр. Менә күрегез, янәсе...

Ринат Рәхимов шигырьләре дә шул әйбәт туфракта өлгергән бөртекләр...

СИБГАТ ХӘКИМ

# ЕЛДАН-ЕЛ КАМИЛЛӘШӘ...

Рәис Даутов матур әдәбият әсәрләрен русчадан татарчага тәрҗемә итү эше белән күп еллардан бирле шөгыльләнә. Ул тәрҗемә кагыйдәләрен дөрес үзләштергән һәм аларны практик эштә дөрес куллана белүче, танылган, талантлы тәрҗемәчеләребезнең



бирсә. Татарстан китап нәшриятында ул тәрҗемә иткән, укучылар тарафыннан яхшы каршы алынган унга якын китап басылып чыкты. Алар арасында хикәя җыентыклары да, повестьлар да, зур күләмле романнар да бар. Шулардан саф әдәби телдә тәрҗемә ителүе, сыйфатының яхшылыгы, оригиналга тәңгәллеге белән аеруча игътибарга лаеклы булганнары түбәндәгеләр: Н. Нечволодова һәм Л. Резниченконың «Ленинның яшьлеге» (повесть), Марк Твенның «Янки король Артур сараенда» (роман), Ф. Куперның «Соңгы могикан» (роман), Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» (роман), А. Купринның «Повесть һәм хикәяләр»е.

Р. Даутов иптәш «Казан утлары» һәм «Азат хатын» журналларында да ара-тирә катнашкалап килә: тәрҗемә хикәяләр, очерклар бастыра.

Аның тәрҗемәләрен мин берничә елдан бирле кызыксынып күзәтеп килэм. Рәис Даутовның тәрҗемәче буларак ничек үсүе, камилләшүе кызыксындыра мине.

Аның тәрҗемә осталыгы елдан-ел камилләшә, яхшыра бара. Әгәр аның беренче тәрҗемәләре белән соңгы елларда басылып чыккан тәрҗемәләренең сыйфатларын чагыштырып карасаң, соңгыларының сизелерлек дәрәҗәдә яхшырак, сыйфатлырак, әдәбирәк икәнлеге бик ачык сизелеп тора.

Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» романы тәрҗемәсе миндә аеруча яхшы тәэсир калдырды. Тәрҗемә җиңел, шома укыла. Әгәр китапның беренче битенә «русчадан тәрҗемә» дип язылмаган булса, укучыларның аны оригиналь әсәр дип кабул итүләре мөмкин. Чөнки тәрҗемә җөмләләренең гадилеге, шомалыгы, әдәбилеге белән автор оригиналы дәрәҗәсенә җиткерелгән.

Р. Даутов образларның телләренә, сөйләү манераларына да тиешенчә игътибар иткән, крестьяннарның, мулла-мәзиннәрнең, хаҗиларның, морзаларның үз телләрен тапкан.

Әсәрдә төрле сыйнфый катлау кешеләре тарафыннан язылган берничә хат бар. Алар язылышлары, телләре белән бер-берләреннән бик нык аерылып торалар. Аларның имзаларына карамыйча да, теге яисә бу хатны кайсы сыйныф вәкиле язганлыгын белергә мөмкин. Болар барысы да Р. Даутовның тәрҗемә эшенә бик җитди карaганлыгын, аны чын иҗади эш итеп санаганлыгын күрсәтеп тора.

А. Купринның «Повесть һәм хикәяләр»е дә яхшы тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәче оригиналның әдәби үзенчәлеген һәм идея-мәгънә төгәллеген тулысынча саклаган һәм тәрҗемәне югары сыйфатлы итү өчен әдәби телебезнең барлык мөмкинлекләреннән файдаланган. Шуның нәтиҗәсендә бу китап та оригинал кебек шома, җиңел укыла.

Р. Даутов иптәш бу мактау сүзләреннән чыгып: «Мин инде тәмам камилләшкәнмен икән, миңа хәзер тәрҗемәчелек осталыгын үстерү өчен артык тырышмаска, маңгай тирләрен агызмаска да мөмкин»,— дигән ялгыш нәтиҗәгә килмәсен иде. Р. Даутов, тәрҗемәче буларак, мактауга чыннан да лаеклы булса да, әле аның тәрҗемәләрендә ара-тирә кайбер кимчелекләр һаман да очраштыргалый.

Тик аның бу кимчелекләре оригиналның идея эчтәлеген бозарлык кимчелекләр түгел, ә рус теленең кайбер специфик үзенчәлекләреннән котыла алмау, ягъни кайбер җөмләләрне саф татарча биреп җиткерә алмау кимчелекләре генә.

Р. Даутов бу кимчелекләргә җитди игътибар итәр, моннан соң аларны булдырмас дип ышанам һәм аңа СССР язучылары союзына член булып керү өчен рекомендацияне тыныч күңел белән бирәм.

АФЗАЛ ШАМОВ

# ӨМЕТЛӘРНЕ АКЛАДЫ



Рәшит Әхмәтҗановның беренче шигырьләренең берсе «Давылда» дип атала. Анда кыя ташка давыл, котырынган давыл бәрелгәндә бөркет үз баласының очышын сынап карарга тели. Бала бөркетнең:

Каерыла бугай канатлары,  
Бер югары менә, бер түбән...  
Бөркет әйтә кебек:— Очалмасаң,  
Синең өчен түгел тау түбәм!

Әйе, поэзия Парнасы түбәсендә яшәр өчен дә сәескан булып кына түгел, бөркет булып, талант беркете булып туарга һәм сыналырга кирәк. 1957 елда 16 яшьлек Рәшит Әлмәтнең нефтьчеләр газетасы редакциясенә беренче шигырен китерә. Редактор белән секретарь укып карыйлар да бераз гаҗәпләнеп үзара ымлашып алганнан соң:

— Үзең яздыңмы соң бу шигырьне! — диләр. 16 яшьлек малайның мондый шигырьне яза алган булуына ышанып җитмиләр.

— Безгә менә хәзерге көз көне турында бер шигырь кирәк иде, язып кара әле,— дип, Рәшитне бер буш бүлмәгә кертеп, ишекне бикләп куялар. Нигә язмасын, ачык һавада — яңгырлар астында да ташчы булып эшли башлаган бу егеткә Әлмәт көзе бик таныш ич,— яза. Һәм бу — сыналу шигыре газетада басылып та чыга.

Алтмышынчы еллар башында Сибгат Хәким белән Әлмәт ягына, халык арасына чыккан идек. Безнең номерга кыяфәте һәм холкы белән Шәүкәт Галиевне хәтерләткән бер сөйкемле егет килеп керде. Рәшит исемле бу егет үзенең шигырьләрен укып карарга, киңәш алырга теләвен әйтте.

Укыдык. Шигырьләрен дә, үзен дә яраттык. Ләкин без дә, Әлмәт газетасы редакциясендәге вакыйганы белмәсәк тә, сынап карарга теләгәнбездер, күрәсең: шигырьләрнең кайберләрен төзәтеп-үзгәртеп, яңадан язып китерергә киңәш бирдек. Икенче көнне ук үзе төзәткән вариантларны алып килде. Шактый таләпчәнлек белән тагын бер кат күздән кичердек һәм әдәби табыш икән бит бу егет дигән фикергә килдек.

Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләрен безнең зур журнал да һәм башка газета-журналлар да дөньяга чыгара башлады. Рәшит безнең өметләрне тулы рәвештә күптән раслады инде.

Рәшитнең кайбер шигырьләрендә Гарсиа Лорка йогынтысы бардыр кебек тоела. (Мәсәлән, «Әллә инде кыр казлары кайта» шигырендә.) Ләкин Рәшит Испания чегәннәре фольклорына гына хас булган «табышмаклы», катлаулы метафораларның йомшак якларын, татар шигыренә ят икәнлекләрен яхшы белә. Рәшитнең сурәтли торган үз теле бар. Үз кичерешләрен генә түгел, халык йөрәгендәге кичерешләрне дә чын шигырь югарылыгына күтәреп, образлар аша әйтеп бирә ала ул.

Рәшит гаҗәп әдәпле, тыйнак кеше. Газеталарда, журналларда чыккан шигырьләре генә дә аның инде күптән Язучылар союзы члены булырга тиеш икәнен раслаганнар иде. Аның иҗади канатлары давылларда сыналган инде.

ХӘСӘН ТУФАН

## Зәкия Туфайлова



### Яфрак ява

Күк зәп-зәңгәр — диңгез кебек,
Әйтерсең лә чыңлый һава.
Тирбәлешкән күбәләктәй,
Җир өстенә яфрак ява.
Зәңгәр һава, зәңгәр һава,
Җир өстенә яфрак ява.

Сары яфрак күлгә куна,
Алтын яфрак кемгә куна?
Шатланабыз менә шуңа:
Яфраклар да безнең кебек —
Шатланалар, биешәләр.
Әйтерсең лә көлешәләр.
Кыштыр-кыштыр килешәләр.
Сикерә-сикерә йөгерешәләр...
Зәңгәр һава, зәңгәр һава,
Җир өстенә яфрак ява.

### Трай

Әти кичә мине бик нык тиргәде:
— Гел урамда трай тибеп йөрмә,— ди.
Шулчак энем йөгереп кенә килде дә,
Әй, әтине юмалый бу, юмалый,
Битләреннән үбеп-үбеп куйгалый:
— Миңа да,— ди,— «трай» алып бирерсез,
Абыйдан да шәп тибәрмен, күрерсез!



### Яңа мәктәп

Яңа мәктәпкә барабыз.
Хәерле сәгатьләрдә!
И мәктәбем, өйрәт безне
Иң матур гадәтләргә.

## Кыш килде



Кыш килде, кыш килде —
Безгә яңа эш килде:
Мамык карлар күрибез,
Юллар ясап йөрибез.
Юллар такыр, киң булсын,
Асфальт юлга тиң булсын!
Әтиләр һәм әниләр,
Укучылар, әбиләр...
Шул юллардан үтсеннәр,
Рәхмәт әйтеп китсеннәр.


## Заһирә Гомәрова

## Кайсы берлек

Әни бирде Исхакка
Берәр сумлык өч акча:
— Бер берлеккә ипи ал,
Бу берлеккә сора бал,
Монысына — әнис алма.
Кара аны, ялгыш алма!
Исхак кайтты бернисез,
Үзе шундый күңелсез,
Белмибез ни әйтергә...
— Юкмыни бер әйбер дә?
— Ник булмасын, бар да бар,
Алма да бар, бал да бар.
Оныттым мин барганда:
Кайсы берлек ипигә дә,
Кайсы — балга, алмага?..



## Илгизнең диңгезе



Илгизнең диңгезе
Тәрәзә төбендә.
Балыклар йөзәләр
Көнен дә, төнен дә.

Шул диңгез ярында
Утыра песи дә.
Күзләрен уйната,
Диңгезне исни дә.

Ирене тисә дә
Андагы балыкка,
Бу диңгез бикле шул —
Пыяла савытта.

## Җәй

Бул син безгә, җәй, мәңге!
Җәй тылсымлы җәймәңне.

Янда булса чиләгең,
Үзе тула җиләгең.

Концерт бирә урманың:
Оркестрың, хорларың...

Җәйрәп ята җәйләвең,
И рәхәт тә, җәй, ямең.

Кал син бездә, җәй, мәңге,
Җәеп яшел җәймәңне.

## Яратам сары балны

Ямьле соң умарталык,
Йөрим мин хәйран калып.
Яратам сары балны.
Чү, кортлар сырып алды...

— Балдан авыз ит, диләр,—
Кунак булып кит! — диләр.
Абау, алар нишлиләр,
Битне-кулны тешлиләр!..

Алар укол кадыйлар:
— Ашатабыз бал,— диләр.

Башыма да кундылар,
Кашыма да кундылар,
Битемә дә кундылар,
Иренгә дә кундылар...
Каш-кабагым, иреннәрем
Кабартма күк булдылар.

Фаил Шәфигуллин

# ҖАН АЛИ

хикәя



Ни өчен редакция эшеннән киттең, дисезме? Аның үзенә күрә бәләкәй генә тарихы бар.

Көннәрдән бер көнне минем эш бүлмәмә, күгәрчендәй гөрли-гөрли, базык гәүдәле, яшь чырайлы бер кеше килеп керде. Уң кулының чәнти бармагында — кашы ат күзе чаклы йөзек. Өстендә искереп беткән кыска кожан. Күлмәк якалары керләнгән булса да, галстугы өр-яңа. Кожан кесәләренә эш бияләйләре бөтереп тыккан.

— Сәлам, сәлам каләмдәшләргә!..

— Исәнмесез!

— Җан Али, шагыйрь...

— Шигырь китердегезмени?

— Сонетлар,— диде Җан Али эре генә.— Җиде поэмам, сигез балладам бар иде. Яшьләр гәҗите белән хатыннар журналы талап калды. Сонетларым озакламый нәшриятта аерым китап булып чыгачак. Тәрҗемәче тапсам, Мәскәүдә дә китап чыгарырга исәп. Нишлисең, кирәк бит... То мунчасы, то верандасы, то яңа сорт телевизоры, дигәндәй... Кеше төсле яшисе килә... Син нитмә, китап чыккач бер иркенләп утырырбыз әле. Инде хәзер тыңлап кара! — Җан Али куеныннан бер төргәк кәгазь тартып чыгарды. Кожан төймәләрен ычкындырып, кулларын бутый-бутый, ярты сәгать чамасы урам җырларына охшаш такмаклар укыды.

— Барысы да шундыйлармы? — дип бүлдерергә мәҗбүр булдым мин аны, ниһаять:

Уфа кая, Уфа кая?
Уфа тауда, калкуда.
Юкә чәчәк аткан вакыт
Рәхәт була басуда.—

дигән җыр куплетын тыңлагач.

— Мондыйлары дүрт йөз кырык сигез юл. Менә арада бер канатлы сонетым да бар. Укыйммы?

— Укы,— дидем мин, сабырлыгымны җуймаска тырышып.

— Киләчәккә хатлар озак бара —
Телеграм сугыйк, иптәшләр!
Иптәшләр үзебезнеке,
Бәлки, гаеп итмәсләр...

— Минем иҗат позициям бик ачык чагыла бу сонетта,— дип, Җан Али урындыкка килеп утырды.— Беренчедән, Такташ традициясен батырларча дәвам иттерәм; икенчедән, телеграм сүзе мисалында новатор буларак кыю дебют ясыйм. Өченчедән, халык авыз иҗатына бик оста таянам һәм бу минем бөтен иҗатым буенча кызыл җеп булып тартыла.

— Шулаен ул шулайдыр да,— дип суздым мин, тирләгән маңгаемны сөртә-сөртә,— безнең газета өчен бармас шул мондый шигырьләр.

— Нәрсә?! — Җан Али күкерт кебек кабынып китте. Түш кесәсеннән тагын бер төргәк таушалып беткән кәгазь тартып чыгарды.— Менә,— диде ул, күзләреннән яшеннәр атып,— бусы шигырьләремнең сонет булулары хакында райпотребсоюз работникларының гомуми җыелышы карары, менә бусы лесхоздан үтенеч... менә бусы минем Җамали түгел, Җан Али булуым турында авыл советыннан белешмә!..

Мин кулларым белән чигәләремне кыстым.

— Кирәк дип тапсагыз, районрагыларнын да берәрсеннән раслатып чыга алам,— дип дәвам итте Җан Али.

— Кирәкми, зинһар, кирәкми. Казандагы берәр шагыйрьгә укытыр идегез, ичмасам.

— Шагыйрьгә?! — Җан Алиның гаҗәпләнүдән күзләре маңгаена менде.— Үзем шагыйрь була торыпмы?! — дип, баягыдан да битәррәк кызып китте ул,— юк инде, мин массалар фикере белән генә килешәм.

Мин, телемне чак-чак кына әйләндереп, ләкин әле һаман да сабырлыгымны җуймыйча, болай дидем:

— Ярый, калдырыгыз шигырьләрегезне. Иптәшләр белән укып карарбыз.

— Түлке озакка сузмагыз,— диде Җан Али боерулы тавыш белән,— минем быел дача саласы ел. Аннары,— Җан Али кинәт тавышын йомшартты,— көн саен районга килеп булмый. Идән буявы ала кайтырмын дигән идем... Бер-ике-өч тәңкә генә булса да нитеп тор әле миңа, ә... басылып чыккач хисаплашырбыз...

Тизрәк котылыйм бу бәйләнчектән дип, мин Җан Алига үз кесәмнән бер тәңкә акча чыгарып бирдем...

Берничә көннән Җан Алига шигырьләренең начарлыгын әйтеп хат яздык. Ә тагын берничә көннән мине редактор чакырып алды. «Авторлар белән тупас мөгамәлә итә» дип, Җан Али минем өстән жалоба язган икән...

Ниһаять, шушы аңлашудан соң, бәлки, котылырмын Җан Алидан дип, редактордан чыгып барганда гына, күгәрчен кебек гөрли-гөрли, ул үзе редакциягә килеп керде.

— Сәлам каләмдәшләргә!

Җан Али, тулган айдай балкып, өстәл янына килеп утырды. Бер чеметем мыегын сыйпаштырып, сүзгә кереште:

— Шигъри роман язып аттым бит әле. Романымда заман сулышы кызыл җеп булып сөйрәлә.

— Шәп булган,— дидем мин, еларга җитешеп.

— Сонетларымны кайчан басасыз?..

— Беркайчан да.

— Әгәр дә мин Казанга жалу бирсәм...

— Бир.

— Мәскәүгә язсам!..

— Яза бир.

Җан Али, башын иеп, авыр сулады.

— Бәлки, бер өлешен генә басарсыз, ә?

Мин эндәшмәдем.

— Карале, дус кеше, әгәр дә биш-алты сонетымны төзәткәләп бассагыз, больше ике аягымның берсен атламас идем редакциягезгә.

Минем эчкә җылы кереп китте. Көн йокламам, төн йокламам, өр-яңа шигырьләр язармын, әмма котылырмын бу сонет җәфасыннан.

— Чынлап әйтәсеңме? — дидем мин, шатланып.

— Чынлап инде, чынлап,— диде Җан Али.— Түлке гонорарын алдан биреп куярсыз.

— Бездә гонорарны әсәр басылып чыккач кына бирәләр.

— Ә миңа хәзер үк кирәк,— дип киреләнде Җан Али,— дачаны эшләп бетерәсе бар... Сез генә карунланып утырасыз. Әнә күрше районда ике сонетым басылды. Шартлатып ике кило кадак алдым. Шул ук перевод кило ярым буяуга да житте!.. Олиф алырга гына акча юк хәзер.

— Анда безнең ни эш бар?!.

— Ихтыярың-мәйлең,— диде Җан Али, китәргә җыенып.— Түлке карагыз аны, үпкәләштән булмасын. Иртәгә үк ике мең юллык шигъри роман китерәм...

— Туктале, Җан Али.

— Нәрсә тагын?

— Ничә тәңкә кирәк сиңа?

— Ну... мин ярты пот олиф сөйләшеп куйган идем.

Мин, «сөйләшкән сүзеңдә торсаң гына» дип, Җан Алига үз кесәмнән чыгарып биш сум акча бирдем.

— Нибарымы? — диде Җан Али, җилкәләрен җыерып. Үзе акчаны тиз генә кожан кесәсенә салып куйды.— Хәзер шагыйрьгә шулай гына бирәләрме инде? — дип мыгырданды ул, ишеккә таба атлый-атлый.

Иртәгесен Җан Али редакция өстәленә кирпеч калынлыгы дәфтәр китереп салгач, мин көлеп җибәрдем.

— Ник көләсең? — диде Җан Али, гаҗәпләнеп.

Мин йодрыгымны Җан Алиның борын төбенә куеп алдым да, эштән китүем хакында язылган гаризамны күтәреп, редакторга кереп киттем.

Вахит Монасыйпов

# КАЗАН КЕШЕСЕ

ЮМОРЕСКА



Вискоз эшләпәле кеше дүртенче көн инде район ашханәсендә туклана иде.

Әле моңарчы күренмәгән яңа вә сәер кеше булганга, ашханә мөдире аны беренче күрүдә үк мыек очына чорнап куйды. Аш пешерүче апа-түтәйләр янына кереп, колакларына тукыды:

— Әнә теге агайны күрәсезме? Карагыз аны, абайлап эш итегез: Казан кешесе! Берәр юньсез әйбер ашата күрмәгез!

Пешекчеләр бер авыздан:

— Борчылмагыз, иптәш мөдир, һич борчылмагыз! — диделәр.— Сый-хөрмәттән өзмәбез үзен! Авызы-борыны майда-балда гына булыр!

Һәм алар сүзләрендә тордылар да: гади клиентлар әчкелтем-төчкелтем кәбестә шулпасы чөмергәндә, вискоз эшләпә итле аш, тутырган тавык, майда чыжылдап пешкән өчпочмак сыпырып утырды.

Мөдир боерыгы белән, кадерле кунакны гомуми залдан аерым бүлмәгә күчерделәр. Ни әйтсәң дә, Казан хәтле Казаннан килгән кешегә җыен сукбай-клиентлар белән янәшә утырып ашау бер дә килешми, дип фикер йөртте мөдир.

Бишенче көнне мөдир ашханәгә, чалбарына ут капкандай, атылып керде дә пешекчеләргә ябырылды:

— Эшләпәгә нәрсә пешерәсез? Гөбәдия? Отставить! Вак бәлеш? Отставить! Чәк-чәк? Отставить!

— Ни булды, иптәш мөдир? Зинһар, аңлатып бирегез! — диешеләр түтәйләр.

— Ялгышканбыз! Казан кешесе дигәнебез безнең районга яңа килүче ат духтыры икән!..

...Әбәт вакытында вискоз эшләпәле ветеринар әчкелтем-төчкелтем кәбестә шулпасы алып ашады.

## Аскольд Буланов

### Багана

Бу дөньяда кемгә нәрсә,
Баганага терәү ошый.
Шуңа таянып яши ул,
Һичнәрсәгә эче пошмый.

### Качты

Берәү кәлтә еланының
Ялгыш өстенә басты.
Ә тегесе, әләктем дип,
Койрыгын өзеп качты.

### Күнекте

Беркөн ат юлга шулчаклы
Алды күнеп,
Үзе йөри, үзе йоклый,
Төшләр күреп.

### Ал да гөл

Көл савыты ал да гөл,
Аны хөрмәтләп төпчекне
Идәнгә ташлыйлар гел...

### Яраталар

Яраталар себеркене
Чүп-чар, тузан:
Чөнки себерке себерми,
Күптән тузган.

### «Соавтор»

Черки атны
Тотып буган,
Соавторы
Бүре булган.

### Зарлана

Тавык астына куймады күкәй,
Чебеше юк!.. дип зарлана түтәй.

### Мактанды

«Зифа буйлы каен идем!» диеп гел
Мактанды ди мич алдында яткан көл.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Татарстан язучылар союзы идарәсенең чираттагы утырышлары булды. Анда союз каршындагы иҗат секцияләренең эше тикшерелде һәм оештыру мәсьәләләре каралды. Шагыйрь Зәки Нури «Казан утлары» журналының баш редакторы вазифасын үтәүдән азат ителеп, Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе итеп сайланды. Язучы Гариф Ахунов «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп сайланды. Ә аның урынына, Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре итеп, шагыйрь Ренат Харисов билгеләнде.

## КҮБРӘК ҺӘМ ЯХШЫРАК БУЛСЫН!

Шушы елның май ае ахырында үткәрелгән проза секциясе утырышы хикәяләр турында сөйләшүгә багышланды. Язучылардан М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Б. Камалов, Г. Мөхәммәтшин, Л. Ихсанова, С. Сабиров, Х. Сарьян, М. Мәһдиев, М. Хәбибуллин, В. Нуруллин, Ф. Мансуров катнашында үткәрелгән ул җыелышта әдәбиятыбызда хикәя жанрының торышы аның үңай һәм кимчелекле яклары хакында Габдрахман Минский доклад ясады. Ул безнең әдәбиятта хикәя жанры элек-электән зур урын алып килүен, аның Шәриф Камал, Фатих Әмирхан кебек осталары булуын билгеләп үтте. Ләкин, диде аннары докладчы, соңгы елларда безнең өлкән әдипләребез нигәдер хикәя жанрыннан читләшә башладылар. Күбрәк зур күләмле әсәрләр язу белән мавыгып киттеләр. Сүз дә юк, повестьлар, романнар да кирәк. Әмма хикәяне дә онытырга ярамый. Яхшы хикәяне укучылар яратып укыйлар. Хикәядә әһәмиятле проблемаларны күтәрергә, замандашларыбызның образларын ачык итеп чагылдырырга мөмкин. Дөрес, соңгы елларда яшь хикәячеләр шактый активлашып баралар. Араларында әйбәт кенә язучылары да бар. Ләкин әле аларга тәҗрибә җитенкерәми.

Докладтан соң сүз алган Габдрахман Әпсәләмов хатын-кыз язучыларыбызның хикәяләре турында сөйләде. Ул М. Маликова, К. Тимбикова, Г. Зәйнашева, С. Сөләйманова хикәяләренең отышлы һәм житешсез якларын күрсәтеп үтте. Соңгы елларда хатын-кыз язучыларыбызның шактый күп яза башлауларын әйтте һәм аларга киләчәктә тагын да активрак язарга киңәш итте. Фикер алышуда катнашкан Мирсәй Әмир, хикәяләрдә берникди дә фальшь булырга тиеш түгел, алар укучыны ышандырырлык булырга һәм аның исендә калырдай итеп язылырга тиеш, диде. Аның сүзен куәтләп, Фатих Хөсни һәм Гариф Ахунов, хикәядә сурәтләнгән вакыйгалар гыйбрәтле, кызыклы булырга һәм хикәяне укып чыкканнан соң аның эчтәлеген сөйләп бирерлек итеп язылырга тиеш, дигән фикерне әйттеләр.

Г. Мөхәммәтшин, Б. Камалов һәм Э. Шәмин иптәшләр дә фикерләре белән уртаклаштылар.

## КУБАНЬДА СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Шушы елның 11—21 маенда Кубаньда совет әдәбияты көннәре булып узды. Кубаньга Советлар Союзының барлык өлкәләреннән диярлек 60 язучы җыелды. Алар арасында Вадим Кожевников, Константин Симонов, Алим Кешоков, Виталий Закруткин, Давид Кугультинов, Сергей Давыдов кебек исемнәре илгә таралган язучылар һәм шагыйрьләр бар иде. Әдәбият көннәре Краснодар шәһәренең драмтеатрында зур әдәби кичә белән ачылды. Икенче көнне язучылар Краснодар крайкомында әңгәмә үткәрделәр, шәһәр белән таныштылар, предприятиеләрдә, клубларда чыгыш ясадылар. Аннары, үнике бригадага бүленеп, районнарга чыгып киттеләр. Колхозлар, совхозлар, югары уңыш үстерү осталарының эше белән танышып, әдәби кичәләр үткәрделәр. 18 майда язучылар Новороссийск шәһәренә барып, Бөек Ватан сугышында дан алган атаклы шәһәрне, аның тарихи урыннарын карадылар. Билгесез матрос һәйкәле янында шигъри митинг үткәрделәр.

Илебезнең икмәк амбары саналган, яңа бодай сортлары җитештергән, бөтен дөньяга атаклы галимнәре булган Кубань яклары язучыларда зур тойгы калдырды.

Әдәбият көннәре «Авыл хезмәтчәне һәм матур әдәбият» дигән теоретик конференция белән тәмамланды.

Кубаньдагы совет әдәбияты көннәрендә татар язучыларыннан Гариф Ахунов, Башкортстаннан шагыйрь Рафаэль Сафин катнашты.

Гариф Ахунов «Кубань» авыл хуҗалыгы институтының биология кафедрасы мөдире профессор Иван Сергеевич Косенко турында документаль повесть язарга материал туплап кайтты.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Ижевск шәһәрендәге тимер юлчылар культура йортында өлкән язучыбыз Нәкый Исәнбәт һәм ТАССРның халык артисты Илһам Шакиров китап сөючеләр һәм тамашачылар белән очраштылар. Н. Исәнбәт очрашу кичәсенә җыелган халыкка бүгенге татар драматургиясе һәм үзенең иҗаты турында сөйләде, ә Илһам Шакиров Ижевскида үткәргән гастроле вакытында туган тәэсирләре белән уртаклашты. Соңыннан

Илһам Шакиров, «Идел» инструменталь ансамбле белән бергәләп, татар халык көйләреннән төзелгән концерт бирде.

* * *

Башкортстан язучылар союзы чакыруы буенча Мәхмүт Хәсәен Нефтекамск шәһәренең предприятиеләрендә һәм уку йортларында булып кайтты. Ул анда китап укучылар белән очрашты, аларны үзенең иҗат планнары белән таныштырды.

* * *

Казанның Дербышка поселогы культура сараенда әдәби кичә үткәрелде. Шагыйрьләрдән Галимҗан Латыйп, Тәүфикъ Камалиев, Роберт Миннуллин һәм прозаик Вакыйф Нуруллин ул кичәдә үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. «Казан утлары»ның бүлек мөдире В. Нуруллин кичәгә килгән әдәбият сөючеләрне журналның алдагы елга планнары белән дә таныштырды.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә ике республика галимнәренең әдәбият-фольклор бәйләнешенә багышланган фәнни конференциясе булды. Анда Татарстан галимнәреннән профессор Хатип Госман «Борынгы тарихи шигырьдә һәм халык поэзиясендә шигырь төзелеше», Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының директор урынбасары Илбарис Надиров «Халыктан — шагыйрьгә, шагыйрьдән — халыкка», шул ук институтның фәнни хезмәткәре Нурмөхәммәт Хисамов «Кыйссаи Йосыф» поэмасында мәкальләрнең идея-эстетик вазифасы», Алабуга педагогия институты доцентлары Фатих Урманчеев «Нурихан Фәттахның тарихи романында фольклор чыганаклары», Тәлгать Галиуллин «Утызынчы еллар поэзиясе һәм фольклор» дигән темалар буенча докладлар ясадылар.

Конференциядә башкорт һәм татар халыкларының әдәбият һәм фольклор бәйләнешләре хакында кызыклы тәкъдимнәр әйтелде, бай мәгълүмат китерелде. Башкорт галимнәреннән Кирәй Мәргән, Салават Галин һәм башка иптәшләр дә әдәбият һәм фольклор фәненең мөһим бу өлкәсенә кагылышлы мәсьәләләр буенча чыгышлар ясадылар.

## ГЫЙЛЬМИ ДӘРӘҖӘЛӘР

Республикабыз галимнәре быел вәруча зур уңышка ирештеләр. Бары тик бер ай эчендә (июньдә) генә дә биш галимебез, диссертацияләрен уңышлы яклап, фәнни дәрәҗә алуга лаек булдылар. Филология фәннәре кандидаты М. Х. Хәсәнов «Октябрьдан соңгы чорда Г. Ибраһимов иҗатының эволюциясе» дигән тема буенча докторлык диссертациясе, тәнкыйтьче Р. А. Мостафин «Соңгы еллардагы эзләнүләр һәм яңа материаллар яктылыгында Муса Җәлилнең Моабит чорындагы тормышы һәм иҗаты», Г. С. Мөхәммәдова «Габдрахман Әпсәләмов әсәрләренең художество үзенчәлеге», К. З. Хантемирова «Әдәби тәрҗемәдә оригиналның милли үзенчәлеген тудыру», А. Х. Айнетдинов «Татар фронт матбугаты (1942—1945 еллар)» дигән темалар буенча кандидатлык диссертацияләре якладылар.




## МӘСКӘҮДӘ БАСЫЛЫП ЧЫКТЫЛАР

Әле шушы көннәрдә генә Мәскәүдәге «Детская литература» нәшрияты Татарстан әдибе Рафаэль Мостафинның «По следам поэта героя» («Герой шагыйрь эзләреннән») исемле китабын 50 мең данә тираж белән рус телендә бастырып чыгарды.

* * *

Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» исемле повесте журналыбыз укучыларына яхшы таныш. Ул әсәр безнең журналда басылып чыккан иде. Бу елның июнь аенда әдипнең шул әсәрен Мәскәүдәге «Советский писатель» нәшрияты 30 мең данә тираж белән шулай ук рус телендә бастырып чыгарды.

## ТАГЫН БЕР МУЗЕЙ

Илебезнең төрле шәһәрләрендәге һәм районнарындагы мәктәпләрдә герой шагыйребез Муса Җәлил музейлары көннән-көн арта бара. Әле күптән түгел генә Пермь шәһәренең 70 нче мәктәбендә тагын бер Муса Җәлил музее ачылды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Азнакайда яшәүче прозаик Мәхмүт Хәсәновның Кама автозаводын төзүчеләргә багышланган «Кама таңнары» исемле яңа романы тикшерелде. Шунда катнашкан язучылардан Г. Бәширов, Р. Төхфәтуллин, Р. Фәйзуллин, Г. Афзал, Ю. Әминов ул романның уңай һәм кимчелекле яклары хакында сүз алып бардылар һәм авторга әсәрен яхшырту өчен конкрет фикерләр әйттеләр.

## ЯЗУЧЫЛАР САЙЛАУЛАР

Шушы елның 13 июнендә уткәрелгән РСФСР, ТАССР Верховный Советларына һәм хезмәт ияләре депутатларының җирле советларына сайлауларга әзерлек чорында Татарстан язучылары коллективы актив катнашты. К. Тимбикова, М. Маликова, Д. Зөбәерова Ә. Әдиатуллина һәм Ә. Сафина агитаторлар булып эшләделәр. Казан шәһәренең Бауман районының бер округы (№ 79) комиссиясе тулысынча Язучылар союзы коллективы вәкилләреннән төзелгән иде. Самат Шакир, Газиз Мөхәммәтшин, Хәсән Сарьян, Флера Габбасова һәм Сагыйдә Гайфетдинова составындагы ул комиссия үзенә йөкләтелгән эшне уңышлы башкарды.

* * *

Казан шәһәренең Киров районы хезмәт ияләре ТАССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Нуретдинов Зәки Шәрәфетдин улын (Зәки Нурины) күрсәткәннәр иде. Зәки Нури ТАССР Верховный Советына депутат итеп сайланды.

## РСФСРда БЕРЕНЧЕ

РСФСР китапханәләре арасында барган социалистик ярышта республикабыз китапханәләре быел да беренче урынны яулап алды. Шул уңай белән Казандагы актерлар йортында Татарстан китапханәчеләренең слеты уткәрелде. Слетка килгән китапханәчеләрне КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советы исеменнән республика Министрлар Советы председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов котлады. Аннары ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиевның «КПССның XXIV съезды һәм республика китапханә хезмәткәрләренең бурычлары» дигән темага доклады тыңланды. Слетта катнашучылар алдында Язучылар союзы идарәсе председателе Зәки Нури да чыгыш ясады һәм китапханәчеләргә эшләрендә тагын да зуррак уңышлар теләде, татар әдипләренең китапларын укучылар арасында киңрәк пропагандаларга чакырды.

Слетка килгән алдынгы китапханәчеләрнең байтагына Татарстан Культура министрлыгының Почет грамоталары тапшырылды.

## ЧАЛЛЫ МУЗЫКАЛЬ КУЛЬТУРА УНИВЕРСИТЕТЫНДА

Чаллыдагы музыкаль культура университеты занятиеләре шактый кызыклы һәм файдалы итеп уткәрелә. Анда республикабызның күренекле композиторлары һәм артистлары катнаша. «Муса Җәлил һәм музыка» дигән тема буенча уткәрелгән занятиедә, мәсәлән, РСФСРның халык артисткасы З. Хисмәтуллина, ТАССРның халык артисты И. Ишбүләков, ТАССРның атказанган артистлары Э. Җәләлетдинов һәм Ә. Яһүдин иптәшләр катнашты.

Университет занятиеләрендә композиторларыбыздан РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты А. Ключарев, ТАССРның халык артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты З. Хәбибуллин га катнаштылар. Алар язган көйләрне университетта укучыларга ТАССРның халык артисты С. Йосыпов, артисткалардан Г. Теркулова, Л. Хангильдина, Б. Тимербаева һәм башкалар җырлап та күрсәттеләр.

Университетның «Халык шагыйре Тукай һәм музыка» дигән тема буенча уткәрелгән занятиесе дә тыңлаучылар күңеленә бик хуш килде. Тукай әкиятләренә нигезләнеп язылган музыкаль әсәрләрне һәм Тукай шигырьләрен Культура университетында укучылар аеруча яратып тыңладылар.

## ГАСТРОЛЬ ӘЙБӘТ ҮТТЕ

Әлмәт драма театры Чаллы якларында гастрольдә булып, Кама автомобиль заводын төзүче эшчеләргә Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү», Г. Хугаевның «Хатынымның ире», Г. Мөсриповның «Козы-көрпеш һәм Баян-сылу», Х. Хәмзәнең «Бай һәм хезмәтче» спектакльләрен күрсәтте. Әлмәтлеләрнең спектакльләрен тамашачылар бик кызыксынып карадылар. Гастрольдә зур уңышка ирешкәннәре өчен, Партиянең Чаллы шәһәр комитеты театр коллективын һәм аерым артистларны Мактау грамоталары белән бүләкләде.

## «ЯШЬЛӘР АЛДАТМЫЙЛАР» — ТАШКЕНТ СӘХНӘСЕНДӘ

Ташкент шәһәренең Ахунбабаев исемендәге культура йортында татар драма коллективы тарафыннан әзерләнгән яңа спектакльне кабул итү тантанасы уткәрелде. Мирхәйдәр Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар» исемле әсәре буенча әзерләнгән ул спектакльне Үзбәкстан халык иҗаты йорты һәм театр җәмгыяте вәкилләреннән торган комиссия югары бәя биреп кабул итте.

Спектакльне үзешчән драма коллективы члены Гөлзадә Әбүбәкирова сәхнәгә куйды, сәнгать җитәкчесе — Вилли Әхмәдиев.

## КОНКУРС НӘТИҖӘЛӘРЕ

Июнь аенда үзешчән театр коллективлары һәм халык театрларының традицион язгы конкурсына йомгак ясалды. Ул конкурста егермедән артык театр коллективы катнашкан иде. Конкурс нәтиҗәсендә халык театрлары арасында Урицкий исемендәге культура йорты һәм мәгариф работниклары йорты, үзешчән коллективлар арасында Киров исемендәге культура йорты һәм Түбән Каманың «Нефтехимик» культура йорты үзешчәннәре җиңүче булып чыкты. Аларга беренче дәрәҗәле дипломнар һәм акчалата бүләкләр бирелде.

Шул ук вакытта үзешчән тынлы оркестрлар арасында да конкурс барган иде. Аларның да нәтиҗәләре ачыкланды. Бу конкурста профсоюзларның Бауман районы культура йорты коллективы беренче урынны яулап алды. «Теплоконтроль» заводы клубы үзешчәннәре икенче, Ленин исемендәге культура сарае коллективы өченче урынга чыкты.

Хөрмәтле укучыбыз!

Журналыбызның Яңа ел саны Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы белән ачыла. Күренекле язучыбыз Мирсәй Әмирнең «Балыкчы ялганнары» дигән повестен да Сез шушы саннан укырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210